# КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ринат МӨХӘММӘДИЕВ. Ак кәгазь нидән саргая... *Роман*. ....3

Рифә РАХМАН. Милләтем барында яшим мин... *Шигырьләр*. ....60

Роза ТУФИТУЛЛОВА. Язмыш җиле. *Роман*. ....65

Равил РАХМАНИ. Милләтебез яшәеше һәм фәлсәфи аңында «Хак» феномены. Кеше хаклары. *Фәнни-поэтик трактат*. ....104

Дамир ГАРИФУЛЛИН. Үткән белән сөйләштерә чын тарих... *Робагыйлар*. ....127

Идият АШИРОВ. Уйлар гел туган якта... *Шигырьләр*. ....146

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Раушан ШӘРИФ. Мин сине мәңге сөярмен. *Моңсу комедия*. ....130

ЯҢА ИСЕМНӘР

Розалина ТИМЕРБУЛАТОВА. Сагыну. *Хикәя*. ....150

*Җәһәт тәнкыйть:* сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. ....152

«ШИФАЛЫ КУЛЛАР» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Гөлнур АЙЗАТ. Саф чишмә. *Хикәя*. ....154

«ТАТАРСТАН. ТАРИХ. ШӘХЕСЛӘР» ӘДӘБИ ОЧЕРКЛАР КОНКУРСЫ

Индүс ТАҺИРОВ. Онытылмас еллар хатирәсе. *Очерк*. ....161

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ. «Халкым җырын саклый алсам иде...» *Очерк*. ....164

ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рифә РАХМАН. Хатирәләрне яңартучы шигърият. ....172

ЮБИЛЕЙЛАР

Олег ХИСАМОВ, Бәхтияр МИҢНУЛЛИН, Рифат МИРХӘЕВ. Таш кыяларга язылган тормыш җыры *(Фәрит Йосыповка 80 яшь)*. ....175

ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

*Фотоархив:* Фаил Шәфигуллин тормышыннан мизгелләр. ....178

*Бер җыр тарихы:* «Солдатым» (М.НОГМАН сүзләре, С.САДЫЙКОВА көе). ....180

*Музейларыбыз:* Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН. Фатих Кәримнең музей-йорты. .... 181

*Шаян сәхифә:* Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ алып бара*. ....182

*Бәләкәйләр:* Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Бәләкәй Хатыйп. ....184

«Казан утлары» архивыннан. ....170

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН УТЛАРЫ
*(«Огни Казани»)*
*№ 5 (1159) 2019*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Ринат Закиров**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Данил Салихов**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Рамил Ханнанов.**

*Җаваплы сәркатип:* **Вакыйф Нуриев.**

*Бүлек мөхәррирләре:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**

*Мөхәррирләр:* **Лилия Вагыйзова, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева.**

*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (өлкән бухгалтер).

*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1617).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
💻: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.


---

ТМ Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.04.2019, график буенча 29.04.2019, басылып чыгу вакыты 13.05.2019.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^1/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-1150. Тираж 4752.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2019 ел



Ринат
Мөхәммәдиев

# АК КӘГАЗЬ НИДӘН САРГАЯ...

РОМАН

## БЕРЕНЧЕ ТАРИХ

### 1

Мәскәү астындагы исәпсез-хисапсыз бистәләрнең берсендә, ниһаять, үземә тыныч һәм җылы бер почмак таптым. Язу өстәле янында каләм белән кое казып утырудан тәмам туйгачтын, табигать кочагына чыгасың, әйләнә-тирә урам һәм тыкрыклардан, урман сукмакларыннан саф һава сулап бер урап кайтуга ни җитә! Бу урманнарда әүвәл гөмбә, җиләк, сихәтле үләннәр җыйганнар, куян, төлке һәм бүре ише төрле кыргый җәнлек-җанвар арлы-бирле чабулап йөргән дип сөйлиләр. Бүген исә кая карама, анда төзелеш бара, әле кичә генә чыршы-нарат үсеп утырган куелыкларда сарай арты яңа сарай калкып чыга. Йортлар күккә ашкан, таш коймалар биек, урамнар тар. Каршыңа ник бер кеше очрасын икән дә, хәл белешеп, ник бер адәми зат сәлам бирсен икән. Ә машиналар... берсеннән-берсе затлырак машиналар, тыз да быз узып кына тора. Аларда кем утырганны күрәм димә, тәрәзәләре чем-кара булыр.

Аның каравы, сине белүче һәм танучы юк монда, анда-санда очраганнар да бер-беренә сәлам-фәлән биреп тормый. Һәркем үз дөньясына кереп бикләнгән. Әллә адәми зат, әллә аларның өрәкләре генәме – һич белгән юк. Син дә рәхәтләнеп үз уйларыңа бирелеп йөрисең, үз-үзең белән бәхәсләшәсең һәм туйганчы фикер алышасың.

Көндәгечә, тар тыкрыклар буйлап берьялгызым ипле генә узып барам. Чү, колагыма ишетелдеме, кемдер дәште кебек...

– Улым, – дигән тавыш ишетелгән тарафка борылып карадым. Рус телендә әйтелде шикелле. Әмма, кайсы гына телдә әйтелсә дә, җанга рәхәтлек бирә торган җылы сүз. Җиденче дистәгә якынлашып килгән көннәреңдә «улым» дип дәшсеннәр әле үзеңә!

Юлдан беркадәр эчкә кертеп салынган бу өйне, каршысыннан күпме үтеп-сүтеп йөрсәм дә, шул көнгәчә искәрмәгәнмен. Ул башка йортлардан үзенең җыйнаклыгы

---

Ринат МӨХӘММӘДИЕВ (1948) – *язучы һәм җәмәгать эшлеклесе; «Кенәри – читлек кошы», «Сират күпере», «Утлы таба өстендә» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, Төркиянең әдәбият һәм мәдәният өлкәсендәге Халыкара әдәби премиясе лауреаты. Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Мәскәүдә яши.*

һәм агачтан салынганлыгы белән аерылып тора. Түбәсе беркадәр кыйшая төшкән һәм каралты-курасы да шактый ук таушалган кебек. Таш пулатлар арасында адашып калган шул кечкенә өйнең капка төбендә орчык кадәрле генә, чандыр гәүдәле бер карт утыра. Абайламый да узып баруым икән – дәшүче шул булган.

Туктала төшеп, кулымны югары күтәрдем, үземә күрә сәлам бирүем инде. Ә ул мине җавап бирде дип уйлады булса кирәк:

– Ишетмәдем бит, улым, – дип, кулын колагына куйды.

– Сәлам бирүем иде, – дидем. Һәм шундук хатамны төзәтергә ашыктым. – Исәнмесез, бабай, хәлләрегез ничек?

– Колагым каты шул, якынрак килә алмассыңмы, улым.

Якынлашмый чарам калмаган иде.

– Көн дә шушы вакытта үтеп-сүтеп йөрисең, башың түбән салынган була, бер-бер борчу яисә кайгың бармы әллә, улым?

– Юк, агай, барысы да яхшы. Ходайга шөкер, зарланырга сәбәп юк. Шулай йөрергә гадәтләнелгән булса кирәк...

– Алай гына икән, ярый, – дип, тамак кырып куйды ул. – Мондагы кеше түгелсең ахры, соңгы арада гына күзгә чалына башладың...

– Сез хаклы, бу якларга соңгы арада гына килеп чыктым.

Сүзләремне ишетте кебек, әмма җавап бирергә яисә бер-бер сүз кыстырып куярга ашыкмады. Күзләрен чекерәйтеп һаман сынап карап торуында булды. Бу кем икән дип, уйга биреләдеме, әллә кемгә дә булса бер-бер таныш-белешенә охшаттымы үземне? Сизәм, күреп торам ич, тикшерепме тикшерә: аяк очымнан баш түбәмә тикле барлап чыкты.

Андый чакта кемнең күңеле кырылмас икән...

– Ярый, агай, мин юлымда булыйм. Сезгә исәнлек-саулык... – дип, кузгалырга, юлымны дәвам иттерергә җыенган идем инде, капылт кына сүземне ярты юлда бүлдереп куймасынмы.

– Александр Иванович, – дип, урыныннан чак кына кузгала төшеп, миңа таба кулын сузды. Торуын тормады, әлбәттә, аның өчен урыннан тору җиңел түгелдер, сизәм. Әмма, үзенчә ихтирам күрсәтүе иде булса кирәк.

– Ринат, – дидем. Мин дә кулым бирдем. Уң кулыма өй кыегыннан салынып төшкән бер уч салкын боз кисәкләрен учлап тоткандай булдым.

Минем исем көтелмәгән иде булса кирәк, ул аны ничектер сәер кабул итте. Беркавым ни әйтергә белми торды кебек хәтта.

– Ринат... Ринат... – дип кабатлады артымнан.

– Нәрсә, Александр Иванович, бу исемне беренче кат ишетүегезме әллә? – дип сорарга мәҗбүр идем. – Безнең татарларда бик таралган исем бу.

– Сезнең татарларда... – диде ул, суза төшеп. – Татарда нинди генә исем юк.

Тагыниләрдер әйтергә иде кебек исәбе, әмма ни сәбәпледер, үзен тыеп, ярты юлда туктап калды.

Аның соңгы сүзләре һәм әйтергә җыенып та әйтми калган сүзләре күңелемә ширпы булып кадалды. Үз халкыма, кемнән-кемнән, әмма шушы бетәшеп барган карттан да тискәре мөнәсәбәт сиздереп, бу хәлгә түзеп торасым килми иде бер дә. Тавыш чыгарырга да уңайсыз. Кулым селтәп китәргә дип борылган идем инде. Шунда, ябыштырып куелган кебек утырган җиреннән, таягына таянып, уф-аһ килеп торып ук басмасынмы...

– Ашыкма әле син. Вакытың булса, бераз сабыр итә күр, – диде ул, гозерләп.

Ул түгел, колагым ишеткәннәрдән мин егылып китә яздым. Александр Иванович дигәнебез миңа татарча эндәште түгелме соң?.. Үз колагыма үзем ышанмыйча югалып калдым. Авызым ачкачтын да әйтер сүз таба алмый тордым байтак кына.

– Ничек? Сез татарча беләсезме?.. Кайда, кайчан өйрәндегез?

Лып итеп кире урынына утырды ул, күрәм, аягөсте басып тору авыр иде аңа. Һәм эскәмиянең бер читенәрәк елышты, үзе белән янәшәдән урын тәкъдим итәргә җыенуы булган икән.

– Шулай басып тору килешми, утыр булмаса, күп вакытыңны алмам, – диде карт.

Уемда булмаса да күрсәтелгән урынга утырырга мәҗбүр булдым. Үпкә-сапка онытылды, кызыксыну биләп алды үземне.

– Татарчагыз шундый чиста, кайчан шулай сөйләшергә өйрәндегез, Александр Иванович? – дидем. Бу сорауның авызымнан рус телендә чыгып очканлыгын соңара төшеп кенә абайладым. Әңгәмәдәшемә җиңелрәк аңлашылсын диюем булгандыр. Ни генә әйтмә, «Александр Иванович» белән сөйләшәм ич...

– Өйрәнмәдем, – дип, сүзен кыска тотты. Әллә сорауны ошатмады, кинәт кырыслана төшкәндәй тоелды ул миңа, урынлы-урынсыз дип әйтимме, берничә мәртәбә тамагын кырып куйды.

Миннән болай гына котыла алмассың инде абзый, дип уйлап куйдым. Үзең чакырып китердең, янәшәңнән урын тәкъдим иттең, сорауларыма җавап тапмый торып китү юк инде ул хәзер. Кызык ич...

– Сез бит әле генә минем белән саф татарча сөйләшә башлаган идегез... «Өйрәнмәдем», дисез...

– Чит телне өйрәнәләр, ә туган телне өйрәнмиләр, беләләр... – диде ул, мине шул сүзләре белән чираттагы мәртәбә хәйран калдырып.

– Ә исемегез – Александр Иванович, – дип, төпченүемне дәвам иттем мин.

– Әйе, ышанмасагыз паспортымны күрсәтә алам, – дип, кесәләрен үк капшарга керешкән иде инде, таба алмагач көлемсерәп куйды. – Өйдә калган. Күпме яшәп, капка төбендә паспортның кирәге чыкканы юк иде шул әлегәчә.

– Юк-юк, кирәкми. Керәшен татарларыннан да дус-ишләрем аз түгел минем. Ышанам.

– Каян таптың аны, мин бит сиңа үземне керәшен димәдем кебек.

– Юк, алай димәдегез, әмма... – дип, сүземне бүлдем, урынсыз төпченүдән туктарга вакыт җиткәнлеген аңладым шунда.

Әмма тел очымда байтак кына сораулар эленеп калган иде әле. Сүзсез дә аңладымы, ул сорауларга үзе үк җавап кайтарырга кирәк тапты агай. Шактый өлкән яшьтә булуына да карамастан, фикерләре аек, сүз сөреше ачык иде аның.

– Рус яисә чуваш та түгел. Мөселман да түгел... – диде, һәм берара дәшми торганнан соң ачыклык кертте. – Чын татар, әтием дә, әнием дә Казан кешеләре иде.

– Ә сез? – дигән сорау чыгып ычкынды авыздан. Тел йөгәнсез ич.

– Кешеләр белән рус телендә сөйләшәм. Руслар арасында үстем һәм яшәдем, дуслар таптым, аралаштым. Ә хәзер менә берьялгызым көн күрәм. Мәчет-фәлән күргән кеше түгел. Әти-әниемне бик аз хәтерлим. Озын гомерле булмадылар. Эштән киткәнемә дә унбиш ел чамасы узды кебек. Кем белән сөйләшим, айга ике тапкыр кибеткә барып киләм, ә бер мәртәбә почтальон пенсия китерә. Рус хатыннары икесе дә – кайгыртучан һәм тәрбияле кызлар.

– Ә татарча кем белән сөйләшәсез?

– Үзем белән үзем сөйләшәм. Бала чакта әти-әни белән сөйләшкәнмен. Менә хәзер сезнең белән...

– Кызык, – дидем, баш чайкап. – Үзең белән үзең сөйләшеп буламы?..

– Башыңа төшсә – башмакчы булырсың, ди торган иде минем әни, – диде ул, мине чираттагы мәртәбә хәйран калдырып. Тел белү, аны онытмау бер хәл, күр инде син аны, ничек урынлы итеп халык әйтемнәре һәм мәкальләреннән файдалана.

Гадәттә, сөйләшкән саен сорау кими бара торган була, ә монда, очраклы рәвештә юлымда очраган бу карт белән хәл белешкәндә, нәкъ киресенчә килеп

чыга түгелме? Ул җавап бирә... Ә аның һәр җавабы бер түгел, әллә ничә яңа сорау уята. Хуш, кайсы милләттән булуын ачыкладым да ди, ә «мөселман түгелмен» дигәнен ничек аңларга киңәш итәрсез... Үземнең дә «мин мөселман» дип, күкрәк кагып кычкырып йөргәнем юк анысы. Ә күңелдә бар ич, ата-бабалардан килгән изге ышану, әхлак, иман, яшәү рәвешенең нигез тамырлары шунда барып тоташа түгелме?!. Мөмкин, кешенең башка диндә булуы да ихтимал. Дөнья булгач, төрле хәлләр була. Гаепкә алырга җыенмыйм берәүне дә, ата-баба динен алыштырган кешеләрне дә очратырга туры килгәне бар. Исеме русча яисә бөтенләй чит-ят халыклардан алынган исем белән яшәүчеләрнең очравы да яңалык түгел. Кем генә юк бу дөньяда... Шулай да, ә нигә әле сорау бирмәс борын, «мөселман түгелмен» дип кистереп җавап кайтарырга кирәк булды икән?.. Мин бит аның дингә мөнәсәбәте белән кызыксынмадым кебек.

– Александр Иванович, сез нәрсә, чиркәүгә йөрисезме әллә? – дип сорарга мәҗбүр булдым. Гаеп итү түгел иде уемда, бу сорауны мөмкин кадәр кече күңелле булырга омтылып бирергә тырыштым.

– Каян алдың, – дип, шелтәле, кырыс караш ташлап алды. – Син үзең шуннан кайтып килми торгансыңдыр бит...

Карале, ничек сөйләшә! Җавап эзләп кесәгә керә торганнардан түгел бу абзый... Килде-китте кеше булырга охшамаган күренә...

– «Мөселман түгелмен», дидегез, шуңарга соравым.

– Дин белән, аеруча мулла-мунтагайлар белән алыш-бирешем юк, – диде ул кистереп. Бер уңайдан, бу хакта өстәмә сораулар биреп тинтерәтмә, энем, ярыймы, дип әйтүе дә булды сыман.

– Аңлашылды, – дидем. Аңардан бигрәк үз-үземә әйттем кебек.

Ул тагы елмайгандай итте һәм үзалдына уйлана төшеп, бер-ике мәртәбә мәгънәле генә итеп, тамак төбен кырып алды.

– Аңлавын аңламадың инде. Бәхәс кузгатып та торасың килми, шулай бит... Мин үзем дә сүз куертырга теләмәгәндә шулай итәм.

– Сизәм, – дидем, шулай да. – Бер-бер дин әһеле белән арагызда низаг-фәлән чыккан булса кирәк. Шуңарга кул селтәгәнсез.

Башын чайкап алды карт.

– Ә сез гоманларга оста икәнсез... Дөрес сукалыйсыз, – диде ул, йомшара төшеп. – Һәрнәрсәнең үзенә күрә бер сәбәбе яисә очы була.

– Шулай, – дип, җөпләргә ашыктым. Бу серле картны сөйләштерәсе, аның серләрен бераз гына булса да сүтәсе килү теләге көчле иде бит. Максатым шул. – Димәк, сезне бер-бер дин әһеле рәнҗеткәнгә охшаган?

– Алар белән эш иткәнем булмады, күргән-белгән кешеләрем түгел.

– Ә ни өчен шулай катгый рәвештә баш тартасыз үзләреннән? Хәзер бит, ышанамы-юкмы, һәркем динле булып китте. Президент кадәр президентлар чиркәүгә йөри... Аннан бит әле дин әһелләре белән алыш-биреш итми генә дә Аллаһның кодрәтенә ышанырга, иманлы булырга мөмкин.

– Иман – башка нәрсә. Сез мине имансызга чыгармый торгансыздыр бит?

– Аллам сакласын, алай димәдем. Сезгә, үземнән өлкән кешегә, хөкем чыгарырга минем, гомумән, хакым юк. Сәбәп тә күрмим әлегә. Әмма...

Әйтергә теләгән сүземне ничегрәк итеп әйтергә икән, дип уйлана төшеп торган арада, үзе елгыр гына эләктереп алмасынмы. Кибеп бетәшкән карт диген син аны менә...

– Аңлашылмый торган кеше, дип әйтергә телисеңдер... Бер дә очратканың булмагандыр шул минем кебекләрне...

– Сезнең белән иркенләп, ачыктан-ачык, чишелеп бер сөйләшергә иде дә бит, Александр Иванович.

– Сөйләшәбез ич менә...

– Юк, бу сөйләшү түгел, Александр Иванович. Табышмак яисә мәсьәлә чишеп утыргандай хис итәм мин үземне. Инде менә ни гомер сөйләшәбез, бер сорауга да төпле-башлы җавап алганым юк.

– Менә ничек икән, – дип, тавышын көчәйтә төште ул. – Нашатырь да сиптем – йон да чыкты, булмый торгандыр ул. Мин бит әле синең хакта да, исемеңнән башка берни белмим, ишетмәдем кебек. Ә син инде барлык сорауларыңа да җавап табарга җыенасың. Шул ниятең тормышка ашмаганнан эчең дә поша башлады түгелме? Кызык килеп чыга бу...

– Соң чиктә без бит әле икебез дә татарлар.

– Ташла аны, татарның да ниндие генә юк. Татар барда – хәтәр бар, дип тә юкка гына әйтмәгәннәрдер.

Килешергә телимме-юкмы, ризалашырга мәҗбүр идем. Бу абзыйның серләренә ачкычны алай җиңел генә табып булырга охшамаган күренә...

– Ярар, – дидем, китәргә вакыт икәнлекне белгертергә теләп, – тагы бер күрешербез әле. Каршы килмәсәгез, сөйләшеп тә утырырбыз. Инде кайда яшәгәнегезне дә беләм.

– Ә мин белмим, – диде ул. – Белсәм дә, файдасыз, өйдән ерак китә алмыйм. Аяклар бик авыр хәрәкәтләнә. Туксанны тутырабыз инде, боерган булса...

«Боерган булса...»сын колагыма элдем. Имансыз-фәлән кеше түгел бу, андыйга охшамаган, серле һәм бик катлаулы язмышка дучар ителгән кеше булуы да ихтимал, дип нәтиҗә ясадым үзалдыма. Һәм, һичшиксез, тагы күрешүгә ышанып, хушлашып, үз юлым белән китеп барырга туры килде.

– Көн дә шушы вакытларда һава суларга капка төбенә чыгып утырам мин, – дип, озатып калды ул.

## 2

Шәһәрдә яшәүчеләр мине аңлар, монда көннең ничек узганын сизми дә каласың. Хәер, көн генәме, кайчак атна һәм айлар да күз ачып йомганчы артта кала. Шул арада кылган эшең яисә гамәлең булса бер хәл, еш кына тик тә утырмадым, ничек узды соң әле бу көннәр, дип баш ваткан чакларың да була.

Күрешүне айларга сузмадым сузуын, әмма ике атна чамасы заман үтеп киткән иде инде. Шәһәр читендәге бистәгә килеп чыккачтын да, вакытын туры китереп, мин таныш урам һәм тыкрыклар буйлап йөреп кайтырга уйладым. Ялгышмаганмын, серле танышым, ягъни Александр Иванович үз урынында утыра иде. Теге вакыттагы сыман капка төбендәге такта эскәмиядә. Ул мине абайламады әлегә. Утырып торуына да карамастан ике кулы белән таягына таянган, ә күзләре аска, аяк очына текәлгән, тирән уйга чумган иде булса кирәк. Шул рәвешле куырылып утыргангамы, ул тагы да кечерәеп калгандай тоелды бу юлы.

Тукталдым. Әмма, рөхсәт сорамыйча, янына барырга кыймадым. Мине күрәсе, сөйләшәсе киләме-юкмы, белеп булмый ич. Беренче очрашуда шактый ук кырыс һәм туры сүзле кеше булып хәтергә уелып калган иде. Ә хәзер, менә шулай читтән карап торганда, ничектер, кызганыч. Мин тукталган сукмактан аның капкасына аз дигәндә җиде-сигез адым ара булгандыр.

– Александр Иванович, хәлләрегез ничек? – дип дәштем үзенә. Ишетмәде кебек. Башын күтәрергә ашыкмады.

Өч-дүрт адым якынлаша төшеп яңадан кабатладым шул ук сүзләрне. Ишетте. Сак кына башын күтәрде. Ләкин танымады, ләм-мим сүз катмады. Болайга киткәч, янәшәсенә үк барып басырга туры килде. Татарчага күчтем.

– Әллә танымадыгыз инде димме... Хәлләрегез ничек, Александр Иванович?

– Ә-ә, син икәнсең, татар-малай, – диде ул, ниһаять, җанлана төшеп. – Мин

инде сине югалткан идем, килмәде, дип нәтиҗә ясаган идем... Килеп чыгуың яхшы булган, көне дә бик матур, утыр, бераз урман һавасы сулап ял итеп кит, – дип, бер читкәрәк тайпылып янәшәсеннән урын тәкъдим итте.

Таныш-белешләр буларак, хәл-әхвәл белештек. Күзгә күннәрнең матурлыгы, шәһәрдән бик ерак җир булмаса да бу якларда һаваның чисталыгына мөнәсәбәтебезне белдердек. Бу уңайдан фикерләребез уртак икән. Әмма байтак кына барыбер җанлы әңгәмә кора алмый азапландык.

– Үзегез генә яшисез ахры, Александр Иванович, – дип әйтеп куйганмын, тора-бара сүзне каян башларга белми утырган бер мизгелдә. Сүз булмаганда – сүз булсын, исәнме, кодагый, дигән сыман килеп чыкты инде ул.

Җавап бирергә кирәк тапмадымы агай, тамак кырып кына алды, дәшмәде. Бу исә минем каршыда аның дәрәҗәсен шактый күтәрә төште. Карт булса да, беркатлы кеше түгел, кистереп үз фикерен әйтергә, турыдан ярып сөйләшергә күнеккән.

– Яшегез дә бара, ялгызың бик кыенга туры килә торгандыр, дип әйтүем, – дип, бераз ипли-сипли төштем соравымны.

– Ялгызлык – минем бердәнбер куанычым, – дип әйтеп ташламасынмы.

Аның бу фикере белән кем килешер иде икән, мин дә дәшми кала алмадым.

– Ялгызлык куаныч булмый торгандыр. Бәгрәк тә сезнең яшьтәге кеше авызыннан, нәрсә-нәрсә, андый фикер ишетермен дип башыма китермәс идем. Бу сезнең үз-үзегезне тынычландырырга яисә акларга тырышу гына түгелме?..

– Исемеңне кем, дидек әле?

Берочтан миңа кырыс караш ташлап алырга да өлгерде.

– Ринат, дидек...

– Менә нәрсә, Ринат энем... – дип, шундук аңлатырга да кереште ул. – Бу дөньяда абсолют дөреслек юк. Һәркем үз тәҗрибәсеннән, үз язмышыннан чыгып фикер йөртә. Мин үз фикеремне берәүгә дә, шул исәптән сиңа да тагарга җыенмыйм, әмма шулай уйларга хакым бар дип беләм. Килешәсеңме-юкмы, анысы синең эш...

– Килешәм, – дими чарам булмагандыр. Өлкән кешегә ихтирам күрсәтергә дә кирәк бит әле. Берочтан үзалдыма чираттагы мәртәбә тагы нәтиҗә ясарга да өлгердем: «Югары белемле, югары интеллектка ия кеше булырга охшаган бит бу... Сүз эзләп кеше кесәсенә керми, фикерләре эзлекле һәм катгый. Әңгәмәдәшенә яраклашу турында уйламый, әйтәсе сүзе бар икән – турыдан яра...»

Ә ул тынычлана һәм йомшара төшеп дәвам итте.

– Мин бу араларда сине бик еш кына искә алдым. Минем әти-әни телендә шулай чиста, матур итеп сөйләшүчене байтак гомерләр очратканым юк иде инде. Очрасалар да, Александр Иванович белән, йә, кем татар телендә сөйләшә башлар икән?.. Теге юлы да күп сораулар бирдең. Сизеп торам, бүген алар тагы да ишәйгән булырга охшый.

– Юк, мин һич кенә дә сорау алырга дип килмәгән идем...

– Күзләреңнән күреп торам.

– Сораулар юк түгел анысы. Сез үзегез бик серле кеше күренәсез кебек.

– Бернинди серем дә юк. Язмыш шундый, энем, язмыш шундый булып чыкты. Ә язмыштан узмыш булмаганны беләсең.

– Ишеткән бар, – дидем мин, битарафлык күрсәткән атлы булып. Һәм үзалдыма тагы бер кат аның тел байлыгына сокланып куйдым. Татарчасына...

– «Ялгызлык» турында әйткәнем ошап бетмәде инде үзеңә. Ә бит минем шулай дип әйтергә хакым бар. Күз алдыңа китерә аласыңмы, мин гомерем буе ялгыз. Малай чакларымнан бирле. Олыгайгачтын да ялгызлыкны кулай күрдем. Ялгызлыктан үзенә бер тәм табып, ялгызлык белән сөйләшеп, киңәшеп яшәргә күнекмәгән булсам, мин инде әллә кайчан җир куенында ята идем.

Үз сүзләренә мөнәсәбәтемне белергә теләпме, шул мәл башын күтәрә төшеп текәлеп миңа карап куйды ул.

– Нәрсә диим, Александр Иванович, килешеп, баш кагып утыра алмыйм. Башка сыймастай авыр нәрсә – ялгызлык турында сөйлисез ич. Мин булдыра алмас идем... Әмма сезне игътибар белән тыңларга әзермен.

– Кызыксынсаң – тыңла. Кызыксыз булса, әйтерсең, шунда ук тукталырмын, – диде ул. Ә үзе кулындагы таяк очы белән бертуктаусыз аяк тирәсендәге яшел чирәмне тырный. – Сиңа бу көнгәчә берәүгә дә сөйләмәгән серләремне чишәм.

– Мине шундый ышанычка лаек саныйсыз икән, рәхмәттән башка сүзем юк...

– Ышанганга түгел, – дип кистереп куйды шунда ук. – Ышаныч яулау өчен, ким дигәндә, бер пот тоз ашарга кирәк бергә-бергә. Ә без җүнле-башлы танышлар да түгел.

– Әйе, нибарысы икенче кат күрешүебез.

– Нигә сөйләргә булдым? Үзем дә белмим. Гыйбрәт булсын дип тә түгел. Безнең халык гыйбрәтләрдән узган, ул үз хаталарына бәя биреп, аларны анализлап, алардан гыйбрәт алып яшәргә күнекмәгән. Әйе, мин үзебезнең хакта, татарлар турында әйтәм! – дип искәртергә, басым ясап узарга кирәк тапты ул шул мизгелдә. – Бәлки, башка сөйләр кешем булмаганга сөйли торганмындыр, сүз сыйдыра торган кешегә охшагансың. Татар кешесе булганың өчен сөйлим. Күптән очраткан юк иде үзебезнең телдә сөйләшкән-аңлашкан кешене... Күреп торасың, мин бит урман кешесе – шәһәргә чыкмыйм соңгы араларда, аннан да минем янга килергә дип ашкынып торучылар күп түгелдер. Һәм һичкемне моның өчен гаепләмим, үзем сайлаган язмыш, бу ялгызлыкка мин үзем ирештем. Үз көчем һәм үз тырышлыгым белән...

«Тынгысызлана... Бик нык дулкынлана, – дигән нәтиҗә ясадым үзалдыма. – Юкса, ул монда көн дә чыгып утыра булса кирәк. Эскәмия астында ике аяк эзеннән шомарып беткән такыр җир шул хакта сөйли. Ә аның әйләнә-тирәсе ямь-яшел чирәм, монда бу көнгәчә таяк белән үлән актаручы булмаган...»

– Игътибар белән тыңлыйм, Александр Иванович.

– Хәтерлисеңдер булса кирәк, мин сиңа теге юлы дин әһелләрен өнәп бетермәвем турында әйткән идем. Өстәп тагы шуны әйтим, язучыларны, әдәбият-сәнгать тирәсендә чуалучы галим-голамәләрне дә җенем сөйми...

Башка китереп суктылармыни... Ирексездән, як-ягыма карангалап алдым. Бу минем кем булуым, ни белән шөгыльләнүемне белеп сөйләшә түгелме соң?!. Әллә үзем белән, юри генә, танымаган чит-ят кеше булып мәчеле-тычканлы уйнарга җыенамы?.. Каракның бүреге яна, дигәндәй, бит очларым кызышып куйды, колак яфракларым кызарып чыкты булса кирәк. Шунда телеңне тыеп, теге кем әйтмешли, к...не кысып кына утырырга иде дә бит. Көтелмәгән шул сүзләргә җавап буларак, авыздан чыгып очмасынмы:

– Ярый әле язучы түгелмен, юкса...

– Юкса, менә шушы таяк белән бер сыптырган булыр идем үзеңә, – дип, зәһәр очлы таягын һавада бер болгап алды ул. Юк, шаяру-көлүнең эзе дә күренми иде аның сүзләрендә һәм үз-үзен тотышы да табигый.

– Ә нигә дип яратмыйсыз соң сез аларны, язучыларны, дим... Галим-голамәләр һәм язучыларның кайчан, кемгә зыяны тиде икән, һич аңлый алмыйм... Революциянең ни тегесен, ни монысын алар ясамады, илне алар таратмады, кешене кычкыртып талаучылар да алар булмады ич...

– Сорауларыңны бирми тор, ярыймы. Кызыксынам, дидең, тыңла.

Кеше авызын шул рәвешле томалап куярга оста да соң үзе! Күренеп тора, һич тә тормыш арбасыннан төшеп калган затка охшамаган.

– Тыңлыйм...

– Минем әти биш буын мулла нәселеннән. Казанда иң дәрәҗәле һәм алдынгы мәдрәсәләрнең берсендә белем алган зыялы кеше була ул. Революциядән соң Көнчыгыш педагогия институтында укыта, доцент буларак, студентларга белем бирә. Татар әдәбиятын, аның тарихын өйрәнеп китаплар яза, гыйльми конференцияләрдә катнаша, алай гына да түгел, үзе дә шигырьләр, милли театр өчен пьесалар иҗат итә. Татар фольклорын өйрәнә, гыйльми экспедицияләрдә катнашып, бик кыйммәтле мирас туплый. Кыскасы, егерменче-утызынчы елларда, үзе укыткан студентлар арасында гына түгел, татар дөньясында киң мәгълүм булган күренекле шәхескә әверелә...

Шул урында, иркенләп сулыш алырга теләпме, әллә нәрсәнедер әйтергәме-әйтмәскәме икән, дип икеләнеп, төртелеп тордымы, ул беразга сүзсез калды.

Ә мин исә колагым ишеткәннәрдән инде әллә кайчан телсез калдым. Чак сорау арты сорау яудырырга керешмәдем үзенә. «Фамилиясе нинди булган, исеме... әллә шуның улымы син?» – дип әйтергә ачкан авызымны ничек тыеп кала алдым? Үзем дә белмим.

Картның күңеле сизгер, ул минем күңелдәге үзгәреш һәм тойгыларны сизмәде түгел, сизде. Тагын бер мәртәбә сынап карап куйды үземә.

– Нәрсә, кызык түгелме? Бу хакта ишеткәнем бар, дип әйтергә җыенасыңмы? Яңалык түгелдер, әлбәттә. Бу хакта күп яздылар ич соңгы араларда. Белгәне дә, белмәгәне дә яза, сөйли. Заманасы шундый...

– Сөйләгез, сөйлә, мин тыңлыйм...

– Аңладым, – диде ул, катгый бер нәтиҗә чыгарып. – Аның исемен-фамилиясен белергә телисең, шул турыда уйлап куйдың... Кирәкмәс, азапланма, аның хакында синең ишеткәнең юк. Күптән онытылды, халык һәм ил хәтереннән күптән җуелды инде аның исеме. Йөзәрләгән-меңәрләгән кешеләрне оныттык шул рәвешле, әйтерсең, алар бу якты дөньяга тумаган, гаилә кормаган, җәмгыятькә файдалы һичбер эш майтармаган...

– Кеше китә, җыры кала, диләр бит. Үзен оныта төшсәләр дә, хезмәтләре, кылган гамәлләре кала кешенең...

– Кайда кала, ә кайдадыр бик тиз оныталар.

– Дөрес сөйлисез, нәрсә-нәрсә, хәтер ягы безнең халыкта бик кыска шул.

– Халыкта түгел гаеп, гаеп синдә, миндә, безнең ишеләрдә.

– Нигә алай дисез? Мин үзем татар авылында туып, урта белемне татар мәктәбендә алган кеше. Әтиегез исемен дә ишеткән булуым ихтимал...

«Мин – язучы, татар әдәбияты тарихын һәм шул дәверләрнең иҗтимагый фикерен җентекләп өйрәнгән кеше» дип әйтәсем бик килсә дә, дәшми торуны артык күрдем әлегә. Ул бит мине бу уңайдан кисәтеп тә куйган иде. Арканы тимер таяк белән кашытасы килми. Шаярып сөйләшә торган кеше түгел, инде үзем дә инандым, бу серле картның безнең язучы халкына мөнәсәбәте чын-чынлап уңай түгел. Ни өчен шулай икәнлекне генә аңлый алмыйм әлегә.

– Әти-әниемнең исем-фамилиясен син белмисең, башыңны ватма, – диде ул, бу хакта сүз шуның белән тәмам дигәнне аңлатып. – Татарлар күптән онытты инде аларны. Искә төшерүче юк...

– Сез каян беләсез, бәлки ялгыша торгансыздыр. Хәзер бит тарихны, аеруча шул дәверләрне өйрәнү модага кереп бара кебек.

Көтмәгән-уйламаган сорау биреп куйды ул шунда:

– Син нәрсә, Казанда яшисеңме әллә?

– Казаннан киткәнемә инде егерме ел булды. Үземне, Нижгар егетләре әйтмешли, «мәскәүче» саныйм.

– Менә шул, – дип, кеткелдәп көлеп алды ул. «Мәскәүче» дигәнем күңеленә хуш килде, ниндидер хатирәләрне искә төшерде булса кирәк. Әмма читкә

тайпылмыйча сөйләвен дәвам итте. – Ә минем, урманда яшәсәм дә, өемдә һәрчак татар радиосы сөйләп тора. Инде хәзер телевизорларын да карыйбыз. Көн-төн татарча җырлыйлар... Җырчылары күп, ә җырлары бик аз. Рәшит Ваһаповка, Илһам Шакировка, Хәйдәр Бигичевка алмаш күренми әлегә. Шигырь-фәлән дигәннәре дә Тукай-Такташлардан бик ерак. Ә галим-голамәләре ярарга тырыша, депутатларны, хакимият тирәсендәгеләрне мактыйлар күбрәк, безнең халык һаман шулай куштан, һаман искечә сукалыйлар... Килешәсеңдер? – дип, күтәрелеп, чираттагы мәртәбә күземә текәлде карт. Шул рәвешле, кинәт, син бөтенләй көтмәгәндә-уйламаганда карап куя иде ул, сискәнмәс җиреңнән сискәнерсең.

Бу аның сынап караваы иде. Һәм ул җавап көтә... Аның фикерләре белән, нигездә, килешсәм дә, турыдан-туры хупларга кыймадым. Каршы килеп, бәхәскә кереп китсәм, аның миңа булган ышанычын югалтуым ихтимал. Минем бит әле үзенең, эти-әнисенең язмышы турында бик күп мәгълүмат ишетәсем, бик күп нәрсәләр беләсем килә. Ул сөйләгән саен җавапсыз сорау һәм табышмакларым артканнан арта гына бара бит әлегә... Шуңарга да турыдан-туры чын ялганга күчүдән башка чарам калмагандыр.

– Мин бит, Александр Иванович, радио һәм телевизорлар белән бигүк дус түгел, – дидем. – Карасам да, шул яңалык һәм футбол матчларын гына карыйм. Ә Казан миндә, гомумән, күрсәтми.

– Гаҗәпләнмим, – диде ул, шундук хуплагандай итеп. – Бер син генә түгел, күпләр шулай хәзер, телевизор карамый, радио тыңламыйлар. Көндәлек мәшәкатьләргә чумып яшәгән кеше өчен милләт проблемалары соңгы чиратта хәзер. Нигә ул бездә шулай? Үзем дә аңлый алмыйм. Ә бит үз-үзен хөрмәт иткән халык, иң элек корсагын түгел, милләтенең язмышын, аның киләчәген, мәдәниятен, туган телен кайгыртырга тиеш иде кебек...

«Син каян беләсең, картлач... Кеше белән аралашмыйм, берьялгызым яшим, дидең түгелме соң? Кем-кем, сиңамы инде милләт турында сөйләшергә...» дип искәртергә иде дә бит. Ярар, әлегә торып торсын...

– Ә сез менә тыңлыйсыз икән бит!

– Тыңлаудан бигрәк, мин алар белән сөйләшәм. Һәм бәхәсләшәм... Якаларыннан тотмасам да, ут уйнатып сүккән чакларым да була... Ишетмиләр генә.

Үз сүзләреннән кызык табып, кеткелдәп көлеп тә алды ул шунда. Юк, бу һич тә аның беркатлылыгы яисә риясызлыгы чагылышы түгел иде. Бу кеткелдәү минем өчен булды, шулай үзенең эчкерсезлегенә ышандырасы килә иде кебек. Кем белә, ашыгыч нәтиҗә ясап, ялгышкан булуым да ихтимал.

– Ә нигә аларны ачуланырга!.. Телевидение-радиода эшләгән кызлар һәм егетләрнең берөзлексез агылып торган очсыз кәмиттә ни гаебе бар, – дип, эчтән генә үземә күрә күргән-белгән таныш-белешләремне яклаган атлы булдым.

– Казаннан булганнары өчен түгел, көн-төн түрәләрнең артын ялаганнары өчен яратмыйм мин аларны. Кем килсә – шул дөрес, түрәләр бер гөнаһсыз акыл һәм мәрхәмәт иясенә әйләнә дә куя һәммәсе өчен. Шулай ук, үз фикерләре юк микәнни аларның, дип әйтер идем...

– Минемчә, хикмәт – үз фикерең булу-булмауда түгел. Һәркемнең яшисе бар, яшисе килә. Ә хакимият кулында чикләнмәгән хокук һәм мөмкинлекләр. Без бит үзең уйлаганны әйтә торган җәмгыятьтә яшәмибез. Хәер, чынлабрак уйласаң, гомумән, җир йөзендә бармы икән соң ул андый җәмгыять?

– Анысы шулай. Кеше булган җирдә абсолют ирек була алмый. Мәскәүдә дә аз түгел мондый хәлләр. Әмма, миңа калса, төбәкләрдә һәм шул исәптән, Казанда бу күренеш аеруча нык күзгә ташлана торгандыр.

– Казанны яманлыйсыз, сез үзегез дә Казанда тугансыз түгелме соң, Александр Иванович?..

– Булса ни, кем кайда тумас.

– Бик тә кызыклы кеше икән сез, – дип, чираттагы мәртәбә ихлас сокланып алдым үзенә. Әмма Казаныбызны яклап бәхәс кузгатып тормадым. Кузгатып нишлисең, бу очракта барыбер файдасы булырга охшамаган...

– Әтием турында сөйли идем бит, – дип, төп темага кайтып төште ул яңадан. – Егерменче-утызынчы елларда мәдәният һәм әдәбият өлкәсендә үз милләтенә, халкына ихлас хезмәт иткән кешеләрнең язмышы ни белән тәмамланганын ишеткәнең бардыр...

– Әйе, ишеткән бар.

– Утызынчы еллар уртасында минем әтине дә кулга алдылар. Алты-җиде яшьтә генә булсам да, ул елларны әле дә яхшы хәтерлим. Кабан күле читендә ике катлы агач йортның икенче катында яши идек без. Ике бүлмәле фатир. Бүлмәләр зур һәм иркен. Кич эштән кайтып, тамак ялгап алгач та, гадәтенчә, әти үзенең эш өстәле янына барып утыра. Зур өстәлнең ике як-ягында китап киштәләре, алар китап белән шыплап тулган. Гарәпчә, фарсыча, төрекчә, французча... Татар һәм рус телендәгеләре турында әйтеп тә тормыйм инде. Бу телләрнең барысында да укый һәм яза белгән минем әти. Өстәл өстендә дә төрле-төрле китап һәм кәгазьләр таудай өелеп тора. Шулар арасына күмелеп, аларны барлый-барлый ниләрдер язып һәм сызып кайсы вакытларда таңга кадәр утыра торган иде ул. Эш өстәле янына килергә ярамый, андагы бер китап яисә бер кәгазьнең урынын алыштырсам, моны әти шунда ук сизеп ала һәм мине яратып кына шелтәли, колагымны бора торган иде...

– Малай-шалай чакта кемнең генә колагын бормаганнар, – дип әйтеп куйганмын, дәшми утырудан уңайсызланып.

– Көн-төн шул өстәл артында утырасың, әти. Ниләр язасың һәм кем өчен язасың? – дип сораганымны хәтерлим.

– Халык өчен, аның киләчәге өчен тырышабыз, улым, – дип җавап кайтарды ул. – Бик бай мираска ия халык ич без, шуларны түкми-чәчми кире кайтару зарур.

– Ә ничек була ул «кире кайтару», аны кем урлаган яисә кем тартып алган? – дип төпченгәнмен.

– Тормыш авырлыклары, тарихи гаделсезлек тартып алган, улым.

– Ә хәзер ул гаделсезлек беттеме?

– Бетте, улым. Ходай кушкан булса... – дип, үзалдына уйланып, сузып куйганын хәтерлим.

– Башка һичбер вакыт кабатланмасмы ул гаделсезлекләр?

– Кабатланмас, дип өметләнергә кирәк. Үзебездән тора, улым... Миннән, синнән...

– Ә «мирас» дигәне нәрсә була инде аның, әти?

Ул миңа Габдулла Тукайның халык авыз иҗаты турындагы бик матур сүзләре белән җавап кайтарган иде. Сүзләрен төгәл генә хәтерләмим дә кебек инде хәзер... «Саф вә раушан көзгегә» тиңләгән булса кирәк Тукай аларны... Шунда, гел көтмәгәндә, әти миңа Хуҗа Насретдин мәзәкләреннән берсен сөйләп күрсәтте. Әле дә онытасым юк:

«Көннәрнең берендә Хуҗа Насретдинга бер бай:

– Хуҗа әфәнде, әйдә бәхәсләшик әле, син мине алдый алырсыңмы икән? – дигән.

– Әйдә, – дип килешкән Хуҗа, – әгәр алдый алсам, нәрсә бирерсең соң?

Бай әйткән:

– Йөз чикләвек сатып алам, син мине алдый алсаң, алар сиңа булыр, алдый алмасаң, чикләвекләрнең бәясен син түләрсең, – дигән. Хуҗа риза булган. Бай чикләвек өчен акча түләгән дә Хуҗа чикләвекләрне үз кесәсенә алып салган.

Аннан, байга: «Өйдән акча алып килим әле», – дигән дә йөгереп өенә кайтып киткән. Бай Хуҗаны көтә дә көтә икән. Бер сәгать көткән, ике сәгать үткән, өч сәгать узган, ә Хуҗа юк та юк. Көтә-көтә кич тә җиткән. Иртәгесен Хуҗа очрагач, бай:

– Йә, кайчан алдашабыз инде? – дип сораган.

Хуҗа:

– Йөз чикләвек өчен ике кат алдашмыйлар, кичә бер тапкыр алдадым бит инде, чикләвекләр минеке, – дигән дә үз юлы белән китеп барган».

Миңа бик тә кызык булды, рәхәтләнеп көлгәнемне хәтерлим.

Тагын да укуын сорагачтын, кыстатып тормады әти, үземне җәлт кенә тез башларына утыртып куйды да тагы бер мәзәк сөйләде. Анысы да истә:

«Бервакыт Хуҗа авыл читендәге каен агачына сөялеп тора икән. Хуҗа янына бер бай килеп чыккан:

– Йә Хуҗа, мине бер алдап кара әле, – дигән.

– Алдавын алдар идем дә, алдар капчыгым өйдә калган бит, – дип җавап кайтарган Хуҗа.

– Бар, алдар капчыгыңны алып кил, – дигән бай.

– Килүен килер идем дә, менә бу каенны терәп торырга кирәк, югыйсә ул ава, кеше өстенә төшүе ихтимал, – дигән Хуҗа.

– Бар, алып кил, үзем терәп торырмын, – дигән бай.

– Кара аны, аудара күрмә, югыйсә бәла-казага сәбәпче булуың бар, – дигән Хуҗа.

Шуннан соң, Хуҗа өенә киткән дә ятып йоклаган. Бай бер сәгать көткән, ике, өч, дүрт, биш сәгать буена каенны терәп торган. Ахырда түзмәгән, кинәт кузгалып киткән һәм куркуыннан аяклары җиргә тияр-тимәс йөгергән. Байтак киткәч, артына борылып караса, ни күзе белән күрсен, кәкре каен аву түгел, селкенми дә икән. Шунда гына бай үзенең бик нык алданганлыгын аңлаган».

Минем Хуҗа Насретдин мәзәкләрен тагын да тыңлыйсым, әтидән сөйләтәсем килде.

– Сабыр ит улым, тиздән без боларны Хуҗа абзыйның үз авызыннан ишетербез, боерган булса. Аның мәзәкләре бик күп, күрәсеңме, минем өстәлдә дә таудай өелеп торалар, – диде ул, язу өстәле өстендәге кәгазьләренә күрсәтеп.

– Ничек, үз авызыннан?.. Хуҗа Насретдин исәнмени ул?.. Безнең Казанга килергә тиешме әллә? – дип сораганым хәтердә.

– Аны да кайтарырбыз, улым...

– Килсә, тизрәк килсен иде инде...

– Килер, улым. Менә шул тизрәк килсен дип, тырыша-тырыша язып утырган көнем бит инде. Буш вакытымда хәтта, Хуҗа Насретдин булып сөйләшә башлыйм... Аның турындагы мәзәкләрне барлыйм көн-төн...

– Ничек, әти, син аңарга хат язасыңмы?.. Чакырасыңмы?.. Ә ул сине тыңлармы соң?

– Тыңлатырбыз, улым. Боерган булса, театр сәхнәсеннән бөтен Казан халкына сөйләтербез әле үзен. Ә без, синең белән янәшә утырып, аны тыңларбыз...

– Әнине дә алырбызмы соң?

– Театрга әнисез баралар диме! Без өчәүләп барырбыз, боерган булса, иң алгы рәтләрдә утырырбыз. Син уртада, бер ягыңда әниең, икенче ягыңда мин, килештекме...

Килешми диме! Шул көннән соң мин көн дә, ә бәлки, көненә әллә ничә мәртәбәләр, әти янына килеп, аны урынсыз сорауларым белән тинтерәтеп бетерә торган идем:

– Хуҗа Насретдин хатыңны алдымы икән, әти? Җавабы килмәдеме? Кайчан килеп чыга инде безнең Казаныбызга?.. Без белми калсак, нишләрбез, әти...

– Ашыкма, улым, ашыкма, тиздән килер. Театрга да ул безне үзе чакырачак, – дип тынычландыра, күңелне күтәрә торган иде ул...

Мин хәтта ишегалдындагы дусларым белән шәһәрнең икенче тарафында урнашкан театр бинасын эзләп таптым һәм эти-әнигә сиздерми генә андагы игъланнар белән таныштым. «Хуҗа Насретдин килә» дигән хәбәрне беренче булып ишетәсем, үз күзләрем белән күрәсем килә иде шул. Аннан тагы шунысы да бар, сөенечле хәбәрне этигә беренче булып үземнең җиткерәсем килгәндер. Әтинең эше күп, вакыты бер дә юк, ишетми калуы да ихтимал...

Хисләнүдәнме, нәрсәнедер хәтерләпме, Александр Иванович шулчак күз читендә барлыкка килгән яшь тамчыларын кибеп укмашкан уч төбе белән сыпырып куйды. Борынын тарткалап алды.

Хуҗа Насретдинне күрдеңме, театрга бардыгызмы, дип, тормышка ашмаган һәм ашмастай тарихи вакыйгаларны искә төшерү, башны тилегә салып, театр хакында сораштыру минем тарафтан чамасыз дорфалык булыр иде. Дәшмәвең – мең алтын, диләр андый очракта. Авыз ачып сүз әйтү түгел, тирән сулыш алырга да уңайсызланып калдым. «Менә ничек... Менә кай тарафларга, нинди вакыйгаларга барып тоташа икән безнең абзыйның тарихы...»

Тиз арада үзен кулга алып, сөйләвен дәвам итте Александр Иванович.

– Әнинең дә эше җитәрлек. Аш өстәлен җыештыргач та, шул ук өстәлгә яңа җәймә ябып куя торган иде ул. Һәм шунда, эшкә йөри торган сумкасыннан дәфтәрләр чыгарып өя. Таудай өелеп торыр иде алар да. Шул рәвешле укучыларының дәфтәрләрен тикшерергә керешә. Һәй, такыр баш, әйтмәдем бугай бит әле, минем әнием Яңа бистәдәге татар мәктәпләренең берсендә үзебезнең тел һәм әдәбиятыбызны укыта иде.

Алар үз эшләре белән мәшгуль, ә мин ерак бер почмактагы урыныма, җылы юрган астына кереп йокларга тырышып ятам. Әти белән әни – икесе ике өстәл янында тын да алмый эшлиләр. Ул минутларда ишетелсә дә, шул кәгазь кыштырдаган аваз гына ишетелгәндер...

Бер-берсенә сораулары булса, пышылдап кына сөйләшәләр. Мине йоклый дип уйлыйлар, уятудан куркалар, янәсе... Ә мин юрган астыннан бер колагымны чыгарып, сулыш та алмый тыңлап ятам... Кайсыбер сүзләрен ишетәм, кайсыларын юк. Пышылдап сөйләшүдә аеруча әни оста иде безнең, бер сүзен дә аңлап булмый. Әтинең аерым сүзләрен яхшы ишетәм, пышылдыйдырмы-юктырмы, барыбер, гөбедән чыккандай калын иде аның тавышы. Ишетсәм дә, һични аңлый алмыйм. Кем турында, нәрсә турында сөйләшәләрдер... Сабый аңларлык вакыйгалар булмаган икән шул...

«Аны да алып киткәннәр... Кая булсын, Черек күлгә инде... Галимҗанмы? Аны атканнар, дип сөйлиләр... Кем дисең?.. Ә аны Мәскәүгә алып киткәннәр... Мәскәүгә киткән кешенең кире әйләнеп кайтканы юк, диләр әлегә...»

«И Аллам, яман кешеләрдән, нахакка гаепләнүләрдән саклый күр...» – дип ухылдап куйды. Монысы әни иде.

Мин барыбер берни аңламадым. Хуҗа Насретдин турында бер-бер яңалык ишетү иде дә теләгем, аны искә төшермәделәр кебек... Йоклап киткәнмен.

...Һич онытасым юк. Ял көне иде бугай, кояшлы матур иртә. Кыектан тамчылар тамып тора. Яз килүгә, тәрәзә каршындагы миләш агачына кунган песнәкләр куана, канат кагына. Ял көнендә эти дә, әни дә эшкә дип чыгып йөгермиләр, алар өйдә. Әти эш өстәле янында, әни мич янында кыстыбый пешереп йөри. Иртәнге ашны ашагач та мин урамга, малай-шалай, ягъни дус-ишләрем янына ашыктым. Нинди генә уеннар уйнамый идек без. Иртә язда исә, кар тәгәрәтеп кыш бабай ясыйбыз. Борыны кишердән, авыз урынына кыяр кабыгы ябыштырып куябыз, күзләренә кәҗә койрыгы астыннан төшеп калган «шомыртлар» бик тә килешә. Чәч урынына чыбык-чабык. Үзебез генә түгел, зурлар сокланып карап китә иде без ясаган кыш бабайга... Бер-беребезне куыша-куыша әбәкле уйныйбыз. Йөгерешеп

туйгач, тирләп чыккач, баштагы бүрекләрне, кулдагы йон бияләйләрне салып куеп, туктап хәл алабыз, һәр сүздән кызык табып мәзәк хәлләр сөйләшәбез... Кабан күле буенда күбрәк татарлар яши торган иде ул елларда, без бары тик татарча сөйләшә, татарча гына шаярыша һәм уйный торган идек. Арабызда ара-тирә рус малайлары булса, алар да татарчаны яхшы аңлый, безнең белән бергә рәхәтләнеп шаярыша-көлешәләр.

Шулчак урам яктан узып барган бер кара машина, тизлеген киметә төшеп, безнең ишегалдына борылды. Барыбызның да күзләре шул машинада. Ул заманнарда машиналар санаулы гына, ишегалларына алар, гомумән, кереп тә тормыйлар иде...

– Җегетләр, кара машина... – дип, ачыргаланып кычкырып җибәрмәсенме шунда Йосыф исемле яшьтәшебез.

– Кара булса соң, барыбер түгелме, – дип әйтеп куйганмын.

– Ибраһимның әтисен шундый машинада алып киттеләр, – диде икенчесе.

Ул арада әлеге машина нәкъ безнең урам як ишек каршысына килеп тукталмасынмы... Аннан ялтырап торган күн итекле өч кеше килеп чыкты. Ачкан авызларын йомарга онытып, ух та ах килде малайлар. Барысының да күзләре миңа текәлде.

– Сезгә... – диде алар, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә минем чын исемемне атап. – Ә мин, беркатлы сабый, үзалдыма куанып куйганмын.

– Безгә булса, бу беләсезме кем, Хуҗа Насретдин үзе килгән. Театрга чакырып килгән. Әти белән мине һәм әниемне алырга дип...

Ике уйлап тормый гына, дус малайларымның ай-ваена да карамыйча, бүрегемне күккә чөя-чөя, Хуҗа Насретдин һәм аны озатып килүчеләр артыннан өйгә кереп йөгергәнмен... Өйгә керсәм, тупса башында катып калдым. Хуҗа Насретдин дигәнем, әтинең беләгеннән кысып тоткан да аны ишеккә таба өстери. Әти карыша.

– Бу нинди хәл... Минем бер гаебем дә юк. Бу зур ялгышлык, – дигән өзек-өзек сүзләре хәтергә уелып калган.

– Киенегез. Без ялгышмыйбыз. Анда ачыкларлар... – диде мин Хуҗа Насретдин дип уйлаган кара мыеклы татар кешесе.

Әйе, ул чынлап та саф татар телендә сөйләшә иде.

– Бу ялгышлык. Мин кайтырмын, улым, борчылмагыз, – диде әти, такыр башымнан сыйпап. Әнине аңарга якын җибәрмәделәр, ул күз яшьләренә буылып тупса башында елап калды. Мин исә әти артыннан урамга ук йөгереп чыктым.

– Әти, мине калдырма! Мин дә синең белән, – дип, үзенә барып сарылам да кочаклап алам дигәндә генә, әлеге дә баягы теге «Насретдин» дигәнем ямьсез сүзләр белән кычкырып күн итеге белән артыма китереп типмәсенме.

...Машина китеп тә барды. Мин урам як ишек төбендәге юеш кар өстенә егылып калдым. Иптәш малайларым йөгереп килде. Алар мине җылы сүзләр әйтеп юатырга, пычранган өс-башымны сыпырырга, каккаларга керештеләр...

Менә шулай, кардәш, шул китүдән кайтмады әтием. Юк булды. Еллар узгач кына белдем: «Буржуаз пропаганда алып барган халык дошманы», дип гаепләп атканнар үзен. Казанда атканнар. Кабере дә юк, исеме дә...

– Әйе, башка сыймаслык кыргыйлык, коточкыч заман... Нинди вәхшилекләр кылынган бит, – дип, үзалдыма сукранып алдым мин.

– Иң кызыгы шул: әти китеп бер сәгать вакыт узгандырмы-юкмы, безнең ишекне тагы шакыдылар. Әтием кайткан дип шатлануымны белсәң... Берөзлексез елау һәм күз яшьләреннән шешенеп беткән әни аны-моны аңлап өлгергәнче, йөгереп барып ишекне ачтым. Ачсам, анда бер абый басып тора. Чит-ят кеше түгел, әтинең танышы. Минем дә аны күп тапкырлар күргәнем бар иде. Соңгы араларда, әни әйтүенчә, юк йомышын бар итеп, бик еш килеп йөри башлаган иде

ул безгә. «Шигырьләр яза, шигырьләренең әллә ни мактар җире юк», ди торган булган әти аның турында. Әмма әтинең килгән кешене борып чыгару гадәте дә юк иде. Эше күп булуга да карамастан, озаклап сөйләшә торган иде ул аның белән. Күбрәк тегесе сораулар яудыра, әти җавап бирә, ниндидер язуларын укый, киңәшен кызганмый. Әни үзләрен өстәл янына чакыргачтын да мавыгып сөйләшүләрен дәвам итә торган иде алар.

Бу юлы да килгән кешене борып чыгара алмады әни. Шагыйрь иң элек безнең кайгыбызны уртаклашкандай итте:

– Бик борчулы көнегез икән. Түземлекләр телим үзегезгә, – диде ихлас тавыш белән.

Әнинең йөзе караңгыланып китте.

– Ә син каян беләсең аны алып киткәннәрен? Әле эзе дә суынмады ич... – дип сорап куймасынмы.

Мондый сорау көтмәгән иде теге, ни әйтергә, ничек җавап бирергә белми ык-мык килеп торды бер мәл. Әмма җавапсыз калмады.

– Ишеттем, Казан зур шәһәр түгел ич. Чыбыксыз телефон эшли, андый хәбәр бик тиз тарала.

Артык төпченеп, кабат-кабат сораулар биреп торыр хәлдә түгел иде әни. Тамак төбенә килеп тыгылган төерен йота-йота, үз-үзен тынычландырырга теләп әйтеп куйды.

– Озак тотмаслар, кайтарырлар әле...

– Бәлки, кайтыр, – дип мыгырданды килүче.

Үзе безне тынычландырган атлы, ә күзләре берөзлексез әти өстәлендәге кәгазьләр һәм киштә булып өелгән картотекаларда. Ул да түгел, хуҗаларча, әтинең эш өстәле янына барып, андагы кәгазьләрне актара ук башламасынмы. Күзләре май исе сизеп алган песинеке кебек ялт та йолт килә... Кайсысына барып тотынырга белми.

– Мин бит сезгә ашыгыч йомыш белән, – диде ул, ниһаять. – Бу кәгазь һәм документларны алып китәргә килдем.

– Ничек, алып китәргә? Мин аларны беркемгә дә бирергә җыенмыйм. Алар иремнең гомер буе эшләгән, җыйган хезмәтләре нәтиҗәсе. Каян килгән сүз ул, «алып китәргә», имеш, – дип, кулларын канат сыман җәеп, өстәл белән теге ыспай шагыйрь арасына кереп басты әни. Мин дә, кулларымны йодрыклап, аның янәшәсенә килеп бастым.

– Туктагыз әле, сез мине дөрес аңламадыгыз, – дип, бер читкә тайпыла төшеп, ипле генә йомшак итеп җавап кайтарды шагыйрь. – Мин бит сезгә изге ният белән, яхшылык эшләү, ярдәм итү өчен килдем. Ә сез, «бирмим», имеш, аңларга тырышудан элек күтәрелеп бәреләсез.

– Бу кәгазьләрнең үз хуҗасы бар. Аларның язмышын бары тик ул үзе генә хәл итәчәк, – диде әни, сүзендә нык торуын белгертеп.

– Ә ул кайда?– дип әйтеп куймасынмы килүче.

– Кайда гына булмасын, ул бер гаепсез. Ачыкларлар һәм кире өйгә кайтыр, Алла боерса...

Шагыйрь дигәннәре, кәпрәеп, авызларын турсайта төшеп, бер позага басмасынмы шунда. Авызыннан төкерек чәчеп юмаларга кереште әнине:

– Сез аңлагыз, безнең дәүләт органнары бүген кулга алып, иртәгә кире кайтарып, мәчеле-тычканлы уены уйнамый. Кулга алганнар икән, димәк, гаебе бар. Ни кызганыч, остазыбызның кире кайтулары бик икеле. Шуңа әзер булырга кирәк.

– Җитте, – дип, тавышын күтәрде әни. – Җитте, башка берни дә ишетәсем килми. Чыгып китегез, калдырыгыз безне...

Алай җиңел генә кире борылып китәргә уенда да юк иде теге затның. Рөхсәт-

фәлән сорап тормый гына, хуҗа диярсең, этинең эш өстәле каршында торган кәнәфигә кереп утырды ул. Һәм ап-ак тешләрен кыса төшеп, ысылдаган елан сыман, теш арасыннан сөйләргә, өр-яңадан аңлатырга, үгетләргә кереште.

– Бик калдырыр идем дә бит, калдыра алмыйм... Бу кулъязма һәм китаплар арасында уникаль, һич бәяләп бетергесез кыйммәтле документлар бар. Алар югалырга тиеш түгел, алар сезнеке түгел, халыкныкы. Иртәгә иртүк монда органнардан кешеләр киләчәк һәм ул кәгазьләрне сезнең ай-ваегызга карамыйча зур кычыткан капчыкларына тутырып алып китәчәкләр. Ә тагы бер көннән ул кыйммәтле әдәби вә мәдәни ядкарьләр Черек күл буендагы ишегалдында янып көлгә әвереләчәк. Йә, шул язмыш канәгатьләндерәме үзегезне?!. Шундый язмышка дучар ителү өчен тупланган хезмәтләрме болар?..

Юк дип тә, ризалашып та җавап бирүче булмады аңарга. Әни, телсез калгандай, чарасыз калып торды. Ә мин аңардан узып нәрсә әйтә алыйм?!

– Мин аның гаепле түгеллеген беләм. Аны кире кайтарачаклар, – дип әйтә алды әни шактый озакка сузылган тынлыктан соң.

– Кайтса, сез бит мине яхшы беләсез, таныйсыз. Ул хезмәтләрне, кәгазь һәм документларны берсен дә югалтмыйча, остазыбызга мин үзем китереп бирәчәкмен...

Икеләнеп калды әни, йомшара төште. Шулай да этинең гомер буе җыйган, туплап килгән, эшкәрткән һәм язган хезмәтләреннән аерылуны күз алдына да китерә алмый иде ул. Ә теге адәм исә, бу үзгәрешләрне күреп, һөҗүмен дәвам итте.

– Ихтимал, сезгә бу фатирны да бушатырга туры килер.

– Нинди фатир! Бу безнең әби-бабалардан калган үз йортыбыз.

– Элеккеләрне онытырга вакыт, хәзер бит яңа бласть (әйе, ул махсус шулай «б» хәрефенә басым ясый төшеп әйтте), Сәвитләр илендә яшибез!

– Әйттем ич, өй үзебезнеке. Без бит фатирга кермәгән. Дәүләтнеке дә түгел...

– Ихтимал, дидем ич. Бәлки калдырырлар, кем белә бит...

– Ә сезне мин, туганым, бүген таный алмыйм. Хуҗа өйдә чакта мондый түгел идегез. Шул тикле дә матур телле, йомшак күңелле кеше икән дип, соклана идем үзегезгә. Ә бүген сез бөтенләй башка. Барысын беләсез, ни буласын алдан күреп торасыз. Хуҗа итеп тотасыз түгелме үзегезне?..

– Ни уйлау сезнең эш. Әмма мин үзегезгә ярдәм кулы сузып килдем. Остазыбызны хөрмәт иткәнгә. Аның хезмәтләре югалмасын, көл булып күккә очмасын, дип килдем. Йортыгыздан куып чыгарсалар, кая китәрсез, кемгә барырсыз, бу китап һәм кәгазьләрне кая куярсыз?.. Хәер, аларны сезгә бирүче дә булмас. Алда үзегезне ниләр көткәнлеген кем белә бит әле... Озын сүзнең кыскасы шул, мин боларны бүген үк, менә хәзер үк алып китәргә дип килдем.

Хуҗаларча, колачын киң җәеп, эш өстәлен һәм бар китап киштәләрен, шулар белән бергә гүя татар халкының гасырлар буе таралып, сибелеп яткан бар мирасын, кочаклап алган сыман хәрәкәт ясап куйды ул.

– Ярар, – дип, ниһаять, җавап бирергә мәҗбүр булды әни. Бу шулкадәр дә тоник тавыш белән әйтелгән сүз чарасызлыктан, ни чарадан бичара әйтелгән иде, билгеле. – Аларны ничек алып китә алырсың икән соң?

Шунда ул аңа беренче тапкыр үз исеме белән дәште. Ә тегенең барысы да алдан уйланылган, хәл ителгән күренә.

– Анысы өчен борчылмагыз. Җигүле ат ишек төбендә, – диде ул. Шул мизгелдә аның ничек җанланып, зур эш башкарган кешедәй канатланып киткәнлеген күрсәң иде син. Сабантуйда мәйдан токан баш батыр диярсең...

Ул җәт кенә урамга чыгып йөгерде һәм күз ачып йомган арада үзен утыртып килгән ат хуҗасы белән зур гына буш сандык күтәреп керделәр. Өстәл өстендәге һәм киштәләрдә тупланган кулъязма һәм картотекаларны бик пөхтәләп, кадерләрен

белеп шул сандыкка тутырдылар иң элек. Сандык авырайды, уф-ах килеп, зур авырлык белән генә күтәреп алып чыгып киттеләр. Киштәдәге китапларны, ярылган утынны ташыгандай, кочаклап ташыдылар.

Әни бер почмакка посып, яулык чите белән битен каплап, шыпырт кына шыңшып еларга керешкән иде. Мин аны аркасыннан сөеп тынычландырырга тырышканмын... Ә китап ташучыларның инде бездә гаме дә юк, гүя күрмиләр-ишетмиләр. Бөтен өйне яңгыратып үзара киңәш-табыш итәләр.

– Ай-һай, бигрәк күп булган болар, атка авыр килмәсме? – дип сорап куйган булды тәмам тирләп-пешеп чыккан шагыйрь.

– Бәлки, җитеп торыр әлегә? – дип эләктереп алды атның хуҗасы.

– Калдырып булмый. Калган эшкә кар явачак!

– Алай булгач, үзебезгә янәшәдән атлап кайтырга туры килер инде, – диде атның хуҗасы.

Учын-учка сугып, китап тузаннарын каккандай итте шигырьләр язучы ыспай кеше. Бу аның китәргә җыенуы иде. Инде эш тәмам, максатына иреште, рәхмәт-фәлән әйтеп тору кая инде ул. Игелек эшлим диеп килгән ич.

Ишек катындагы почмакта бер чарасыз калып басып торган әнигә күзем төште шулчак. Көнозын елаудан шешенеп беткән күзләре өй түрендә бушап калган китап киштәләренә, әтинең кинәт ятимләнеп калган эш өстәленә текәлгән. Нәрсә уйларга, ни диярга белми иде ул. Шулай да сүзсез генә чыгып барган шагыйрьгә дәшәр көч тапты:

– Бер-бер язу яисә «расписка-фәлән» дигәннәрен калдырасыңмы соң әллә... Бигрәк тә кадерле әйберләрне алып китәсең ич... Үзе сораса, ни диярмен.

– Сорамас, – диде теге, муенын ата каз сыман турайта, ялтырап торган ап-ак тешләрен тагы да кыса төшеп. – Аларның кирәге чыкмас инде аңарга хәзер.

– Ул кайтачак, күңелем сизә. Бер-бер язу булса да калдыр.

– Юк, язу-фәлән калдыру юк. Сезгә иртәгә тентү белән киләчәкләр. Мин калдырган язуны тапсалар, аңлыйсызмы, бу хезмәтләр барысы да юкка чыгачак. Һичкемгә әйтмәгез бу хакта, мин монда булмадым, сез мине белмисез, мин – сезне. Аңладыгызмы! – диде ул, янаган сыман, тавышын кинәт күтәрә төшеп.

– Аңладым, – дими хәле калмагандыр әнинең. Ул тәмам чарасыз иде шул.

Шунда безне ташлап чыгып баручы шигырь язучы, шаярган атлы булып, борыныма чиртеп узды. Яратып, үз итеп шаяруы түгел иде, әлбәттә. Мин чирканып куйдым. Бу аның үзенә күрә мине түбәнсетергә, мыскыл итәргә теләве булгандыр.

– Ә син, юеш борын? Син дә аңладыңмы?.. Кара аны, мин әйткәннәрне хәтереңә киртләп куй, юкса телеңне кисеп к...не яматырмын! – дип янады, бармагын борын төбемдә болгый-болгый.

Җавап бирергә иде дә бит, сүз таба алмый тордым. Хәер, икенче уйласаң, тел әрәм итүнең кирәге дә булмагандыр, баш кагып кына куйдым кебек. Менә шул. Әтинең үзе артыннан ук, ул гомер буе җыйган, туплаган хезмәтләре, ягъни гыйльми һәм әдәби мирасы да китеп барды. Шул көннән соң эзе суынды теге адәмнең, очратканда да безне күрмәде, танымас булды. Ә әтинең язмышын беләсең...

– Аның хезмәтләре... Мирасы белән ничек булып бетте?

– Ул кадәресен белмим. Ә теге шигырь чыгаручы соңгы елларгача исән иде әле. Үзе турында зур галим һәм бөек язучы, дип сөйләгәннәрен дә ишетергә туры килде... Аның турында сораштырма башкача, ярыймы. Ишетәсем дә, сөйлисем дә килми.

– Ул бәндәнең исемен белә торгансыздыр ич? Нигә аны яшерәсез? – дип сорамый кала алмадым шулай да.

– «Бәндә» диеп дөрес әйттең! Әмма, ул да инде бу дөньядан киткән булса кирәк. Киткәннәр белән булышу кирәкме икән бүген?..

– Дөрес сөйлисез, киткәннәр белән булышу урынсыз анысы. Ләкин бит әле хакыйкать һәм гаделлек дигән төшенчәләр дә бар. Һәрхәлдә, булырга тиеш! Иртәме-соңмы гаделлек өскә чыгарга, кайчан да булса барыбер хакыйкать тантана итәргә тиеш...

– «Тиеш» дип әйтү җиңел. Әмма, йә әйт, кайчан, кайсы заманда дөреслекнең өскә чыкканы яисә гаделлекнең тантана иткәне бар икән бездә? Тарихка карасак та, бүгенге тормышыбызда да моның нәкъ киресе кабатланып килә түгелме?..

Мин баш кагып кына утырдым, хәер, авыз ачып сүз әйтү артык булыр иде. Ә Александр Иванович кинәт утырган җирендә кыбырсып куйды. Урыныннан торырга җыенуыдыр, дип кабул иттем моны.

– Арыттым ахрысы. Өйгә керер вакытыгыз җиттеме? – дип сорарга мәҗбүр булдым.

– Арыдым, дип әйтмим. Әмма, бу тарихны яңадан хәтергә төшерү, кичерү минем өчен һичкайчан җиңел булмады.

– Ләкин мине бик тә кызыксындырган сораулар кала бит әле... – дидем, бу сөйләшүнең менә шул рәвешле ярты юлда өзелүен теләмичә.

– Син сорау алучы, мин җавап бирүче түгел, – диде ул, башкача сөйләшергә уенда булмаганны ачык аңлатып. Һәм таягына таянып, авырлык белән генә күтәрелә төште, гәүдәсен турайтты. Аркасы белән капка баганасына терәлде. – Синең дә вакытыңны алдым, үземә дә керергә вакыт...

– Александр Иванович, тагы күрешербез бит әле, шулаймы?.. – дип, мин дә урынымнан торып бастым.

– Вакытың булса килеп чыгарсың, – диде, баш тартмады. Борылып, капка келәсенә кулын куйгач, өстәргә кирәк тапты. – Чәйгә чакырмадым, үпкәли күрмә, ярыймы. Минем өйгә чит-ят кешенең кергәне юк, шулай гадәтләнелгән. Яратмыйм...

– Рәхмәт, чакырсагыз да керә алмас идем. Үземнең дә вакыт ягы тыгыз иде бүген, – дип тынычландырырга, салпы ягына салам кыстырырга кирәк таптым.

Авыр тимердән ясалган келә эчке яктан шалтырап төшеп, капка бикләнгәч кенә үз юлым белән китеп барырга мәҗбүр булдым.

**3**

...Күпме генә онытырга, бу очрашу хакында уйламаска тырышсам да, булдыра алмадым. Көндез – эштә, төнлә – төштә дигәндәй, орчык кадәргә калып кибешкән, бөкрәя төшкән әлеге картның серләре, аның сүзләре, үз-үзен тотышы, холык-фигыле колагымда һәм күз алдымда йөрде. Ул кем, кемнең улы икән соң? Алга таба тормышлары ничек булган? Бу тарафларга язмыш ничек китереп чыгарган?.. Япа-ялгыз яшәү, кешеләргә һәм җәмгыятькә ышанычын югалткан хәлдә көн күрү... Хәер, шулай дидем диюен, әмма Александр Иванович дигәнебез, язмыш сынауларын шактый ук күрсә дә, үз-үзенә ышанычын югалтмаган, кызганыч һәм көчсез кешегә һич кенә дә охшамаган. Кистереп үз фикерен әйтә белә, сүзләрен дә кырык кат үлчәп сөйли...

Шулай да әтисенең кулъязмаларын, бар мирасын алып киткән бәндә кем булыр – ул кем икән?.. Күреп түгел, ишетеп кенә булса да мин аны да беләм, таныйм булса кирәк... Исеме шактый ук мәгълүм кеше, диде түгелме... Сорау өстенә сорау... Гомерен татар әдәбияты һәм мәдәниятенә багышлаган кешенең, аңлашылса кирәк, бу сорауларга җавап эзләве гади кызыксыну гына түгел. Җавап тапмый ничек тынычланырга мөмкин?..

Чираттагы күрешүебезне озакка суза алмадым. Бу юлы инде ул күрешүне зарыгып көттем. Ике-өч көн үттеме-юкмы, тагы таныш сукмаклар буйлап урман куенына кереп поскан әлеге дә баягы теге өйгә таба китеп бардым. Бераз суыта

төшсә дә, көн аяз иде. Ялгышмаганмын, ул мин уйлаганча, гадәттәгечә, берьялгызы капка төбендә утыра.

– Александр Иванович, мин тагы килеп чыктым бит әле, – дип, аваз салдым килә-килешкә. Һәм култык астына кыстырылган чәкчәк тартмасын суздым. – Бусы сезгә Казан күчтәнәче...

Кырыс кына карап куйды миңа. «Казан»ны искә төшерүем ошап җитмәдеме соң әллә? Һәм, кабалана төшеп диярлек, сорап куйды:

– Нәрсә, Казанга бардыңмы?

– Юк, алып килделәр, – дигән ялган белән котылдым. Югыйсә, «Бәхетле»дән алдым, дип тә котылырга мөмкин булгандыр.

– Кирәкмәс иде... Күчтәнәчләр белән йөрмә бүтән, миндә нәрсә кирәк, шул бар,– дип, карышуына да карамастан, ике уйларга урын калдырмыйча, күчтәнәчне капка келәсенә элеп куйдым.

Ә ул исә «рәхмәт» әйтергә мәҗбүр булды. Аннан бер-беребезнең хәл-әхвәлләрен белешеп алдык.

Картның кәефе чагыштырмача ярыйсы күренә иде бүген. Шуннан файдаланырга теләп, күңелне бимазалап торган сорауларымның иң четереклесеннән башларга булдым.

– Сезгә менә тагы «Александр Иванович» дип дәштем. Әмма моның әти-әниегез биргән исем түгел икәнлеген белгәч, ничектер уңайсыз... Бәлки, ачыклык кертерсез, «агай» дип әйтимме, беренче кабат очрашуыбыз түгел бит инде...

– Мин дә ялган сөйләп утырмыйм, паспортта ничек булса – шулай дидем...

– Ләкин, барыбер, бу бит сезнең чын исемегез түгел!

– Нигә алай дисең?

– Татар халкының авыз иҗатын, әдәби мирасын җыйган һәм өйрәнгән галим үз улына андый исем кушмас. Үзебездә дә матур исемнәр бетмәгән ич... Татар исемнәре дип әйтүем.

– Бу дөньяда нәрсәнең чын, нәрсәнең ясалма икәнлеген кем белеп бетергән... – диде ул, артык исе китми генә.– Кеше исем белән тумый, исемне безгә тугачтын яисә дөньялыкта яшәү дәверендә бирәләр.

– Шулай да исемен яшергән, ата-ана биргән исеменнән качкан кешегә мин үзем бигүк ышанып бетмим.

– Син ышансын өчен исем алыштырыргамы инде миңа?..

– Алай димим. Әмма әти-әниегез сезгә башка исем кушкан бит.

– Шулай укмы! – дип, күтәрелеп сынап карап куйды ул. – Тикшерү органнарында эшләми торгансыңдыр ич...

– Юк, алай уйласагыз, нык ялгышасыз. Гади бер пенсионер...

– Ярар... Гади бер пенсионер, дисең инде, – дип, ялт кына күзләрен миңа текәп алды ул. Ниндидер сер бар иде кебек аның бу карашында. Бәлки миңа гына шулай тоелгандыр. Шулай да озак көттермәде, берни булмагандай илле һәм тыныч кына сүзен дәвам итте. Үз кешегә санап, шаяргандай кыланды. – Бик кызыксынучан кеше булып чыктың бит әле, синнән җиңел генә котылам димә икән. Кызыксынсаң, тыңла, теге көнне өзелеп калган җирдән дәвам итәм.

– Тыңлыйм... – дидем һәм үзалдыма уйлап куйдым: яше шактый булуга карамастан, хәтере дә әйбәт икән әле бу картның.

– Теге, шигырь чыгаручы бәндәнең әйткәннәре дөрескә чыкты ул чакта. Икенче көнне үк тентү килде өйгә. Ә өстәл һәм киштәләр буп-буш. Берничә урында өелеп торган гәҗит-журналлардан тыш берни дә калмаган. Әтинең язу-сызуларын таптырыпмы-таптыралар үзебездән. «Булмаганны каян алыйк?..» дибез. Ышанмыйлар. «Үзегезне дә алып китәргә туры килмәгәе» дип, куркытып та карадылар. «Юк, булгач, юк инде. Бәлки эш урынында, институтта калдыргандыр

сез эзләгән кәгазьләрен», дип аңлаткандай итте әни. Янадылар, куркыттылар да киттеләр... Ә тагы ике-өч көннән фатирдан ук куып чыгардылар. Кеше түгел, хуҗасыз этләрмени! Хәер, хуҗасыз этләр белән дә алай кыланмыйлар. Теге, үзен шагыйрь дип санаган адәмне әйтәм, әүлия диярсең, бар әйткәне дөрескә чыгып барды...

– Урамга ук кумаганнардыр инде... Бер-бер почмак бирделәрме соң?

– Бирделәр, ди... Халык дошманы калдыкларының кайгысы түгел бездә, кайда оя табасыз, шунда куныгыз, диделәр...

– «Оя» диделәр, «фатир» түгел...

– Әйе, оя! Эт оясын күздә тоттылармы, кош оясынмы, белгән юк...

– Барыр җиребез юк, бала белән кая чыгып китим, – дип аңлатып карады үзләренә әни.

– Тапмасагыз, үзебез табарбыз, – диде арадан берсе коры гына. – Себердә урын күп анда. Сезгә дә җитәр...

– Кудылармы?

– Сорыйсың! – диде ул, кырт кисеп.

– Кайда урнаштыгыз инде?

– Урнашуын-урнаштык, әнинең ерак бер туганы кертте. Әмма, вакытлыча дигән шарт белән. Бер атна уздымы-юкмы, әнине дә эшеннән азат иттеләр. «Халык дошманы хатынына совет мәктәбендә урын юк» дигәннәр... Әтинең язмышы белән кызыксынып кая гына бармадык, безнең белән сөйләшергә теләүче табылмады. Ул эшләгән институтның бусагасын атлап керә алмадык. Черек күлдә урнашкан оешмалар турында әйтеп тә торасы юк... Бар мирасын, китапларын алып киткән адәмнең адресын эзләп табып, соң чиктә шуның янына бардык. Ярдәм итмәсә дә, бер-бер хәбәре булмасмы, дип өметләнгәнбездер инде...

Ишек катында безне күргәчтен чирканып куйгандай итте ул да, фатирына чакырмады. Затлы җылы халатка төренеп тышкы якка үзе чыкты. Әни белән без баскыч читендә катып тордык.

– Сезгә нәрсә калган... Ник килдегез монда? – булды беренче сүзе.

– Башка чарабыз юкка килдек, – диде әни. – Ул кайда икән? Бәлки син белә торгансыңдыр...

– Белмим һәм белергә дә теләмим, – булды җавабы.

– Берни алмады бит, буш кул белән чыгып киткән көенә, – дип елап җибәрде әни.

Юату яисә бер-бер җылы сүз әйтеп куйса, ни булган, тегенең уенда да юк.

– Аңарга берни дә кирәкми инде хәзер, эч пошырып йөрмәгез, ярыймы! Мине дә, адресымны да онытыгыз,– диде ул, бер-бер кеше күрмиме дигәндәй як-ягына карангалап. – Әйттем ич, мин сезне белмим, сез – мине, дидем.

– Алмашка кием-салым да алмаган иде... Ашарына бармы икән? – дип өзгәләнде әни аның саен.

– Мин берни дә белмим. Һәм белергә дә теләмим! Аяк астында буталып йөрмәгез башкача... – диде дә, кырт борылып, кире үз фатирына кереп китте. Әни белән мин шапылдап ябылган ишекнең урам тарафында торып калдык.

– Үзен «шагыйрь» дигән адәм шулай кыландымы! – дип, гаҗәпләнүемне белдергәнмен. – Һич ышанырлык түгел ич моңарга...

– Ышану-ышанмау синең эш, кардәшем. Йә, әйт, уйлап чыгару, арттырудан миңа ни файда?.. Ничек булган, шуны сөйлим. Хәтеремә бөтен кыланышлары уелып калган.

– Шагыйрьләрне нечкә күңелле, кешелекле буладыр, дип белә идем. Шуңарга соравым, – дидем. Аңлашылса кирәк, әңгәмәдәшемдә шик-шөбһә туа күрмәсен тагы, дип тырышуым. Шагыйрь һәм язучыларга мөнәсәбәтен алдан ук искәртеп куйган иде ич. Белә калса, эш харап... Бабабызның кулында тимер таяк.

– Күпме яшәп, мин ул кадәр дә икейөзле һәм мәрхәмәтсез кешене очратмадым башкача, – диде Александр Иванович һәм көрсенеп куйды. Бу – аны онытыйк, сүзне башкага борырга вакыт, дигәнне аңлатуы иде.

Башым кагып, ризалашкан атлы булдым. Ә ул дәшми генә, карашын аяк очына төбәп, тик утыруын дәвам итте. Бераз көттерә төшеп сорау бирдем:

– Алга таба ниләр кичердегез?

– Әтине алып киткән теге имансызлар әнине эзләргә керешкән булып чыкты. Мәктәпкә барып сораштырганнар... Күренә-нитә калсак, хәбәр итәргә кушып киткәннәр. Без вакытлыча тукталган хуҗалар да тынгысызлана башлады. Таныш-белешләр сүз берләшкәндәй: «башыгыз исән чакта шәһәрдән чыгып китү кирәк», дип киңәш итте. Кайгы-хәсрәт һәм чарасызлыктан әни берөзлексез елый. Көн дә бүген кайда кунарга икән дип баш ватабыз. Билгеле инде, әни миңа барысын да сөйләп бетермәгән, үзем дә аның итәгенә ябышып, артыннан ияреп йөрүче бер иркә малай гына бит әле. «Китәргә дә китәргә» диләр. Әйтергә җиңел ул. Ләкин менә кая һәм ничек чыгып китәргә, кемгә, кай тарафка – анысын әйтүче юк. Безнең гаиләдә барын да әти хәл итә торган иде бит, әни шуңарга күнеккән...

Көннәрнең берендә тимер юл вокзалы тарафына барып чыктык. Билет алу кая, вокзалга якын килерлек түгел. Кеше өстенә кеше, умарта оясына таяк тыгып болгатканнар, диярсең. Кая карама, анда хәрби конвой, төркем-төркем халыкны куып китерәләр дә каядыр озаталар. Өстәвенә, кассаларда документ тикшерәләр икән... Кире борылып китеп барганда, артыбыздан йөгереп килгән берәү каршыбызга басмасынмы?.. Әни укыткан мәктәпне берничә ел элгәре тәмамлап чыккан укучысы булып чыкты. Исеме белән олылап дәште ул аңарга. Хәлләребезне сораштырды. Ничек булса – шулай, дөресен сөйләде әни үзенә. Ишеткәч, ярдәм итәргә алынды. Ул шушы вокзалда җаваплы урында эшли икән.

– Кирәк-яракларыгызны җыештырып алыгыз да бүген үк төнлә вокзалга төшегез. Ярдәм итәргә тырышырмын, – диде.

Без ул кушканча эшләдек. Һәм караңгы төн уртасында товар вагонында, тактадан ясалган ниндидер тартмалар артына кереп посып, бөтенләй күрмәгән-белмәгән Урал тарафларына китеп бардык...

Казаннан китеп котылдык котылуын, әмма юлда салкын тидеме, вокзалдан вокзалга күчеп йөри торгач, башка бер-бер йогышлы авыру эләктеме, әни авырый башлады. Ятып ял итү, бераз шифалану кая инде ул, башны куеп тынычлап хәл алыр урыныбыз да юк. Ашыйм дисәң, ризык табарлык түгел. Кая барып чыкма, аннан куалар, торыр урының булмагач, эшкә дә алмыйлар. Шулай йөри торгач, әни тәмам хәлсезләнеп егылды. Чиләбенең аръягында урман эчендәге ниндидер бер станциядә тукталган идек. Көннәрдән бер көнне, йогышлы авыру таратып йөрисез, дип, әнине, ай-вайларына колак та салмыйча, ике култыгыннан ике кеше эләктереп хастаханәгә өстерәп алып киттеләр.

– Улым, улым... – дип, ачыргаланып кычкырып нидер аңлатырга теләде кебек әни. Аның сүзләренә колак салучы булмады.

Артларыннан ияреп барганымны күргәч, теге ир-атларның берсе борылып яныма килде дә якамнан тотып күтәреп, шундый итеп типте. Кая барып төшкәнемне хәтерләмим. «Хастаханә» дигәч, күңелгә җылы кергәндәй булды шулай да. Әнине тиз генә, дарулар биреп терелтерләр дә, җибәрерләр, дип өмет иткәнмендер. Япа-ялгызым таныш булмаган бистәнең вокзалы янында урамда торып калдым...

Шуннан күпме генә эзләсәм дә, таба алмадым үзен. «Хастаханә» дигәннәрен дә эзләп таптым, югыйсә. Бер атнага якын аның капкасы тирәсендә буталып, әниемнең чыкканын көттем. Әнине белүче дә, ишетүче дә булмаган. «Йогышлы авырудан үлгәндер», диделәр. Кешедә кеше кайгысы түгел иде, кемнең – кем, кемнең – кайда

булуын белүче дә юк. Безнең кебекләр белән дөнья тулган... Ә үземне, хуҗасыз эт баласыдай, урамда тотып алып ятимнәр йортына илтеп яптылар. Менә шул рәвешле әтисез-әнисез калдым...

– Аңладыңмы инде! – дип, үзе сөйләгәннәрдән дымсулана төшкән һәм тәмам тоныкланып калган күзләрен миңа текәде ул, ниһаять. Әйтерсең, дөньяның шулай буталуында минем дә гаебем бар.

Ул еллар, ул дәвер турында беренче генә кат ишетүем булмаса да, ишеткәннәрдән, телсез-өнсез калып торган чагым иде. Ишеткәнем дә бар, укыганым бар, телевидение һәм киноларда да әледән-әле кабатланып тора ич ул елларда илнең, кешеләрнең башыннан кичкән коточкыч җәбер-золым. Хәтта архивларда өйрәнгәнем булды ул дәвернең кыргый вәхшилекләрен. Әмма боларны искә төшерү яисә сөйләвем белән янәшәмдә утырган картаеп, бөкшәеп беткән карт агайга ярдәм итә ала идемме соң мин?!. Әллә, киресенчә, мәңге төзәлмәс йөрәк ярасына чираттагы мәртәбә тоз сибүче генә булып чыгар идемме?..

– Менә шулай, – дип, янә үзалдына көрсенеп куйды карт. Телемне тешләгәндәй сүзсез калып югалып торуымны сизде кебек ул. Һәм бераздан өстәп куйды. – Ә син миннән чын исемемне таптырасың... Исем кайгысы идемени?..

– Ачуланмагыз, – дип, тынычландырырга тырыштым үзен. – Мин болай гына, үзегезгә, әти-әниегез кушкан чын исем белән эндәшәсем килгәнгә сораган идем.

– «Ятимнәр йорты» дип әйтергә җиңел, әмма анда НКВД нинди тәртипләр урнаштырганын сөйләп кешегә аңлатырлык түгел. Син күз алдыңа да китерә алмассың. Кемнәр генә юк иде анда. Үзара аңлашу һәм мөнәсәбәтләрдә, тел түгел, йодрык хәл итә иде барысын да. Ә мин, әти-әниемнең сөекле бердәнбер иркә малае, урамда үсмәгән, сугышырга күнекмәгән. Кемлегемне, исемемне белеп алгач: «Әй, син, татарчонок!», «чаплашка», «татарская морда» яисә «черножопый» дип кенә сөйләшәләр, аннары тукмыйлар иде... Теркәү вакытында үз исемемне әйттем югыйсә, ә олы бер абзый: «А по-русски как?» дип сорамасынмы. Мин кеше исеменең русчасы-татарчасы барын белми идем, соравына җавап тапмадым. Ә ул күп уйлап тормаган, тоткан да дәфтәренә «Александр Иванович» дип язып куйган. Менә шул рәвешле «Саша» һәм «Александр Иванович» булдым. Чын исем-фамилиямне искә төшермәскә тырыштым, алай гына да түгел, шулай язганнары өчен рәхмәтле дә булып йөрдем әле. Юкса, «халык дошманы калдыгы» дигән ярлык күтәреп, гомер буе газап чигәсем шиксез. Ә ул елларда әти-әниләре кулга алынган балаларны ничек рәнҗеткәннәрен һәм кимсеткәннәрен беләсеңме?!. Үзебез кебек яланаяклы ыштансызлар да мыскыл итте аларны, өлкәннәр һәм түрәләр дә. Кешегә санамадылар, хәрби училище һәм югары уку йортларына алмадылар. Күпме кеше гомерләре буе «кара тамга» белән яшәп, шул тамга белән теге дөньяга китте... Үз башыңнан кичми торып, моны аңлап булмый, әлбәттә...

– Шулай икән, – дидем. Тагы ни әйтим соң?

– Ә син әти-әниең кушкан исем, дисең... Исем кайгысы булдымы бездә?!

Аңладым, төшендем, һәм исем турында сорау кузгатмадым башкача. Кирәк санаса, берзаман үзе әйтер әле, дигән нәтиҗәгә килдем.

– Әниегезнең язмышы ничек булганны ачыклый алдыгызмы?

– Ачыклау кая, шул китүдән, суга төшкәндәй, эзсез-хәбәрсез югалды.

– Ә сез?..

– Мин Саша, Александр булып киттем. Үз исемемне генә түгел, татар икәнлегемне дә оныттым, искә-хәтергә төшермәдем башкача. Һичкайчан, һичбер җирдә, һичкем шикләнмәде, белмәде минем кем булуымны, кайда тууымны. Ике татар сөйләшеп торганын очратканда да аңламамышка салына торган идем. Үзем уйлап тапкан биографиямә шик ташлаучы очрамады, хәтта тора-бара үз ялганнарыма үзем дә ышанып яши башладым. Әмма үз-үземә сүз бирдем, әтием

һәм әнием язмышын, соң булса да, ачыкларга ант иттем. Әти өстеннән шикаять язучыны да ачыкларга кирәк иде бит... Шундый максат белән югары уку йортына кердем, махсус белем алдым. Эшкә урнаштым... Чәчем белән җир себерсәм себердем, әмма максатыма ирештем...

– Ачыкладыгызмы?..

– Әни, әйткәнемчә, эзсез-хәбәрсез югалган булып чыкты. Ничек кенә эзләп һәм эзләтеп тә җеп очын таба алмадым. Тапмадылар... Шифаханәдә архивлар сакланмаган, агач бинада янгын чыккандыр, ахрысы. Кем белә, бәлки үзе дә шунда янып үлгәндер... Кулга алынуы хакында архивларда язу-фәлән калмаган. Менә шулай, кешенең кадере юк иде шул ул заманнарда... – Тирән сулыш алып уфтанып алды ул һәм сүзен йомгаклап куйды. – Хәер, бүген дә кадеребез артты, дип әйтеп булмый торгандыр...

Аңарга ияреп, ирексездән, үзем дә баш кагып куйдым. Әмма башкага кушылып дөньяны сүгү, тормыштан зарлану уема да кереп карамады. Шулчак тел очымда эленеп торган чираттагы сорау чыгып очты.

– Ә әтиегез?

– Аны бер атна эчендә хөкем итеп, атканнар булып чыкты. Кабере юк, Казанда Архангел зиратында күмелгән булса кирәк, диделәр. Архив документларын өйрәнгәчтен генә күзем ачылды. Өстеннән язылган шикаять белән дә таныштым хәтта, – диде ул, һәм тукталып тирән сулыш алды, уйга калып торды бераз. Әйтергәме-юкмы дип, икеләнде булса кирәк. Һәм карашын миңа текәде. – Йә, ул кәгазьне кем язган дип уйлыйсың?

– Мин каян белим... Хәер, үзләре белән аралашып яшәгән берәр бәндә язган булуы ихтимал. Безнең татарда хөсетлек чик-чамасыз ич ул.

– «Бәндә» диеп дөрес әйттең. Теге вакытта безгә килеп, әтинең бар мирасын төяп алып киткән адәм актыгы үзе язган булып чыкты. Аноним түгел, һич яшермичә үз кулы белән язган, каләмен карага манып имзасын, исем-фамилиясен тулысынча теркәп куйган. Кулъязма ачыклаучы белгечләргә биреп тикшерттем хәтта, расладылар. Шагыйрь диген инде шуны, галим диген, ничек җир күтәреп йөртте икән үзен?..

– Килешәм... Мин сезнең белән тулысынча килешәм. Әмма «шагыйрь»ләр бакчасына атылган таш кына менә, ничектер, күңелне тырнап тора. Рифма-ритмга салып язган һәр зат шагыйрь саналырга тиеш түгелдер, минемчә. Шагыйрь ул милләтенең бар кайгы-хәсрәтен үзенеке санап, шуларны үз җилкәсенә күтәрергә сәләтле олы шәхес, сынмас-сыгылмас намуска ия кеше була торгандыр. Тукай, Такташ, Җәлил кебек, мәсәлән...

– Килешәм, – дип күтәреп алды ул шундук һәм шаяру катыш әйтеп куйды. – Синнән дә акыллы сүзләр чыга башлады бит әле. Гади пенсионер дигән буласың тагы...

Шунда гына үземнең, саксызлык күрсәтеп, мавыгып киткәнлегемне аңладым. Үз халәтемне яшерергә тырышу теләгеннәндер, кабалана төшеп, тагы бер кат кабатлансам кабатланганмындыр, сорап куйдым:

– Ул бәндәнең исемен миңа әйтергә ярый торгандыр бит?

– Нәрсәгә кирәк ул сиңа, ташла, – дип, кулын селтәгәндәй итте карт. – Кирәкле кешеләр бу хакта белә, Казан һәм Мәскәү архивларында аның кулы белән язылган дистәләгән шикаятьләр әле дә саклана... Һәммәсенең күчермәләре бар миндә.

– Сез ул архивларга үтә алдыгызмы? Аларга бит теләсә кемне якын җибәрмиләр, – дип, гаҗәпләнүемне белдердем.

– Максат итеп куйсаң, барын да ачыкларга, хәл итәргә мөмкин икән ул. Әйттем ич, мин шактый ук җаваплы урыннарда эшләдем. Архивларга керү минем өчен проблема булмады. Ә менә әтинең тулысынча аклануын озак көтәргә туры килде.

Чөнки үземнең кем улы булуымны һичкайчан һичкемгә сиздермәдем, белдермәдем ич. Читләп, чит-ят белгечләр аша гына эш итәргә тырыштым.

– Төпченүем өчен гафу үтенәм, Александр Иванович, ул адәмнән үч алу теләге тумадымы үзегездә?

– Юк...

– Ул бит җинаятьче, нәселегезнең тамырын корыткан кеше булып чыга...

Ничек җавап бирергә икән дипме, бераз уйга калып торды әңгәмәдәшем, йөткергәндәй итте. Әмма, озак көттермәде:

– Мин уйлыйм, ул болай да тыныч яши алмагандыр. Картайган көннәрендә йокысы тыныч булгандыр, дип уйлыйсыңмы әллә ул бәндәнең?.. Ул үзенә үзе хөкем чыгарган...

– Билгеле шагыйрь, галим булып киткән, дидегез түгелме соң?..

– Галим булмагае, академик булсын!.. Башка берәүләргә яманлык кылган кеше тыныч гомер кичерә, дип уйлыйсыңмы әллә?.. Ишегенә кем дә булса килеп шакыган саен карт күсе сыман сискәнеп куйгандыр, төннәрен куркып уянган, ямьсез төшләр күреп гомере буе саташкандыр, дип уйлыйм мин аны.

Ә мин аның саен әрсезләнүемне дәвам иттем. Ачыклыйсы килә ич, бу минем өчен бик тә мөһим... Хәер, төшенүен төшенәм дә кебек, әмма моны Александр Ивановичның үз авызыннан ишетәсем килә иде.

– Аның исемен әйтегез, зинһар өчен?

– Исемен дә, үзен дә искә аласым килми. Икенче бер вакытта әйтермен, килештекме... – дип, кулын сузды ул. – Вәгъдә...

Килештек. Әмма аның кул бирүе китәргә җыенуы да булган икән, урыныннан күтәрелергә талпынды шунда ук. Култыгыннан тотып, торырга ярдәм иттем үзенә. Рәхмәт әйтте.

– Соңгы соравым, Александр Иванович, – дип, әле һаман да әрсезләнүемне дәвам иткән көнем бит үземнең.

– Тыңлыйм...

– Әти-әниегезне дәүләт куркынычсызлыгы органнары алып киткән. Һәм юк иткән... Аңлавымча, сез үзегез дә шул даирәдә эшләгән булып чыгасыз түгелме?.. Һәрхәлдә, миңа шулай тоела. Башыма сыймый, бу мөмкинме, сез ничек, ни рәвешле сыена алдыгыз алар арасына?

– Башыңа төшсә – башмакчы буласың, диләр. Ишеткәнең бармы?..

– Әйе, бар андый әйтем.

– Мин әти-әнием язмышына бәйле бар сорауга да җавап табарга тиеш идем...

– Таптыгызмы?

– Җавабын таптым табуын. Әмма үзләрен кайтарып булса икән ул... Килешәсең булса кирәк, адәм баласы өчен иң кадерле кешеләр – ул ата белән ана...

– Һәм балалар, әлбәттә! – дип йомгакларга ашыктым.

– Авырткан җиргә тиясең, тукта, – дип, башлаган сүземне тәмамларга бирмәде ул миңа. – Гаилә корып, балалар үстерү бәхетеннән дә ваз кичәргә туры килде миңа.

– Бер тапкыр да өйләнмәдегезме, гаилә кормадыгызмы?

– Баштарак кирәк санамадым. Үземнән дә торгандыр, эшем һәм һөнәрем дә шундыйрак булды. Кыскасы, ялгызым гомер кичердем. Вакыты узгач, соңара төшеп аңладым-аңлавын: үз-үземә бикләнеп йөри торгач, гомер узып киткән булып чыкты.

– Аңлыйм, – дидем. Аңламасам да, шулай дияргә мәҗбүр идем кебек...

Килешүен белдереп, баш кагып куйды ул һәм фикерен дәвам итте:

– Күз алдына китерә аласыңмы, менә минем әти-әниемнең, барып баш иим дисәң, каберләре дә юк бит шушы җир йөзендә. Алар, әйтерсең лә бөтенләй булмаган, тумаган һәм яшәмәгән бу дөньяда, хезмәтләре дә эзсез югалган,

исемнәре дә... Гомеремнең күп өлеше Мәскәүдә яисә ерак чит-ят илләрдә узды. Кая гына барып чыкма, дөньяның күп почмакларына хас булган бер матур гадәт бар, язлар җиткәчтен дә, кешеләр төркем-төркем булып зиратка, әти-әниләре, туганнарының каберләре янына барырга ашыга. Чәчәк куялар, гөлләр үстерәләр... Мин аларны күргән чакларымда ишек бусагасына утырып аз еламадым. Җир йөзендә чарасызлыктан, ятимлектән һәм ялгызлыктан тамган күз яшьләреннән дә авыррак тагы ни бар икән?!. Моны сез белмисез һәм аңлый да алмаячаксыз...

Ни диим, килешүемне белдереп, бер тын дәшми тордым. Әмма дәшми тору бик тә авыр икән бит ул кай вакытларда.

– Димәк, ачыклыйсы сораулар әле бетмәгән... – дидем бераздан.

– Башка һичкемгә, һичбер соравым калмады инде минем хәзер, – диде агай. – Эзләдем, бик күп нәрсәләрне ачыкладым. Җавапсыз калган сорауларым да аз түгел... Кыскасы шул, бу дөнья белән алыш-бирешне мин үзем дә төгәлләдем кебек инде...

– Ә ничек сез шул профессия, шул кешеләр арасында... шул дәүләткә...

– Аңладым, җитәр, ярага тоз сипмә, – дип, чираттагы мәртәбә башлаган сүземне әйтеп бетерергә дә бирмәде ул миңа, кырт кисте. «Шул дәүләткә хезмәт иткәнсез», дип әйтергә теләгән идем. Әмма гаепләп түгел, хәйран калып...

– Дәүләт... дәүләт, – дип, ике-өч мәртәбә кабатлады ул үзалдына. Ни әйтим икән моңарга дип, уйланып та калды кебек. – Ә дәүләтнең монда гаебе юк. Мин үз ватаныма хезмәт иттем, намус белән хезмәт иттем... Куенында үз ватаныңа таш саклап яшәү мөмкин түгел. Килешәсеңме?

– Шул фидакярлекне бәяләүче булдымы соң?

– Бәяләсеннәр өчен, күкрәккә орден-медальләр таксыннар өчен хезмәт итмиләр ватанга. Бу намус эше...

– Намус дигән төшенчәне күпләр онытты да кебек инде, – дип, аның сүзләрен хупларга ашыктым.

– Онытсалар ни эшләтәсең,– диде ул һәм бераз уйга калып торды. – Исләренә төшәр, әмма соң булуы бар... Шулай түгелме әллә?..

Каш астыннан гына миңа сораулы караш ташлап алды ул. Минем фикерне белергә теләве булды, ахры. Килешми чарам юк.

– Шулай, Александр Иванович, байлык дигәндә, Ватанны гына түгел, аналарын да сатарга әзер кешеләр ишәеп китте шул хәзер... Килешәм. Ничек кенә килешәм әле...

– Бу хакта сөйләшү бик авыр миңа, бүгенгә шул урында туктатып торыйк булмаса, ярыймы. Ә хәзер кереп даруларымны эчәргә һәм бераз ятып торырга кирәк. Үз хәлемне үзем генә беләм... – диде ул, кинәт аркасы белән капкага сөялә төшеп.

Күтәрелеп, үзенә карасам, исем китте, әллә кай арада йөзеннән нур качкан, күзләре тоныкланып калган иде аның. Йөрәк «жуылдап» куйды, бер-бер хәл була күрмәсен тагы. Юк-бар сорауларым белән тәмам теңкәсенә тигәнмен түгелме соң?.. Капка келәсендә әлегәчә эленеп торган кучтәнәчне алып картның буш кулына тоттырдым. Һәм якын көннәрдә тагы күрешергә сүз куешып, аерылдык. Гадәттәгечә, үз юлыбыз белән икебез ике тарафка китеп бардык...

## 4

Чираттагы күрешүне озакка калдырасым килмәде, икенче көнне үк аның йорты каршысыннан бер түгел, ике-өч мәртәбә урап килдем. Әмма хуҗа күренмәде. Хасталандымы әллә, дигән шик керде уема, хәтта капкасына ук төртелеп карадым. Капка эчке тарафтан бикле булып чыкты. Киләсе атнада килүемдә дә шул ук хәл

кабатланды. Александр Иванович юк, ә капка бикле. Ни диярга, нәрсә кылырга да белмәссең. Тагы бер атнадан һәм бер айдан соң да очрата алмадым аны...

Тәмам пошаманга төштем: бер-бер хәл булганмы соң әллә?.. Хәтергә төште, почта китерүче һәм кибетчене беләм, дигән иде кебек. Кибет бер өй аша гына, кердем, әмма соравыма җавап таба алмадым. Әллә таныш булмаган кешегә җавап бирәселәре килмәдеме: «Белмибез...» диделәр. Почта ташучы кыз исә ялга китеп барган булып чыкты.

Үкенмәс җиреңнән үкенерсең. Урамга йөрергә чыктыммы, келт итә дә хәтергә Александр Иванович килеп төшә. Урман эчендә башка сукмак һәм башка юл беткән диярсең, тагы шул тарафка тарта аяк. Көтмәгәндә-уйламаганда очрашкан идек, хушлашмый да аерылышкан булып чыктыкмы икәнни?.. Аны очрату түгел, аның хакында бер-бер хәбәр ишетүдән дә тәмам өметем өзгән идем инде.

***

...Күпмедер вакытлар узгач, үзебез яшәгән бистә идарәсенә ут, газ һәм су өчен җыелган бурычларны түләргә килдем. Араны өзеп китеп барганда бистәнең коменданты артымнан йөгереп чыкмасынмы:

– Сез Ринат исемле икән ич...

– Әйе, шулай.

– Без бит сезне байтактан эзлибез.

Сагая төшеп туктап калдым.

– Бер-бер хәл булдымы әллә?

Комендант шактый ук калку гәүдәле, таза ир уртасы кеше. Миңа аның отставкадагы хәрби офицер булуы да мәгълүм. Дөресен әйтергә кирәк, очраганда бер-беребезгә баш кагып уза торган булсак та, якыннан танышырга, аралашырга туры килгәне юк иде моңа кадәр.

– Сез Александр Ивановичны беләидегезме? – дип сорап куймасынмы шунда.

Кулымдагы кәгазьләрне төшереп җибәрә яздым. Димәк, минем танышым һәм якташым Александр Иванович белән нидер булган.

– Беләидем. Ә ул кайда, соңгы араларда бер дә күренми башлады? – дип, тәкатьсезләнеп, соравына сорау белән җавам кайтардым.

– Ике атна чамасы элек аны соңгы юлга озаттык.

Колагым ишеткән сүзләрдән башым әйләнеп китте, бер мәл ни диярга белми, телсез калып тордым. Әмма үземне кулга алырга тырыштым.

– Ә ул инде байтактан күренми иде кебек...

– Хастаханәдә иде, Кремль хастаханәсендә, шунда китеп тә барган...

– Кайгыртучы, янында караучысы да булмагандыр. Озатучы булдымы икән, соңгы юлга, дип әйтәм...

– Ничек булмасын, Александр Иванович сугыш ветераны, бик күп орденнар кавалеры... Шуның өстенә – генерал да иде бит әле ул. Гади генерал гына түгел, – дип, тирән итеп сулыш та алып куйды тагы. – Мин үзем дә белми идем, гаҗәп кеше булган. Легендар... Хәрби оркестрлар белән, олылап Троекуров зиратына күмделәр үзен.

– Яхшы булган, – дидем, колагым ишеткән яңалыкларны күптән белгән атлы булып. – Ул зур хөрмәткә лаек кеше иде шул...

– Ничек кенә әле, – дип, комендант та хуплап куйды үземне. Сер бирмәдем, димәк. Инде сораштырырга форсат чыкты кебек.

– Ә сез аны яхшы беләидегезме? – дип сорадым, җай чыгудан файдаланып.

– Беләидем. Бик яхшы кеше иде. Әмма якыннан аралашканыбыз булмады. Ул, гомумән, кешеләр белән бик аралашмый иде кебек. Разведкада һәм контрразведкада эшләгәннәр шундый була бит. Өенә кеше-фәлән чакырмады,

ялгызлыкны яратты күбрәк. Аннан бит, яшь ягыннан да, дәрәҗәсе белән дә ул бик зур кеше иде...

Ә мине һаман үз сорауларым кытыклап тора, шуларга якынлашу бар теләгем.

– Ә ул кайсы милләттән иде соң? – дигән сорау чыгып очмасынмы шунда авызымнан.

– Рус кешесе, әлбәттә, чын рус каһарманы... Әмма, белмим ни сәбәпле, чиркәүгә йөрмәде ул. Күмгәндә дә дин әһелләре чакырмаска, кабер ташы өстенә дә тәре түгел, урак-чүкеч һәм йолдыз рәсеме куярга васыять итеп калдырган. Чын совет генералы...

– Анысы шулай, – дидем, боларның барысын да белгән атлы булып. Ә үзем балтасы суга төшеп җуелган кеше хәленнән чыга алмыйча аптырыйм.

– Сезне туктатуымның сәбәбе бар, – дип аңлатырга кереште комендант. – Александр Иванович бер конверт калдырган, аның тышында «М.Ринатка» дигән сүздән башка һични язылмаган. Ничә көн инде кемгә икән диеп баш ватабыз, фамилия-фәлән юк. Ә келәйләнгән конвертны ачу уңайсыз. Анда ни булмас... Фамилиягезнең баш хәрефе дә туры килә, димәк, ул сезгә булып чыга,– дип, конвертны миңа сузды комендант.

– Әйе, миңа, – дип, кулыма алдым конвертны. «Ул минем фамилиямне белми иде шул», дип әйтергә кыймадым. Хәер, нигә белмәскә, ачыклаган булып чыга... Хатны кеше алдында ачып тормадым, җәт кенә куен кесәмә шудырдым да рәхмәт әйтеп, бик эшлекле кыяфәт белән юлымны дәвам иттердем.

***

«Ул хатта ниләр язылган иде соң?» дип кызыксынадыр укучы.

Нибарысы дүрт-биш җөмлә. Һәм мине аеруча хәйран калдырганы тагы шул: хат саф татар телендә иде. Ышанасызмы-юкмы, бер хатасыз язылган:

«Кызганыч, мин менә хастаханәгә килеп юлыктым бит әле. Моннан чыгарга язгандырмы-юкмы, әйтеп булмый. Сезнең белән тагы бер тапкыр гына булса да күрешеп сөйләшкәндә дә яхшы буласы иде дә бит... Бик әйтәсем килеп тә әйтергә өлгермәгән сүзләрем калды. Ходай ни кушкандыр, алдагысын белеп булмый. Бер серемне ачам шулай да, мин беренче очрашуыбыздан соң ук сезнең кем икәнлегегезне ачыклаган идем. Казан турында, язучылар турында әйткән сүзләрем өчен, зинһар, миңа үпкәли күрмәгез, кичерегез. Сезне кузгатыр өчен, сынау максатыннан махсус шулай сөйләштем. Нишләтәсең, бу минем профессиональ авыруымдыр инде. Ә теге «бәндәнең» исемен сез үзегез дә чамаладыгыз булса кирәк. Әйе, аның исеме «Нәкис».... Шәрехләп тору кирәкмәстер, сезгә таныш кеше, шулай бит?!.»

Үз күзләремә үзем ышанмыйча югалып калдым башта. Аннан эсселе-суыклы булып китте, тәнемнән бер оя кырмыска чабышып үткәндәй булды. Баш түбәмдә калган санаулы гына чәчләрем дә үрә торып баскан иде булса кирәк... Хатның кайбер юлларын, нәрсәләрнедер ачыкларга теләп булса кирәк, кабат-кабат укыдым...

## ИКЕНЧЕ ТАРИХ

### 1

Кечке ашны ашап, чәйләр эчкәчтен, көндәгечә, эш өстәле янына барып утырды Җамал Вәлиди. Аның хәзер кырыкмаса кырыкка ярылыр чагы. Көнчыгыш педагогия институтында алдагы атнадан «Татар теленең тарихы» дигән яңа фән укыта башлаячак. Үзе өчен бик тә якын һәм көтеп алынган фән. Шулай булуга да карамастан, беренче лекция беренче инде, махсус әзерләнергә туры

килә. Җаваплылык та зур, дулкынлану да бар. Аннан бит әле беренче лекциягә Республиканың мәгариф өчен җаваплы җитәкчеләре һәм соңгы арада бик тә активлашып киткән дәүләт куркынычсызлыгы оешмасыннан да вәкилләр килүе ихтимал. Соңгылары татар тарихы, аның әдәбияты һәм теленә кагылышлы бер генә вакыйганы да игътибарсыз калдырмыйлар бу араларда. Өстәвенә, тагы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нең икенче томы корректурасын карап, төзәтмәләр кертеп чыгасы бар. Ашыктыралар... Галимҗан Ибраһимов эшчәнлеге хакында әдәби тәнкыйть мәкаләсе язырга алынган иде, аны да көтәләр булса кирәк, сузарга ярамый. Моннан байтак еллар әүвәл, академик Бартольдның «Кыскача ислам мәдәнияте тарихы» дип исемләнгән хезмәтен тәрҗемә итеп бастырган иде ул. Китап матбугатта югары бәя алды һәм бик тиз таралып бетте. Әмма, ни өчендер, шул китап уңае белән соңгы араларда шактый тәнкыйть сүзләре ишетергә туры килә иде аңарга. Югары органнардан да кызыксынучылар бар кебек. Эшне зурга җибәрмичә, үз вакытында, шул язмаларга да вакытлы матбугат аша җавап бирү кирәк иде. Бу эшне дә озакка сузу ярамас. Татар халкының мәкаль һәм әйтемнәрен дә туплап чыгарыр вакыт җитте кебек. Табышмаклар, кыска җырларны да озак сузу ярамас. Һәммәсе дә, әнә, эш өстәлендә, аның шүрлекләрендә тау-тау өелеп, чират көтеп ята. Яңа чыккан газета һәм журналларны да карап, күз йөгертеп кенә булса да укып, танышып бару кирәк. Институтта көннең ничек узып киткәнен дә абайламый кала, өйдә дә күпме эш көтеп тора үзен. Вакытны гына ничек җиткерәсе...

Ә шулай да һәммәсенә өлгерергә кирәк. Эш күп булудан зарланалар димени, эшсезлектән изаланырга язмасын... Балалар өчесе дә әниләре белән чаршау артында. Алар да囗 эштә, дәрес хәзерлиләр. Йоклар вакытлары да җитә булса кирәк инде. Аны эшеннән бүлдермәс өчен аяк очына гына басып йөргән хатыны Ләйлиҗиһан әледән әле «т-с-с-т-с-с» дип, аларны тавышланмаска чакырып тора.

Ниһаять, инде җиң сызганып эшли башладым дигәндә генә тышкы яктан кемдер килеп ишекләрен шакымасынмы.

– Вакытлы вакытсыз кем йөри инде тагы... – дип, аны Ләйлиҗиһан барып ачты. Ишек төбенә килгән кешене кире борып булмый, керергә чакырды үзен.

Вәлиди, эшеннән аерылырга теләмәсә дә, керүченең сүзләренә колак салмый булдыра алмады:

– Соңлап йөрүем өчен, гафу итегез, Җамалетдин абзый, мин сезнең янга килгән идем.

Вакытсыз йөрсә дә, көткән кешесе булмаса да, урыныннан тормый гына ишеккә таба борылырга мәҗбүр булды галим. Егерме биш-утыз яшьләр чамасындагы бу кеше соңгы араларда аның күзенә бик еш ташлана башлаган иде. Юк эшен бар итеп институтка да кереп чыкканы бар. Танышканнар да иде кебек хәтта, әмма исеме хәтердә калмаган. Башкорт якларыннан килгән булса кирәк, мөгаллимлек итә икән.

– Ә-ә, син икәнсең әле, – дип, торып, килүчегә ике кулын сузарга мәҗбүр булды галим. Урындык тәкъдим итте үзенә. – Йә, ишек тупсасында басып торма, кил, түрдән уз. Безнең якларга нинди җилләр ташлады үзеңне?

– Эштән бүлдереп йөри дип, берүк ачулана күрмәгез инде, Җамалетдин абзый, – дип, бик тә итагатьле итеп башлап китте ул сүзен. – Киңәш-табыш итү өчен сездән дә игелекле кеше булмаганга килергә мәҗбүр булдым яныгызга. Зинаһарлар өчен, гафу итә күрегез, Җамалетдин абзый...

– Сөйлә, тартынма, ни булды тагы? – дип, кулына алган китабын кире өстәлгә куйды Вәлиди. – Утыр. Җитди сүз аягүрә сөйләшенмәс...

– Рәхмәт, Җамалетдин абзый, сез миңа һәрчак ихтирамлы булдыгыз. Әдәбият дөньясында яше-карты сезгә рәхмәтләр укып яши. Кая барма, шунда мактау

сүзләре белән искә алалар үзегезне. Тукайны яклаган, Фатих Әмирханны һәм Ибраһимовны күтәргән кеше ич сез. Сездәге кайгыртучанлык, ярдәмчеллек җитми шул бик күпләргә...

– Ярар, ярар, мактау сүзләрен калдырып тор әлегә, – дип бүлдерергә кирәк тапты ул аны.

Ялагайлык һәм хөсетлекне җене сөйми югыйсә, шулай да килүченең әлегедәй төче сүзләрен бу очракта колак читеннән уздырды Вәлиди. Тәрбия эше белән шөгыльләнер вакыт түгел.

– Мин уйлаганымны сөйлим, Җамалетдин абзый. Сез бит... Сез бит бүгенге татар дөньясында сирәк очрый торган асыл затларыбыздан...

– Ярар, бу кадәресе аңлашылды... Инде без – татар зыялылары – бер-беребезгә ихтирамлы булмасак, бер-беребезне кайгыртып, үзара ярдәмләшеп яшәмәсәк, безне кем кайгыртыр соң? Йомышың бар идеме? Булса, сөйлә.

– Алай да сез бар әле Казанда. Кешеләр бит үз-үзләренә бикләнде, аралашмас булды. Юкса, Җамалетдин абзый, кем янына барып, кемгә сөйләр идек борчушатлыкларыбызны.

– Йә, тыңлыйм үзеңне...

– Килүемнең сәбәбе шул, Җамалетдин абзый... Мин бит, белмисездер, мулла нәселеннән. Әтием, бабам мулла булган... – дип башлады ул сүзен.

– Ата-ананы сайлап алмыйлар. Ә мулла малае булуы оятмыни? Киресенчә, горурланырга кирәк. Муллалар начарлыкка өйрәтмәде халыкны. Гыйлемгә, әдәп вә инсафлылыкка өндәде алар. Барыбызның да иң әүвәлге остазларыбыз мулла булды.

– Шулаен шулай да бит... Кемдер менә минем мулла нәселеннән икәнлегемне органнарга җиткергән. Чакырта, сораштыра башладылар. Төпченәләр... Куркыталар... Бу бер дә яхшылык белән тәмамланмас төсле, Җамалетдин абзый. Эшсез йөрүемнең дә сәбәбе шуннан дип беләм. Редакцияләргә якын җибәрмиләр. Киңәш итегезче, ни эшләргә, ничек котылырга бу бәладән?

– Әтиеңнең мулла булуы бәламени?

– Шулайрак килеп чыга шул.

– Тынычлыгың саклау кирәк, – диде Вәлиди, эче пошкангамы, тирән сулыш алып куйгачтын, – гаепсез кешегә тимәсләр. Аннан, шигырьләреңдә дә син бит алай мөгез чыгармыйсың кебек соңгы араларда.

– Әллә укыдыгыздамы, Җамалетдин абзый?

– Кулга кергән китапны уку кирәк, кардәшем, укыдым...

– «Җидегәнче»ләр белән араны өздем бит мин хәзер, – дип, кош тоткандай, яңалыгы белән уртаклашырга ашыкты килүче. – Җидегәнчеләрне, беләсездер инде, күптән туздырдылар, кайсы кая китеп, аеры-чаеры таралып беттеләр.

– Араны өзеп дөрес эшләгәнсең. Шигырьне бит төркемнәр түгел, аерым шәхес иҗат итә. Кулына каләм алып шигырь язарга алынучыны мин илаһи бер зат итеп күрәм.

– Җамалетдин абзый, сез Тукайның үзе белән аралашып яшәгән кеше, килүемнең сәбәбе башка, әмма сорамый кала алмыйм: шигырь нинди булырга тиеш соң ул? Сезнең фикерне белү бик тә кызык булыр иде... Мине мактап матбугатта бер-бер мәкалә дә язып бастырмассызмы икән? Вәт, булыр иде ул вакыйга-а...

– Ул кадәресен вәгъдә итә алмыйм әлегә. Ә менә шигырь хакындагы соравыңа килгәндә, анысы да җиңелләрдән түгел, әлегәчә төгәл генә һичкемнең җавап бирә алганы юктыр моңа.

– Ә шулай да?

– «Шигырь – ул нәрсә», дип кат-кат үз-үземә сорау биргәнем бар. Әмма, кистереп кенә җавап бирә алмыйм. Шулай да, шигырь – мәхәббәт авазы түгелме... Ничек уйлыйсың?

– Матур әйттегез: «Мәхәббәт авазы түгелме?..» Шәп бит, шәп! Ә безнең «җидегәнче»ләр нинди генә мөгез чыгарып карамады.

– Әйе, мөгезне чыгарып күрсәттегез. Арагызда сәләтлеләр дә бар кебек, миңа калса. Мисал өчен, Гадел Кутуйны искә алырга мөмкин. Сәйфи Кудаш атлы егетнең дә үз тавышы бар кебек. Кемнең кем буласын, алдагы көннәрдә кем каләме ни юнәлештә үсеп китәсен алдан әйтеп булмый, әлбәттә. Ә шулай да күпчелеге, мин әйтер идем, «тыкы-тыкы, каты-коты...» язалар төсле.

– Сез әйткәнчә, Җамалетдин абзый, мин инде хәзер мөгез чыгармаска да тырышам, тормыш өйрәтә икән ул.

– Дөрес әйтәсең, тормыш өйрәтә. Чыгымлый башласаң, шундый иттереп китереп суга ул...

– Бүген яныгызга килүем дә, Җамалетдин абзый, шул уңайдан иде бит. Тормыштан зарланып килдем. Әтиемнең мулла булуы кара койрык сыман артымнан ияреп йөри һаман. Уфадан качып чыгып китүем дә шуның аркасында булды. Казан еракта, бәлки онытырлар, кызыксынмаслар, белмәсләр дигән идем.

– Белсәләр, ни булган? Син беренчесе һәм соңгысы түгел. Бик күпләребезнең ата-бабасы мулла. Булса соң, гаепмени?..

– Гаеп булмаса да гаеплиләр бит менә.

– Дөнья булгач, гаепләүләр дә булыр. Татар булган өчен дә гаепләгәннәр, динебез ислам булган өчен дә. Нишлисең, барыбер яшибез бит әле менә... Башка суктылар дип тормыйбыз, күтәреләбез, калкабыз. Республикалы да булдык кебек, әнә...

– Ярый да сез мулла нәселеннән түгел?..

– Анысы ни дигән сүз тагы...

– Сезне ярлы крәстияннардан дип ишеткән идем. Дөрес түгелме әллә?

– Кем әйтте сиңа? Ата-бабаларымнан баш тартырга җыенганым юк әлегә. Тәтеш-Апас якларында минем ата-бабамны белмәгән, танымаган кеше бармы икән?.. Аларның укымышлы кеше – мулла булулары да сер түгел. Мин моны һичкемнән яшермәдем, уема да кереп караганы юк. Киресенчә, ата-бабам белән, аларның мулла булуы белән горурланып яшим.

Колагы ишеткәнгә бик нык гаҗәпләнгәндәй кыланды соңлап килгән кунак. Югыйсә, ул бу хакта хәбәрсез түгелдер... Үзенә күрә, сынап каравы иде кебек...

– Бә-ә-әй, – дип сузды ул, – һич ялгансыз менә, иманым камил, мин сезне чын-чынлап ярлы мужик нәселеннән дип йөрим тагы.

– Ишеткән булсаң – яхшы. Анкета һәм тәрҗемәи хәлгә «ярлы крестияннардан» дип язу модага керде ич хәзер. Кемдер язган икән, язсын... Үзем ялган-йолган белән көн күрмәдем. Сораганга горурлык белән җавап бирдем: «Әтием һәм җиде буын бабам мулла булган!»

– Сез дә мулла нәселеннән, димәк. Менә ничек, бу минем өчен яңалык бит әле, – дип, куанып куйгандай итте кунак.

– Шуны ачыкларга килмәгәнсездер ич!.. – дип, сүзне кыска тоту ягын кайгыртты Җамал Вәлиди. Сүз булмаганда сүз булсын, өч көн үткәч, исәнме кодагый, дип утыра торган вакыт түгел. Стенадагы күкеле сәгать тә әнә шул хакта искәртеп алды. – Миннән нинди киңәш сорыйсыз инде?

Җәелеп китеп сөйләшергә җыенган иптәш өчен хуҗаның сүзне коры тотуы көтелмәгән иде кебек. Сизгер булып чыкты үзе, аңлады. Уңайсызлануданмы, әллә үчләшү яисә ачуы чыгудан, ике бит алмасы кызарып чыкты аның кинәт. Күзләрен челт-мелт йомгалап алды һәм тешләрен кыса төшеп дәвам итте.

– Өч улым бар. Берсеннән-берсе кечкенәләр әле. Хатын эшләми. Казанда кардәш-ыру, туган-тумачаларыбыз юк, Җамалетдин абзый. Икебез дә башкорт

якларыннан бит без. Эшсез йөрү бик тә авыр, бер-бер ярдәм күрсәтмәссезме, дип килгән идем.

– Мөгаллимлек итәм, дисең түгелме?

– Итә идем дә бит, эшләгән җиремнән җибәрделәр...

– Эшсез калгансың, димәк... Эш белән ярдәм итәргәме? Эш табу җиңел түгел шул хәзер...

– Эше дә кирәк инде... Аннан бераз... сорарга да уңайсыз, теге ни, Җамалетдин абзый...

– Акча кирәкме?

– Әйе-әйе, акча булмасмы дигән идем... – Һәм бертын дәшми торгачтын, кабалана язып тәгаенли төшәргә кирәк тапты. – Бурычка... бурычка соравым, әлбәттә, кайтарып бирү шарты белән.

Бу очракта нидер әйтүне кирәк тапмады Вәлиди, утырган урынында ипле генә борыла төшеп, янәшәдәге өстәл тартмасына үрелде. Ачты. Һәм аннан бер төргәк акча чыгарып аны каршысында торган кунакка сузды.

– Менә, минем бер айлык мәгышем шушы. Бәхетең, бүген эш хакы алган көнебез иде. Кирәк кадәрен ал.

Әйтелгән сүзгә колак салмавы яисә ишетмәгәнгә сабышуы булдымы, уңайсызланып яисә тартынып та тормады теге, педагогия институты доцентының бер айлык хезмәт хакын санамый-нитми генә үзенең куен кесәсенә шудырды.

– Рәхмәт, – диде диюен, һәм урыныннан сикереп үк торды. – Хәзер кайтып китсәм дә була. Хатынны һәм балаларны шатландырырга кирәк.

Ачкан авызын йомарга онытып, тегенең кыланышларын ничек бәяләргә белми, бер тын исе китеп карап торды Вәлиди.

– Ә эшнең кирәге калмадымы инде? – дип искәртергә мәҗбүр булды, ниһаять. Килүченең кош тоткандай куануы һәм кабалануларына хәйран калган иде ул. – Кешедән алган акча тиз бетүчән.

– Оныта язганмын бит... Әллә эш белән дә ярдәм итәсезме?

– Мулла нәселеннән булгач, ярдәм итми ярамас, – дип шаярткан атлы булды Җамал Вәлиди. – Менә, ике данә «кемлек кәгаземне» бирәм үзеңә. «Спартак» аяк киемнәре фабрикасына, аның директоры янына кер. Шушы «кемлек»не бир һәм аңлат. Ул сиңа ярдәм итәргә тырышыр. Булмаса, ерак түгел, әнә Әтнәгә дә барып кайт. Анда мәгариф бүлегенә керерсең һәм Гарифҗан исемле агайны сора. Ул һичшиксез ярдәм итәр, соңгы күрешүебездә «Тел һәм әдәбият укытучылары кирәк» дигән иде. Миннән сәлам күндерергә дә онытма үзләренә. Булдымы?..

– Булды. Ничек кенә булды әле, – дип, хушлашмый, рәхмәтен әйтергә дә онытып чыгып йөгерде теге. Тупсаның аргы ягына чыккачтын тавышы тагы да көррәк яңгырады. – Бер вакыт табып тагы киләм әле яныгызга, ярыймы, Җамалетдин абзый, сорауларым бик күп сезгә. Рәхәтләнеп сөйләшеп тә утырасы килә. Шигырьләр дә укырмын үзегезгә... Мине мактап мәкалә дә язарсыз әле бәлки, шулай бит, Җамалетдин абзый...

Егет шактый әрсез һәм бәйләнчек булып чыкты бит әле. Моңарга ирек куйсаң, башыңа менеп утырырга да күп сорамас. Әмма шигырь язучының теләкләренә каршы төшәсе яисә үзенә каты бәреләсе килмәде әлегә. Сабыр төбе – сары алтын бит ул.

– Ярар, килерсең, укырсың, дими, ни әйтәсең тагы...

**2**

Чакырылмаган кунак чыгып киткәчтен дә чаршау артыннан хатыны Ләйлиҗиһан килеп чыкты. Ишекне бикләп килде иң элек. Аннан аяк очларына ипле генә басып ире янына якынлашты, җылы йомшак кулын аның җилкәсенә салды.

– Бер дә тынычлап эшләргә бирмиләр үзеңә...

– Нишлисең, килгән кешене борып чыгарып җибәреп булмый шул.

– Эш урынында очратса да яраган бит... Якының, туган-тумачаң түгел. Кеше өенә шушы вакытта килеп керергә...

– Анысы шулай, әмма институтта да тоту җиңел түгел шул мине. Берөзлексез лекцияләр, студентлар, яшь галимнәр... Килүче-китүчедән дә өзелеп торган юк. Һәркемнең үз соравы, үз мәшәкате дигәндәй... Милли әдәбият өлкәсендә, фәндә шактый ук җанлану сизелә соңгы араларда.

– Бу кеше бер дә ошап бетми миңа, Җамалетдин. Син ни диярсең?..

– Хикмәт ошату-ошатмауда түгел, кадерлем. Башка барыр җире, ярдәм сорар кешесе булмаганга килгән бит, рәхәт тормыштан түгел.

– Бирәүгә дә җиңел түгел инде, – дип сузып куйды Ләйлиҗиһан. – Акча сораучылар күп булыр ул, акча бирәүгә дә җитми. Әнә, Искәндәр белән Ибраһимның да алмашка күлмәкләре юк. Әминәнең аяк кабы тузып беткән. Синең хезмәт хакыңны көтеп дәшми йөри идем...

– Боерган булса, киләсе айда алырбыз. Дөрес сөйлисең әнисе, балаларны кимхур йөртергә ярамас.

– Бу айда булмасмы?

– Бу айныкы бетте, китте шул инде, аппагым.

– Барысын да бирдеңме?.. Кешегә әйтсәң, кеше ышанмас. И-и-и, Җамалетдин, бигрәкләр дә беркатлы һәм юмарт инде үзең. Хәтерлисеңдер, безнең Апас якларында синең кебекләр турында «ыштансыз да соң» дип әйтә торганнар иде.

Хатыны әйткән комплименттан күңеле булып, рәхәтләнеп бер көлеп алды Җамал Вәлиди.

– Кемнән-кемнән, синнән бу тикле дә җылы мактау сүзе ишетермен димәгән идем, Ләйлиҗиһан. Кил әле, шуның өчен үзеңне бер кочыйм әле, – дип, кулыннан тотып тезләре өстенә тартып утыртты ул аны. Чәчләреннән сыйпап бит уртасыннан үбеп алды.

Хатын-кыз барыбер үзе булып кала. Иренең җилкәсенә башын куеп, беркавым иркәләнгәчтен, сүзен дәвам итте:

– Белгән кешеңмени, исеме ничек соң аның?.. Теге әле генә китеп барган ыспай егетне әйтәм...

– Исемен хәтерләмим, танышкан да кебек идек, онытканмын. Шигырьләр яза дип беләм, яшь булуына да карамастан, гаиләсе зур икән, өч улым бар, диде, әнә...

– Бик төче телле һәм елгыр күренә үзе... Бер дә кыенлыклар кичергән кешегә охшамаган.

– Ярар, җанкисәгем, башка кайгың булмаса, оныт аның турында. Килештекме...

– Син әйткәч, килешми кая барасың. Хәерлегә булсын инде, Җамалетдин, – дип, ирен тынычта калдыру нияте белән, торып китәргә җыенды хатын.

– Алай ашыкма әле, аппагым, – дип, кочагыннан ычкындырмый торды аны Җамал. – Балалар ничек соң, дәресләрен хәзерләп бетерәләрме инде? Рәхәтләнеп сөйләшеп тә утыра алганым юк бит. Алай да син бар күз-колак булырга...

– Искәндәр олыгаеп китте соңгы арада, өй эшләрен дә үзе башкарып чыга. Мөстәкыйль булырга тырыша. Минем киңәшләргә мохтаҗлыгы юк. Укытучылары да мактап бетерә алмый. Математика һәм төгәл фәннәрне бик ярата, шул юлдан китәр төсле... Ибраһим күбрәк синңа охшаган, берөзлексез укый, китаплардан аерып булмый. Әтисе юлыннан китәр төсле, тарих һәм әдәбиятка кагылышлы китап күрсә, дөньясын оныта. Аннан, сүз тыңлаучан тагы, «нинди эшең бар, әни» дип сорап кына тора. Балалардан зарланырлык түгел анысы.

– Ә минем татлы кызым Әминә ничек?

– Әминә бала гына шул әле. Бик шук, кайчак холкын да күрсәтеп ала. Башы

эшли үзенең һәм бик кызыксынучан. Абыйларына да, миңа да берөзлексез сораулар яудырып кына тора. Җавап бирми торып, котылам, димә...

– Бу бит яхшы, аппагым. Аның яшендә шуклык һәм җорлык бик яхшы күренеш. Шул сыйфатларга дөрес юнәлеш күрсәтә белү генә кирәк. Шулай түгелмени?..

– Хәерлегә булсын инде, кыз балага бераз тыйнаклык турында да онытмаска иде дә.

– Сабый гына бит әле... Барысының да үз вакыты бар. Тыйнаклык та ерак йөрмәс, боерган булса. Исән-сау гына булсыннар берүк.

– Ә син һаман эштә. Көн дип белмисең, төн дип белмисең, кайчан карама шул китап һәм язуларың өстендә. Йокың да юк, ялың да. Бераз һавада йөреп керсәң, ял итеп алсаң да ярар иде дә, – дип, кайгыртуын белгертергә кирәк санады хатын. Бу аның күптән күңелендә, тел очында булып та, шул көнгәчә әйтергә форсат таба алмый йөрткән сүзләре иде.

– Һәрнәрсәнең үз вакыты була, ял да итәрбез, аппагым. Быел җәен, боерган булса, балалар белән бергәләшеп, туган якларга кайтып килербез. Зөя суларында йөзеп, тау итәкләрендә җиләк җыеп, Апас урман-кырларының саф һавасын сулап гизеп йөрербез. Үзебез дә ял итәрбез, балалар да... Туып-үскән якларны һич онытырга ярамас, балалар да нәсел-ыруның тамыры, чишмә башы кайда икәнлекне күреп үссеннәр... Килешәсеңдер ич?

– Килешү генәме! Тик менә син шулай дисең дә бит, соңыннан бер-бер эш йә мәшәкатең килеп чыга тора. Ел да хыялланабыз шул хакта... Тормышка гына ашыра алганыбыз юк.

– Быел, боерган булса, вәгъдәмне бозмам. Үзем дә сагындым, бик сагындым туып-үскән Апас тарафларын...

– Мин бик риза да. Синнән тора, синең вакытыңнан, Җамалетдин.

– Сүз бирәм, кайтабыз дигәч кайтабыз быел туган якларга.

Әле һаман иренең тез өсләрендә утырган хатын сәгатькә күз төшереп алды шунда. Чаршау артында калган балаларның, Ибраһим белән Искәндәрнең, нидер бүлешә алмыйча бәхәсләшеп алулары да сүзне йомгакларга этәрде.

– Ярый, мин китим инде... Балаларны үз вакытында йоклатасы да бар. Ни гомер сине эшеңнән бүлдереп утырам икән бит, – дип, ипле генә урыныннан торып чаршау артына кереп югалды Ләйлиҗиһан.

Җамал Вәлиди, ниһаять, эш өстәленә борылды. Тау-тау өелеп торган китаплар, таралып яткан кульязмалар – һәммәсе аның игътибарын көтә. Дөньясын онытып туган тел һәм әдәбият дөньясына кереп чумды ул. Авыр, әмма милләт өчен, үзен шул милләттән санаган һәр адәми зат өчен соң дәрәҗәдә мөһим һәм үтә кирәкле булган хезмәт. Бу эшкә бары күңеле саф, җаны изгелек һәм игелектә булган асыл затлар гына алынса кирәк. Халыкның дәвердән-дәверләргә күчеп туплана торган рухи һәм әхлакый мирасын үз акылы һәм йөрәге аша кичереп, килер буыннарга түкми-чәчми тапшырырга алынган затларның берсе ич ул. Ходай биргән һәр көн, һәр сәгать һәм минутның кадерен белеп эшләргә туры килә...

**3**

Көндәлек эш һәм мәшәкатьләр белән көн арты көн, ай арты ай үтә торды. Әмма вакыт заяга узмый. Эшләгән эш нәтиҗәсез калмый. Татар теленең ике томлык аңлатмалы сүзлеге үзен зыялы санаган һәр татарның китап киштәсендә тора хәзер, «Коръән» белән янәшәдә. Хәер, изге «Коръән» китап киштәләреннән сандыкларга яшерелә, мендәр асларына күчә башлады бит әле соңгы араларда. Хакимият башында утыручылар дошман арты дошман эзли, дин әһелләре, муллалар белән көрәшә, изге китаплар белән булыша башладылар. Мәчет манараларын аударырга-җимерергә җыеналар икән, дигән

сүзләр дә йөри. Халыкның эчен шул пошыра, шундый хәбәрләр тынгылык бирми...

Казан, Ырынбур һәм Уфада татар телендә чыгып килүче әдәби һәм гыйльми журналлар Җамал Вәлиди хезмәтләрен зарыгып көтеп ала, ә укучылар тарафыннан исә ул мәкаләләр вакыйга буларак кабул ителә. Көнчыгыш педагогия институтында аның лекцияләренә студентлар гына түгел, яшь галимнәр, әдәбият-сәнгать тирәсендә кайнашкан иҗат әһелләре һәм белгечләр төркем-төркем килә тора.

Кичкырын Казанны кыл урталай бүлгән Болак читләп өенә кайтырга чыга ул. Кулында таушала төшкән күн портфеле, башында кара эшләпә. Үз-үзен тотышы, кием-салым һәм тышкы кыяфәте белән гавамнан аерылып торуны өнәмәсә дә, әллә каян күреп, танып алалар аны. Узып киткәчтен әледән-әле артыннан чыш-пыш килеп: «Әнә, Җамал Вәлиди шул була инде...» дип, бармак төртеп күрсәтеп калуларга да күнеккән. Юлына каршы чыгып, юк сорауны бар итеп, сораштыручыларга да исе китми. Сәлам бирүчегә сәлам кайтара, сорау белән килүчеләрне игътибар белән тыңлый һәм тәфсилләп җавап бирә. Әдәбият һәм сәнгать белән кызыксынган, милли тарихка битараф булмаган замандашлары һәм милләттәшләре артканнан-арта баруга сабыйларча ихлас куана ул...

Кабан күленә чыгучы тар тыкрыкларның берсендә урнашкан ике катлы агач йортның югары катында урамга караган ике тәрәзә булыр. Тәрәз төпләрендә гөлләр, алар һәр заман чәчәктә. Шул гөлләр артында аның эштән кайтуын зарыгып көтеп торучы күзләр булыр. Ул күзләр аның сөекле кызы Әминә яисә уллары Ибраһим белән Искәндәрнеке. Әтиләренең кайтыр вакыты якынлаша башлагачтын да, алар, алмашып, тәрәзә төбендә аны көтәләр. Һәм куанычлы хәбәрне, үзенә күрә сөенчене, беренче булып әниләренә җиткерергә ашыгалар...

Кабан күле читләп сузылган урамнан килеп, үз тыкрыкларына борылгач та алсу һәм ак чәчәкле гөлләр белән әллә каян балкып торган тәрәзәдән аңарга кул болгадылар. Кызы Әминә өлгер булып чыкты – димәк, сөенче аныкы.

Үз тупсаңны атлап җылы өйгә килеп керүгә, синең өчен иң кадерле кешеләрнең көләч елмаеп каршы алуына ни җитә. Гаилә бәхетен аңлый һәм кадерли белгән кеше өчен моңардан да зуррак тагы нинди куаныч булуы мөмкин?! Колачларын җәеп йөгереп килгән кызы кай арада аның муенына менеп сарылыр, уллары Искәндәр белән Ибраһим да бер-бер артлы ипле генә килеп әтисенең күкрәгенә сыенырлар. Ә Ләйлиҗиһан, чаршау читеннән башын чыгарып, бәхетеннән балкып тыйнак кына елмаеп карап торыр аларга... Өстәл өстендә чыжлап самавыр кайнап утырыр, өйгә тәмле аш исе таралган булыр...

Әтисенең өс киемнәрен салганын да көтмиенчә тынгылык белмәс кызы Әминә, көндәгечә, үзенең уңышлары белән мактанырга керешер:

– Әти, мине тыңла, мине... мәктәптә бүген ике бишле алдым.

– Булдыргансың, кызым, йә, кайсы фәннәрдән...

– Туган телдән, аннан хисаптан алдым бишлене.

– Яхшы булган, кызым, – дип, толымлап үрелгән, ике иңбашына сузылып төшкән йомшак чәчләреннән сыйпап ала ата. – Ә тәртип бозмадыңмы соң?

– Тәртип тә бозмадым, әти, – диде кыз, бераз тавышын баса төшеп. – Бер малай чәчемнән тарткан иде, этеп җибәрдем. Бу бит тәртип бозу түгел, шулай бит, әтием.

– Төртешү-этешү кызларны һич бизәми, кызым. Башкача алай итмә, ярыймы?

– Чәчтән тартмасын иде... Ул бит үзе башлады.

– Ә укытучы ни диде, орыштымы үзеңне?

– Орышмады, шелтәләде генә. Ул да синең кебек, кисәтте, соңгысы булсын, диде.

– Дөрес әйткән, укытучының һәр сүзен тыңларга кирәк, кызым... – Шунда,

кулында китап тотып, бер читтә басып торган улы Искәндәргә игътибар итте Вәлиди. – Улым, ә синең уңышлар ничек?

– Барысы да яхшы, әтием.

Шуның белән түгәрәкләнде Искәндәр белән хәл-әхвәл белешү, ул, гомумән, күп сөйләшергә яратмый. Кечкенәдән тырыш, тыйнак һәм мөстәкыйль малай.

– Ибраһим, ә син ничек?

– Барысы да яхшы, әтием. Чиреккә дә гел бишлеләр чыгарга охшаган.

– Менә минем улым, дип мактанырлык булсын инде, ярармы?

– Ярар, – дип, тыйнак кына китап-дәфтәрләре янына китеп барды Ибраһим.

Ибраһимның кулындагы китапны танып, Вәлиди, кинәт, сискәнеп куйды. Чү, Мирсәет Солтангалиевнең соңгы хезмәте түгелме соң? Әйе, 1928 елда Казанга соңгы тапкыр килүендә Мирсәет үз кулы белән имзалап бүләк иткән китапчык ич.

– Ибраһим, – диде ул, кырыслана төшеп. – Улым, ул нинди китап синең кулыңда?

Үз чиратында малай да каушап, уңайсызланып калды. Әтисенең китап киштәсеннән рөхсәтсез алган иде шул. Ә ул мондый эшне бигүк өнәп бетерми.

– Мирсәет абый Солтангалиевнеке, әтием. Нәрсә, алырга ярамый идеме әллә?.. Мин аны бик кадерләп кенә тотам.

Ни дияргә соң бу малайга... Теге атнада бер почмакка посып Троцкий хезмәтләрен укып утыра иде. Бүген – Солтангалиев! Мондый болгавыр заманда бу мавыгу хәерлегә илтмәскә мөмкин ич. Ә гаеп аның үзендә булып чыга, бу китапларны үсмер бала күзеннән генә түгел, гомумән, кеше-карадан да яшерергә күптән вакыт иде.

– Кил әле, яныма кил, улым, – дип, үзе янына чакырды ул Ибраһимны.

Гаепле кешедәй, кыяр-кыймас атлап әтисенә якынлашты малай.

– Белмәдем бит, әтием, башка бер вакытта да синнән рөхсәтсез алмам...

Әтисе аны иң элек аркасыннан сөеп, башыннан сыйпап куйды.

– Син әле бик яшь, улым. Бу китапларны укырга иртәрәк. Үсеп җитәрсең менә, ни теләсәң шуны укый башларсың, боерган булса... Нигә кирәк булды соң әле сиңа алар?..

– Мәктәп директоры, Мирсәет абыйны «халык дошманы» дип сөйләде бүген безгә. «Түгел, нигә ул дошман булсын?..» дип әйтәсем килде. Кыймадым. Аның бит безгә дә килгәне бар, шулай бит, әтием. Теге гимнастёркалы, күн итек киеп килгән абый шул иде бит. Сез кич буе сөйләшеп утырганда мин бар эшемне онытып, шыпырт кына чаршау артында тыңлап яткан идем.

– Олылар нәрсә сөйләшмәс, – диде Вәлиди. Тагы ни әйтсен, үзе ихлас хөрмәт иткән, олылаган фикер иясен хурларга керешсенмени?..

– Мирсәет абый дошман түгел, шулай бит, әтием...

Бала, сәясәт турында сөйләшер, фикер йөртер өчен әле шактый ук яшь булса да, әтисеннән җавап көтә иде. Туры җавап бирсә, мәктәптәге укытучыларга, рәсми газеталарга каршы куячак ул аны. Ялган да сөйли алмый.

– Юк, улым, Солтангалиев халык дошманы түгел, киресенчә, халкыбыз бәхете өчен, аның дәүләтчелеген булдыру өчен үз-үзен аямыйча көн-төн хезмәт иткән каһарман. Син шуны белеп тор әлегә, ә калганын тарих үзе күрсәтер. Әмма, кара аны, малай актыгы, бу хакта һичкем белән сүзгә кермә, бәхәсләшәсе булма, ярыймы? Килештекме... Юкса, колагыңны борырмын.

– Аңладым, әтием, килештек.

– Ә хәзер ул китапны миңа бир дә, бар, өйгә бирелгән эшләреңне эшлә.

Улы китеп баргачтын, башын чайкап, үзалдына уйлап куйды Вәлиди: «Бала, дибез... Әнә ниләр белән мавыга, менә нәрсәләр белән кызыксына аның улы. Ходай кушып, исән-сау булса, үзе башлаган эшләрне улы Ибраһим дәвам итүе бик ихтимал. Хәерлегә булсын инде...»

Әтиләре өстен-башын алмаштырып, кулын юып чыккан арада гаилә тулысынча чәй өстәле артына җыелган иде. Әниләре барысы да ярата торган тәмле ризык – дучмак пешереп куйган бүген. Аның камыр һәм бәрәңге өстеннән йомырка белән ягылган йөзе, мичтән чыккач, сары көнбагыш чәчәгедәй балкып үзенә тартып тора. Өстеннән ак май белән майлап та җибәргәчтен күзеңне алырлык түгел, ә капсаң – телеңне йотарлык менә.

– Дучмакны бу тикле дә тәмле һәм матур итеп бары әниегез генә пешерә белә, – дип мактап куя шунда әтиләре.

– Син гел шулай, нәрсә пешерсәм дә мактыйсың инде, – дип, үзен мактаганга тартына төшеп җавап кайтара әниләре. Кыюсызрак булып утырган Искәндәрнең алдына чираттагы дучмакны куя ул. – Тартынма, аша, улым. Егет кешенең ашаганда колагы селкенсен, эшләгәндә йөрәге җилкенсен, дип әйтә торган иде безнең әти мәрхүм.

– Әниегездән үрнәк алырга кирәк, балалар. Ишеттегезме, әнә, халкыбызның нинди матур әйтемнәрен урынлы файдаланып сөйләшә ул.

– Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың, диләр бит... – дип елмайды хатын.

– Монысы да бик урынлы чыкты, аппагым, – дип хуплады Вәлиди. Һәм сүз уңае чыгудан файдаланып, әйтергә кирәк санады. – Менә тиздән, боерган булса, нәшриятка халкыбызның мәкаль һәм әйтемнәрен туплаган кульязманы тапшырырга җыенам. Бер китапка сыймас, алары да ике том булырга охшаган... Ул китапка кергән мәкальләрнең байтагын мин синең авыздан ишетеп теркәп бардым, Ләйлиҗиһаным...

– Хәерлегә булсын инде, – дип, тыйнак кына үзалдына әйтеп куйды Ләйлиҗиһан. Күңеленнән нindидер дога да укып алган кебек булды.

Бар нәрсәне белергә, ачыкларга күнеккән Әминә сүзгә катышмый яисә сорамый каламы соң:

– Әтием, ә нәрсә була ул «мәкаль һәм әйтемнәр» дигәнең?

– Ашаганда андый сораулар белән бүлдермә әтиеңне, соңыннан аңлатыр үзеңә, – дип, кызын аркасыннан сөйде әнисе.

Ә Вәлиди кызы соравына җавапсыз кала алмады. Бала кызыксына икән, аңарга, эшең никадәрле тыгыз булуга карамастан, җавап бирү кирәк, дип саный иде ул.

– Мәкаль вә әйтемнәр, кызым, халыкның гасырлар дәвамында тупланып килгән тапкырлыгы, акыл һәм фикри тәҗрибәсе җимеше. Аларны урынлы һәм үз вакытында файдалана белү сөйләүченең зирәклеген, сүзенең үтемле һәм тирән мәгънәле булуын тәэмин итә... Аңладыңмы инде, кызым?

– Ә мин, әтием, синең ул китаплардан өйрәнеп, гел мәкаль һәм әйтемнәр белән генә сөйләшәсем килә.

– Бик яхшы, кызым. Шулай итсәң, авызыңнан чыккан һәр сүзеңне бар кеше сокланып тыңлар... Бу каян килгән акыллы кыз, кем кызы икән, дип хәйран калырлар...

– Әй, ничек яхшы. Мин аларга Җамал Вәлиди һәм Ләйлиҗиһан кызы диярмен...

Ата белән ана, үзара сүз берләшкәндәй, дәшми генә соклану катыш горурланып, кызларына карап тордылар. Ә ул сорап куйды:

– Әтием, ә син ул әйтемнәрне каян алдың, үзең уйлап чыгардыңмы?

– Кызым, әйттем кебек ич, алар төрле заманда туып, телдән-телгә күчеп шомарган һәм безгә килеп җиткән хәзинә. Алар халыкныкы.

– Ә кем җыйган аларны, кем язып алган?

– Әтием үзе! – дип, белдеклелеген күрсәтеп горур гына сүзгә кушылды Искәндәр.

– Аларны, кызым, синең кебек шәкерт чакларымнан ук кызыксынып җыя

башлаган идем. Һәм кая барсам, кем белән сөйләшсәм дә, колакка чалынган һәр мәкаль-әйтемне теркәп бардым. Авылда да, Ырынбурда да, Казанда да... Бүген дә дәвам итәм бу эшне, татарлар яшәгән ерак авылларга баруым да шуның өчен.

– Менә ничек, менә ничек кызык икән, – дип, уйга бирелеп утырды кыз. – Син ул мәкальләрне җыярга барганда мине дә үзең белән алырсыңмы, әтием?

– Алырмын, кызым.

– Ә мине? – дип, Ибраһимның сораулы карашы текәлде шунда.

– Сине дә алырбыз, улым.

– Искәндәр абыйны да, шулай бит, әтием? – дип, сүзгә Әминә кушылды тагы.

– Теләге булса, Искәндәрне дә алырбыз, боерган булса.

– Йәгез, җитәр инде, кызым, әтиегез эштән арып кайткан, тынычлап чәй эчәргә дә бирмисез үзенә, – дип, көтмәгәндә кузгалган бу сөйләшүне әниләре Ләйлиҗиһан йомгаклап куйды...

**4**

Милләт... Нәрсә соң ул милләт?.. Һич бәхәссез ки, ул гаять мөһим төшенчә. Әмма аны тотып карау кая, тоемлау һәм күз алдына китерү дә җиңел түгел. Шуңа да карамастан, күпме җан иясе үз халкына, үз милләтенә хезмәт итүне беренчел һәм иң изге бурычы санаган һәм шул юлда нинди генә каршылык һәм киртәләр очрамасын, аларны җиңеп чыгарга омтылган. Дөньяда һәм ватаныбызда яшәгән һәр инсанның үз милләте булганы кебек, без татарларның да бай тарихлы, ерак гасырлардан тупланып килгән зур мираска ия милләтебез бар. Милләтнең йөзен аның әхлакый һәм рухи хәзинәләре, бары үзенә генә хас күңел тибрәнеше, шатлык һәм сагышларының кайтавазы булган моң, халык авыз иҗаты һәм, әлбәттә, иң кыйммәтле казанышы – тел билгели булса кирәк.

Бер уйласаң, милләт ул – без, «син» һәм «мин», «ул» һәм «алар», җыеп кына әйткәндә, һәммәбез. Тамырларыбыз буталган, әмма күпме генә буталган булмасын – уртак. Шулай дибез икән, ә ни өчен соң гомер-гомергә үз милләте язмышы, аның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге өчен җан атып яшәгән һәм эшләгән инсаннарның гомере аянычлы була. Милләтемне яшәтим дип кылган хезмәт тиешле бәя алмый, киресенчә, гаепкә, эзәрлекләүләргә дучар ителә. Ханнар һәм патшалар заманында булсын, совет дәверендә яисә демократия артына посып килгән кыргый капитализм шартларында булсын, хакимият вәкилләре иң элек үз милләтенә, халкына ихлас хезмәт итүчеләрне эзәрлекли башлаган. Дөньяның кендеге саналырга хыялланучылар өчен «милләтче» дигән ярлык «җинаятьче» сүзеннән дә хәтәррәк тоела. Нигә шулай... Үз милләтеңне, үз халкыңны, башкаларга каршы куймый гына, күтәрергә омтылу, ихлас сөю, ни өчен дип әле гаеп саналырга тиеш булды икән?!.

Җамал Вәлидинең хезмәтләре һәм язмышы хакында фикер йөртергә керештемме, мине әнә шундый уйлар biләп ала. Татар баласы булып тугач, үз халкының тарихын, бай рухи мирасын һәм җир йөзендәге һәммә энҗе-мәрҗәннәрдән дә кыйммәтлерәк туган телен кайгыртып, көнне-төнне белми берөзлексез хезмәт кылу кемгә зыян итте икән?.. Ул бит әлеге хәзинәләрне башка берәүләр сыман үз кесәсен яисә корсагын тутырыр өчен җыймый, халыкның үзенә кайтарып бирү турында хыялланып хезмәт итә.

Колачы җитсә, үз милләтен кочып алырга әзер булган, гомеренең иң катлаулы мизгелләрендә дә һичкемгә, һич берәүгә ялгышып та яман сүз әйтмәгән, җылы сүз һәм ярдәмнән башканы белмәгән татар зыялысы кемнең юлына аркылы төште икән соң?.. Бер карасаң, бу большевиклар хакимияткә халык исеменнән, хезмәт халкының авыр тормышын җиңеләйтү дигән, берсеннән икенчесе матуррак лозунглар белән килгән иде. Ә ни өчен соң әле алар җиң сызганып шул халыкны белемле һәм иманлы итәргә гомерләрен багышлаган мулла һәм мөгаллимнәр,

язучы һәм тарихчылар, гомумән, һәммә фикер ияләре белән көрәшергә кереште. Һич кенә дә башына сыйдыра алмый иде боларны Җамал Вәлиди. Егерменче еллар башыннан ук тырнак астыннан кер түгел, дошман эзләү дәвам итә. Инде житәр, инде ниһаять тукталырга, тынычланырга күптән вакыт иде дә бит... Әмма юк, киресенчә, урак өсте җиткән диярсең, тоташ җыялар, тоташтан кыралар милләтнең асыл затларын. Үзең уйлаганны ярып әйтү түгел, кемнедер яклау яисә хуплау, урамда очраган таныш-белешеңә кул бирү дә гаеп санала башлады түгелме?..

Ул гына да түгел, иң аянычлысы шул: әле кичә генә каләмдәшең яисә мәсләктәшең дип санап йөргән, үз фикерләрең белән эчкерсез уртаклашкан таныш-белешләр яисә үзең тәрбияләп үстергән, белем биргән шәкертләрең сиңа юкны бар итеп яла ягарга мөмкин. Матбугатта бер-бер гыйльми хезмәт йә булмаса мәкалә белән чыгыш ясарга өлгермисең, уңнан да, сулдан да сине гаепләргә керешәләр, фикереңнең асылына төшми торып тәнкыйтьләргә алыналар. Урамнан узып барган кеше каршына койма астыннан атылып чыккан һәм аның артыннан ямьсез өреп калган әнчекләрмени... Һич кенә дә милләт кайгысы түгел бит үзләрендә, максатларын һич аңлармын, димә...

Шуларның барысын күрәсең-кичерәсең дә кулга каләм аласы килмәгән көннәр була. Илһам кача, күкрәк кыса шундый минутларда. Ә югыйсә, күпме эш, башлап ташланган яисә тәмамланмаган күпме хезмәт көтә үзен. Милләтнең бүгенге тәрәккыяте, көн кадагына килеп баскан кичектергесез ихтыяҗы өчен соң дәрәҗә кирәк булган хезмәтләр...

**5**

Менә тагы чираттагы эш көнен тәмамлап, гадәтенчә, үз уйларына бирелеп Болак читләп иплe генә атлап өенә таба кайтып бара Җамал Вәлиди. Гәрчә Казанда туып-үсмәсә дә, монда һәр йорт, һәр бина таныш һәм берсеннән-берсе җылы истәлекләр белән бәйле иде аның өчен.

Унынчы елларның башында Ырынбурдан туган якларына кайтып барышлый бер атнага Казанда тукталырга туры килгән иде аңарга. «Йолдыз» гәҗите редакциясеннән чыгып барганда, уйламаган-көтмәгәндә, Габдулла Тукай белән очраштылар. Шагыйрь аңарга олы ихтирам күрсәтеп, үзе белән бераз йөрергә чакырды. Бертуган Шәрәфләрнең китап кибетенә чакырып чәй белән сыйлады иң элек. Аннан менә шушы Болак читендә Тукай белән икәүдән-икәү генә милләт һәм шигърият хакында әңгәмә корып йөрде алар. Тукайның Казанда аеруча үз иткән урыннары шушы Болак буе һәм Кабан күленең әйләнә-тирәсе булды кебек...

Ә бер заман әнә теге ике катлы бинаның җир астына яртылаш иңгән бүлмәсендә Гаяз әфәнде Исхакый белән кара-каршы утырып, чәй эчеп, сөхбәт итеп утырганнар иде. Гаяз әфәнденең милләтне кайгыртып ачынып сөйләгән һәр сүзе әле дә аның колак төбендә яңгырап тора...

Юллары төшеп Галимҗан Ибраһимов белән кызып-кызып бәхәсләшкән минутлары келт итеп хәтергә килде. Гомумән, Ибраһимов үзе белән бәхәсләшкәнне өнәп бетерми. Шуңадыр, Җамалга каты ук бәрелгән чаклары да булмады түгел. Ләкин, ничек кенә тәкәбберлек күрсәтмәсен, Галимҗан Галимҗан инде – татар милләтенең ихтирамга лаеклы олы әдибе һәм фикер иясе булып кала...

Ә менә бу Болак аша салынган чираттагы таш күпер читендә Ильяс Алкин белән кайчан очрашканнар иде соң?.. 18 нче елның башлары булгандыр. Алкинның һәр адымы, хәрәкәтеннән бетмәс-төкәнмәс гайрәт ташып торган чагы, коңгырт күзләре ут булып яна, якын килсәң, аның ялкыныннан ут кабар сыман үзеңә...

Чү, моннан ике-өч ел чамасы элек Мирсәет Солтангалиев һәм Һади Атласи белән очрашып, төн буе фикер алышып утырган бина янәшәсеннән узып бара икән ич. Фатих Мөхәммәдияров фатиры иде кебек. Микъдәт Борындыков һәм телгә

үтә дә җор журналист Мәхмүт Бөдәйли дә бар иде араларында. Солтангалиевнең Казанга соңгы килүе булды кебек. Хәзер кайда һәм тагы нинди газап-хәсрәтләр кичерә торгандыр Мирсәет... Шуны белсәң иде дә, үзенә ярдәм итә алсаң иде ул... Атласи белән дә башкача күрешә алмадылар. Берсен алып икенчесен куярлык түгел, милләтнең нинди асыл затлары бит!.. Садри Максудиларыбыз кая, Йосыф Акчура, Рәшит Ибраһимов, Фуад Туктаров?.. Югалган һәм китеп барганнарның исәп-хисабы юк. Милләт горурлыгы саналган шәхесләребезнең кадере бөтенләй калмады! Кая барабыз, алда тагыниләр көтә икән безне?!.

Әле кайчан гына Тукайның вакытсыз китеп баруы милләт өчен әйтеп-аңлатып бетергесез зур югалту буларак кабул ителгән иде. Алла кушып, ул шушы көннәрне күргән булса, нишләр иде икән? Һич шөбһәсез ки, инде әллә кайчан, иң беренчеләрдән булып кулга алыныр һәм юк ителер иде, мөгаен. Урыны җәннәттә булсын шагыйрьнең, кадер күрмәсә дә үз кадерен белеп китте якты дөньялардан. Туган халкын, милләтне уятып, безнең күңелләрдә бетмәс-төкәнмәс гайрәт һәм өмет чаткылары калдырып китте. Бөтен халык үз улы, үз шагыйре санап озатты соңгы юлга. Ә бүген исә, озату кая инде ул, туганнарына, балаларына да күрсәтмиләр әнә, «халык дошманы», «пантюркист» һәм «чит мәмләкәт шпионы» кебек ярлык чәпәп, бер-бер артлы озатып торалар милләтнең иң асыл улларын. Барып баш ияргә, догалар укып искә алырга, хәтерләргә каберләре дә калмый...

Үзалдына шундый уйларга чумып барганда, кинәт сискәнеп китте Җамал Вәлиди. Каршысына әлеге дә баягы теге, башкорт тарафларыннан килгән, исеме бигүк таныш булмаган шагыйрь каршыга чыкмасынмы. Аның кайту юлында махсус көтеп торганга охшаган иде ул.

– Җамал Вәлиди әфәнде, – диде ул коры гына. Моңа кадәр күрешүләрендә һәрчак, олылап, «Җамалетдин әфәнде» дип дәшә иде түгелме соң?.. Ә бүген, аңламассың, тәртип бозган шәкерт белән сөйләшәмени. Тавышы да бөтенләй башкача тамак төбеннән чыга, әнә. – Кичегеп йөрисез, мин сезне инде байтактан көтеп торам, туңып беттем.

– Ни булды, бер-бер ашыгыч йомышың төштеме әллә? – дип кызыксынды Вәлиди, гадәттәгечә кече күңелле һәм кайгыртучан тавыш белән.

– Йомыш бар инде ул, – дип, сүзне нәрсәдән башларга белми бераз төртелеп калды теге. – Татар әдәбиятының үткәне һәм бүгенгесе турында бер киңәшләшеп утырасы килгән иде дә бит. Аягүрә сөйләшә торган сүз түгел...

– Хәлләрең ничек соң, эш урының бармы? – дип сорарга кирәк санады Вәлиди иң элек. – «Спартак» фабрикасында озак тоткарланмагансың, Әтнәне дә ташлап киткәнсең, дип ишеттем. Нигә алай гел күченеп йөрисең, башка эш тапмагансыңдыр бит?

– Эшем юк әлегә. Фабриканың исен яратмадым, тире исе шагыйрьләр өчен түгел икән. Шигырьләреңнән кәҗә тиресе исе килә, дип шаяртучы һәм көлүчеләр ишәеп китте, шуңа ташларга мәҗбүр булдым...

Юл чатында тукталып торудан уңайсызланып, Вәлиди тәкъдим кертте.

– Булмаса, әйдә, юл уңаена кайтышлый сөйләшик. Хәрәкәттә – бәрәкәт, диләр бит, җылынырсың да, туңгансың күренә...

– Ашыга торган җирем юк, мин бит сезне көтеп тордым. Булмаса, әйдәгез, озатып куйыйм үзегезне.

Шагыйрь юкка гына көтмәгәндер үзен, йомышым да бар, диде кебек. Ул сүзен башлаганчы, Җамал Вәлиди уфтанып әйтеп куйды:

– Ишеткәнсеңдер, «Спартак»ның директорын «корткычлыкта» гаепләп кулга алганнар. Син барында булдымы бу, син киткәчтенме?

Көтелмәгән сораудан бит очлары кызарып чыкты тегенең. Тыныч кына

янәшәдән атлап барган җиреннән, бер сәбәпсез кыбырсый төшеп, туктап калды, әйтерсең лә, ялганда яисә караклыкта тотылган диярсең үзен:

– Юк-юк, мин киткәчтен булган бу хәлләр.

– Әтнә мәгариф бүлеге җитәкчелеген дә фаш иткәннәр дип ишеттем...

– Дөрес эшләгәннәр, бер дә җүнле кеше булып чыкмады ул, теге сезнең Гарифҗан исемле танышыгыз. Авылдагы мулла-мунтагайлар белән чыш-пыш килеп йөрүдән башканы белми. Кулакларны фаш итүгә дә каршы чыккан...

– Ә син катнаштыңмы, фаш иттеңме соң үзләрен – кулакларны һәм мулла-мунтагайларны дим?

Теге тәмам коелып төште бер мәлгә. Әмма тиз арада үзен кулга алып, шундук һөҗүмгә күчәргә кыюлыгы җитте:

– Мин, аның каравы, халык дошманы Солтангалиев белән яшерен фатирларда очрашып йөрмәдем, Җамал Вәлиди иптәш.

– Менә ничек... – дип әйтүдән башка сүз тапмады галим. Үзенә каты итеп җавап биргәндә дә ярар иде анысы, әмма «нәҗескә басма – исе чыгар» дигән сүз бар халыкта, түзде. Һәм берара сүзсез генә янәшә атлап баргачтын, берни булмагандай, сорап куйды: – Ниндидер йомышым да бар дигән идең түгелме соң?..

– Йомыш, дип инде, бер сорау гына иде ул. Сезнең кардәшегез Садри Җәләлне таба алмыйм, белмисезме, аны кайдан эзләргә икән?

– Кайда бару, кем белән очрашулары хакында ул миңа хисап бирми. Аның үз тормышы, минем – үземнеке... Нигә кирәге чыкты соң әле аның сиңа?

– Болай гына, без аның белән яхшы танышлар бит.

– Танышлар булгач, үзең беләсең булыр. Таба-нитә калсаң, миннән сәлам тапшырырга онытма үзенә, ярыймы...

– Ә Мәхмүт Бөдәйлине?..

Җавап бирү түгел, бу юлы хәтта дәшмәүне артык күрде Җамал. Ә тегенең сораулары бетмәс-төкәнмәс булырга охшаган. Имтихан алырга килгән диярсең... Гали Рәхим хакында да сораулары булып чыкты, Г.Газиз, Ф.Бурнаш, К.Тинчуриннар белән дә кызыксынды...

«Ни булган моңарга бүген!.. Солтангалиевкә ишарә ясап узуы да юкка булмады кебек. Инде дә килеп, йомышчы малай белән сөйләшә диярсең, Гали Рәхимне, Садрины һәм Бөдәйлине таптыра. Очраклы рәвештә генә туры килүме бу, әллә моның махсус бер-бер ният белән йөрүеме?..» Шулай да үз-үзен булдыра алганча тыныч тотарга тырышты.

– Кардәшем, син нәрсә, миннән сорау алырга килдеңме әллә? – дип, башлаган сүзен тәмамламый туктап калды Вәлиди. Аның түземлеге тәмам бетеп бара иде инде. Хатын-кыз күңеле сизгер була шул, Ләйлиҗиһан беренче күргәч тә искәрткән иде югыйсә: «Җүнле ният белән йөрми бу...» дигән иде кебек. Үзе гаепле, үзе йомшаклык күрсәтте, вакытында ук читкә тибәрергә кирәк булган моны. Шигырь язган, шигырь җене кагылган кешегә аерым бер хөрмәт яши иде шул күңелендә, шуңаргадыр үзеннән читкә тибәрә алмады ул аны.

– Сорауны башка урында, башка кешеләр алыр Җамал Вәлиди әфәнде, анысы минем эш түгел, – дип әйтеп куймасынмы теге.

Ниһаять, Кабан күле читеннән өйләренә борылган чатка килеп җиттеләр. Вәлиди туктап калды. Гаиләсе, балалары яшәгән ишегалдына бу адәмне ияртеп килеп керәсе, кеше-кара күзенә аның белән күренәсе килмәде аның. Үз-үзен тотышы, мәгънәсез сораулары белән гайрәтен чигерүе дә бик җиткән. Ихтимал, балаларның тәрәзәгә күз төшергән мизгеле булырга мөмкин. Күренмәсен аларның күзенә, күрмәсеннәр үзен...

– Ярый, мине өйдә көтәләрдер, – диде ул, иркен сулыш алып. – Сүзләрегез шул гына булса, хушлашырга вакыт.

– Ә сез мине өегезгә чакырмыйсызмыни инде?

– Сөйләшер сүзебез бетте дип беләм, – диде Вәлиди, кырт кисеп.

– Ә мин сезне чәйгә чакырырсыз дип өмет иткән идем.

– Боерган булса, башка вакытта, ярыймы. Сулыш алыр ара да юк, эшләрем бик күп җыелган чак.

– Йа-а-ра-ар, – дип сузып куйды теге. – Берәүнең эшләре бик күп икән, аңлашылды.

Тешен кысып булса да түзде Вәлиди, һичбер авыр сүз әйтмәде. Күпме гомер якты дөньяда яшәп, үзе белән шулай дорфа һәм мыскыл итеп сөйләшкән кешене очратканы юк иде әле шул көнгәчә. Хушлаштымы, юкмы – һич хәтерләми, кәефе тәмам кырылган иде инде. Ишегалдына килеп кергәч тә, гадәтенчә, гөл һәм чәчәкләргә күмелеп һәрчак балкып торган үз тәрәзәләренә күтәрелеп карар көч тапмады хәтта.

Шулай да әтиләренең эштән кайтуына ихлас куанып үзен каршы алган өч бала һәм Ләйлиҗиһанга ул бу хакта һични сөйләмәде һәм сиздермәскә тырышты. Бусагадан, гадәтенчә, шат елмаеп, көләч йөз белән атлап килеп керде.

**6**

Төн уртасында алар яшәгән фатирның ишегенә тышкы яктан дөп тә дөп күн итек үкчәсе белән типтеләр. Бер кеше генә түгел, икәү-өчәүләшеп тибенделәр булса кирәк, өй дер селкенеп торды. Үзләре генә түгел, бөтен күрше-күлән сискәнеп йокыдан уянсын дигәннәр булса кирәк...

Җамал Вәлиди эш өстәле артында шактый озак утырган иде ул төнне, ике томлык «Татар халык мәкальләре» җыентыгын нәшриятка тапшырыр вакыты җиткән иде. Утны сүндереп урынына барып яткачтын да күзенә йокы керми аптыратты. Заманалар бик болгавыр, җан тыныч түгел, анысын уйлыйсың, монысын дигәндәй. Татар әдәбияты һәм мәдәниятенең зыялы һәм затлы әһелләренә, фикер адәмнәренә көн бетте, әле берсен йолкып алалар, әле икенчесен йолкып озаталар. Йолку гынамы, печән өсте диярсең, чалгы белән печән чапкандай кыралар милләтнең асыл егетләрен. Әлегә ректә йөрүчеләр дә күкрәк тутырып сулыш алыр хәлдә түгел, уйларында бер үк сорау: «Кайчан миңа чират җитәр?..» Ә урамда яз, Кабан күле боздан арчылды, анда төркем-төркем кыр үрдәкләре, киек казлар кайта. Ачык форточкадан бүлмәгә өй каршында гына үскән шомыртның чәчәк исе кереп тулган.

Ишекне үзе барып ачты Җамал, көттермәде. Штыклы мылтыкларын «атам-чәнчим» дигәндәй алга сузып өч солдат бәреп керде иң элек. Алар артыннан револьверын болгый-болгый кара күн куртка һәм күн итек киеп алган офицер өй түренә узды. Җыенырга, киенергә ара калдырмадылар, ике ягыннан култыклап урамга өстерәделәр хуҗаны. Өстендә йокы өчен тегелгән киң ак ыштан һәм ак күлмәктән башка берни юк, шул көе өстерәп алып чыгып та киттеләр. Йокы аралаш йөгереп артыннан чыккан Ләйлиҗиһанга ул, каерылып, нибарысы: «Балаларны сакла һәм...» дип, эш өстәле өстендәге кулъязмаларына ишарәли алды.

Ә иртәгесен иртүк өйгә тентү керде. Галимнең гомере буйлап җыйган китапларын кычыткан капчыкларга тутырдылар. Эш өстәле, китап киштәләре шәрә торып калды. «Тентү вакытында 25 кг тыелган басмалар һәм Лев Троцкий әсәрләре табылды» дигән кәгазьгә Ләйлиҗиһаннан имза куйдырдылар.

Балаларны мөмкин булганча тынычландырып мәктәпкә озаткач, Ләйлиҗиһан Җамал Вәлидинең бушап калган эш өстәле янына узып озак кына моңсуланып карап торды. Бераздан хәл алырга теләп аның урындыгына ук килеп утырды. Әле узган төндә генә, Ләйлиҗиһан ничә тапкыр күтәрелеп карамасын, тамыр

җибәргәндәй, Җамалетдин шушында утыра иде бит. Урындыкта әле иренең тән җылысы да суынмаган иде кебек.

«Үзе кайда икән хәзер?.. Йокларга яткан җиреннән өстерәп алып чыгып киттеләр ич, ут капкан диярсең...» Өс-башына кием, ашарына хәстәрләп илтергә кирәк булыр. Аның соңгы сүзләре һәм ым кагып әйтергә теләгән үтенечен кат-кат искә төшерде ул. Чәче белән җир себерсә себерер, балаларны ким-хур итмәс анысы. Кулъязмаларын да көн яктырып кеше-кара йөри башлаганчы, өлкән улы Искәндәр белән икәүләп, ишегалдының ерак бер читендәге утын сараена чыгарып яшерергә өлгерделәр. Юкса, тентү вакытында аларны да капчыкларга тутырып алып киткән булырлар иде. Җамалетдин үзе сизенгән булса кирәк, дигән нәтиҗәгә килде ул. Юкса, гомер анда-монда таралып яткан язуларын төргәк-төргәк туплап, папкаларга салып әзерләп үк куйган булыр идеме?.. Сизенүен сизенгәндер, урынга килеп яткачтын да күзенә йокы кермәде бит аның, берөзлексез боргаланып чыкты. Әмма хатынына һәм балаларга һични сиздермәде. Хәер, гадәте шундый ич аның, авызы тулы кара кан булса да, кеше алдында төкерә торганнардан түгел.

Бер кулына иренең киемнәрен, икенчесенә ашык-пошык булса да хәстәрләнгән ризыкларын күтәреп, Черек күл тарафына юл тотты ул. Әмма анда Ләйлиҗиһанны көтүче, аның белән кешечә сөйләшергә җыенучы табылмады.

– Миңа Җамал Вәлиди кирәк иде, аны кайдан табарга икән, әйтмәссезме? – дип, кемнән генә сорап карамады.

– Ул кем, андый кешене белмибез, танымыйбыз. – Шул булды җаваплары.

– Ничек инде белмисез?.. Күренекле татар галиме һәм әдәбиятчы Вәлидине белмисез? Аны Казанда танымаган, белмәгән кеше юк иде бит, – дип тә аңлатып карады.

– Монда галимнәр юк, апа, аяк астында буталып йөрмәгез. Монда – «халык дошманнарын» һәм «буржуаз милләтчеләрне» китерәләр.

– Минем ирем дошман түгел, – дип аңлатырга тырышты ул. – Ничек инде Җамал Вәлиди үз милләтенең дошманы булсын...

Аның сүзләренә колак салучы табылмады. Үзалдына мыгырдану кебек кенә яңгырады ул сүзләр.

Шулай итеп, бер ишектән икенчесенә күчеп, күпме генә йөрмәсен, аны һичкемгә якын җибәрмәделәр. Соң гына, бер нәтиҗәсез, төенчекләрен күтәргән көе, арып-талып, кире фатирларына әйләнеп кайтырга мәҗбүр булды ул. Балалар өчесе дә мәктәптән кайткан, өйдә иде инде. Әниләре бусагадан атлап кермәс борын ук каршысына йөгереп килделәр. Йөзләрендә һәрчак балкып торган яктылыкның эзе дә калмаган, олыгаеп, әллә кай арада тартылып киткәндәй тоелды алар бүген.

«Әти кая, кайтмадымы әле?» – булды беренче сораулары.

Ничек итеп җавап бирергә белмәде, бер мәлгә югалып калды Ләйлиҗиһан. Балаларны гына түгел, үз-үзен дә тынычландырырга тырышты ул:

– Кайтыр, балакайлар, кайтыр, боерган булса. Бер гаепсез кешене озак тотмаслар...

**7**

Ул да түгел, хәрби киемдәге ике адәм шакымый-нитми генә ишектән килеп керде. Исәнләшү юк, аңлату юк, яшәгән фатирларын бер тәүлек эчендә бушатырга кушып киттеләр.

– Өч бала белән мин кая барыйм, – дип әйтеп карады Ләйлиҗиһан. Сүзләренә колак салучы да булмады.

– Комиссарлар тар һәм тынчу бүлмәләрдә яшәгән бер вакытта, «халык дошманнары» иркен, якты фазендаларда яшәп ятарга тиешме? – дип җикеренделәр аңарга.

Аяз көнне яшен яшьнәгәндәгедәй тәэсир итте бу хәбәр. Фатирсыз калу, өч бала белән урамга чыгып китү бер хәл. Бу бит әле «менә кайтыр, менә кайтыр» дип тәүлекләр буе ирен көткән хатын өчен өмет чаткыларының тәмам юкка чыгуы дигән сүз иде. Ләйлиҗиһан моны яхшы аңлады, димәк, башка төшкән бу кайгы-хәсрәт вакытлыча гына булырга охшамаган. Алдагы көннәрдә тагы да зуррак сынаулар, әлегә күз алдына да китерергә мөмкин булмаган авырлыклар көтә булса кирәк аларны.

Җамалетдиннең «балаларны сакла...» дигән сүзләре берөзлексез яңгырап торды аның колак төбендә. Әле генә бөтен тирәнлеге белән аңлады ул: менә нинди көннәрнең килү ихтималы турында кисәткән. Балаларны урамда яшәтеп булмый, ашатырга, киендерергә, укытырга кирәк. Аларның күңелендә киләчәккә булган өмет нурлары сүнәргә тиеш түгел. Җәмгыятькә, бүгенге хакимияткә дә каршы куярга теләми иде ул аларны. Юкса, бер канатсыз кош балалары сыман хис итә башлаячак бит алар үзләрен. Шуны истә тотып, балалар янында ул һичкемне гаепләп сүз әйтмәскә, тормыш авырлыгыннан зарланмаска тырышты.

Әмма яшәү өчен баш өстеңдә түбә булуы кирәк, эш урыны һәм акча кирәк. Бер-бер ярдәм-фәлән булмасмы дигән өмет белән, Җамалның эш урынына, Институтка барып карады Ләйлиҗиһан. Анда аны күрергә яисә тыңларга җыенучы табылмады, ә җитәкчелеккә якын да җибәрмәделәр. Нәшриятта дөнья күргән хезмәтләре өчен дә аласы акчасы бар иде кебек. Әмма, «нинди акча, безне ут астына салып башкача килеп йөрмәгез» дип, аннан да бик тиз борып чыгардылар. Җамалның таныш-белешләрен дә бик очрата алмады. Гали Рәхим генә, якын көннәрдә, баш исән булса, ярдәм итүнең бер-бер җаен табарга вәгъдә итте. Ул үзе дә канаты каерылган күгәрчен сыман күренде аңарга. Ә иртәгесен өйне бушатырга кирәк... Кесә дә буш, җыйган акчалары булса икән аз гына. Акча тота белмәделәр, Ходайның биргәненә шөкер итеп, киләчәккә ышаныч һәм өмет белән яшәргә күнеккәннәр иде шул.

Көне буе вакытлыча гына булса да торып торырга бер-бер почмак һәм эш табып булмасмы дип йөреп, кояш баегач кына арып-талып кире өйгә әйләнеп кайтты Ләйлиҗиһан. Әмма бу хәлендә балалар күзенә күренүдән уңайсызланыпмы, әллә бераз хәл алу уе белән икенче катка алып менүче баскыч култыксасына таянып туктап калды. Һәм үзен дә белештермәстән, йомшаклык күрсәтеп елап җибәрде. Сулкылдый-сулкылдый елады ул, һич туктамый берөзлексез агып торган күз яшьләре борын читләрен өтеп-өтеп алып, түбәнгә – таш баскычка тамдылар. Инде тынычланырга вакыт иде, мондый көндә балаларга йомшаклыгыңны һәм күз яшьләреңне күрсәтү ярамый.

Шулчак, түбән каттагы ишекләрнең берсе ачылып, аннан елга вокзалында җитәкче булып эшләүче күршеләре, бер рус кешесе, килеп керде. Якыннан аралашканнары булмаса да, үзара хөрмәт күрсәтеп, җылы итеп сәламләшеп яши торганнар иде. Ул озаклап сорашмады, сүзсез дә аңлашыла иде бит хәлләре, һәркем күреп, ишетеп, белеп тора.

– Фатирдан да куалыйлар, дип ишеттем, дөресме? – дип сорады ул, үтеп барышлый туктала төшеп.

– Иртәгә бушатырга, диделәр... Барыр җир юк.

– Ә үзегез соң кайда эшли идегез?

– Өч бала бит, аларны тәрбияләргә, карарга кирәк. Эшләмим шул...

– Хәлегез җиңелләрдән түгел, – дип, башын кашып алды күрше. – Сезнең хәлдә калучыларны эшкә алу да куркыныч.

– Һәммәсе шуңардан курка. Таныш-белешләр күп иде дә бит, югыйсә...

– Урам себерүдән башка эшкә ала алмам әлегә, – диде күрше, ниһаять, бер карарга килеп. – Аның каравы, подвалда булса да, торыр урын табарга тырышырбыз. Шуңа ризамы?..

– Риза булмый хәл юк. Балаларны ашатырга, кайдадыр яшәргә кирәк бит...

– Бер-ике сәгатьтән яныгызга минем хатын керер. Сорауларның барысын да аның белән ачыклап бетерерсез... Минем ашыгыч эшләрем бар, – диде һәм җәт-җәт адымнар белән ишегалдына юл тотты күрше.

Менә шул рәвешле, уйламаганда-көтмәгәндә үзенә күрә бер җае да чыгып куйды кебек. Күз төпләрен яулык очы белән сөртә-сөртә балалары янына ашыкты Ләйлиҗиһан.

***

Икенче көнне таң белән аларның ишегенә тагы күн итек белән типтеләр.

– Өйләгә кадәр фатирны бушатырга кирәк, – диде ишек катында басып торган әзмәвердәй ир-ат.

– Барыр җиребез ачыкланмаган, берәр көнгә кичектереп булмыймы, – дип аңлатып карады, мәктәпкә җыенучы өч баланы кайгыртып, чәй өстәле артында йөгергәләп йөргән Ләйлиҗиһан.

– Барыр җирегез булу-булмау безне кызыксындырмый. Дүрт сәгатьтән фатирның үз хуҗалары килә.

– Үз хуҗалары, – дип, үзалдына кабатлап куйганын сизми дә калды Ләйлиҗиһан.

– Әйе, ялгыш ишетмәдегез, үз хуҗалары. Бу фатир бүгеннән алып капитан Шакиров гаиләсенеке.

– Күченеп өлгермәсәк...

– Үзегезгә карагыз, безне андый сорау кызыксындырмый. Өлгермисез икән, чүпрәк-чапракларыгызны чүплектән җыеп алырсыз,– диде теге. – Җиһазларга кагылмыйсыз, китап шкафлары, өстәл-урындыклар барысы да фатирда кала. Ишеттегезме?!

– Ничек? Алар безнеке ич, үзебез ясаткан...

– Ясатмагае... Менә бу боерыкта акка кара белән язылган: «Фатир мебельләре белән бергә капитан Шакировка бирелә» диелгән, аңлашыламы?..

– Ә балалар кайда дәрес хәзерләр, алар кайда йокларга тиешле булып чыга?

– Сез диванга ятып камин каршысында җылынып яткан чакта, без идәндә аунап үстек, апай. Заманалар башка, инде сез аунагыз ул чүплектә – буржуйларның чираты җитте. Шуның белән тәмам, дүрт сәгать вакытыгыз бар...

– И Аллам, и Ходаем... – дип әйтергә генә калды.

– Әйе, «Алла» дигәнегез ярдәм итәр микән, карарбыз, – диде дә ишекне каты шапылдатып күздән югалды теге адәм актыгы.

Тупсага утырып кая куярга белмәгән бер башын ике уч төбенә салып «ух-ах» килде Ләйлиҗиһан. Ул арада тагы ишек шакыдылар. Монысы Елга вокзалы директорының тормыш иптәше Маргарита ханым булып чыкты.

– Сезгә ачкыч керттем, – диде ул кулындагы тимер кисәкләрен сузып. – Вокзалга җитәрәк сул якта ике катлы иске бараклар булыр. Беренче подъездга кергәч тә сул яктан 3 нче бүлмә. Хәзергә шунда яши торсыннар, диде... Аннан, оныткачы әйтим, тагы шуны тапшырырга куштылар, күрше-күлән кем булуыгыз, каян килүегез белән кызыксына кала икән, дөресен сөйли күрмәгез. Авылдан күчеп килдек, дип әйтегез. Юкса, эш харап...

– Рәхмәт инде. Бик зур рәхмәт, алай да сез бар әле... Менә бит гел көтмәгән җирдән, – дип, кунак итәрлек сые булмаса да күршесен өстәл артына, чәйгә чакырырга кыюлыгы җитте Ләйлиҗиһанның.

– Беләм, сездә чәй кайгысы түгел хәзер, – диде дә ничек көтмәгәндә килеп кергән булса, шулай ук җиңел генә үз юлы белән чыгып та китте Маргарита ханым.

– Инде ничекләр итеп күчәрбез икән, – дип, үзалдына уйга калып торган әнисе каршысына ул арада өлкән улы Искәндәр килеп басты.

– Борчылма, әни, күчәрбез. Мин барысын да җайлармын, – дип әйтеп куймасынмы шунда. Ана шул мизгелдә беренче тапкыр улының инде буй җиткереп килгән егет булуын тойды.

...Искәндәр белән Ибраһим әллә кай арада ике «уф-алла» арбасы табып ишек төбенә китереп куйдылар. Кием-салым һәм кирәк-яракларны ташый башлаганнар гына иде, әллә каян җигүле ат килеп туктады алар каршысына. Арбадан сикереп төшүчене күргәч, телсез кала язды Ләйлиҗиһан. Бу, теге, Җамалетдиннең бер айлык хезмәт хакын бурычка алып киткән шагыйрь иде. Бирәм дигән колына – чыгарып куяр юлына, диләрме әле. Бурычын китерә килгәндер бәлки, дигән уй үтте аның башыннан. Исемен-фәлән белмәсә дә таныган кеше ич, эченә җылы кергәндәй булды.

– Бу арбалар белән күченәләрме инде, – дип кычкырды ул, якын кешеләре белән күрешкәндәгедәй сәлам биргәннән соң. – Әйдәгез, ат арбасына төягез.

– Юк, кирәкми, рәхмәт, – дип карышты Ләйлиҗиһан. Чит-ят кешеләрнең белми торуы да мөһим дип кисәттеләр бит әле аларны. Бигүк чит-ят булмаса да, моның да нинди уй белән йөрүен белеп булмый ласа...

Ә теге исә, ике уйлар урын калдырмады үзләренә, «уф-алла»га төялгән төенчекләрне, капчыкларны капшый-капшый ат арбасына күчерергә кереште. Малайлар карышмады, Ләйлиҗиһан гел югалып калды. Бер уйласаң, моның килеп чыгуы әйбәт булды, юкса балаларга авырга килер иде... Икенче уйласаң, сүз чыгу ихтималы инде. Шулай да күңеле тыныч түгел иде аның, моңарга дөресен сөйләү ярамас, бер-бер уйдырма тапканың хәерле булыр... Аннан, нигә соң әле һаман капшана икән ул, төенчекләрдә нәрсә булса да барыбер түгел микәнни аңарга?..

– Кемгә илтәбез боларны, ераккамы? – дип сорады, ниһаять, ат арбасына кирәк-яракларны урнаштыру белән мәш килгән «кунак».

– Берәүнең ташландык подвалына илтеп торырга булдык әлегә, – дип җавап кайтарды Ләйлиҗиһан.

– Ат арбасында урын тагы бар, язу-сызуларны да чыгарыйк булмаса, – дип әйтеп куймасынмы шунда. Менә нидә икән хикмәт!..

Бу тәкъдимгә җавап бирергә ашыгучы күренмәде. Малайлар астыртын гына бер-бер артлы әниләренә карангалап алды. Әниләренең болай да башы әйләнгән чак, әллә ишетмәде сорауны, әллә ишетмәмешкә салынды.

Ә теге исә тавышын күтәрә төшмәсенме шунда:

– Җамалетдин абзыйның кулъязмалары, папкалары кая, дим. Сездән сорыйм, ник дәшмисез, телегезне йоттыгызмы әллә?

– Ә-ә, аларны сорыйсың икән,– дип, сорау әле генә башына барып җиткәндәй җавап бирде Ләйлиҗиһан. – Аларны бит, теге, шул көнне үк кычыткан капчыкларга тутырып алып киттеләр. Аңламый да торам...

– Китапларын алып киттеләр. Ә кулъязмалар сездә!

– Юк шул, барысын да алдылар. Әллә ничә кычыткан капчык белән...

Әниләренә сүзен тәмамларга да бирмәде теге адәм, тәмам ярсып кычкырырга ук кереште.

– Сез, нәрсә, мине алдарга җыенасызмы?.. Булмас! Кулъязмалары кая, дип сорыйм ич сездән. Яшереп калдырган өчен, беләсезме, нәрсә булачак? Сезне, сезнең барыгызны да аның артыннан озатырга кирәк.

– Алып киттеләр, дидек бит. Кычкырма безнең әнигә...

Бу Ибраһимнең җавабы булды. Теге исә атылып малай каршысына килеп басты һәм тешләрен кысып аның иягеннән каты итеп учлап тотып:

– Син нәрсә дидең, малай актыгы? Син кемгә тавыш күтәргәнеңне беләсеңме?! Мин сине, беләсеңме, нишләтермен?!

– Абый, Ибраһимның гаебе юк, тимәгез аңарга, – дип, энесе белән шагыйрь

арасына Искәндәр кереп басты. – Әтинең кәгазьләрен берсен дә калдырмый алып киттеләр бит. Ышанмасагыз, әнә, өйгә кереп үзегез карап чыга аласыз.

– Син дә мине алдарга җыенасыңмы, көчек, – дип, Искәндәргә ыржайды теге. Кыяфәте, үз-үзен тотышына караганда менә-менә малайның өстенә ташланыр да аны шул мизгелдә үк ботарлап атар кебек иде ул. Ачу һәм нәфрәтенең чикчамасы юк.

– Алдамыйм, абый...

– Алдыйсың! Хәер, сез барыгыз да бер калыптан сөрелгәнсез. Кешечә сораганны аңламыйсыз икән, сезнең белән ничек сөйләшергә белермен.

Бер кавым, икеләнепме, дәшми торганнан соң, ярсуыннан басыла төшеп, ул яңадан Ләйлиҗиһанга мөрәҗәгать итте:

– Соңгы тапкыр сорыйм, апа-җаным, аның кәгазьләрен, папкаларын кая яшердегез, кемгә бирдегез?

– «Аның» түгел, Җамал Вәлидинең! – дип, басым ясап ачыклык кертер көч тапты Ләйлиҗиһан үзендә. – Бу – бер! Икенчедән, бездә папкалар кайгысы түгел әлегә, моны сезгә аңларга кирәк иде.

– Ярар, сезнеңчә булсын. Ә кулъязмалар кайда, аларны кемгә бирдегез, дип кабатлап сорыйм үзегездән...

– Ни булса, барысын да алып киттеләр, дидек. Бәйләнмә балаларга, аларга болай да бик авыр. Кабатлап әйтәм, кәгазь кайгысы түгел бездә, аңла...

Ә аның исә үз туксаны – туксан.

– Мин, апа-җаным, нәрсә сөйләгәнемне беләм. Аларны мин барыбер табачакмын. Тапмасам, сез аларны үз кулларыгыз белән китереп бирәчәксез миңа. Яхшылык белән сораганны аңламыйсыз икән, ничек сөйләшергә белермен...

Бу адәмне беренче күрүдә үк ошатмаган иде Ләйлиҗиһан, ялгышмаган булып чыга. Кара син аны, ничекләр сөйләшеп күрсәтә ул бүген. Җамалның гомер буе җыйган-туплаган мирасы, кулъязмалары кирәк булган икән берәүгә. Юк инде, болайга киткәч, кем булуың һәм ни өчен безнең тирәдә берөзлексез чуалуың аңлашылды...

– Син инде безне куркытма, ярыймы, янама да безгә. Без болай да җитәрлек куркытылган, – дип әйтә алды ул нибары, башкача сүз тапмады.

Тегесе исә, дөньясын оныткандай, кинәт кызып китеп, ат арбасына менеп басты. Һәм, менә мин кем дигәндәй, гәүдәсен бер турайтып алды да анда төялгән тормыш кирәк-яракларын һәм төенчекләрне уңга-сулга ыргыта башлады. Кайсын кулы белән болгап атты, кайсыларын тибеп кенә очырды арбадан. Күченүчеләр аны-моны уйлап өлгергәнче, арбасын бушатып та бетерде. Һәм дилбегәне кагып куйды.

– Киттек, әйдә, бахбай... Син аларга ярдәм итәргә дип киләсең... Яхшылык белән... Кадер белмәгән ишәкләр, – дип, берөзлексез борын астыннан мыгырданамыгырдана, атын урамга таба чаптырды.

Ул китте. Әмма аның китүенә уфтанучы күренмәде, киресенчә, тынычлана төштеләр кебек әле. Артык күз, артык сүз дә булмас, дип үзен тынычландырды Ләйлиҗиһан. Ә уллары кайсы кайда, аяк астында аунап яткан тормыш кирәк-яракларын бер читтә бушап калган «уфалла» арбаларына төяргә керește. Тик кызганыч, арбадан тотып ыргытылган самоварның борыны кителеп төшкән һәм фарфор чәй сервизы челпәрәмә килгән иде.

Кешедә кеше кайгысымыни соң хәзер?! Бу хәлне күрүче, искәрүче булдымы икән, әйтүе кыен. Әнә, Казан урамнарының берсеннән Яңа Бистә, ягъни елга вокзалы тарафына, тәртә эченә кереп, ике үсмер малай бер-бер артлы ике арба тартып бара. Арбаларга ниндидер төенчекләр, капчыклар, тормыш кирәк-яраклары төялгән. Беренче арба артыннан сабый кыз ияргән, ул әллә этә, әллә абына-сөртенә

арба артыннан калмаска тырышып йөгерә, аңламассың. Ул да түгел, әнә, юлдагы ташка абындымы, сөрлегеп барып төште, егылып калды кыз бала, аягына кигән сандалилары як-якка очып китте. Икенче арбаны тартып барган малай, абыйсы булса кирәк, тартып килгән арбасын калдырып, ярдәмгә йөгереп килеп җитте. Сеңлесен тартып торгызды, аның күлмәк итәкләренә кунган тузанны кагышты, аяк киемнәрен табып кидерде. Һәм яңадан җәт кенә тәртә эченә кереп, юлын дәвам итте. Бераз калыша төшеп башына шәл ураган, ике җилкәсенә нииндидер төенчекләр аскан какча гаүдәле бер хатын атлый. Әллә төенчекләре авырлыгыннан, әллә тормыш кыенлыклары басканга, адымнары салмак, карашы түбән текәлгән.

Бу малайлар кулыннан эш килә. Шул ук көнне, урамга кичке караңгылык төшкәчтен дә, кеше-кара күзенә чалынмый гына, бер арбага төяп этиләренең утын сараена яшерелгән кулъязмаларын да алып кайттылар.

Юеш подвал кеше яшәү өчен яраклы түгел иде, әлбәттә. Башка барыр җирең булмагач, нишлисең, урнаштылар. Такта идәнгә матрас җәеп салгач йокларга да урыннары булды. Якын-тирәдә генә хуҗасыз калган җимерек йорттан Искәндәр белән Ибраһим бер иске өстәл юнәттеләр, аркасыз ике урындыкка гарбил такта сузып куйгач менә дигән эскәмия килеп чыкты. Ә кулъязмаларны кая яшерергә? Яшәгән җирдә тотарга ярамый, билгеле. Тикшерү-фәлән килеп чыкса, ни буласын беләсез. Ул гына да түгел, аларны кулга төшерү уенда йөргән теге адәмне дә онытырга ярамас. Ничек янады, ничек ярсыды бит әнә. Куйган максатына ирешү юлында аңардан барын да көтәргә мөмкин...

Икенче көнне үк балалар, гадәттәгечә, мәктәпкә киттеләр. Укый торган мәктәпләре ерагайды ерагаюын, әмма башыңа төшкәч түзәргә туры килер. Балаларга исең китәр, ник шунда берсенең авызыннан ялгышып кына булса да бер зарлану яисә канәгатьсезлек сүзе ычкынсын икән. Ә Ләйлиҗиһан эшкә чыкты. Эш урыны үзләре тукталган бaрактан ерак түгел иде. Өстәвенә, якында гына, көрәк һәм себерке кебек эш кораллары саклау өчен җайланган тимер будкадан ачкычлар да бирделәр үзенә. Ул бер карарга килде: Җамалетдиннең язуларын шунда яшереп тору урынлы булыр. Балалар мәктәптә чакта илтеп тә урнаштырды ул аларны. Бала кешеләрнең әлегә бу хакта белми торулары да хәерледер, дигән нәтиҗәгә килде...

Бер атна-ун көн уздымы икән, теге шигырь чыгаручы ыспай адәм тагы эзләп тапты бит үзләрен. Кичкырын өч бала һәм ана бергә җыелып тимер мич – «буржуйка» янында җылынып утырган чаклары иде. Май ае булса да көннәр, аеруча төннәрен, суык тора иде әле. Шуның өстенә, озак вакытлар кеше яшәмәгән подвалда юешлекнең һич бетәсе юк. Шакымый-нитми ишекне бәреп килеп керде теге, исерек һәм дорфа хуҗа үз өенә кайтып керде диярсең. Килеп керде, исәнләшү, хәл белешү юк, авызын ачып ник бер сүз әйтсен икән. Ул да түгел кергән шәпкә бүлмәнең астын өскә китереп актарына, эзләнә башламасынмы, өстәл асларына да башын тыгып алды, ерак почмакта өелеп яткан кием-салым, йорт кирәк-яракларында да казынды.

Бу хәлне ничек аңларга һәм аңлатырга белми, хәйран калып, чарасызлыктан бер-беренә карашып тордылар байтак кына.

– Нишләвең бу, нәрсә эзлисең син?– дип әйтә алды, ниһаять, Ләйлиҗиһан.

– Үземә кирәкне эзлим, – булды җавабы.

– Ни җитми сиңа, нәрсә кирәк бездән тагы...

– Кулъязмалар кайда?

– Әйттек ич, алып киттеләр, – дип, аның каршысына уникенче яше белән барган Әминә барып басты иң элек.

– Синнән сорамыйлар, кызый, – дип, җиңелчә этеп җибәрде ул аны. – Әниеңнән сорыйм: табыгыз, бирегез миңа ул кәгазьләрне. Юкса, үзегез өчен проблема чыгуы ихтимал.

– Без сиңа җавап бирдек инде, башка әйтер сүзебез юк, – диде Ләйлиҗиһан.

Аның саен китәргә уенда да юк тегенең, өстәл читендәге эскәмиягә үк килеп утырды. Һәм үзенә күрә хәйләгә кереште:

– Соң, болай гына бирергә теләмәсәгез, сатыгыз соң чиктә, алам. Аз булса да акча да булыр үзегезгә.

Ләйлиҗиһан аның бу сүзләрен шунда ук эләктереп алды.

– Анысы дөрес, акча кирәк... Акча бик тә кирәк безгә.

– Соң, сатыгыз. Ул кәгазьләрнең һичкемгә, һичкайчан кирәге чыкмаячак башкача. Нигә ике уйлап торасыз, сезгә нәрсәгә алар?..

– Алай акчаң күп булгач, син теге чакта иремнең бер айлык хезмәт хакын алып киткән идең, бәлки шуны кайтарырсың. Күреп торасың, безнең бик тә авыр чагыбыз...

– Ха, – дип көлемсерәп куймасынмы теге. – Акча кирәк булган икән боларга. Мин сездән бурычка акча алганым юк.

– Алдың ич, үз күзләрем белән күрдем.

– Күзләрегезне саклап йөрергә киңәш итәм. Күпне күрү, күпне белү хупланмый торган заман, – диде ул, һәр сүзенә бер сер салырга теләгәндәй итеп.

– Менә ничек, – диюдән башка сүз тапмады Ләйлиҗиһан.

– Әйе, менә шулай! – дип көлемсерәде теге. – Әмма дә ләкин мин ул кәгазьләрне барыбер табачакмын, белегез шуны. Яхшылык белән бирмәсәгез, яманлык белән табачакмын, ишетәсезме?.. – дип кычкырынды-кычкырынды да, ничек көтмәгәндә килеп кергән булса, шулай ук, саубуллашмый-нитми, ишекне каты бәреп чыгып та китте.

**8**

– Исемең?..

– Җамалетдин... Җамал, дип кенә дә әйтә аласыз.

– Ничек эндәшергә синнән сорамаслар. Артык сүз кирәкми! Исемең?

– Җамалетдин.

– Фамилия?

– Вәлиди...

– Фамилияңне сорадым. Каян килгән «Вәлиди» ул! Соңгы тапкыр кисәтәм, син буржуаз милләтчеләр мәҗлесендә яисә мәчеттә түгел, ГПУ органнарында.

– Аңлыйм.

– Синең фамилияң ничек дип сорадым? – дип җикеренде тикшерүче Беспалов.

– Вәлидов.

– Син Казанда «Буржуаз-милләтче зыялыларның контрреволюцион төркеме»н оештыруда гаепләнәсең. Гаебеңне таныйсыңмы?

– Оештыру түгел, минем үз гомеремдә бернинди сәяси төркем яисә группа эшендә катнашканым булмады.

– Дөресен сөйлә, гаебеңне таны, дидем бит мин сиңа.

– Булмаган гаепне ничек таныйм. Мин әдәбиятчы һәм тел галиме, эшем болай да муеннан ашкан. Үз эшләремне башкару өчен дә вакытым җитми.

– Куелган сорауга җавап бирә беләсеңме син? – дип, ярсып урынынннан торып басты тикшерүче. Ашыкмый гына уң кулына кара күн перчаткасын киде һәм көтмәгәндә, Җамалетдиннең муен тамырына ике тапкыр кирәмәйләп китереп сукмасынмы. – Менә монысы «әдәбиятың» өчен, ә менә монысы «телең» өчен. Инде аңладыңмы?..

Утырган урындыгында аңын югалтып бөгелеп төште Вәлиди. Тикшерүче исә, шундук аны якасыннан өстерәп, кире урындык аркасына терәп куйды.

– Чираттагы сорау. Солтангалиев белән кайчан һәм нинди шартларда таныштың?

– Ачык кына хәтерләмим. Октябрь революциясенә кадәр, шәкертлек елларыннан ук белә идек бер-беребезне.

– Солтангалиевчеләр группасына кайсы елларда килеп кушылдың?

– Мин андый группа барлыгын белмим. Ул хакта ишеткәнем дә булмады.

– Син бит әле генә «танышлар идек» дидең. Белми, имеш, ничек кенә беләсең әле! Кабатлап сорыйм: Солтангалиев белән соңгы елларда кайда һәм нинди шартларда очраштыгыз? Анда кемнәр катнашты? Советларга каршы нинди чаралар оештыру белән шөгыльләндегез?..

– Мин Мирсәет Солтангалиевне элек-электән таный һәм белә идем. Казанга һәр килүендә, эшләре ничек кенә тыгыз булмасын, күрешеп хәл белешү өчен ара табарга тырыша иде. Аерым гына чәй эчкән чакларыбыз булды, чәй мәҗлесләрендә дә катнашырга туры килде...

– Менә-менә, шул мәҗлесләр турында ачыграк итеп сөйләргә тырыш хәзер. Анда кемнәр катнашты? Нинди мәсьәләләр кузгатыла иде?

– Мәҗлес – ул киңәшмә түгел, анда җитди мәсьәләләр тикшерелми, ашыйлар-эчәләр, хәл-әхвәл белешәләр.

Көтмәгәндә тимер дагалы күнитек үкчәсе белән галимнең шәрә аяк очына китереп басты тикшерүче. Һәм оятсызларча елмаеп карашын аның күзләренә юнәлтте.

– Авыртамы? Аягың, дим, авыртамы?

– Авырта...

– Авыртса, дөресен сөйлә. Ашыйлар-эчәләр, имеш, хәл-әхвәл белешәләр, имеш... Кемнәр, дип сорадым, һәм нинди программалар төзедегез?

– Мин күпләрне танып та бетерми торган идем, хуҗа кеше кемне чакырса, мәҗлескә шулар килә инде. Минем бернинди программа турында да ишеткәнем булмады.

– Әллә колагың ишетми инде синең, – дип, бу юлы галимнең колак төбенә җан-фәрман китереп сукты Беспалов. Һәм, үзенең тапкырлыгыннан күңеле булып, каһкаһә илә көлеп җибәрде – Инде ишетә башладымы, колагың дим...

– Ишетәм.

– Ә син үзең большевикларга каршыниләр сөйләдең, хәтерлисеңдер бит?..

– Дөресен әйтим, мин большевикларның бик күп гамәлен өнәп бетермим. Үз халкың белән, аның зыялылары белән көрәшү, халыкка белем бирүче, дин һәм әдәпкә өйрәтүчеләрне эзәрлекләү һич кенә дә башка сыя торган эш түгел. Әмма бу фикерләремнән сәясәт ясау теләгем һичкайчан булмады, үз фикеремне башкаларга көчләп такмадым. Сөйләшәм икән, кемгәдер ярарга тырышып, кемнәндер куркып сөйләшмәдем.

– Большевикларны яратмыйсың, димәк. Монысы өчен, мә, ал, тагы берне,– дип, йөгереп килеп китереп типмәсенме галимгә. Вәлиди бер якка очып барып төште, ә урындык икенче тарафка. – Без дә бит менә сезнең ише буржуаз милләтчеләрне яратмыйбыз, тамырыгызны корыту эшенә алындык.

Көтмәгәндә китереп тибүдән башы белән таш идәнгә барып төшкән Вәлидинең авыз-борынынннан кан киткән иде. Әмма берни дәшмәде ул, бераз хәл алгачтын да, җиң очы белән яраларын сөртә-сөртә кире урындыгын эзләп тапты. Һәм яңадан тикшерүченең каршысына килеп утырды.

– Сорау алуны дәвам итәбез, – дип, зур эш башкаргандай канәгатьлек алып, тикшерүче дә үз урынына барып утырды. – Үзеңне син тел белгече һәм галим, дисең. Тик менә аңлашылмый, ни өчен соң әле син яңа әлифба кертүгә каршы имза куйдың? Үз халкыңның белемле булуын теләмисеңме, әллә үз асылыңны яшерү өчен уйлап табылган маскировка гынамы ул телче, әдәбиятчы дигән сүзләрең...

– Мин үз халкымны белемсез, димәдем. Аның күпгасырлык язма әдәбияты бар, бай тарихы, теле һәм мәдәнияте... Гомумән, бездә укый-яза белмәгән кеше юк дип саныйм. Гомер-гомергә һәр авылда мәдрәсәләр булган, бер түгел, җидешәр мәдрәсәле авыллар бар иде. Мин боларны үзем күреп беләм.

– Миңа әкият сөйләмә!.. Татарның надан халык булуын яхшы беләм. Сорауга җавап бир. Яңа әлифбага каршы кул куйдыңмы?

– Куйдым.

– Аңлашыла... Син хәтта асылыңны, максатларыңны яшереп тә тормыйсың. Бу кадәр дә оятсыз һәм явыз «контр»ны шушы көнгәчә очратканым юк иде. Гаҗәп, бик тә гаҗәп!

– Гаҗәпләнер урын юк. Яңа әлифба кертү – милли мәдәният өчен ул чын фаҗига, чөнки бу озак еллардан дәвам итеп килгән традицияләрнең тулысынча өзелүе дигән сүз. Бөтен халык кинәт кенә, бер мизгел эчендә наданга әверелә... Милләтләрне кайгыртып, аларны белемле итү ниятеннән башланган эш түгел бу. Нәкъ менә шуңа күрә дә яңалифне кертүгә каршы имзамны куйдым.

– Сафсатаңны калдырып тор, туктат. Син менә шуны әйт әле: сиксән ике кеше кул куйган ул хатны кем язды икән?

– Сорамадым, белмим.

– Ә сиңа кем алып килде ул хатны, кул куйдырырга?.. Башлап йөрүче, котыртучысы кем? Кулыңны куйгансың ич...

– Кем алып килүе хәтердә калмаган. Әйтә алмыйм.

– Хәтерләмәсәң, хәтереңне дә яңартабыз, – дип, йодрыгы белән нык кизәнеп, галимнең күз төбенә китереп сукты ул. Урындык әйләнеп китеп чираттагы мәртәбә башы белән таш идәнгә килеп төште Вәлиди. Аңын югалтты, башка һични хәтерләми...

Сорау алуга көненә өчәр мәртәбә чакыралар иде аны. Өчесе өч тикшерүче, ә сораулары һаман бер үк. Кыланышлары белән һәм кансызлыкта да берсен алып икенчесен куярлык түгел. Көн-төн кыйналулар эзсез узмый, Вәлиди үз аякларында басып тора алмаслык хәлгә китерелде. Нәтиҗәдә, ул бер айга якын төрмә хастаханәсендә «баш мие селкенү» диагнозы белән ятып чыкты.

***

Хастаханәдән чыккач та, аны төрмә җитәкчесенең урынбасары үзе белән әңгәмәгә чакыра. Саф татарча эндәшә китель киеп алган түрә. Җамалның күңеленә җылы керә, ни дисәң дә татар кешесе ич, бәлки аны аңларга сәләтле булыр...

– Гаепләнүче Вәлидов, үзеңне ничек хис итәсең? – дип сорый ул. Тавышы һәм үз-үзен тотышы да алай дорфа күренми. Сүзне дә бит, әнә, хәл белешүдән башлады.

– Хәлемме? Авыртмаган җирем, сынмаган кабыргам калмады. Сорау алуларны йодрыксыз һәм тибү-сугуларсыз гына алып бару мөмкин түгелме икәнни?..

– Ник мөмкин булмасын, мөмкин, – дип күтәреп алды ул аның сүзләрен. – Моның өчен нибары куелган барлык сорауларга да җавап бирергә кирәк, совет власте дошманнарының барысын да фаш итәргә, һәм, әлбәттә инде, беренче чиратта, үз гаебеңне танырга. Бер дә үтәп булмаслык эш түгел бит, ә... Тагы үтенечләрегез бармы? Башка үтенечегез булмаса...

– Бар, тагы бер үтенечем бар. Мөмкин булса, үз телебездә сөйләшә торган тикшерүче куйсагыз иде миңа. Сезнең белән менә аңлашып та, сөйләшеп тә була. Юкса, кайбер иптәшләргә милли әдәбият һәм тел мәсьәләләрен аңлату авыр була... Аннан бит әле кайберәүләр татар милләтен мыскыл итүгә кадәр барып җитәләр.

– Ай-һай, шундый тикшерүчеләр дә бар, дисезме... – дип, гаҗәпләнгән, хәйран калган атлы булып башын чайкап алды теге.

– Бар шул, кызганычка каршы, әллә кемнәр бар икән сезнең монда...

– Аңладым. Сезнең буржуаз милләтче булуыгызны истә тотып, үз милләтегездән тикшерүче дә куелыр киләчәктә.

– Тагы бер үтенеч. Гаилә белән, балалар белән күрешү мөмкин булмасмы? Сагындым... Кирәк-яраклар да бар иде.

– Бу ял йорты түгел... Тәмам! – дип, ярты юлда бүлдерде тегесе, башлаган сүзен әйтеп бетерергә дә ирек куймады ул аңарга. Һәм сулыш алыр ара да калдырмыйча, ишекнең аргы ягында сакта торган хәрби кешегә кычкырды. – Чиратта кем бар анда, алып керегез. Ә монысын – камерага...

***

Озак көттермәделәр, шул көнне үк аны тикшерүче янына чакыртып алдылар. Тикшерүче яңа кеше. Төрмә җитәкчелеге сүзендә тора булып чыкты, килеп керүгә үк саф татар телендә эндәште.

– Җамалетдин Вәлидов буласыз, димәк.

– Әйе, Җамалетдин Вәлидов булам. Ә сезне, кардәшем, кем дип белим?

– «Кардәшем»! – дип, аның артыннан кабатлап көлемсерәп куйды тикшерүче. Һәм ул да түгел, җикереп җибәрмәсенме, сукса утын тумранын бер сугуда урталай сындырырдай зур йодрыгы белән имән өстәлгә китереп бәрде. – Сезнең кебек «контр»лар белән кардәш булырга җыенганым юк, саграк, уйлабрак сөйләшергә киңәш итәм. Ишетмәгән булсаң ишет, мин өлкән тикшерүче Бикчәнтәев.

– Аңлашылды, – дип әйтә алды Вәлиди, тәмам пошаманга төшеп. Үз гомерендә аның ялгышып та башка кешегә сукканы һәм күпме яшәп чит бер кешенең аңарга кул күтәргәне юк иде бит шушы «тәмуг»ка кергәненә кадәр.

– Конкрет сорауга шундый ук тәгаен җавап көтәм. Телеңә салына башласаң яисә ялган-йолган сөйлисең икән, менә моны күрәсеңме, – дип, тагы теге йодрыгын бутап алды ул баш өстендә. – Юеш урын гына торып калыр үзеңнән...

– Аңлашылды...

– Йә, сөйлә, Вәлидов: большевикларга каршы эшне ничек оештырдыгыз? Нинди программа, нинди чаралар...

– Минем бернинди көрәш оештырганым булмады.

– Ә кемнәр аны оештырды?

– Андый кешеләрне күргән-белгәнем булмады.

– Солтангалиевне дә күргәнең булмадымы?

– Очрашкан чакларыбыз булды. Әмма ул үзе большевик бит, үз-үзенә каршы ничек сугышсын икән?.. Ул һәр килүендә Татарстан республикасын кайгыртып, Советлар иленең милли сәясәтен яклап сөйләшә торган иде.

– Аңлашылды-ы, – дип, уйга калган сыман итеп, күзенә төшеп торган чәчләрен артка сыпырып куйды Бикчәнтәев. – Инде икенче сорау: татар буржуазиясе идеологы Гали Рәхимне беләсезме?

– Аны да шәкертлек елларыннан ук беләм. Әмма Гали Рәхим һичнинди идеологиягә мөнәсәбәтле кеше түгел. Ул бит сәясәт белән бөтенләй кызыксынмый, күптән булып узган вакыйгалар турында гына яза.

– Ә менә без аны буржуаз Төркия белән элемтәдә гаепле саныйбыз. Өендә, эш өстәлендә «Төреклек әсаслары» исемле китап ятуын ничек аңлатырсыз?

– Бик җиңел, тикшерүче иптәш Бикчәнтәев, без татарлар – үзебез дә төрки милләт ич. «Төреклек әсаслары» – бу бит безнең уртак рухи нигезләребез турындагы китап. Мин дә, сез дә шул милләтнең балалары...

– Сто-о-оп! – дип, кычкырып җибәрмәсенме Бикчәнтәев, өстәлне төя-төя. – Мине буржуаз милләтчеләр белән, үзегез белән бер җепкә тезеп сөйләшмәвегезне үтенәм!.. Төрекләр белән бездә нинди уртаклык булырга мөмкин, үз акылыңдамы син!..

– Гали Рәхимне мин чын татар зыялысы буларак кына беләм.

– Стоп-стоп, нәрсә диган сүз ул «зыялы»? Ялгышмасам, сез буржуаз милләтчеләр, контрлар барыгыз да «зыялы».

– Зыялы кеше – укымышлы, тәрбияле, белемле, югары әхлаклы, диган сүз. Мин шул мәгънәне күздә тоткан идем...

– Ә без – большевиклар, эшче һәм крестьян уллары! Җыен сезнең ише «заялылар» белән һич уртаклыгыбыз юк. Аңлашылдымы? – дип, йодрыгы белән тагы бер мәртәбә өстәлгә кундырып алды ул. Имәннән булып чыкты, ахры, өстәл, әле дә түзә.

«Заялы» түгел, «зыялы», дип, тикшерүченең сүзләренә төзәтмә кертергә бик теләсә дә дәшми калуны кулай күрде Вәлиди. Юкса, ачы тәҗрибәсе җитәрлек, үзләрен төзәткәнне, үзләренә киңәш биргәнне бер дә өнәп бетерми шул бу халык. Өч сыйныф белеме бармы-юкмы, алар барын да беләләр. Һәрхәлдә, үзләрен шуңарга инандырганнар. Дөньяның кендеге диярсең, күрмисезме әллә, әнә, өстәл артында ничек утыра...

– Гали Рәхим, сезгә мәгълүм булса кирәк, ул бит Галимҗан Ибраһимов белән кулга-кул тотынышып Совет властена хезмәт итә. Кемне-кемне, әмма Гали Рәхимне гаепләү мөмкин түгелдер, дип уйлыйм мин, – дип, бая сөйли башлаган фикерен дәвам итте Вәлиди.

– Ибраһимовка да чират җитәр, ашыкмый тор! Аны калдырып торыйк әлегә. Газиз Гобәйдуллинны беләсезме?

– Ник белмәскә, шәкертлек елларыннан ук бер-беребезне яхшы белә идек. Казанда укытучылар мәктәбендә бергә укыдык... Соңрак, көн саен диярлек күрешеп, биш еллар чамасы бер ишегалдында яшәдек.

– Йә, ниләр сөйләшә идегез?

– Милли әдәбият һәм аның тарихы, бүгенге хәле турында фикер алыша идек. Газиз бик тә укымышлы, нык ихтыяр көченә ия кеше.

– Буржуйның да ниндие әле, шулай бит?

– Анысы дөрес, чыгышы белән хәлле гаиләдән. Әмма, бар булган мөлкәтен милли матбугатка, милли мәдәнияткә сарыф итте.

– Буржуаз милләтче, дип әйтүеңме?

– Киресенчә, чыгышы нинди булуга карамастан, ул революциягә зур өметләр баглады. Хәтта дөнья революциясе белән дә рухланып сөйләшергә ярата торган иде...

– Советлар власте дошманы түгел дисең инде, – дип, утырган җирендә киерелә төшеп, үзалдына мыскыллы елмаеп куйды Бикчәнтәев. – Сине тыңласаң, совет властеның дошманнары, гомумән, юк икән бит...

– Газиз Гобәйдуллин һич кенә дә дошман түгел!

– Садри Җәләл белән сез туган-тумача булып чыгасыз, шулай бит?

– Шулай булып чыга, Садри белән без якын туганнар.

– Синең туганың да булгач, ничек соң әле ул буржуаз милләтче булып китте?

– Буржуаз милләтче булырга, Садри Җәләлнең советка каршы эшчәнлеге, гомумән, булырга да мөмкин түгел.

– Синең кардәшең булганы өченме?

– Аңарда сәясәт кайгысы түгел! Ул бит каты авыру, паралич кичерде, өстәвенә күзләре дә күрми диярлек... Аның үз хәле – хәл.

– Күзләре күрми, дисең... Ә ничек итеп ул ак чехлар корпусына барып эләккән

һәм буржуаз гәзитләрдә эшләгән икән соң! Милләтчеләрнең мыжгып торган оясы – Хәрби шурада секретарь булып та хезмәт иткән!.. Болар синең өчен яңалыкмы, әллә беренче кат ишетүеңме?..

– Ләкин ул сәясәткә катышкан инсан түгел, мин моны яхшы беләм.

– Мулла малае булуын да яхшы беләсең... Хәер, икегез дә бер калыптан ясалгансыз ич! Мулла токымы мулла токымын якламый нишләсен, шулаймы?.. Дәшмисең... Әйтер сүзең юкмы, авызың томаландымы?..

– Безгә әти-әниләрне сайлап алу хокукы бирелмәгән, иптәш тикшерүче...

– Бирелгән булса ни эшләр идең?

– Кулымнан килсә, мин аларны мәңге яшәтер идем.

– Кулыңнан килми, анысы дөрес. Ә без, большевиклар, аларны – сыйнфый дошманнарны барыбер яшәтмәс идек. Шул исәптән сезнең үзегезне! Барыгызны да... – дип, гел урынсыз, кирәксә-кирәкмәсә җикеренеп тә алды ул.

– Иптәш Бикчәнтәев, иптәш тикшерүче, мин бит сезгә бер ялган сүз дә әйтмәдем. Дөресе шундый булгач ни эшләмәк кирәк...

Ниһаять, чираттагы мәртәбә урыныннан торып басты һәм, корбанына ташланырга җыенган хәйләкәр арыслан кебек, дәшми-нитми ипле генә атлап, Җамал Вәлидигә таба якынлашты Бикчәнтәев.

– Мин синең белән сөйләшеп карадым. Әмма, син кешечә сөйләшкәнне аңлый торган контр булып чыкмадың. Алай икән, без башкача да сөйләшә беләбез, – дип, ике учы белән кинәт галимнең ике колагыннан эләктереп алды ул, һәм утырган җиреннән аны югары күтәрде. Аяклар җирдән аерылгач та колаклар, шытырдады гына түгел, өзелеп чыгардай булып сузылды-тартылды.

Ни түзем булган Вәлиди, авыртуга чыдый алмый, шунда кычкырып җибәргәнен дә абайламый калды. Берара күтәреп торганнан соң, аны кире урындыгына утыртты тикшерүче.

– Нәрсә, әллә авыртамы? – дип, борынын җыерып, тешләрен ыржайтып, бу юлы инде галимнең каршысына ук килеп басты ул. – Суксам, сугарлык җирең калмаган, мин дә үзегез кебек, теге нәрсә диден әле, «заялы» гына булып сөйләшәм бит синең белән. Икенче юлы баш түбәндә калган утыз алты чәч бөртегеңнән эләктереп түшәмгә элеп куячакмын. Мин дә бит «заялы» булырга телим, башкалар күк сукмыйм-какмыйм, урыныңнан торырга гына ярдәм итәм. Ха-ха...

– Иптәш Бикчәнтәев...

– Мин сиңа иптәш түгел, дидем.

– Милләттәшем, дип әйтимме...

– Каян килеп милләттәш булыйм мин сиңа, – дип, искәртү өчен генә, имеш, үз итеп кенә, хәлсезләнеп бөгелеп төшкән галимнең муен тамырына кул кыры белән берне китереп сыдырмасынмы Бикчәнтәев. Шундый итеп сукты ки, Вәлиди аңын җуеп торды бер мәл. Ул да түгел, таш диварларны селкетеп акырып җибәрде тикшерүче. – Кайчан дөресен сөйли башлыйсың син?.. Гаепләреңне кайчан таныйсың, сиңа әйтәм! Синнән сорыйлар, ишетәсеңме...

– Булмаганны, бар, дип әйтә алмыйм бит...

– Безгә кемнең кем булуы барысы да күптән билгеле, «заялы» абзый. Син якладың дип кенә котылмас берәү дә. Гаебеңне танып, башка дошманнарның чын йөзен ачып кына җиңеләйтә аласың үз хәлеңне. Алар бит менә, синең чын йөзеңне ачып салды... Үз гаепләрен дә таныдылар, синең кем булуыңны да... Ни өчен телләре чишелгән дип уйлыйсың? Яшиселәре килә, шуның өчен. Ә син кире кәҗә тәкәсе кебек... Булмый абзый болай, булмый... – Бераз дәшми торгачтын, иләмсез әче тавыш белән кычкырып хәбәр салды. – Әй, охрана, алып чыгып китегез моны, уголовниклар камерасына илтеп ябыгыз үзен. Теге, кеше ите белән туклана торганнары янына, аңлашылдымы?!. Зиһене ачылып китмәсме шунда...

***

Шул рәвешле, «үзебезнең егет» Бикчәнтәев барысын да уздырып җибәрде. Вәлидинең, тикшерүче Беспалов һәм Дроздовларны искә алып, сагынып елар чаклары да булмады түгел. Тегеләре дә оҗмах кошлары түгел иде, әмма да моңарга җиткәне булмас... Һич кенә дә үзенең җаваплары белән канәгатьләндерә алмады аны Җамал Вәлиди. Ничек кенә аңлатырга керешмәсен, «Стоп, акыл сатма!» дип туктата да йодрыгы белән инде имән өстәлгә түгел, аның яңагына яисә кабыргаларына җан-фәрман китереп кенә ора. Кәефе шәп булса, таш идәнгә салып аңын югалтканчы типкәләргә дә күп сорамый. Һәр очрашудан канга баткан, ике-өч җире сынган хәлдә өстерәп кайтарып ата торган булдылар аны.

Ә камерада уголовниклар. Боларының инде үз фәлсәфәсе, интеллигенция вәкилләрен кешегә дә санамыйлар. Утырырга урын, ятарга ятак бирми азапладылар. Таш идәнгә авып хәл алыйм дисә, бер-бер сәбәп табып, торып басарга мәҗбүр итәләр. Явызлыкта, кансызлыкта тикшерүчеләр белән уголовниклар арасында һичбер аерма юк, уйларында бары бер нәрсә – көчсезне рәнҗетү, ярдәмгә мохтаҗ булганны түбәнсетү һәм мыскыл итү... Атналар-айлар буе шул бер үк хәл кабатланып торды, җәбер һәм золымның очы-кырые күренми...

***

Көннәрдән бер көнне иртәнге сәгатьләрдә Казанның кыл уртасында урнашкан Пләтән төрмәсенең ишегалдында хәрәкәтсез яткан бер ир-ат гәүдәсен табып алалар. Төнге смена китеп, иртәнге смена эшкә килгән вакыт була бу. Төрмәдә эшләүчеләрдән шактый кеше җыйнала. Әмма җитәкчеләр түгел, аларның әле җылы өй түрендә мамык түшәкләрдә янәшәдә яткан хатыннарына арка куеп изрәп йоклап яткан чагы.

– Ни булган үзенә? – дип сорый арадан берәве.

– Уголовниклар үтереп аткан.

– Уголовникларга ул нигә, үзе ташланган булса кирәк, – дип, пыш-пыш хәбәрләшкән имеш-мимешләр колакка чалынып кала.

Ул арада эшкә килеше булган бер шәфкать туташы ерып керә уртага. Хәрәкәтсез ятучының баш очына иелә һәм беләген күтәреп, аның кан тибешен тикшерә.

– Ул үлмәгән, ул исән, кан тибеше бар, – дип, тавыш бирә, ярдәмгә чакыра ул.

– Кайсы камерадан? Качарга җыенуы булдымы икән, – дип пышылдый кемдер.

– Пләтәннән кача алган кеше юк әлегә, – дип җавап кайтара икенчесе, төрмә каравылчыларыннан берәве булса кирәк.

– Таныдым, бу бит язучы, бик зур галим. Кем соң әле... Җамал... Җамал...

– Әйе, Җамал Вәлиди, – дип раслый, әлеге дә баягы теге шәфкать туташы. – Аның болай да тәнендә исән җире калмаган иде инде...

– Телеңә салынма! – дип кычкырып җибәрә кулына штыклы мылтык тоткан төрмә каравылчысы. – Телеңне тиз кыскартырлар...

Шәфкать туташы тавышсыз-тынсыз гына күздән югала. Ә бераздан ашыкмый гына бинадан килеп чыккан ике әсир аны, күпне күргән такта носилкага салып, каядыр алып китәләр. Җамал Вәлиди озак вакытлар аңына килә алмый, аяклары-куллары сыну гына түгел, эчке әгъзаларына да зур зыян килгән була. Ничек егылган, төртеп төшергәннәрме, әллә өченче каттан үзе сикергәнме – болар вак мәсьәлә саналган күрәсең, тикшерү-фәлән үткәреп тормаганнар. Һәрхәлдә, архивтагы документлар арасында андый мәгълүмат юк. Соңгы сәгатьләрен кайда уздыруы, кайда һәм нинди шартларда вафат булуы һәм кайда күмелүе хакында да тәгаен генә әйтеп булмый. Ул гына да түгел, 1932 елның 30 ноябрендә Казан төрмәсендә көн-төн каты җәзалаулар нәтиҗәсендә вафат булган күренекле әдәбиятчы һәм

тел галименең соңгы көннәрен махсус буташтыру кемгә кирәк булгандыр тагы... Рәсми оешмалар, үз вакытында, Җамал Вәлиди Беломор-канал төзелешендә суык тиеп, хасталыктан үлде, дигән хәбәр тарабалар. Әмма моның уйдырма булуы һич шөбһәсез ки... Аның сулышы Казанда – Пләтән төрмәсендә өзелә...

***

Безне капчыкта яшереп булмый, диләр. Ә бәлки, була да торгандыр. Әмма күренекле тел галиме, фольклорчы һәм әдәбият белгече Җамал Вәлидинең вафаты турындагы хәбәр, чыбыксыз телефоннар аша, шул ук көнне Казанның барлык почмакларына барып ирешә. Гомер булмаган хәл, төрмә капкасы төбенә төркем-төркем халык агыла. Хатыны Ләйлиҗиһан, уллары Искәндәр белән Ибраһим һәм кызы Әминә дә була алар арасында. Яңа Бистәнең исән-аман калган дин әһелләре, муллалары килә, галимнең шәкертләре, студентлары җыела. Шау-шу куба, тавыш-гауга чыга.

– Мөселманнарда кабул ителгәнчә җирләү өчен, Җамалетдин әфәнденең гәүдәсен бирегез ичмаса, – дип таләп итә халык.

Әмма гади халык һәм җәмәгатьчелек фикеренә колак салмаганнар ул заманда, бүген дә алай түгел дип әйтеп булмый торгандыр...

– Юк, – диләр. – Ул – ирегеннән мәхрүм ителгән халык дошманы. Дошманның исеме дә, кабере дә булмый. Дошман эзсез югалырга, онытылырга тиеш.

Гозерләп үтенгәнгә колак салу, гаилә һәм балаларның күз яшьләренә игътибар итү кабул ителмәгән заман. Төрмә җитәкчелеге халыкны мылтык прикладлары белән кыйнап, һавага атып, куып таратырга мәҗбүр була...

## 9

Ул елны кыш бик суык килде. Мичкә ягыйм дисәң – күмер юк, утын сатып алырга – акча. Инде хәзер сатып алыйм дисәң дә, утын табарлык түгел. Бер алар өчен генәмени зәмһәрир суыклар, ил белән шул ук хәл. Әйләнә-тирәдәге иске-москыны, утын сарайларын, җимерек коймаларны күптән ташып ягып бетерде шәһәр халкы. Җәйге чилләдә дә җылынмый торган ярымподвал торакның нинди хәлдә булуын үз башыннан кичергән кеше генә аңласа аңлый алыр. Шуның өстенә елга вокзалы директорын, юк сәбәпләрне бар итеп, кулга алдылар. Ә Ләйлиҗиһанны, кыш көннәрендә елга тарафына йөрүче юк, дип, эшеннән бушаттылар.

Аларына гына түзәр идең әле, Ибраһимга суык тиеп, бик нык авырый башлады шул кышта. Хастаханәгә, урын юк дигән сәбәп табып, алмадылар үзен. Әлеге дә баягы шул «халык дошманы» дигән ярлык үзенекен итә. Әби-баба ысуллары белән ничекләр генә тәрбияләргә, аякка бастырырга тырышып карамады үзен Ләйлиҗиһан. Булмады, унҗиденче яшенә чыккан яшүсмер егет юеш ярымподвал өйдә әнисенең кочагында дөнья белән хушлашты... Саклый алмады шул уртанчы улын, Җамалның «балаларны сакла» дигән соңгы үтенечен үти алмады. Елаплар гына кире кайтарып булса икән ул баланы... Ир хәсрәте артыннан ук инде менә бала хәсрәте.

Мәктәпне гел яхшы билгеләренә генә тәмамлаган олы улы Искәндәрне дә институтка алмадылар, табиб булырга бик тә хыяллана иде дә бит. Сәбәбе һаман да шул: әтисенә тагылган яман ат кара сакал булып эзәрлекләп килә үзләрен. Хәзер, әнә, эшче һөнәре алу өчен укып йөргән көне. Ә күңелендә һәм телендә – һаман табиб булу теләге. Әнисенә сиздермәскә тырышса да, Искәндәр бик нык борчыла... Хәер, борчу-хәсрәтсез кем калды икән инде бу дөньяда? Җамалетдин белән бергә эшләгән, якыннан аралашкан дуслары, таныш-белешләреннән шәһәрдә

һичкем калмады дисәң дә була. Кайсын кулга алганнар, кайсын озатканнар, күбесен атканнар, дип сөйлиләр. Аларны искә алыр кеше очраса да, пыш-пыш килеп, як-якка карангалап кына фикерләшергә калды.

Менә бүген дә Искәндәр белән Әминә укуда. Ләйлиҗиһан, Җамал Вәлидинең төсе булып калган кайры тунын аркасына салып, балаларга йон оекбаш бәйләргә утырды. Куллары – эштә, ә уенда өйне ничек җылыту, балаларга кием-салым юнәтү һәм, әлбәттә инде, кайтуларына ризык хәстәрләү. Барысына да акча кирәк, акча юк һәм аның керер юлы да күренми. Сату өчен, бер-бер ризыкка алыштыру өчен өйдә берни калмады. Ничек яшәргә, алга таба да балаларны ким-хур итми ничекләр генә көн күрергә?..

Шулчак тышкы яктан ишекне шакыдылар. Кем булыр, балаларның кайтыр вакыты әлегә җитмәгән. Сак кына ишек катына узды Ләйлиҗиһан.

– Кем бар анда?

– Мин... Ишекне ачыгыз.

Аргы тарафтагы затны ул тавышыннан ук таныды, шуңа йөрәге «жуылдап» куйды. Анда әлеге дә баягы Җамалетдиннең кульязмалары артыннан йөрүче кеше иде. Ачаргамы-ачмаскамы дип икеләнеп торган арада теге тавыш тагы яңгырады. Димәк, кире борылып китәргә дип килмәгән...

– Ачыгыз... Мин сезгә ярдәм кулы сузып килдем.

Ишекне ачмый хәле юк. Ачса, анда аягына җылы ак «фитыр» итек, башына колакчынлы бүрек, өстенә ак каракүл якалы кара пәлтә киеп алган шагыйрь басып тора. Бераз арырак ниндидер капчык салынган кул чанасы күренә.

– Керергә рөхсәттер бит? – диде ул, якасына кунган кар бөртекләрен сыпыргалап.

– Килгәнсең икән, кер...

Тупсаны атларга ашыкмады ул, иң элек тартып килгән чанасына кире борылып, андагы капчыкны күтәреп керде.

– Менә он алып килдем, бераз ярдәм булсын, дидем...

Ярты капчык онны ишек катына идәнгә куеп, үзе өстәл читендә торган такта эскәмиягә килеп утырды. Ашыкмый гына башындагы бүреген салып куйды, пәлтә изүләрен ача төште. Ә Ләйлиҗиһан исә аңарга ничек дип җавап бирергә дә белми торды.

– Он алып килдем, дисең инде, – дип уйга калды ул. – Онның кирәк чагы, яхшы булыр иде дә. Әмма акчам юк, ала алмыйм...

– Акчага түгел, ярдәм йөзеннән китердем, – дип, җаваптан күңеле булып, җанланып китте теге. – Хәлегезне аңлыйм. Кыш суык, өч баланы ашатырга да кирәк бит аны...

– Өчәү түгел, инде ике балам гына калды, – дип, бер читкә борылып елап җибәрде ана.

– Нәрсә, югалттыгызмыни? – дип, коры гына сүз кыстырып куйды килүче. – Еллар авыр, үлем-җитем күп шул хәзер...

Башкача ләм-мим, ул хакта һични сораштырмады һәм кызыксынмады да. Ана өчен монысы, бәлки, кулайрак та булгандыр әле.

Алдын-артын уйлап, онның бушка булмасын чамаламады түгел, чамалады Ләйлиҗиһан. Шулай да өйгә кергән кешене, кешесеннән дә бигрәк ризыкны кире борып чыгара алмады. Бер-ике сәгатьтән балалар – Искәндәр белән Әминә сабактан кайтып керәчәк, ачыгып кайтачаклар, ә өйдә биш-алты вак бәрәңгедән тыш берни дә юк.

– Ярар алайса, рәхмәттән башка сүзем юк, – дип җавап кайтарды ул гаепле кеше сыман тын гына. – Бурычларыңны онытмау яхшы...

– Нинди бурычлар тагы? – дип мыгырдангандай итте килүче. Әмма артык сүз кузгатып тормады.

Ләйлиҗиһан аның ул сүзләрен ишетмәмешкә салынды, сак кына үз урынына барып утырды. Җилкәсендәге тунны бер читкә куеп, кулына бәйли башлаган оекбашын һәм йомгакны алды.

– Бәйләп бетерәсе эшем бар иде, – диде, җавапсыз калудан уңайсызланып.

Ә теге исә ипләп кенә сүзен башлап җибәрде.

– Җамалетдин абзый инде юк, – диде ул, бик мөһим яңалык китергән кешедәй. – Ә тормыш дәвам итә. Сезнең яшисе, балаларны тәрбияләп үстерәсе бар.

– Шулай инде, ни эшләмәк кирәк... Урыны җәннәттә булсын!

– Анысы шулай, – дип куйды килүче, һәм форсат чыгудан файдаланып калырга ашыга төшеп, монда килүенең төп максатына күчте. – Ә менә аның кулъязмаларын югалтырга түгел, төсе итеп булса да сакларга кирәк иде бит...

– Югалтырга түгел иде дә бит...

– Җитте, Ләйлиҗиһан апа, туктагыз, – дип, кинәт урыныннан сикереп тора язды чакырылмаган кунак. – «Алып киттеләр» дип әйтергә телисезме тагы? Алдамагыз, алдашу сезгә килешми. Сездә икәнлекләрен беләм.

– Белсәгез, бик әйбәт булган... – дими чарасы калмаган иде. Өстәвенә, алар бит әле өйдә, ул утырган эскәмия белән янәшәдә генә торган иске сандыкка яшерелгән. Эштән чыккачтын да аларны кире өйгә алып кайтырга мәҗбүр булган иде. Башкача кая куясың...

– Мин ул кулъязмаларны алып китәргә дип килдем. Җамалетдин абзый булмагач, аларны саклаудан сезгә ни файда? Тикшерү-фәлән килеп, тапсалар, үзегезне илтеп ябулары бик ихтимал. Балаларыгыз бар...

– Менә ничек...

– Әйе, шулай, апа-җаным, аларның миндә сакланулары хәерле. Сезгә бәла-казадан башка файда китермәячәк ул кәгазьләр...

Икеләнә калды Ләйлиҗиһан, уйга чумды... Җамалетдин үзе исән булса, башына да килмәс иде андый уйлар. Аның соңгы сүзләре әле дә булса колак төбендә яңгырап тора: «Балаларны сакла һәм...» дип, өстәлдәге язу-сызуларына ымлады ич ул. Аның өчен балалары кебек үк кадерледер, күрәсең, ул хезмәтләр. Ә алар ничәнче кыш, ничәнче җәй инде менә, кадерсезләнеп, анда-монда күчеп йөри. Утын сарае да калмады, көрәк һәм себеркеләр янәшәсендә яту дисеңме, инде менә шушы юеш подвал...

– Онга алмаштырыйк, дисең инде, алай булгач, – дип әйтеп куйды ул.

– Әйе, ашамыйча яшәп булмый, сезгә он кирәк. Ә миңа ул язулар... Юкса, алар шушы подвалда череп бетәчәк...

– Ә син аларны ни эшләтергә, сер булмаса, кая куярга җыенасың инде?

– Саклармын, югалтмам, – диде шагыйрь, урыныннан сикереп үк торып. – Вакыты җиткәч, дөньяга чыгарырмын.

– Югалмаслар, дисең инде...

– Югалмаслар.

Тәмам теңкәсенә төште бит бу адәм, күрәмсең, кулъязмаларны бирми торып, моңардан котылып булмас, дип уйлап куйды Ләйлиҗиһан. Он да алып килгән бит, әнә...

– Ярар алай булгач, ал инде, әмма, берүк әрәм-шәрәм итә күрмә, – дигән җавап чыгып очмасынмы аның авызыннан. Башка чарасы калмаган иде шул. – Тик сиңа зур үтенечем бар, зинһар өчен, кадерсезли яисә югалта күрмә инде үзләрен. Җамалетдинне әйтәм, күз карасыннан да болайрак кадерләп җыйган хезмәтләре иде бит. Ничәмә еллар буе җыйды аларны, татарлар яшәгән кай тарафларга гына барып чыкмады, төннәр буе эшләп, шуларны тәртипкә салып утырыр иде. Соңгы төнендә дә өстәле янында утырды бит...

Һәм күзенә килеп тыгылган кайнар тамчыларны тыя алмыйча, башындагы яулыгына уралып читкә борылды.

– Кайда соң алар? – дигән аваз ишетелде. Юату, бер-бер җылы сүз әйтү турында уйлаган кеше юк. Аның үз туксаны – туксан.

– Әнә, шул сандыкта. Йозагы ватык, ач та ал...

Сикереп тә торды теге, кабалана төшеп, сандыкның капкачын ачып җибәрде. Күрсәгез иде сез аны шул мизгелдә, бәхет кошы тоткан диярсең... Башы белән сандык эченә кереп китә язды ул, туплам-туплам папкаларның әле берсен, әле икенчесен кулына алып барлап чыккан кебек итте.

– Мәкальләр... Кыска җырлар... Табышмаклар... Аңлатмалы сүзлек... – дип, үз-үзен белешми, үзалдына сөйләнә, кычкырып җибәрә иде ул әледән-әле. Куаныч һәм шатлыгының чиге-чамасы юк... Һәм бер фикергә килеп, әле дә булса, күз яшьләренә буылып, читтә басып торган Ләйлиҗиһанга мөрәҗәгать итте ул, ниһаять.

– Боларны сандыгы белән алырга туры килә инде...

– Юк-юк, сандыгын бирә алмыйм, – дип, кабаланып йөгереп килеп җитте хатын. – Ул минем әби-бабаларымнан калган сандык, аларның төсе итеп саклаган бердәнбер истәлек. Минем бирнә сандыгым.

– Бер дә харап икән... Соң, алай бик тә кадерле сандык булгач, мин аны тотып ашамам, кире кайтарырмын үзегезгә.

– Сандык монда кала, – дип, катгый рәвештә кистереп үк куйды Ләйлиҗиһан.

Ә тегенең исә кеше сүзен тыңлау уенда да юк. Шуның өстенә, максатына ирешү юлында тәмле телен дә һич кызганмый.

– Соң, апа-җаным, аңлагыз, мин менә хәзер ул кәгазьләрне, сандыктан чыгарып, чанага төяп чыгып китсәм, алардан нәрсә кала, күз алдына китерә аласызмы шуны?.. Тышта суык җил, өстәвенә, җәяүле буран чыкты, кар сибереп тора. Әйттем бит инде, сандыгын кире китерермен, дидем. Миңа сезнең хан заманыннан калган иске сандыгыгыз кирәк түгел, Җамалетдин абзыйның кульязмалары исән-сау булсын, дип тырышуым. Нәрсә, ул хезмәтләр сезнең өчен аз гына да кадерле түгелмени?..

Бу юлы да үгетләде, бу юлы да ул дигәнчә булды.

– Ярар, сандыкны китерерсең инде алай булгач, – дип, ризалашырга мәҗбүр иде Ләйлиҗиһан. Ризалашмый чарасы юк, тегенең сүзләрендә дә дөреслек бар икән бит, бер уйласаң...

Иң элек җәт кенә, кульязмалардан арындырып, буш сандыкны чанасына чыгарып урнаштырды ул. Аннан, бер кәгазь кисәген дә калдырмыйча, барысын кире чыгарып, сандыкка тутырды. Хушлаштымы, юкмы, Ләйлиҗиһан аны-моны уйлап өлгергәнче, чанасын тартып, үз юлы белән китеп тә бара иде инде теге адәм.

– Тукта әле, мин бит синең исемеңне дә белмим. Исемең ничек соң әле синең? – дигән соравы белән туктатты аны Ләйлиҗиһан.

– Белмисезме?.. – дип, сәерсенеп карап торды теге бер мәл. – Ә сиңа минем исемем нигә кирәк булыр икән соң?

– Шулай да белеп торганың хәерле дип кенә соравым иде...

– Күп белсәң – тиз картаерсың, апай! – диде ул коры гына. Һәм кире борылып, карлы-буранлы тыкрыктан кул чанасын, анда салынган сандык һәм Җамал Вәлидинең гомере буе җыйган мирасын тартып китеп тә барды. Хәтта кайда яшәгәнлеген, өй адресын да калдырмады.

Шул китүдән эзе суынды тегенең, сандык та юк, хәбәре дә...

*(Ахыры киләсе санда)*



Рифә
Рахман

# МИЛЛӘТЕМ БАРЫНДА ЯШИМ МИН...

## Вакыт

Яшьлегемдә мәрҗән эзләдем, дип,
Карап торам тәрәзәдән күккә.
Мәрҗәнмени – йолдыз?! Бәллүрмени?!
Әйләнде бит күк тә бер чүплеккә.

Китте илһам аннан, кача сере, –
Көн арты көн ача бара кеше.
Шигырьләрдән галәм сүзе китә,
Кача бара якты йолдыз төсе.

Карыйм күккә, сердәш эзләгәндә,
Буш хыяллар килеп китә әле.
Күңелемнең күген аңлау кирәк:
Аның менә күктән серле мәле!

Ае салкын – аяк астындагы
Таштан идән, мәрмәр дивар кебек.
Ә бит элек кулны суза идем...
Кочагыма очып кунар кебек,

Атыла күк иде янар йолдыз,
Куллар изәп Җиргә әйдәгәндә.
Күктә безгә берни иш түгел, дип,
Иярченнәр хәбәр бирә әле дә.

Кабер итмәкчеләр төпсез күкне
Заводларның зәһәр калдыгына.
Килде вакыт дога кылыр өчен
Инде йолдызларның саулыгына.

---

Рифә РАХМАН (1962) – *шагыйрә, прозаик, галимә; «Онытырмын димә», «Йолдызлар төстән язганда», «Таулар һаман ерак» һ.б. исемдәге күпсанлы китаплар авторы. Г.Исхакый , Җ.Вәлиди, Ф.Хөсни исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

## Булыр микән?

Буш нигезгә карап торам шашып.
Җавап бирми миңа – тик тынлык.
Авыл тынлыгында була кайчак
Зиратларда торган моңсулык.

Бу нигездә – безнең тарих, имеш.
Язып-сызып шунда күмгәннәр…
Ташлар да юк өстә, туфрак кына…
Аваз килә кебек тирәннән.

Туфрак сулый кебек! Күтәрелеп
Ала кайчак, кабат басыла!
Дәфенләнгән китап сулый мәллә –
Ул көчсез шул нигез ташыннан.

Их, арчырга иде туфраклардан,
Их, кайтырга иде бер кабат.
Карап тора читтән бер агачта:
«Булыр микән?» – диеп ярканат.

## Мәҗлестә

Мәхәббәт турында бер шигырь,
Дисез сез, мең җырым барында!
Аларны мин инде җырламам...
Яңасы бар тагын карында!

Анысын да сезгә сөйләмәм,
Чит кебек мин шушы мәҗлестә.
Бирерме тәм миңа шигырьнең
Яравы бер төнгә, бер кичкә?..

Милләтем турында мең фикер
Башымны бораулар чагында,
Мәхәббәт турында бер шигырь,
Дисез сез тагын да, тагын да.

Кирәкми нотыклар, бәхәсләр,
Әйт, дисез, сүзләрнең купшысын.
Теләкләр бушаган касәне,
Әйдәле, ырмаудан тутырсын.

Юк минем башка бер теләгем:
Яшәүдән изге хис юк миңа.
Милләтем барында яшим мин
Һәм язам мәхәббәт хакында.

Өркетәдер сезне минем сүз,
Мәҗлестә җитдилек – чит нәрсә.
Хисләрем туп-тулы күңелдә,
Ә сезнең алларда – буш касә...

## Җырлый белмәү бәласе

Җырлыйм дисәң, көе саташыла:
Көйгә осталык юк гомердән.
Гомеремне җыр күк язармын, дип,
Яшь чагында әле кем белгән.

Кем уйлаган үзем тапкан көйне
Хата итеп җырлап бирәсен.
Җырлыйсың син тормыш җырын, диләр,
Учларыңа җыеп күз яшен.

Көләсең син, диләр, авыр чакта,
Сагышлы көй кирәк чагында,
Шатлыклы җыр җырлап бирәсең син,
Дип әрлиләр дуслар табында.

Көен бозып җырлыйм мәҗлесләрнең,
Осталык юк аңа гомердән.
Бөтен тормышымның җыры сыйган
Һәр минуты үзгә бер көнгә.

Эх, дигәнче, чишәм мәсьәләне,
Мисалларның иң-иң авырын.
Гомерләрем мисал гына булса,
Мин озайту юлын табармын.

Ул мәсьәлә булса катлаулысы,
Авыр булмас миңа чишәргә.
Әгәр ул – җыр икән, ноталарны
Дөрес ала алмам, бигайбә!

Бутармын мин көйнең шатлыклысын
Моңлылары белән, ялгышып.
Мин өзеп тә ата алырмын күк,
Чияләнгән булса язмышым.

Җырлап кына аның хаталарын
Мин дөресли алмам шикелле.
Дүртле миннән һәрчак ерак йөрде.
Алганым бар җырдан икеле.

Тыңламыйча мөгаллимнең сүзен
Баш тарткан бар хәтта җырлаудан.
Әллә нишләп көем дөрес чыга,
Дип аптырыйм менә бу айда.

Яши башладыммы куркып кына,
Уйлап кына көен гомернең,
Сузам мәллә хәзер? Мин бит беләм
Үземнең һич җырчы түгелне.

## Агыла болыт

*Агыла да болыт агыла.*
Х.Туфан

Агыла да болыт агыла...
Болытлар да язны сагына.
Болытлар да коштай кычкыра,
Болытлар да канат кагына.

Бар болытның алда барганы –
Көтү башы булып калганы.
Тау битләрен күмгән карларга
Күзләреннән яше тамганы.

Тау чәчкәсен табып үпкәне,
Кар астыннан башын төрткәнен
Кочагына алыр бер хәлдә
Ак болытның бик күп көткәне.

Агыла да болыт агыла,
Акмас иде – канат кагына.
Акмас иде – диңгез сагына –
Кайтып бара туган ягына.

Тотынганнар йомшак болытлар
Көтү башы булган болытка.
Яшь койганчы, башын җуйганчы
Яшәр алар өер булып та.

Килер алар чиру кебек тә,
Агар болыт, шифа булып та.
И көтәрбез аны чилләдә,
И сүгәрбез аны суыкта.

Чакырырбыз аны – ул юкта,
Безгә ярап инде аргандыр,
Тау башында бер хәл алгандыр,
Тау-ташына башын яргандыр.

Агыла да болыт агыла:
Агыла ул туган ягына.
Диңгез өсләренә ерак шул –
Җитсәм иде, диеп кагына.

## Сөюгә табыну

Карармын мин сөю кыйбласына,
Бу Җир шары кылдай ярылса да.
Мәхәббәткә дога кылырмын мин,
Тик берүзем аңа табынсам да.

Булырмын мин сөю намазында
Көненә йөз, әгәр кирәк тапсам.
Мәхәббәткә дога кылырмын мин,
Шуның белән җанны коткаралсам.

Бу дөньяның сазы-баткагыннан
Алып кала алсам батырмыйча,
Мин бәхетле, хәтта яшәсәм дә
Сөю таганында атынмыйча.

* * *

Гомер буе шулай яратырга
Ничек була бер үк кешене? –
Буташтырам, ахры, көнем белән
Һәр төн саен күргән төшемне.

Төшләр матур, әгәр башларыңны
Борчымасаң көндез уй белән.
Мин бит борчыйм... Ә төшемнең нидән,
Нидән матурлыгын мин беләм.

## Көтәм...

Көтәм синең номерлардан бер-бер хәбәр,
Кайчагында көткән хәлдә оеп торам.
Мендәремдә урыннар киң, сиңа калган
Җирләренә телефонны куеп торам.

Белмәгәндәй көтәсемне, ничә тәүлек
Килми тавыш, җырлы дәшү йә хат-хәбәр.
Хәлләремне сорау минем, смайлик юллап
Һич югында, авырмыни соң шулкадәр?

Тиен-фәлән генә тора, җибәрермен –
Акчаң юкмы? Корт чактымы бакчаларда?
Корт чаккыры, диеп, сиңа сүгендем шул… –
Һәр теләгем шундук чынга аша бара.

И имансыз, дигән идем, и хәерсез! –
Хәерләрең, иманнарың китте мәллә?
Миңа әйтер җылы сүзең шул мизгелдә
Җир ярылып, ярыгына төште мәллә?

Мәхәббәтсез, дигән идем, мәхәббәтең
Шул минутта бөтенләй үк үтте мәллә?
Мендәремдә урыным тар, дигән сүзем
Колагыңны кылыч кебек кисте мәллә?

Алдадым шул… Сиңа калган җирләренә
Телефонны, телефонны куеп торам.
Мәхәббәтсез, дидем дә бит… Сөям, диеп
Алдавыңнан ничәнче көн оеп торам.

## Дөнья киң, дөнья тар...

Очраттым юлымда.
Исәнме, бәхетем!
Исәнме, язмышым –
Син мине сайлаган.
Сайлавың белән син
Язгы бу көннәрдә
Аралап алгансың
Бәхетсез айлардан.

Хисләрнең гүзәлен
Күр әле көндә, дип,
Аралап алгансың
Күңелсез уйлардан.

Аралап алгансың,
Тапкансың яңадан,
Ай, диеп ялгышам,
Ә бәлки, еллардан?

Ни дип соң уйларга?
Ни дип соң эндәшим?
Исәнме, бәхетем!
Бәхет тә бар икән!
Бер-берсен яраткан
Ярларга кайвакыт
Читлек тә киң кебек,
Аерылсаң...
Дөньясы тар икән!

Роза Туфитуллова

# ЯЗМЫШ ҖИЛЕ

РОМАН

## Акчуриннар килене

*Тимай бай булсаң да – азанчы кумәр.*
«Җыр». Г.Тукай

Сембергә юл тоту янә Истанбул хатирәләрен яңартты. Гөлсем, кайта-кайта, күңеленнән «Төрек йурды»нда Йосыф Акчура белән очрашуларын, аның шәфкать туташларын ничек җылы каршылавын, хәл белешеп, киңәш биреп торуларын искә төшерде. Башкаланың «Мехфаза миллие» җәмгыятенә Төрек оборона фонды өчен хәйрия җыю митингысы да Акчура белән Кәрими тәкъдиме иде[1].

Ул көнне университетка дәрәҗәле ханымнар, принц, паша, бәкләрнең ыспай хәләл җефетләре, язучылар, укытучылар агылды. Укытучы Низхат ханымның сүзләре Гөлсем йөрәгендә аерата тирән уелып калды.

– Без Европада кырык миллион халкы булган Ватаныбызның көчен күрсәтик! Без асылташ, алтыннарыбызны болгар солдаты тартып алсынга сакламыйбыз. Аларны дәүләткә тапшырыйк!

Гөлсемнең битләре кызышып куйды. Ул, үзенең ялкынлы сүзләрен искә төшереп, моңсу гына елмайды:

– Илне саклап калуда катнашуның юллары күп. Бүген шуларның берсе – ханымнарның бизәнү әйберләреннән баш тартуыдыр. Йөрәгеңнән кан саркыганда, атлас күлмәкләргә төренеп, алтын, бриллиантлардан йөрү мөмкин хәлме? Кадерлеләрем минем, миллионлаган апа-сеңелләрнең карашы сезгә төбәлгән. Алар сезнең өчен борчу-кайгыда. Алар сезнең тәвәккәллекне көтә.

Гөлсем, шундый сүзләр белән, үзе махсус тагып килгән алтын муенсасын салып куйды. Бөтен зал, аягүрә басып, аны көчле алкышлар белән озатып калды. Инде һәркем, һич икеләнмичә, үзенең кыйммәтле алтыннарын өстәлгә өя барды.

Йосыф белән Фатыйх абыйлары аның ниләр сөйләячәген алдан белсәләр

[1] Юсупов А. Господа Акчурины. – Казань: Татар.кн.изд-во, 1974.

*Ахыры. Башы узган санда.*

дә, ишегалдында дулкынланып Гөлсемне көттеләр. Йосыф абыйсы куенынннан гына алып ак чәчкәләр бәйләмен сузды. Чөнки Гөлсем бүген сугыш һәм тормыш сәхнәсенең төп героинясы иде...

Акчуриннар дигәндә, шуңа иң элек аның күз алдында Йосыф Хәсән улы Акчура[2] җанланды. Атаклы Сембер купецлары һәм фабрикантларының күренекле бер вәкиленә, XV гасырның кенәз Адаш Акчуралар ыруының затлы, зыялы дәвамчысына сокланулы күңел күзе белән бакты кыз.

Истанбулдан «төньяк төрекләрен» озатырга күпсанлы татарлар җыйналган иде. Рәхмәт һәм хушлашу сүзен дә йөрәкләргә үтәрлек итеп Акчура әйтте. Киләчәктә дә төрки-татар милләтенең югары идеалларына армый-талмый хезмәт итүләрен теләде. Балачактан ук Гөлсем аралашкан даирә дә шундый идеаллар тарафдары иде ич!

1905 елның 20 маенда бөтен мөселман дөньясын шаулаткан, тарихка данлыклы «Чистай туе» булып кергән зур вакыйга моның искиткеч дәлиле. Ул – Ибраһим абыйсының якын дусты, Мөселманнарның милли азатлык хәрәкәте җитәкчесе, сәясәтче, дин, фәлсәфә галиме, язучы Муса Бигиев белән үзе дә акыл һәм гыйлем иясе булган Әсма апасының никахлары. Полиция материалларында «гаять зур туй – митинг» дип мөһерләнгән мәҗлестә нәкъ менә милләт язмышы хәл ителгән. Татарның берләшү мәсьәләләре, кичекмәстән Мөселман корылтае җыю, анда Бөтенрусия мөселманнар партиясе оештыру фикере тәгаенләнгән.

Аннан алар икәүләп фотога төштеләр. Йосыф абыйсы: «Туган илләргә бездән сагынулы сәлам!» – дип, ярда кул болгап, озак кына басып торды.

Инде, гомумән, Акчуриннарга килгәндә, алар Россия империясендә татарлардан иң эре фабрикантлар, постау-сукно җитештерү лидерлары, атаклы Сембер байлары. Сату-алу, сәнәгать һәм хәйрия эшчәнлеге дә буыннан-буынга күчә килә. Кемнәр генә юк бу нәселдә, атаклы сәясәтчеләр дә, беренче журналист, рәссам, археолог, мөгаллим-мөгаллимәләр дә[3]. Гөлсем татарның бу мәшһүр затларын шулай күреп тә, шактый ишетеп тә белә. Хәзер инде аларны туганлык җепләре дә бәйли. Рөстәм Исмаил улы зур байлар исемлегендә йөрмәсә дә, Акчуралар нәселеннән. Чистайның атаклы ишаны, II гильдия сәүдәгәре Мөхәммәдзакирның кызы Шәмсениса Камалова аның хәләл җефете. Ничә айлардан бирле Гөлсемнең күңелен биләп торган кечкенә Равил дә – Акчуриннар варисы.

Шәмсениса монда үзен ничек хис итә икән? Казан, Әмирханнар, Тукайлар белән бәйле гүзәл яшьлек хатирәләре әкренләп онытыла барамы? Гөлсем бик сагынып килә Шәмсенисаны. Ул да шулайдыр. Ни дисәң дә, чит як... Бу кадәр шөһрәтле нәселгә ярап торулары да, ай-һай, бер дә җиңел генә булмас. Йөрәге ни хәл икән, йөрәге?

Уйлар дәрьясы да Иделләргә тиң, очына-кырыена җитәрмен димә. Андый чакта Гөлсем палубага чыгып баса.

«Галибанә яктырып, әкрен генә, ал таң ата...»

Әнә таң атуын дулкыннар ярларга хәбәр итәргә ашыгып йөгерешәләр. Аларга кояшның беренче нурлары ияра. Һәм озакламый, уң яктагы ярлар сөзәкләнеп, калкулык өстендә Сембер калка. Әнә пристань катында җигүле

[2] Йосыф Акчура (1876-1935) – күренекле җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе. «Иттифак-әл-мөслимин» партиясен оештыручыларның берсе һәм лидеры. 1908 елдан Төркиядә яши. Төркия президенты Кемаль Ататөркнең сәясәт һәм мәдәният буенча киңәшчесе, Истанбул университеты профессоры.

[3] Таиров Н. Акчурины. – Казань: Татар.кн.изд-во, 2002.

атлар, кешеләр дә абайлана башлый. Алар арасында Шәмсениса да бардыр. Ул да Идел өстендәге ак пароходны түземсезлек белән күзәтәдер, көтәдер.

...Ә менә Абдулла пароходның бусын гына түгел, инде Идел–Чулман өсләрендә йөзәчәк ак җилкәнле көймәләрне, бизәлгән пар пароходларны, Сембер пристаньнарын, татар дөньясын шаулаткан туй тантанасын да күзаллап өлгергән иде! Гөлсем генә әлегә, эсселе-суыклы булып, Абдулла Акчуринның аны иң элек кочып алуына ни дияргә дә белмичә, Шәмсенисага төбәлгән. Ә анысы тик елмаеп тора бирә. Алай гынамы, Абдулла кызны кочагыннан чыгарырга да өлгерми, ак, йомшак кулын үбеп: «Чибәр каһарман туташ, син минем сөйгән хатыным булырсың! – дип, бөтенләй телдән яздыра.

Ниһаять, чират Шәмсенисага җитә. Ул Гөлсемне кочып, балаларча чәчләреннән иркәләп сыйпый да, башка туганнары кебек үк:

– И бала, сине күрер көннәрем бар икән, – дип, яшь аралаш елмая да, тизрәк таныштыруны мәгъкуль күрә. – Иркә таем, сине баягынак хәйран иткән бу асыл егетебез Абдулла Акчурин була инде.

Абдулла, Гөлсемнең чак кына җитдиләнә төшкән сөрмәле күзләренә тутырып карап, янә бер мәртәбә кулын үпте һәм шушы серле караштa бөтенләйгә «батты» да. Ул – чын-чынлап гашыйк! Ул бу көнне еллар буе хыялланып көтте. Тик Гөлсем генә әлегә боларның берсен дә белми иде. Чистайда Шәмсениса белән Рөстәмнең никахыннан соң, Ибраһим аңа араларында иң чибәре булган кече сеңлесе Гөлсемнең фотосын күрсәтте. Үзенең горурлануын да, уен да яшермәде.

Инде Гөлсемне якыннан күреп, кочагына алу бәхәтенә дә ирешкәч, егет бөтенләй башын җуйды. Шәмсенисаның Абдулланы бу кадәр тәэсирләнгән халәттә күргәне дә юк иде бугай. Җаен китереп, Гөлсемнең дә колагына гына пышылдыйсы итте:

– Канәтем, юкка хафаланма, Абдулла бик акыллы, бик тәрбияле. Һәрхәлдә, сине аңларлык, бәяләрлек кеше.

...Юл бик кыска тоелды. Баскан урыннарында биеп торган атаклы юртаклар, алар утырганын чак көтеп алып, ашкынып юырттылар. Гөлсем белән Шәмсениса бер-берсенә елышып утырган килеш, сорау арты сорау яудырдылар: Рөстәм җизнәсе, кечкенә энекәше ничек? Әнкәсе, туганнары ни хәлдә? Чистай, Казан, Петербург, Төркия хәлләре дә тиз-тизләп булса да барлап чыгылды. Тарантасның беренче утыргычына утырган Абдулла, әледән-әле борыла төшеп, аңа хас җылы, якты бер елмаю белән, кызларның хәлен сорашты: уңайсыз түгелме, туктап алмыйбызмы, ашыйсы-эчәселәре килмиме?

«Рәхмәт»ләре бер тавыштан яңгыраганга, кызлар матур итеп көлешеп тә алдылар.

– Чистай чишмәләре шулай чылтырыйдыр инде, – дип, янә борылып елмайды Абдулла.

Ниһаять, Гөлсем дә телгә килеп:

– Сез дә шагыйрь, ахрысы, Абдулла әфәнде, – диде.

Шәмсениса сүзне Тукайга ялгады:

– И-и, татар йөрәгенә бигрәк тирән яра ясап китте дә соң. Ул көн монда да матәм көне дип игълан ителде. Митинглар үтте, укулар булмады. Тукайны сагынып, яратып искә алдылар.

Абдулла тагын борылды:

– Кем белгән тәкъдирнең шулай буласын? Хәсән абый – Тукай иҗатына мөкиббән кеше. Ярый әле вакытында чакырып калды. Бик тә аны кунак итәсе,

сөйләшәсе килгән иде. Барыш станциясеннән ике тройка белән бергәләп барып алдык, олылап каршыладык. Атнадан артык торып китте. Хөрмәтенә кичәләр оештырдык. Искә алып сөйләр сүзләр күп.

Гөлсем: «Безнеке дә!» – димәкче булган иде дә, тыелып калды.

– Кайтып та җиткәнбез ич, әнә безне каршыларга да чыкканнар, – диде Шәмсениса, әллә каян капка төбендә улын күтәреп торган дустын күреп.

Абдулла аларны тарантастан кул биреп төшерде.

– Кичен күрешербез, сезне кичке ашка көтәбез. Чибәрем, безгә Төркия турында да, Йосыф туганыбыз турында да сөйләр, – дип, Гөлсемнең кулын җибәрмичә торды. Гөлсем дә бу юлы кулын тартып алырга ашыкмады кебек.

Абдулланы чәйгә кыстасалар да: «Башка вакытта, әле фабрикалардан да әйләнеп кайтасы бар», – дип рәхмәт әйтеп, баш тартасы итте. Шул арада күчтәнәчләр, уенчыклар тутырган зур бер тартма биреп:

– Тәти энекәшкә, – диде һәм Шәмсенисага тоттырды да, кул болгап, җәһәт кенә китеп тә барды.

Абдулла киткәч, туганнар да үз иркләрендә калып, ашап-эчеп, сөйләшә-сөйләшә мунчалар кереп, тәмам рәхәткә тиенделәр. Равил бераз көйсезрәк булса да, чынлап та, тәти малай иде. Гөлсемнең аны кулыннан төшерәсе дә килмәде.

– Иркә таем, үзеңә дә уллы-кызлы булыр вакыт җиткән. Акчуриннарга килен булып төшсәң, ким-хур булмассың.

– «Эрләмәгән-сукмаган биатайга күлмәклек» дигәндәй, ни сөйлисең инде?

– Абдулла сүзен җилгә очыра торганнардан түгел.

– Шәмсүк, ә уку?

– Укыган кадәргесе җиткән. Абдулла сиңа чын-чынлап гашыйк. Яшь аермагыз да менә дигән. Куеныңда гына тотар. Бал-майда йөзәрсең.

– Син йөзәсеңме соң?

– Минеке бөтенләй башка. Исмаил каенатай байлар рәтенә кермәгән. (Ни аяныч, «шәхес культы» еллары Акчуриннарның һәммәсен дә диярлек берочтан сөргән. Рөстәм, этисе Акчуриннарда эшләгән өчен генә дә, ун ел төрмәдә утырырга мәҗбүр булган.)

Гөлсем, Акчуриннарның Россия империясендә татарлардан иң эре промышленниклар, фабрикантлар, Сембернең I гильдия сәүдәгәрләре, хөрмәтле, абруйлы гражданнары икәнен дә, алар җитештергән постауларның зур күргәзмәләрдә алтын, көмеш медальләргә лаек булуын да укып, ишетеп белә, билгеле. Хәйрия эшчәнлегендә юмартлыклары, алар төзеткән дистәләрчә мәчетләр, мәктәпләр хакында да бихәбәр түгел. Озакламас, бу нәселнең рухи бай мирасын, аларның да «милләтем» дип җан атуларын, әлеге юлның бихисап каршылыклардан һәм көрәштән торганын күрер. Аларның зур эшчәнлеге белән якыннан танышыр, сокланыр, уйланыр, үзе дә шунда кайнар, һәм бөтен халык башына төшкән сынаулар аларны да читләтеп үтмәс.

...Ә бүген әле тормыш аңа йолдызлы, айлы, хыял һәм сөю тулы бер кичен, алай гынамы икән, киләчәген бүләк итәргә тора.

Абдулла бу кичне ничек җиткерергә белми гаҗизләнде. Фабрикада да озак тоткарланмады. Аш-су әзерләүчеләр янына да әллә ничә сугылып үтте. Йорт-җирләрне, ишегалдындагы фонтаннарны, агач-куакларны, кышкы бакчаларны, өй эчендәге җиһазларны, табынга тезелгән чем-ак фарфор савыт-сабаны эчке бер рәхәтлек белән күздән кичерде. Үзенә кияр өчен бик килешле утыртма якалы ап-ак күлмәген, өстеннән иң затлы коңгырт казакиен сайлады. Әле бер,

әле икенче көзге янында туктап, килеш-кыяфәтен дә «бәяләп» узды. Хикмәт шунда ки, бүген һәрнәрсә ниндидер яңа мәгънә белән тулы: бу җәйге җылы кич тә, сандугачлар сайравы да, буа буенда яңгыраган авазлар да, ак мунчаның тынга капкан кызуы да, салкын чишмә сулары да бөтенләй үзгә, бөтенләй башкача.

Әнә ул хәзер шундый бер дулкынлану белән Чистайның апалы-сеңелле, данлыклы ишан кызларын көтә.

...Ниһаять, капка ачылды. Юк, юк, капка гына түгел, балкып күк капусы ачылды бугай.

...Әнә Гөлсем дә, кәз-кәз генә басып, бәхет баскычларыннан югарыга атлый. Узышлый, бер күз сирпүе белән йорт-җирләрнең бай матурлыгын, җиһазларның затлылыгын, табынның зур зәвык белән әзерләнгәнен, Акчуриннар нәселенең илтифатлы, әмма чак кына сынаулы, горур карашларын да тотып ала.

Акчуриннар... Әнә бүген аның ничәмә-ничә буынында олпат Тимай байның фәлсәфи акылы, кануннары дәвам итә икән. Алай гынамы, тамырларында унбиш буын ата-бабаларының рух ныклыгын, олуглыгын, омтылышларын, милләт сутын саклаган асыл нәсел икәнен Гөлсем инде тоярга өлгергән иде шикелле. Шуңа аның бүгенге миссиясе дә бигүк җиңелләрдән түгел булса кирәк.

Абдулла гашыйк! Монысын биредә көн кебек ачык күрделәр. Хәер, ул аны әллә ни яшерергә дә теләмәде. Алар шулай ук керә-керешкә шәфкать туташының да гаять сылулыгын, чибәрлеген һәм карашының ифрат бер серлелеген абайлап калдылар. Шәмсениса да гадәттәгедән матуррак күренде. Гөлсем һәрберсе белән бик итагатьле, әмма җылы һәм якын итеп күреште. Иң элек әнкәсенең, барлык туганнарының сәламнәрен җиткерде.

Аннан, хуҗалар күңеленә хуш китереп:

– Сембер җирләре, сез яшәгән бу төбәкләр, данлыклы Акчуриннар нәселе безгә әүвәле Шәмсениса аша якын, кадерледер. Аңа булган ихтирамыгыз, яратуыгыз өчен без бик рәхмәтлебез. Инде менә Абдулла әфәнденең безне шулай иртә таңнан каршылавына да, әлеге күркәм мәҗлестә утыруыбызга да ифрат шатбыз. Күңелебез һәрбарчагызга олы ихтирам, ярату белән тулы.

Гөлсемнең бу кадәр сүз рәте, сүз тәме белән сөйләвеннән мәмнүн булган Абдулла, кыздан күзен дә алмыйча, елмая төшеп, тыңлады да тыңлады. Озаграк сөйләсен иде Гөлсем, озаграк дәвам итсен иде бу кич...

– Аннан сезгә бер кадерле әманәт – сәлам дә тапшырырга телим. Ул сезнең кардәшегез, Төркиядә, мөселман дөньясында зур абруй казанган Йосыф Акчурадан туган якка һәм һәрбарчагызга сагынулы кайнар сәламнәр, иң изге теләкләр. Төркиядә Йосыф әфәнденең безгә ярдәме әйтеп бетергесез зур булды. Ул каршылады, озатты. Менә шул вакытларның бер ядкаре, – дип, Йосыф абыйсы белән бергә төшкән фотосын сузды.

Үз нәүбәтләрендә Хәсән абыйсы да, аның гүзәл, зыялы хатыны – Батыр-Гәрәй кызы, Сөләйман Акчуринның оныкчасы Зөһрә ханым да Гөлсемнең Төркиядәге игелекле эшчәнлегенә, каһарманлыгына ихлас бер соклануларын белдерделәр. Гәрчә алар барлык татар мөселман басмаларын алдырып, «Вакыт» газетасында Кәриминең «Истанбул мәктүпләре»н укып, андагы вакыйгалардан хәбәрдар булсалар да, сораулар да шактыйга җыелды. Гөлсемнең җаваплары да хисле-тәэссоратлы хатирәләрдән гыйбарәт иде. Шул арада өстәлгә нинди тәгам-ризыклар гына килмәде. «Чибәрен» туктаусыз сыйлавына, кыставына Гөлсем Абдуллага рәхмәт әйтергә, күзенә тутырып карап елмаерга чак-чак өлгереп барды.

Гөлсемнең күп нәрсәләрдән хәбәрдар булуына, сүз-фикер камиллегенә сокланып, канатланып утырды Абдулла. Кичнең ул көткәннән дә гайре бер табигыйлек, ихласлык белән узуына әйтеп бетергесез шат иде. Тукай шигырьләре кичнең йолдызлы таҗы булды. Гөлсем аларны кабатланмас бер моң, сагынулы йөрәк тавышы белән укыды. Шигырь тәмамлангач та, Гөлсемнең тавышы җанда яңгыравын дәвам итте. Тәмам әсәрләнгән Хәсән агалары: «Афәрин, афәрин, тагын укыгызчы?!» – дип, Гөлсем янына ук күчеп утырды.

– Бик теләп, Тукай минем иң яраткан шагыйрем, – дип, чак кына көрсенеп куйды да укуын дәвам итте:

Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрем,
Билгесездер – кая ташлар бу тәкъдирем;
Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.

Әллә каян гына бер ут күбәләге очып керде. «Тәгаләм, Тукай җаныдыр бу», – дип юрап, эчтән генә көрсенеп тә алдылар.

Билгеле, нәселнең затлы дәвамчылары да Тукайның күп шигырьләрен яттан белә, әмма Гөлсем укуында алар бөтенләй яңача мәгънә алдылар, шагыйрьне җанга ныграк якынайттылар. Мәҗлестән төн уртасы җитәрәк кенә таралыштылар. Шәмсенисага гына, кечкенә улын куеп килгәнлектән, шактый иртә китәргә туры килде. Кучерның җигүле аты инде Гөлсемне әллә кайчаннан җилдереп кенә илтергә әзер тора. Абдулла гына бар вөҗүде белән бу кичнең гомерлек дәвамын тели. Хәсән абыйлары да нык дулкынланган, кичәне ул иртәгә музейда дәвам итәргә чакыра. Һәркем аңлый: бу бик зур ихтирам билгесе.

...Абдулла шактый арган-талган булса да, тиз генә йокыга китә алмады. Аның колагында һаман Гөлсем тавышы яңгырады.

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.

***

Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.

Аһ, ничек итеп әйткән адаш шагыйрь! Бу юллар – борын-борыннан биредә гомер сөргән бабалары, иле, дине, милләте, теле, ыруы, мәгърифәте дип җан аткан, үзеннән соң яхшы исем-ат, дан-дәрәҗә калдырган Акчуриннарның да туган төбәге турында лабаса. Бабалары Абдулла, Курамша, агалары Сөләйман, Әсфәндияр, Йосыф, Ибраһим, этиләре Тимербулат, уллары Хәсән, Якуб, Абдулла үзе дә буыннан-буынга васыять ителгән меңләгән дисәтинә биләмәләрне үзләренең туган җире итеп саклыйлар ич. Киләчәк буыннар өчен аманәт буларак саклыйлар.

Күр, Курамша бабасы этиләре Тимербулатка нинди асыл сүзләр белән язган ул васыятьнамәне:

«Миңа чын-ихлас хөрмәте, бертуктаусыз даими эшчәнлеге һәм угланнарча тугрылыгы өчен... сөрү җирләрен, Гурьевкадагы постау фабрикасын... мәңгегә куллануга калдырам...»

Мәңгегә...

Абдулла бәләкәйдән менә шул җирләрдә аунап-тәгәрәп үскән. Башка байлар кебек ул да өй шартларында атаклы мөгаллимнәрдән яхшы белем алган. Кечкенәдән фабрика тормышы белән кызыксынган. Әтисе Тимербулат һәм абыйлары җитәкчелегендә постау сәнәгатенең иң кыен, катлаулы серләренә өйрәнгән. Егет үзенең гаҗәеп омтылышы, максатчан үҗәтлеге белән барысын да хәйран калдырган. Нәрсәдер хәл итәсе булса, ул, көн димәс, төн димәс, очына чыкмыйча һич туктамас. Хезмәткәрләр дә, эшчеләр дә аңарда легендар әтисенең күп сыйфатларын күрәләр. Аңа ихтирам белән карыйлар. Чөнки ул – һәрчак сүзендә нык торучы һәм иң катлаулы мәсьәләләрне хәл итүче. Ул – чын мәгънәсендә Тимай байның лаеклы варисы. Гурьевка фабрикасының директоры, ширкәтләрнең төп җитәкчесе, иң бай Акчуриннарның бер вәкиле Абдулла Тимербулат улы бүген шундый уйлар, хатирәләр эчендә йөзә. Алла боерса, ул, ниһаять, йөрәк мәсьәләсен дә хәл итәр. Аның балалары да шушы ата-баба җирендә туар һәм яшәр. Аның бүген хыялына һәм бәхетенә иң якын торган көне, дөресрәге, таңы иде.

(Әмма Тимай байның бу бәхетле варисын алда нинди ачы язмыш көткәнен, аның «Азанчы күмәр»гә тиешле иң изге кануннан да мәхрүм буласын, алай гынамы, атаклы җир биләүченең Шифа атлы кызына XXI гасырда кабер өчен өч аршын җир дә табылмасын хәтта фәрештәләр дә фаразлый алмагандыр.)

...Хәсән дә бүгенге хиссияттән тиз генә арына алмады. Аның да хәтерендә яшүсмерләр төсле курач гәүдәле, әмма рухы, шигырьләре белән олпат Тукай җанланды.

Күңел берлән сөям бәхтен татарның,
Күрергә җанлылык вактын татарның.
Татар бәхте өчен мин җан атармын.
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.
Хисапсыз күп минем милләткә вәгъдәм.
Кырылмасмы вавы, валлаһе әгъләм?

– Кем инкарь итәр синең «Үз-үземә» дип язганың безгә дә кагылмый дип?! Әмма милләтне саклау, күтәрү юллары бертөрле генә була алмый, шагыйрем.

Курамша бабам, әнә, татарның кемлеген күрсәтер өчен, 1833 елда Департаментка гаиләсе өчен 8 мең 200 сум акча түләп, үзләрен «Сембер мещаннары» итеп рәсмиләштергән. XIX гасыр уртасында Сембернең Iнче гильдия сәүдәгәре булып саналган.

Акчуриннарга мал-мөлкәт, байлык, абруйлы исемнәр ни-нәрсә өчен кирәк дисеңме? Татар милләтенең данын еракларга яңгыратыр өчен! Милләтне динле, мәгърифәтле итәр өчен! Һәм, бәлкем, иң мөһимедер – башка милләтләр алдында мескен булып, бил бөгеп сөйләшмәс өчен. Үз хисабына ак мәчетләр, җәдидчә мәктәпләр салдыру, ятимнәргә, талантлы яшьләргә үсәргә булышу, кыскасы, татарның син әйткән «җанлылык вакытын», бәхетен, киләчәген күрер өчен. Илгә корылык, ачлык килгәндә, янгын һәм сугыш афәтләре ялмаганда – дөньяга ярдәм кулы сузу өчен. Шагыйрем, болар – Акчуриннар кавеменең күңел кыйбласы!

Ә 1905 елда Гурьевкада митингларның төп шигаре, беләсеңме, нинди иде?! «Бабайга тимәскә!» Бу – халыкның Тимай байга тирән ихтирамы, олы рәхмәте йөзеннән шулай эшләнгән, шагыйрем.

Ә син кәбәм[4] – туры Тукай, бөек Тукай, Аллам рухыңны шат кылсын! Син һаман да милләтнең даны, байлыгы, горурлыгы булып каласың. Гөлсем туташ бүген кабат безне шуңа инандырды. Рәхмәт аңа! Боларны «Үз-үземә» исбатлау да лазем булган, күрәсең, дип, уйларына нокта куйды һәм, үзе дә сизмәстән, таң алдының татлы йокысына чумды.

Гөлсем дә Шәмсенисага «Мең дә бер кичә» төсле серле, озын кичнең дәвамын сөйли. Кечкенә агач караватта, төшләнеп елмая-елмая, әлегә Акчуриннар нәселенең иң нәни дәвамчысы йоклый. Ә Гөлсемнең нигәдер аңа карап елыйсы килә.

– Син инде безне Акчуриннарның башкалары белән чагыштырма. Тауга карап тау булып булмый. Әгәр дә син миңа якын яшәсәң, бәхетле булсаң, шул җиткән. Ә Тукайлы, Әмирханлы Казан – алар йөрәк түрендә урнашкан килеш. Тик минем йөрәкне үзең беләсең.

Алар, кочаклашып, рәхәтләнеп бер елашып алдылар. Аннан, сөйләшә-сөйләшә чәйләр эчеп, тынычланып, тагын Акчуриннарга күчтеләр.

– Хәсән әфәнде – нәселнең алтын баганасы. Гаять зирәк акыллы, киң күңелле гыйлем иясе кеше. Данлыклы коммерсант, мәшһүр меценат. Татарның бай мирасын, Ислам тәгълиматын өйрәнүгә, тарихи-мәдәни истәлекләрен барлауга, җыюга гомерен багышлаган фидаи зат. Ул искиткеч музейны, бай китапханәне үз күзләрең белән күрү кирәк.

...Үз күзләрең белән күрү... Әмма күргәннәрне тиз генә акылга, аңга сыйдырып бетерү мөмкин түгел. Татарның «Эрмитажы»! Бу дәрәҗәдә галим, этрафлы, тәэссоратлы бәян итүчене Гөлсемнең беренче күрүе бугай. Бар вөҗүден татар-төрки дөньясының шанлы дәверләре, гүзәллеге, байлыгы, мәдәнилеге, хиссияте чорный. Гасырлар түрен, йөрәк түрен хан-солтаннар, падишаһлар булып Хәсән Акчурин били. Тарихның сер булып төрелгән рун, туз, тире, күн һәм кәгазь битләренә язылган тылсымлы кайтавазы яңгырап ала. Бар шәркый кыйтгаларның алтын-көмеш акчалары, чулпы, тәңкәләре чыңлап куя. Гөлсем күңеленнән шушы тиңдәшсез мираска, олуг хезмәтләргә бәрабәр асыл сүзләр эзләгән арада, Хәсән аларны үзенең хыял дөньясына алып кереп китә.

Ул – милләте горурланырдай әлеге хәзинәне киләчәк буыннар белән бүлешү, Татарның тарихи музеен, бай китапханәсен рәсми рәвештә төзеп калдыру. Рөхсәт кенә ала алсын... Әмма рус дәүләте аны берничек тә бирергә җыенмый. Моны күптән белсәләр дә, Хәсәннән узып, аның җанына бәрабәр бу теләк-ниятләренә күләгә төшерергә, нидер әйтергә берәү дә җөрьәт итмәячәк. Шулай һәммәсе дә аңа ияреп, хыял канатларында очмакта. Ә Зөһрә ханым – иренең пар ак канаты. Әнә чак кына урнашкан тынлыкны да Хәсәннең һәр тарихи бәһале табылдык өчен мөлкәтен бирергә әзер торуын нинди горур, яратулы сөйләме белән тутырды.

Берочтан үзләренең Германия, Франция, Австриягә сәфәр-сәяхәтләрен дә, Европа шәһәрләренең гүзәллеген, бигрәк тә Венаның архитектурасына гашыйк булуларын, анда нумизмат Хәсәнне балаларча сөендергән табылдыкларны да искиткеч матур итеп ялгап куйды. Аны ничек итеп тыңлауларын гына күр! Мәскәүдә коммерция институтында укучы студент уллары Гомәр дә, аннан кечерәк Мәхмүт тә икесе ике яктан әтиләрен кочкан хәлдә, әниләренә мөкиббән, бәхетле бер елмаю эчендә йөзәләр. Һәм, искәрмәстән, барысының да йөзләренә шул җылы елмаю йөгерә.

[4] Кәбәм – кәгъбәм.

Биредә соклануларның чиге юк. Форсат һәрдаим чыгып тора. Ул зур-зур бүлмәләрдә урнашкан бай китапханә кемне дә «аһ» иттерерлек. Ибраһим абыйларының да төрле ил-җирләрдән җыйган, ә кызларның «су кебек эчкән» татар, рус, француз, алман, гарәп, фарсы, төрек һәм тагын кайбер башка җыентыкларга күз йөртеп чыгуга, китап дөньясы «телгә» килде. Барысы да шау-гөр килеп, берничә телдә аралашып алдылар.

– Афәрин, афәрин! – диде Хәсән, бу көтелмәгән җанлылыкка һәм мәдәнилеккә сөенеп. – Кәбәм, язмыш безне атаклы Камаловларның Акчуриннар хыялланган тагын бер гүзәл мөгаллимәсе белән очраштырды. Татар өчен сезнең дәрәҗәдәге мөгаллимәләр – алтын бәһасе. Мин җиде-сигез ел элек Департаментка җәйге айларда Сембер якларының кырык мөгаллимәсен җыеп, аларны татар грамотасына өйрәтүне һәм яңа алым белән укытуны оештырырга рөхсәт бирүләрен сорап хат юллаган идем.

– Рөхсәт бирмәделәрме?

– Сорауны дөрес куйдыгыз. – Хәсән бу юлы Гөлсемнең күзләренә тутырып, сынап карап торды. – Күңелегезгә авыр алмагыз, анда сезнең дә мөселман иленә ярдәмгә баруыгыз хуп күрелмәстер дип уйлыйм.

Курсистка кызыбыз әле моңа бөтенләй ышанып җитмәсә дә, чынында, бу сүзләр ачы хакыйкатьнең үзе иде.

Ә Сембернең Почётлы гражданины, дистәләрчә мәктәпләр тотучы иң абруйлы меценат Хәсән Акчуринга җавап, беләсезме, нинди булган?! «Мәгариф өлкәсендә сезнең бернинди дәхелегез юк! Рөхсәт бирелми». Йә Аллам, күпме татар бәгъренә кадалган агулы сүзләр, тыю-чикләүләр.

...Бүгенге гаять гыйбрәтле, җаннарны төрле гамьнәр белән баеткан очрашу ахырына якынлашып килә. Алар хәзер Коръәннең бик борынгы нөсхәләре һәм мөселман илләрендә басылган барча Коръәннәр сакланган иң илаһи тарафка юнәләчәк. Гадәттә, гасырларга сәфәр шушыннан башлана яисә шушында төгәлләнә. Уртада яшел постау япкан түгәрәк өстәл, бәрхет тышлы бәләкәй мендәрләр тезелгән, аркасына гаҗәеп тамбур чигешле намазлыклар, йөзле дисбеләр эленгән озын кәнәфи. Идәнгә зур, затлы бохар келәмнәре җәелгән. Биредәге рух югарылыгыннан бер мизгелдә җаннар чымырдап, тетрәнеп китә.

Хәсән «хәзрәт» бүген дә Коръәннәрдән берничә кыска аять укып, кыска гына шәрехләп үтүне дә мәгъкуль күрде. Укыганнарын гаять тәэсирле итеп, кыскалык һәм осталык белән багышлап та куйды. Хикмәти Хода, җаннарның бу гаҗәеп мәкамнән, бу догалардан шулай тиз генә аерыласы да килми икән. Ишан кызларының күңелләре мөлдерәп түгелде...

– Илтифатыгыз өчен һәрбарчагызга рәхмәт! Очрашудан гаять мәмнүнмен. Инде һәммәгезне дә Макай чишмәсенең суы белән тәмләп чәй эчәргә чакырам.

– Хәсән әфәнде, «Макай» – ул сездәге изгеләр чишмәсеме? – дип кызыксынды Гөлсем.

– Менә монысын хәзер Абдулладан сөйләтәбез, яме, – диде Хәсән, төрле сый-нигъмәт, мич ашлары белән тулы табынга дәшеп. – Хәер, кунак кызы башта чәйне эчеп карасын, аннары әйтерсең.

Юка ак фарфор чәшкеләрдә хуш исле чәй килде. Чәй дә, ризыклар да тәмле һәм затлы иде. Гөлсем дә, рәхмәт әйтеп, нәкъ шулай диде.

– Абдулла, хәзер су-чәйләрнең серен ачсаң да ярыйдыр, – дип, Хәсән абыйсы чынаягын тәлинкәсенә каплап куйды.

Абдулла дулкынлана иде.

– Чишмә тикле чишмәләр – изгедер инде алар. «Кешене эчәр сулар йөртә», диләр бит. Тимербулат әткәбезнең безгә ядкарь булып калган сүзләре бар – ул ниндидер сәбәпләр белән моннан китәргә җыенучыларга иң элек шундый сорау биргән: «Син Макай чишмәсенең суын эчеп карадыңмы? Моннан да уңайрак җирне тапмассың, уйла!» – дигән... Бу тирән мәгънәле сүзләрне мин бүген Гөлсем туташка юлламак келим. Атам урынына калган олы агам Хәсән Акчуринның хәер-фатихасын алып, Гөлсем Мөхәммәдзакир кызының гомерлеккә минем сөйгән хәләл җефетем булуын сорыйм. Үтенәм. Мин бу көнне еллар буена, көттем. Юк, гомер буена, дисәм, дөресрәктер.

Абдулла шулай диде дә, куен кесәсеннән бриллиантлар белән бизәлгән алтын муенса алып, күз ачып йомган арада Гөлсемгә кидереп тә куйды.

Гөлсем бу көтелмәгән борылыштан бөтенләй югалып калды, әйтер сүз тапмады. Битләре алланып янды. Хәзер аның йөрәк тибешен бар дөнья ишетәдер төсле тоелды. Ишетмиме соң, аны иң элек мәгърур Хәсәннең гүзәл Зөһрәсе тойды. «Уң канат», иркә генә сыйпап:

– Изге сәгатьтә булсын! Абдулланың тәкъдимен бәхетең итеп кабул ит! Котлыйбыз, Гөлсем канәтем, – дип, кызның күңелен тәмам ярларыннан ташытты.

Барысы да: «Изге сәгатьтә, бәхетле булыгыз!» – дип куәтләделәр. Якуб абыйлары да: «Бәхет-сәгадәт сезләргә», – дип котлап, кәләшкә нәни генә тартма сузды. Гөлсем тагын да ныграк каушады. Шәмсениса кулын катырак кыса төшкәч кенә, үз хәленә кайткандай булды.

– Зинһар, кичерә күрегез, мин бөтенләй каушап калдым. Рәхмәт! Барысы өчен дә, һәрбарчагызга олы рәхмәтем, олы ихтирамым. Ләкин бит әле минем институтны тәмамлыйсым бар.

– Язган булса, анысы да хәл ителер. Шәмсениса килен, син безне иртәгә кияү коймагына чакырасыңдыр ич? Рөстәм дә иртән кайтып җитәргә тиеш. Калганнарын шунда киңәш-табыш итәрбез, – дип, сүзен йомгаклады Хәсән агалары.

Шәмсениса да сүзен тиз тотты:

– Иртәгә барыгызны да төшке ашка көтәбез. Хәсән ага, Алла боерса, коймак та пешәр, бәлеш тә. Чәйләр дә эчәрбез, сөйләшербез дә.

– Хуш, күркәм җавап, Шәмсениса. Шатланып күрешергә язсын, – дип, Хәсән аталарча бер җылылык белән озатып калды.

* * *

Шәмсениса әлеге кунак төшерүләргә күңеле белән әллә кайчаннан әзер иде. Шуңа бүгенге табын аеруча затлылык, күркәмлек белән аерылып торды. Бибифатыйманың кызлары аш-су әзерләргә дигәндә осталарның остасы. Ялт-йолт китерделәр. Тәңкә зурлыгы гына «кияү коймаклары», уймак тикле генә «кияү пилмәннәре», чистайча каз бәлешләре, каклы катламалар, балга катырган бавырсаклар – барысы да нәзакәтле иде. Кунаклар үзләре дә күп күчтәнәчләр, зур бүләкләр белән килгәннәр. Көн генә болытлабрак китте, аның каравы, кояш урынына Абдулла балкыды. Тәти улы белән кунаклар каршылап торган Рөстәм дә бүген гаҗәеп ачык йөзле иде.

Сөйләшүләргә килгәндә, анысы аерым бер күркәмлек, итагатьлелек белән барды һәм бер атнадан Чистайга кыз сорарга кайту, никах укыту, бер айдан туй дигән карар белән тәмамланды. Аңардан соң иң тәмлесе – Җукәтауның чәчкә-үләннәре, төрле җиләк-җимешләреннән төнәтелгән

«Чистай чәе» иде. Шулай итеп, табыннар да, күңелләр дә түгәрәкләнде. Язмыш дигәнең өч көн эчендә Гөлсемне Акчуриннар килене итеп тәгаенләп тә куйды.

* * *

Инде туйларга килгәндә, тирә-якта аларның тиңе юк иде кебек. Гаҗәеп зиннәтле, купшы, мул һәм бик тантаналы үтә Абдулла белән Гөлсемнең туйлары. Күпсанлы туганнары һәм якыннары бирегә Чулман һәм Идел буйлап Сызраньга хәтле пароходта, аннан махсус поездда киләләр. Туйны тәэмин итү өчен, Сызраньнан югары класслы белгечләр, пешекчеләр, официантлар, чәчтарашлар, фотографлар һәм тынлы оркестр чакырыла. Туй тантанасы мылтыктан атулар, фейерверклар, салютлар балкышы белән таң калдыра. Аннан да бигрәк күпләрне кәләшнең күз явын алырлык ак, затлы туй күлмәге, йөзектән үтәрлек сылулыгы, чибәрлеге, серле карашы, эчке бер җылы нуры сокландыра һәм көнләштерә дә иде бугай. Бу әкияти матур туйда чакырылган күпсанлы, дәрәҗәле кунаклар гына түгел, Гурьевка һәм Карасун өязе һәм башка төбәкләрдән килүчеләр дә бәйрәм итә.

Матбугат битләреннән Акчуриннарның 1913 елның 15 июлендә узачак дәрәҗәле туе бар мөселман дөньясына мәгълүм була. «Котлауларның, бүләкләрнең исәбе-хисабы юк иде», диюләре дә хактыр. Хәер, кияү-кәләшнең үз бүләкләре дә хасиятләп уйланылган, юмарт була. Атналар буена Идел–Чулман киңлекләрендә оркестрлар белән пар ак пароход йөзә. Атаклы Акчуриннарның онытылмас һәм кабатланмас туй манзарасын яр буендагы эреле-ваклы шәһәр-авыллар, тирә-як халкы хәйран калып күзәтә. Кыскасы, мәхәббәт тантана итә.

Гөлсемнең тормышына, язмышына ак җилкәннәр, ак пароходлар белән килеп кергән Сембер егете шәфкать туташының күңелен акыл, зур ярату белән били. Җан шагыйре булган Тукайны югалту кайгысы да, Төркиянең фаҗигале көннәре дә әкренләп томан артына күмелә бара. Абдулла кызның йөрәгенә укмашкан борчу-сагышларын бүлешерлек, киңәш-табыш бирерлек, җилкәсенә башын куеп ял итәрлек ир була. Болар өчен ул Абдуллага әйтеп бетергесез рәхмәтле.

Бирелә яшь киленне көн туган саен йә берәр шатлыклы яңалык, йә берәр сәфәр-сәяхәт көтә. Абдулла беркөнне Гурьевкадан (Барыш) алып, Сембер, Сызрань, Сенгилеев өязендәге Акчуриннар тарафыннан ачылган һәм алар акчасына көн күргән мәктәп-мәдрәсәләрне, мәчетләрне күрсәтеп чыкты. Ул төнне Гөлсемнең күзенә бер тамчы йокы кермәде. Сөенү катыш соклану, искитәрлек фидакарьлек! Менә кайда ул татар рухы, тел, дин өчен җан ату, милләтне үстерү, укымышлы итү, тәрбияләү. Акчуриннар, чыннан да, игелекле нәсел, олпат нәсел. Хәзер инде Гөлсем дә – аларның бер вәкиле. Хәзер аның да күптәнге хыялы тормышка ашачак: ул кызлар мәктәбендә мөгаллимлек итәчәк һәм балаларның иң яраткан укытучылары булачак...

...Кайбер көннәрдә алар төнгә чаклы фабриканың исәп-хисаплары белән утыралар. Гөлсемгә үзенең математикадан көчен, осталыгын күрсәтү аеруча рәхәт була. Абдулла да хәйләкәр, аңламаганга салышып төрле сораулар яудыра, чөнки Гөлсемнең үзенчә исбат итәргә тырышуы, Бестужев курсларын бергәләп «үтү» – аның өчен гомернең иң кадерле, матур мизгелләре.

Кайбер кичләрдә Абдулла сөйгәненә Россиянең төрки-татар, мөселман дөньясында зур роль уйнаган нәсел-нәсәп элемтәләрен сөйли: Дебердиевлар,

Юнусовлар, Апанаевлар, Максутовлар, Солтановлар, Шәкуловлар, Баишевлар, Барудилар... Шушы урында туктый да, серле елмаеп, сыный төшеп, Гөлсемгә текәлә. Килен балакай озак көттермичә телгә килә:

– Абдулла кәбәм, ә данлыклы Камаловлар кайда соң?!

Абдуллага исә шул сүз генә кирәк.

– Минем йөрәгемдә, Гөлем. Йөрәгемдә, – дип, Гөлсемне нәфис иңнәреннән кочып, кайнар наз, ярату сүзләренә төрә.

Гөлсемне бу якларга, бу нәселгә чынлап бәйләгән тагын бер вакыйга бар. Ул – легендар Тимай бай – Тимербулат Курамша улы Акчуринның гомер юлы белән бәйле истәлекләр[5]...

Әтисенең тәүлекләр буе фабрикадан чыкмыйча фидакарьләрчә эшләве, оештыручы таланты үз җимешен мул биргән. Төсе, сыйфаты белән дөнья базарларын яуларлык нинди генә сукно-постаулар, төрек, болгар, рус армияләре өчен шинель материаллары җитештерелмәгән. Легендар фабрикант Думаларга сайланган, өязнең җәмәгать эшләрендә катнашкан, дәүләтнең «За усердие» дигән көмеш һәм алтын медальләренә лаек булган. Болары 1880-1981 еллардагы ачлыкта хәйрия эшләре өчен бирелгән.

Кышкы салкыннарда халыкның күп өлеше ачлыктан интегә, ачлыктан кырыла. Менә шул көннәрдә, гыйнвардан алып игеннәр өлгергәнче, Тимербулат әтисе иске Тимошкинода бушлай ашханә оештыра. Көндезге һәм кичке ашларга өч йөзгә якын кеше җыела. Ә җәмгысы бу вакыт эчендә кырык бер мең кеше тукланган. Бирегә кайлардан гына килмәгәннәр дә, кемнәр генә рәхмәт укымаган. Һәрдаим халыкны кайгырту! Менә нәрсә шаккатыра Гөлсемне.

1891 елгы ачлыкта бушлай ашханәнең ишекләре тагын ачылган. Тимай бай мосафирлар өчен итен дә, ипиен дә, акчасын да кызганмаган. Алай гынамы?! Гражданнар сугышында яраланган хәрбиләр өчен хастаханә ачу, янгын көл иткән 240 хуҗалыкка матди ярдәм, аларны мал-туар, кием-салым, утын, ашлык, ипи-чәй белән тәэмин итү – боларның барысын-барысын сиксән яшьлек әти-карт үзе кайгырткан...

Әйтерсең, Гөлсем бу ачлыкларны, янгыннарны үзе кичерде, күзләреннән өзлексез яшь акты. Җаны-йөрәге Тимай байның шушы мәрхәмәт-шәфкате, юмартлыгы өчен чиксез рәхмәт, ихтирам хисләре белән тулды. Менә аның Абдулласы нинди ата баласы! Гөлсем әнә нинди нәселгә килен булып төште. Аның үзенә дә тырышып мөгаллимлек итәргә, хәйрия эшләрендә катнашырга, ярату, игелекләр белән яшәргә!

Гөлсем бу кичне Абдуллага иркәләнеп сыенуга ук йокыга талды. Һәм төшендә Тимай байның алдында торган сый-ризыкларның күплегенә шаккатып уянды. Аның күзе ак касәдәге мүк җиләгенә төшкән иде. Хәзер әнә шул җиләк авызыннан сулар китерә. Өзелеп ашыйсы килә.

...Калда авылыннан дүрт-биш чакрым ераклыкта Акчуриннарның җәйге дачасы урнашкан. Бирердәге шаулап торган ак нарат, чыршы урманнары Кырлай урманнарына аваздаштыр. Абдулла ул якларны барып күрмәсә дә, монда килгәч, Тукайның «Шүрәле»сен искә төшерми калмый. Бүген дә алар, Гөлсем белән бер-берсен бүлә-бүлә, «Шүрәле»не укыйлар.

Бик хозур! Рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы, нарат;
Төпләрендә ятканым бар, хәл җыеп, күккә карап.

[5] Багиров Н. Акчурины. – Казань: Татар.кн.изд-во, 2002.

Шулай ярыша-ярыша сөйләп, кече күлгә килеп җиттеләр. Аннан арырак китеп, ак мүк арасыннан җиләкләрен сыдырып кына җыя торган сазлыкка йөгерделәр. Менә шунда Гөлсемнең учлап-учлап ачы җиләк ашавын елмаеп карап торды да бар дөньяга аваз салды:

– Чибәрем! Безнең улыбыз булачак ич! Абдулла Акчуринның дәвамчысы, Гөлем! Ишетәсеңме? Рәхмәт сиңа! Икенчесе кыз булыр, нәкъ синең төсле!

Йөзьяшәр урман җиләс, рәхәт бер шаулау белән кайтавазны таратты...

Абдулла үзенең бүгенге «ачышыннан» тәмам әсәрләнде. Гөлсемгә учлап-учлап җиләк, кочак-кочак чәчәк җыйды. Арыганчы кулларында күтәреп йөрде.

Әти кешенең юраганнары юш килде. Башта – улы Яхъя, тагын бер ел дигәндә кызы Сафура туды.

Гөлсем исә кызлар мәктәбендә укытуын яратып дәвам иттерде. Ә ул булган һәр җирдә Тукай иҗатына чиксез мәхәббәт, ихтирам хөкем сөрә. Казанда «Шәрык» клубында, «Яңа клуб»та, Эрмитажның җәйге театрында, Панаев бакчасында әдәби-музыкаль кичәләр оештыруда җиң сызганып йөрүче Гөлсем, бөек шагыйрьнең вафатына ике ел тулу уңаеннан, Гурьевкада «Тукай кичәләре» оештыра. Соңгысында Гөлсем Акчурина үзенең 50 сум хезмәт хакын кушып, «Кояш» газетасы идарәсенә 97 сум акча җибәрә. Бу – шагыйрьнең каберенә чардуган һәм хәтер ташы куюга керткән иң зур хәйрия булып теркәлә.

## Язмыш җиле

*Якын дустым! Сиңа миннән киңәш шул:*
*Кешеләргә сереңне сөйләмәс бул.*
*Эчеңдә нәрсә янганын үзең бел,*
*Үзең кайгыр, үзең егъла, үзең көл.*
«Киңәш». Г.Тукай

Җилләр генә агач башыннан йөридер. Калганы кеше башыннан. Хәер, язмыш җиле бүген үзе дә елый-елый Акчуриннар утырган юргаларга сарылмакчы. Соң мәртәбә куеннарга, йөрәкләргә кереп җылыга уралмакчы. Һәм ашыга-кабалана чана эзләрен ак карга күмеп калдырмакчы. Язмыш җиле шулай гаҗизләнеп төн карасына кереп баручы гомер юлының әле алдына, әле артына төшә. Китәләр!.. Туган җирне ташлап китәләр! Китәргә мәҗбүрләр...

Аһ, әле кайчан гына бәхетләр, тормышлар түгәрәк иде. Сембернең тыныч бер почмагына төпләнеп калган Гөлсем үзеннән артык күреп сөюче Абдулланы да, күз карасы кебек балаларын да, яратып мөгаллимлек итүен дә язмышның бәхетле-сәгадәтле еллары санап, куанып яши иде. Ни кызганыч, әмма бу җирдә бәхет гел кыска вакытлы. Дөньяның бер чите гел кителеп тора. Башта Беренче Бөтендөнья сугышы адәм баласын зар елата. Аннан бөтен Россияне чорнап алган революция дулкыны илнең өстен аска әйләндерә. Болар һәммәсе дә язмышка язылганмы икән?! Югыйсә Акчуриннар Сембер җирләренә килгән төрле афәтләрне, кайгы-хәсрәтләрне дә аз күтәрешмәде. Кемнең нинди милләттән, кайсы диннән булуына карамастан, кылынган игелекләре дә аз түгел кебек иде...

Исең-акылың китәрлек, бер дигәнче, бар мал-мөлкәтләре тартып алынды, йорт-җирләреннән куылдылар. Ихтимал, Якуб абыйларының карары дөрес булгандыр. Ул, гаиләсен алып, унҗиденче елда ук тынычрак якларга чыгып китте. Кендеге белән шушында береккән Абдулла гына ата-баба җирләрен, каберләрен алай тиз генә ташларга теләмәде. Ярый әле Хәсән абыйлары бу

мәхшәрне, бу дәрәҗә кимсетү-тарлыкларны күрмичә, мәңгелек йортка күчеп өлгерде. Әмма аны сагынулар, аның белән бәйле якты истәлекләр әйтеп-сөйләп бетергесез. Дөнья бәһасе туганы исән булса, хәтта язмыш сынаулары да җиңелрәк кичерелер сыман иде Абдуллага. Менә шулай уйлары белән үткәннәрне урап, Тимай байның кече улы атналар буе кеше күзенә чалынмаска тырышып, газизләрен яд итеп, зиярәт кылып, хушлашып йөрде.

Гөлсем дә хушлашты. Үзәкләрен иң өзгәне – Шәмсениса белән аерылышу булды. Кулында яңарак кына туган сабые. Үзе минут саен йөрәген тота. «Йә Аллам, син барында көннәрем кояшлы иде әле, – дип, Гөлсемне кочаклап елады да елады. – Башка күрешә алмабыздыр инде...»

– Язмышныкын белмәссең, Шәмсүк. Ул кадәр төшенкелеккә бирелмик әле.

– Алай да бәхилләшеп калыйк. Сезгә рәхмәт. Юлларыгыз уң булсын. Исән-имин йөрегез...

Гөлсемнең ярты җаны шунда калды бугай. Аның, ичмасам, таянырга Абдулласы бар. Алай дисәң, бу вакыйгалар аны да нык сындырды. Ул бер мәлгә бөтенләй югалып калды. «Гөлсем ни әйтер?» – дип, озак кына аның күзләренә карап торучан булды. Ходайның рәхмәте, яраткан хатынының тагын әллә ничаклы асыл сыйфатлары ачылды. Иренең көенечләрен шушы сөенечләр юа төште. Өмет бөреләнде.

Әнә бүген дә алар йөрәкләре, җаннары белән бер-берсен сүзсез тойган, кулларындагы иң зур байлыкларын, йокыга талган Яхъя белән Сафураны күкрәкләренә кыскан хәлдә, кеше-кара күзенә чалынмаска тырышып, «Барыш» станциясенә юл тоталар. Легендар аталары төзеп калдырган, кайчандыр кыңгыраулы пар атларда Тукайны каршылаган, Бибифатыйма әнкәләре сөенә-сөенә, төянеп-ясанып бәби туйларына килгән юлдан, бетмәс-төкәнмәс күңел хатирәләре юлыннан.

Язмыш җиле бүген соң дәрәҗәдә чарасызлыктан гаҗиз. Ул әле юргаларның алларына чыга-чыга кар түши, әле аны җәяүле буран итеп кырга куа. Аннан артка калып, хуҗаларын аклап, әллә сөйли, әллә елый, әллә сагышыннан сыкрап улый:

– Китә-ә-ләр! Кәбәм, туган якны ташлап китә-ә-ләр! Вата, китәргә мәҗбүрлә-әр...

Әйе, китәргә мәҗбүрләр. Юкса Акчуриннарның бу җирдә хаклары да аз түгел. Абдулла белән Гөлсемнең икесенең дә йөрәгеннән – кан, күзеннән яшь тама. Ләкин аны бүген ятка түгел, бер-берсенә дә күрсәтәселәре, белгертәселәре килми. Хәзергә исемнәре каралса да, күр, әнә аларның ак нияттән эшләнгән никадәр ядкарьләре калды. Акшуатның картиналарында сакланачак ак мәчетләре генә түгел, мөселман-татар дөньясының күпме тарихи мирасы, байлыгы, китаплары; меценат Акчуриннар ярдәме белән илнең, төбәкнең төрле почмакларында төзелгән мәчет-мәдрәсәләр, мәктәпләр; алар акчасына белем эстәгән йөзләрчә-йөзләрчә балалар, талантлы яшьләр. Алар төзеткән фабрикалар, йортлар, тулай торак, мунча, базар, хастаханә, вокзал, буа-күлләр, электр, телефон үткәргечләре. Һәм дә ач, салкын кышларда меңәрләгән кешеләр үзләренең исән калуларына, ничә йөзләгән хуҗалыклар янып көлгә әйләнгәннән соң, йорт-җирле булулары өчен, нәкъ менә Акчуриннарга бурычлы түгелмени?!

Беренче Бөтендөнья сугышында армияне шинельле итәрлек тукыма җитештерү өчен, тәүлекләр буе эшләүләр дә әллә җиңелдән булганмы?! Әмма алда адәм балаларын тагын да авыррак сынаулар көтә. Репрессия!

Акчуриннарның күпмесе репрессия корбаны булыр. Нәселе урыслаша барыр. Хәер, алар гынамыни, дөньясы белән шулай. Чоры шундый...

Әлегә бүгенге төн генә шулай караңгы кебек. Хәер, алар бу араларда гел айсыз-нисез кара төндә йөрделәр. Абдулла соңгы кабат фабрика, буа, йорт тирәләрен урап кайтты. Гөлсем дә, кичкырын үзе укыткан кызлар мәктәбенә барып, тактага акбуры сынганчы басып-басып язып калдырды: «Без китәбез, сез каласыз... Бүген барыгызга да «5»ле. Гөлсем апагыз. Мин сезне сагынырмын».

...Ниһаять, станциягә килеп җиттеләр. Уйлар тиз генә йомгакка уралды. Бертавыштан балалар елашып уянды. Инде яраткан кучерлары, яраткан юыртаклары белән саубуллашыр вакыт җитте. Абдулла, гадәтенчә, атларга кесәсеннән икешәр шакмак шикәр чыгарды. Үз гомерендә беренче кат ул алар өчен балаларча шикәр урлады. Колын чагыннан кулыннан сөт эчереп үстергән ак кашкалары бүген беренче кат шикәргә үрелмәде. Абдулла аларның парланып сыкылаган ялларыннан, башларыннан сыйпады. Һәм имәнеп китте: аларның күзләреннән мөлдер-мөлдер яшь ага... Атлар елый! Абдулла түзмәде, әле берсенә, әле икенчесенә яңагын куйган килеш үзе дә үксеп-үксеп елады. Аерылышуның иң авыр минутлары иде бу...

Алай гынамы, озата килгән язмыш җиле дә аларга кушылып сыкрап сыктады. Аннан һәркайсысын үзенчә яратып, сыйпап-иркәләп үтте. Чөнки ул, ни дисәң дә, туган як җиле ич. Ул бары язмыш кушканны гына үтәүче. Ә чит җирләрдә аларны башка язмыш җиле каршылар. Хәзергә алар Мәскәүгә, Хәсән абыйларының тол калган, инде ике ел сагыш-сагыну утларында януы Зөһрә җиңгәләренә юл тота.

– Киттеләр! Кәбәм, туган яктан киттеләр! Вата, китәргә мәҗбүрләр...

Язмыш җиле шулай боегып кына, төн кунарга, үз оясына Сембер, Калны урманнары тарафына борылды.

Хәзер иң биек нарат башына менәр дә ылыс бишегендә җай гына тибрәнеп йокыга талыр. Юк, юк, ничек йокыга талсын, язмыш җиле ничек аларның үзләрен генә калдырсын ди.

– Кәбәм, чит җирләрдә тагын нинди җилләр каршылар?! Тагын да ачырак, хәтәррәк булсалар...

Алар туган якның үткәндәге җылы, йомшак күңелле җилен сагынмый булдыра алмаслар... Ул да «үзенекеләр» белән хушлашсын да... Җил бер дигәнче, агач башларын тибрәтә-тибрәтә, бар урманны шаулатты. Аннан, бар көченә юлда очраган һәрнәрсәгә бәрелә-сугыла, ашыгып, поезд артыннан куа китте.

...Һәм, ниһаять, тыны-көне бетеп, Акчуриннар утырган соңгы вагонга килеп сарылды.

...Инде аларның язмыш юллары бу якларга башка беркайчан да төшмәячәк. Туган якның язмыш җиле башка беркайчан да алардан аерылмаячак һәм... соңгы сулыш булып... мәңгегә йөрәкләрендә калачак.

* * *

Мәскәү умарта корты кебек гөж килә. Зөһрә җиңгәләре яшәгән Мәскәү чите чак кына тынычрак сыман. Хәсән Акчурин Мәскәүдә укучы студент уллары өчен бик зур булмаган ике катлы йорт алып калдырган иде. Абдулла белән Гөлсемгә билет юнәткәнче шактый торырга, салкын кичләрне җылы хатирәләр белән җылытырга туры килде. Мәскәүдә чын мәхшәр. Атыш, үтереш, кычкырыш. Вокзалларга баш тыккысыз. Халык дулкыны

бер-берсен су өстендәге йомычка кебек әле бер, әле икенче якка чыгарып ыргыта.

Ата – улны, ана кызны белми. Себер, Петропавел якларына китүчеләрнең дә исәбе-хисабы юк. Билет алуның, вагонга кереп утыруларның кыенлыкларын әйтеп-сөйләп бетерә торган түгел. Кечкенә балалары бар кешеләргә бу хәлләр сират күперен кичүгә тиң иде бугай.

Акчуриннарның казакъ далаларына, Петропавел-Кызылъяр якларына юл тотулары әлегә иң дөрес карарларның берсе иде. Чөнки анда Абдулланың кыз туганы Гөлсем бу шәһәрнең атаклы сәүдәгәре, финансисты, Бөтенрусия мөселманнары шурасы әгъзасы Мостафа Хәсән улы Тюменевта кияүдә булып, электән үк бер-берсе белән яхшы мөгамәләдә иделәр. Абдулла гаиләсен якты чырай белән каршылап, үзләрендә урнаштырдылар. Иң мөһиме: әле бу тирәләрне революция ялкыны ялмап өлгермәгән. Шәһәрдә ак чехлар хуҗа. Адмирал Колчак исә Иртыш буйларында Сибирия дәүләте төземәкче.

Шәһәр нугай, казакъ, үзбәк сәүдәгәрләре белән тулган. Татарлар да аз түгел. Мәчетләрдә күпчелек татар имамнары хезмәт итә. 1918 елда Самараны кызыллар алгач, Милли идарә, Финанс идарәсе дә бирегә күчәргә карар кыла.

Мөфти Галимҗан Баруди хәзрәтләре үзенең «Кызылъяр сәфәре» исемле сәяхәтнамәсендә болай дип яза: «Шәһре Петрпавл казакъ эчендә иң мәдәниятле, мөселман рухлы шәһәр. Эчке Русиядән килмә нимес, латыш, хахул бу сахралардан вә саир казакъ далаларыннан күп истифадә итеп баеп яталар. ... Йирле халык үз йирләренең бик кадерен белми... Ишим елгасы буенда тау итәгендә урыс вә нугай төпләнеп, мәсҗед вә чиркәү бина итеп шәһәргә бер төс бирмешләр. Янгыннан һәм су басулардан соң, шәһәрнең байтак өлеше тау өстенә күчерелмештер... Байтак ерак мөсафәдән ак гыймәратләре, мәчет манаралары күренә башлый икән. Барлыгы тугыз мәхәллә, җиде мәсҗед бар. Мосафирлар күп. Бохара вә Ташкентка баручы шәкертләр юлы да булмыштыр. Аларга ихтирам зур. Казакъ халкы әхлагын мәдәният берлә бозмаганнар»[6].

Әлегә монда сату-алу, сәүдәгәрлек эшләре дә гөрләп бара. Эчке Русиядән кызыл мал, чәй, шикәр, кием-салым, казакидән тире-йон, ит, мал-туар китерелсә, Төркестан пахта, фәс, чапан һәм дә төрле тукымалар белән дан тота. Сату-алуның бар нечкәлекләре белән таныш Абдулла да сәүдәгәрләр төркеменә кушыла. Гөлсемнең дә үз хыялы: мөгаллимлек итүенең кайчандыр мөлдерәмә тулып торган бәхетен тагын беразга гына булса да кире кайтару. Укучыларын үзе яраткан математика серләренә төшендерү һәм Тукайның бөек шигърияте белән хәйран итү.

Язмыш җиле биредә Гөлсемне куанычлы хәбәрләр белән каршылады. Гаяз Исхакыйның да «Кызылъҗар»да булуы аңа канатлар куйды. Һәм ул ашыгычлык белән Милли идарәнең эш урыны булган «Яшел мәдрәсә»не эзләп китте. Әдип әле декабрь аенда гына чыга башлаган «Маяк» газетасының да баш мөхәррире иде. Гөлсем Кызылъярга килүгә үк, Тюменевның зур бер өстәленә җәеп салынган газеталарны тиз-тиз күздән кичереп алды. Гаяз абыйсы һаман шул «милләт» дип җан ата. Үзенә таныш исемнәрне күреп, Гөлсем тәмам алгысыды. Казакъ шагыйренең дә шигырьләре нык тәэсирләндерде. Магҗан... Казакъ халкының да менә нинди талантлы шагыйре бар икән. Казакъның «Тукае» диярлек... Дәрдемәнднең шигъри авазлары да яңгырап китә. Гөлсем укый, укыган саен таң кала.

6 Баруди Г. Кызылъяр сәфәре. – Казан: «Иман» нәшр., 1425/2004.

Киң дала, күрәсең гуй, ана җаткан,
Җебәктән җәсел чүпкә[7] битен җапкан.
Аскар[8] тау, балдан татлы сулары бар,
Ана шул анам иде мине тапкан.
«Айга»

***

Ике дөнья: Көн һәм Төн... Гомер – Үлем...
Берсе – бишегең... Ә берсе – әзер гүрең.
...Бала булып ята бер бишегеңдә
Сары дала иркәсе – казакъ илем!
«Урал»

***

.............................................................
«Су бул!» – дидең, челтерәп акмадыммы?
Йөз уралып, еландай ятмадыммы?
Ирке чикләнгән судан татыр җанны
Челтрәүдән сихерләп тапмадыммы.
«Җан авазы»

...Гөлсем, Иртышның иң зур кушылдыгы Ишим елгасы ярында урнашкан Кызылъярны күзли-күзли, җил-җил тауга күтәрелә. «Сары дала иркәсе туңып ап-ак карга чумган. Һун далалары ерак гасырлар эченнән тын гына вакыт, заман агышын күзәтә. Язмыш җиле бүген иксез-чиксез дала ихтыярында.

...«Яшел мәдрәсә»не табуы әллә ни кыен булмады. Янәшә торган ишекләрнең берсен сак кына шакуга, эчтән: «Керегез, кер, ачык», – дигән тавыш яңгырады. Гаяз абыйсының таныш тавышы! Ниһаять, Гөлсемнең җанына җылы йөгерде. Суыкта туңган бит алмалары тагын да алсулана төште. Йөрәген сөенечле бер дулкынлану биләде. Иң элек ачык ишектән Гөлсем белән бергә, әйтерсең, иртә яз, ак сиреньнәр исе бөркелеп керде. Гаяз абыйсы башта каршында затлы кеш туныннан, ханбикәләр кыяфәтле, серле елмаюлы Гөлсемне күрүгә, бер мизгелгә бөтенләй югалып калды. Аннан, куанып, бар тавышына оран салды:

– Беләсезме бу кем, беләсезме?! Бу – «Зөләйха»ның кульязмасын саклап калган Гөлсем Камалова! Бу – безнең Чистай чибәре, минем якташым, горурлыгым, бөтен Төркияне сокландырган атаклы шәфкать туташы! – дип тезде дә тезде. «Минем сүгәнем», дияр сүзләре чак-чак тел очында эленеп калды.

– Бу олпаты – татар театрының атасы – Габдулла Кариев, – диде, таныштыруга күчеп.

– Хәбәрдармын. Казанда «Зөләйха»ны куйганын да ишетеп беләм.

– Качып-посып булса да, мин дә карау бәхетенә ирештем.

– Ә нигә «Зөләйха»ны монда да куймыйсыз? – дип сүзгә кушылды бер читтәрәк утыручы казакъ кешесе.

– Театр бинасына чехлар ашлык салганнар. Ишетмәгән идеңмени? – диде Исхакый.

Магҗан, гаҗәпләнүен белдереп, башын шактый озак чайкап торды.

– Хәзер инде бу дөньяда бернәрсәгә дә гаҗәпләнәсе юк, – диде Фуад Туктар, егетнең җилкәсеннән кагып.

[7] Ефәктәй яшел үлән белән.
[8] Биек.

– Чистайның гаҗәпләнүдән туктаган Туктары белән таныштырып торасы юктыр.

– Без – күптәнге танышлар, – дип, алар беравыздан әйтүләренә көлешеп тә алдылар.

– Монда Чистайдан да, Казаннан да күргән-белгән җитәрлек.

– Шулайдыр. Без дә менә Кызылъярга сыенырга уйладык.

– Кызылҗар әлегә тыныч, кунакчыл урын. Борынгы һун бабаларыбыз җире. Дала киңлеге, дала ирке безнең барыбызның да канында. Магҗан – казакъ кардәшебез. Зур шагыйрь. Ул да эзәрлекләүләргә дучар. Бу дөньяның авыр сынауларына тарыган. Хатынын, улын югалткан. Күптән түгел генә тоткынлыктан азат. Шагыйрь, язучыларга нинди ялган гаепләр тагылуын син беләсең... Дала бөркетенең дә яралы чагы...

Магҗан... Зыялылыгы кыяфәтенә чыккан. Әмма җаныннан, күзләреннән әйтеп бетергесез сагыш, моң саркый. Бу кадәр дә моңсу, тирән, сихри карашка Гөлсемнең моңарчы юлыкканы да юк шикелле. Шәфкать иясенең йөрәге шунда ук «телгә» килде:

– Бәлкем, мин сезгә нәрсә беләндер ярдәм итә алырмын?..

Йә Аллам, Тукайга шулай ярдәмгә килергә теләп, бер янган иде түгелме соң?! Тукай шигърияте белән шыплап тулган җанында бүген тагын бер шагыйрь урын даулый түгелме соң?! Шигъри сүз дигән тылсымга Гөлсем балачактан ук мөкиббән. Тагын шул кадәресе дә бар: үзең әлеге игелекле илгә сыен да, үзең игелексез булып кал, имеш. Юк, юк, мондый яшәү рәвеше берничек тә Гөлсемгә хас түгел.

Мең шөкер, әлегә аның ире дә, балалары да янында, исән-саулар. Тик менә Ибраһим абыйлары өчен генә ут йоталар. Кызыллар ягына чыкты да югалды. Һичбер хәбәре юк.

Ә Магҗанны күр, әнә нинди бәхетсезлекләргә дучар булган. Гөлсемнең күңелен парә-парә китереп, яшен тизлеге белән шундый уйлар үтте. Тик әлегә ул бу шәфкатьле йөрәгенең нинди утларда янарын, нинди гайбәтләргә юлыгырын башына да китерә алмый иде.

– Бәлкем, мин...

Магҗан шундый итеп төбәп карады ки, күрер күзгә тыныч, сабыр бу караш эчтән тылсымлы ут-ялкын чәчә ләбаса. Гөлсемнең җаны-тәне чымырдап куйды.

– Безнең курсларга мөгаллимнәр кирәк. Әгәр дә сез безгә килергә риза булсагыз...

– Ирем белән киңәшкәч, мин сезгә хәбәр итәрмен.

Хәзер Гаяз абыйсы да эчтән үзен битәрли иде. Ни дип бу кадәр Магҗанның язмышын шәрехләүне кирәк тапты соң әле ул?! Әдип инде абайлап өлгерде: әнә дала бөркете аның күз алдында Гөлсемне томшыгына эләктереп, шигъри күкләренә күтәрә, кояш катына оча иде.

Ожмахтагы кәүсәр судан,
Өстендәге алтын будан,
Фәрештәләрнең җырыннан,
Ожмах суының шавыннан,
Яфраклар кыштырдавыннан
Тәңренең нәкъ үз нурыннан
Яратылган фәрештәдер,
Туган иле – Гарештәдер.

..........................................
Хыял колы – мин бер акын.
Тормышта тар, тайгак юлга
Алып төшеп килә юрга
Көн кешесен кичкә якын.
Баткан көннең таңын күрдем,
Шул сылуның җанын күрдем.

«Гөлсемгә»[9]

Ә Исхакый аңа йөрәген ачарга, хисләрен аңлатырга соңарды. Шулкадәр тиз кемнеңдер сөйгәне булып куяр дигән уй аның башына да килмәде. Бөтен Төркияне аякка бастырган, көрәшкә чакырып, ялкынлы сүзләр сөйләгән шәфкать туташы үз илендә дә вакыйгаларның эчендә кайнарга тиеш һәм бу юлда алар кулга-кул тотынышып, бергә барырга тиешләр иде кебек. Ул бит аңа төрмәләргә нинди рухландыргыч шигъри хатлар язып торды. Гаяз абыйсы хәзер ташкындай ярсу хисләрен тыя алмыйча, әйтеп саласы итте:

– Бай хатыны булдым, диген инде, Гөлсем?! Байлыкка чумасым килде, диген... Хыялыма хыянәт иттем, диген...

Гөлсем Гаяз абыйсыннан мондый гаепләүне көтмәгән иде. Чак кына югалып та калды, үпкәлисе дә килде. Шул ук вакытта эзәрлекләүләрдән тәмам алҗыган, милләт өчен һаман җанын фида кылырга әзер, инде тәмам ябыгып, мыеклары гына тырпаеп калган әдипне кызганудан яшьләрен чак-чак тыеп торды. Аның аңлаучысы юк...

– Гаяз абый, сез хаталанасыз. Мин үземнең мөгаллимлек дигән зур хыялымнан беркайчан да баш тартмадым, – диде Гөлсем, күтәрелеп карамыйча гына.

Беразга авыр тынлык урнашты.

Гаяз абыйсы инде үзенең болай кабынып китүенә әчтән үкенә дә иде.

– Кичер, катырак бәрелдем, ахрысы, – диде ул, урындыгын Гөлсемгә якынрак күчерә төшеп.

Ике як та карашлар белән генә аңлашты. Ә карашлар йөрәкләргә үтеп керерлек иде.

Сөйләшүнең юнәлешен үзгәртергә кирәклеге көн кебек ачык. Фуад уйлап тапты кебек: Гөлсем алдына гәзитләр төпләнмәсен китереп куярга.

– Син безнең гәзитне күрмәгәнсеңдер әле?

– Ничек күрмим, ди? Бар саннарын диярлек укып чыктым. «Милләт» дип җан атасыз.

– Син дөрес тотып алгансың. Ләкин күп очракта «милләт» дип язуыбызның бер хикмәте дә бар, – диде Гаяз абыйсы. – Юлда килгәндә, йөри-йөри хәреф капчыгы тишелеп, бик күп хәрефләр аккан. Безнең телебездә бик күп кулланыла торган каты «х» бөтенләй югалып беткән. Шуңа күп мәкаләләрдә «халык» дигән сүзне «милләт» сүзе берлә алмаштырырга туры килде, – дип, Гөлсемнең халәтен күзләреннән укымакчы булып, тутырып, озак кына карап торды.

Магҗан да утлы карашын Гөлсемгә бер генә сирпеп алды да, әдип ягына карап, шигырь укыгандай сөйләргә тотынды:

– Себер җанлы сүзгә сусаган иде. Шуңа аны төрки-татар дөньясы олуг шатлык берлә каршы алды. Әдип Исхакыйның «Маягы» бүген, чыннан да, милли юлның маягы. Татар язучыларына рәхмәтебез бик зур.

...Гөлсем рәхмәтләр әйтеп, китәргә җыенды. Аны яратулы, сокланулы карашлар

[9] Флёра Тарханова тәрҗемәсе.

озатып калды, һәм, ишектән чыгуга ук, бу якларның коры, салкын җиле каршылады. Бу җил эчтән яндырып, тыштан туңдырып, күздән яшь китерде. Юл чатында кайсы якка китәргә белми аптырап торганда, аны таныш тавыш куып җитте:

– Гөлсем!.. Джоконда!..

Артына борылып караса, яланбаш, яланөс диярлек, киез каталарын лыштырдатып, сулышы кабып, Гаяз абыйсы йөгерә.

Аны бу кыяфәттә күрүгә, Гөлсемнең болай да тулган күңеле бөтенләй чайпалып түгелде.

– Мин сине үпкәләттем, иркә таем, кичер мине. Берничә көннән мин ерак сәфәргә кузгалырга ниятлим. Очраша алырбызмы без тагын, әйтүе кыен... Белүче – бер Ходай.

Гөлсемнең тагын бер-бер артлы кайнар яшьләре тәгәрәде. Исхакыйның да күз алмаларына тикле кызарып чыкты.

– Үз гомеремдә Камаловлар нәселенең бер генә сылуын яраттым. Мин, чыннан да, йөрәкләребезне йөрәккә куеп яшәрбез, дип хыялланган идем, кулга-кул тотынышып, милләткә хезмәт итәрбез, дигән идем. Син аны бер дә сизмәдеңмени?!

– Язмышлар аерым булган, күрәсең... – диде Гөлсем, бу юлы күтәрелеп карарга да уңайсызланып.

– Шулайдыр... Тәкъдирдер... Насыйп түгелдер...

– Мин хәзер син кискән токмач белән бер тәлинкә кайнар аш ашар идем. Син минем халәтемне аңлыйсыңмы, Гөлсем?!

Ничекләр аңламасын... Тик җавап итеп Гөлсемнең күзеннән яшь арты яшь кенә түгелде...

(«...Эх, хәзер бер тәлинкә токмачлы аш ашарга иде...» Исхакыйның хатларында еш кабатланган үзәк өзгеч сүзләр. Юк, юк, ул ачлыктан туган тойгы гына түгел! Ул хәтер күзәнәкләрендәге әйтеп бетергесез сагыну, җирсү. Ул туган якның арыш-бодай кишәрлекләре, яңгыр елап чылаткан, җил юатып киптергән көлтә-көшелләре. Ул – туган якның кайнар кояшы, салкын чишмә сулары... Әнкәсенең камырлы-онлы, назлы куллары. Учак җылысы, җан җылысы, ярату җылысы.)

– Мин сезне үзебезгә чакырам. Чистайча, зур, тәмле итеп итле бәлеш пешерермен. Сезнең өчен... махсус.

– Рәхмәт... Килүең өчен дә рәхмәт.

Бу аларның язмышлар чатында соңгы очрашу-аңлашулары һәм хушлашулары иде.

Гөлсем юл буе сагышлы уйлардан арына алмады. Әлбәттә, ул зур әдипкә иңен куя алган булыр иде. Иң ышанычлы ярдәмчесе дә булыр иде. Әмма язмышның үз кануннары...

Юкса Камаловаларның берсе дә төшеп калганнардан түгел. Әнә Хәтимә дә Мәскәүдә медицина институтында белем ала. «Ил»[10] газетасын чыгаруда Исхакыйның уң канаты була. Газетага мәкаләләр яза, милләт мәнфәгатьләре белән рухланып яши. Казанга татар хатын-кызларының беренче съездына делегат итеп сайлана. Аның да чыгышы алкышларга күмелә. Шулай итеп, ул Гөлсемгә алмаш булып, көрәш мәйданына килә, әдипнең ышанычын казана. Һәм әллә кай заманнардан бирле яшерен генә хыялында йөрткән сөюе дә эзсез югалмас, ялкынлы көрәшче белән йөрәкләре дә бер аңлашыр төсле иде.

[10] «Ил» газетасы Мәскәүдә 138 нче саны чыкканнан соң, урыс хөкүмәте тарафыннан 1918 елның апрелендә ябыла.

Әмма тәкъдирләр генә без дигәнчә язылмаган. Исхакый Хәтимәгә рәхмәтләрен дә белдерә алмыйча, хушлашмыйча да китеп барыр. Дөресрәге, тагын эзәрлекләүләрдән качар. Язмыш җиле генә: «Китә... Канәт туган җирне бөтенләйгә ташлап китә... Һай, китәргә мәҗбүр...» – дип, артыннан өзгәләнеп калыр. Гаяз әзие ярты җир шарын урап, Төркиягә килеп урнашуына берничә ел узгач, Хәтимәнең шулай яшьли гүр иясе булуын ишетеп бик кайгырыр, офтаныр, сагышланыр.

Шулай беркөнне үзенә урын тапмыйча, Истанбул урамнары буйлап йөри торгач, тарихи Топкапы алдында әсәрләнеп туктап калыр. Ниндидер бер сихри көч тартып китерде түгелме соң аны бирегә?!

Шулайдыр. Игълан-афишалардан күренгәнчә, Балкан сугышы каһарманнарына багышланган зур күргәзмәнең бүген соңгы көне икән. Исхакый ашыгып эчкә узды. Һәм беравык үз күзләренә үзе ышанмыйча басып торды. Гаҗәеп оста кул белән ясалган картиналарның берсе «Хушлашу» дип атала. ...Тышта яз, беренче бөреләр борын төрткән. Ә госпитальнең яртылаш ачык зур тәрәзәләре катына ап-ак киемнәренә тәннәреннән кан саркыган, башлары бәйләнгән яралы солдатлар тезелешкән. Ә аларга борылып карый-карый, куллар болгап, дүрт шәфкать туташы китеп бара... Бу бит Петербургтан Төркиягә ярдәмгә килгән атаклы татар кызлары! Әнә, башкалардан чак кына аерылыбрак торганы – Гөлсем ич моның! Гөлсем! Тукта, нәкъ шул картинаның алдында ап-ак мәрмәрдән ясалган сылу кыз да Гөлсем ләбаса! Әйе, әйе, ак гүзәл сын астына «Гөлсем» дип язып та куелган. Исхакый түзмәде, таш сынны кочаклап ук алды. Билгеле, шул минутта ук күзәтеп торучы музей хезмәткәре дә килеп җитте.

– Пәһале бәй, экспонатларга кул белән кагылырга рөхсәт ителми.

Исхакый, гафу үтенеп, тиз-тиз эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлатырга тотынды. Үзе һаман «Гөлсем»нән күзен ала алмады. Еларлык яшьләре кипте дип уйлаган иде дә, үзеннән-үзе бите буйлап кайнар яшь акты.

– Зинһар, үтенәм сездән, миңа Әхмәт Бакый сынчының үзен табарга ярдәм итегез.

Ни сөенеч, рәссам-сынчы үзе дә бу тирәләрдә генә булып чыкты. Гаяз аны да кочаклап алды.

– Әхмәт Бакый – чок гүзәл сынчы, бөек сынчы! – диде ул, һаман дулкынлануын җиңә алмыйча. – Сез безнең шәфкать туташларын, безнең... минем кадерле якташым, сөеклем Гөлсемне каян беләсез? Бу – искиткеч! Бу – Гөлсемнең нәкъ үзе! Аңлыйсызмы, бу фәрештә – минем җан фәрештәм иде, Әхмәт Бакый... Мин – мөһаҗир. Әдип, татар язучысы Гаяз Исхакый булам.

Әхмәт Бакый да мондый көтелмәгән очрашудан, әдипнең шундый саф хисләреннән, аның иҗатына бирелгән югары бәясеннән нык тәэсирләнгән иде. Ул да, күзләре яшьләнеп, ил өчен, үзе өчен авыр сынаулы елларны хәтереннән кичерде. Рәссам-сынчы үзенең чәрдәкләнгән бармакларының сакланып калуын бары тик Гөлсемнең үҗәт тырышлыгы, тылсымы, җан җылысы аркасында гына булды, дип аңлатты.

– Мин боларны шәфкать туташына зур ихтирам, рәхмәт йөзеннән эшләдем. Без бөтен палатабыз белән аңа гашыйк идек, – диде.

Алар тагын очрашырга сүз куешып, туганнарча аерылыштылар. Һәр икесенең дә күңелләре Гөлсем атлы гүзәл гамь, гүзәл хатирә белән мөлдерәмә тулган иде.

* * *

Иртәнге чәй әзерләп йөргәндә, ишектә көмеш кыңгырау чыңлады. Гөлсем сискәнеп куйды. Таң атмас борын кем йөрер, Абдулланың берәр иптәшеме, әллә Мостафа абыйсын эзләп килүләреме? Гөлсем тау тәүмәлеге өелгән үтә күренмәле беленнәрнең соңгысын табадан төшерде дә ашыгып ишеккә юнәлде. Хезмәтче кыз өлгеррәк булып чыкты. Ул: «Бер акын Абдулла Акчуринга килгән. Керергә рөхсәт сорый», – диде. Гөлсем шунда ук эсселе-суыклы булып китте. Магҗан...

– Килгәч, керсен, – диде ул, кырысрак күренергә тырышып.

Ул арада ишектә Магҗан үзе дә күренде. Иң элек күзенең явын Гөлсем алды. Гәүдәсенә сыланып торган озын атлас халаты, ефәк яулык читеннән күренеп торган чәч бөдрәләре, ак йөзенә серлелек биргән зур коңгырт күзләре, ап-ак беләкләре аны алиһә итеп күрсәтә иде.

Абдулла да, елмая төшеп, балаларын ияртеп, йокы бүлмәсеннән чыкты. Ул эшенә киткәнче, аларның икесен ике тезенә утыртып, сөя-сөя ашатып, эчертеп китә. Магҗан Абдулланы күрүгә, үзен ниндидер кыңгыр эш өстендә тотылгандай, бөтенләй югалып калды. Балаларның чит кеше күрүгә, ничек этиләренә сыенуларын күреп-күзәтүдән аның җаны, йөрәге дерелди иде. Бер мизгелдә ул, гафу үтенеп, чыгып китәргә дә уйлады. Чыгарга да Сардалага йөгерергә, аунап-тәгәрәп еларга һәм бөтенләйгә шунда ятып калырга... Юк, алай килешмәс. Магҗан күз ачып йомган арада хис тезгенен тартып, үзен акыл эзенә төшерде.

– Иртәләрегез аман, көннәрегез уңышлы булсын, Абдулла әфәнде! Кичерегез, сезне күреп калырга дип шулай иртәләвем. Мин – Магҗан Җомабаев – Кызылъярдагы педагогик курсларның мөдире булам. Кичә Гаяз әфәнде Исхакый белән очрашу вакытында мин дә Гөлсем ханым Акчурина белән танышкан идем. Безгә мөгаллимнәр җитешми. Гөлсем ханым бу хакта сезнең белән киңәшермен, дип, күңелдә бер өмет чаткысы кабызып киткән иде. Инде кичектермичә, сезнең карарны белергә килүем... (1910 елдан башлап, ике ел чамасы Уфада «Галия» мәдрәсәсендә һәм аннан соңгы елларда Г.Ибраһимов, М.Гафури, З.Вәлиди, Ш.Бабич, С.Кудашлар белән аралашкан Магҗанның[11] татарчасы да шактый ук әйбәт иде.)

– Әйдәгез, аягөсте сөйләшмик. Хуш килдегез, чәйгә рәхим итегез, – дип, ихлас җылы каршылап, Абдулла кунакны аш бүлмәсенә чакырды.

– Гөлсем кичә кич сезнең хакта сөйләгән иде. Укыдык: шигырьләрегез тирән хис, фикер, ватандарлык белән сугарылган. Бөек Тукаебыз иҗатыннан соң мин беренче мәртәбә Чибәремнең шулай соклануын, хисләнүен күрдем. Безнең математик Гөл-энкәбездә менә шундый искитәрлек шигъри йөрәк, – дип, Яхъя белән Сафураны күкрәгенә кысып, сөеп тә алды.

– Ә Гөлсемнең мөгаллимлек хыялларына килгәндә, без аңа һәрчак теләктәш. Хәзерге заман шартларында укытуын дәвам итәргә мөмкинлек табыла икән, безгә сөенергә генә кирәктер. Туган апабыз балаларга да бик һәйбәт тәрбиячеләр табып куйган. Шулкадәресе дә бар: Магҗан акын, Гөлсем кебек, Петербургның атаклы институтында укыган, затлы мөгаллимәдән белем алу укучыларыгыз өчен үзе бер дәрәҗә булачак. Болары – минем фикер. Калганын Гөлсем ханым үзе әйтергә тиештер, – диде. Гөлсем сүзне бик кыска тотты:

– Магҗан әфәнде, ышанычыгыз өчен рәхмәт. Сез килешсәгез, укуны

[11] Җомабаев М. Җан сүзе. Төзүчесе – Рәдиф Гаташ. – Казан: «Илһам» нәшр., 2013.

киләсе атна башыннан башларбыз. Ул вакытка Абдулла кәбәм дә сәфәрдән кайтыр.

Килешмиме соң инде Магҗан! Ул бу көнне айлар-еллар көтәргә дә риза. Юк шул, алай түгел! Аның бер генә көн көтәрлек тә тәкате юк икән ләбаса!

...Юкса, язмыш шагыйрьгә бүген үзенең сабагын да биреп үтте шикелле. Ул – әле кайчан гына бөтен Русиядә иң атаклы, дәрәҗәле фабрикантлардан саналган Абдулла Акчуринның дөнья һәм гаилә тоткасы булганын да, гүзәл хатынына, йөрәк җимешләренә чиксез мәхәббәтен дә, бәхетенең түгәрәк бөтенлеген дә үз күзләре белән күрде. Күрде, әмма күрүенә үкенде.

– Тәңрем, нигә миннән шундый бәхетне күпсендең?! Аның Зәйнәбе дә гаҗәеп бер сылу иде. Ул сылуын да, сөюен дә, улын да саклап кала алмады. Бахырларны дала җиле, мәрхәмәтсез язмыш җиле көйдерде. Ә шагыйрьнең яралы җанын заманның җан өшеткеч суыгы тилмертте. Җылы эзли Магҗан! Сүнеп калган карашына очкын өстәрлек, казакъ илен кар-боз астыннан чыгарырлык, дөньяны яктыртырлык илаһи бер нур, илаһи бер зат, илаһи бер җылылык. Һәм – юлыга! Ә мәхәббәт алдында беркайчан да: «Нигә?», «Ни өчен?» дигән сораулар тора алмый. Әнә язмыш җиле, үчекли-үчекли, тагын аның артыннан иярә. Бу юлы аны Тәңресе, Гөлгә гашыйк итеп, шигъри утларда яндырачак.

Магҗан китте, ә Гөлсемнең йөрәгендә, нигәдер, әйтеп бетергесез сагыш, моң калды. Азагы хәерле була күрсен. Үзләре генә калгач, Абдулланың күңел кылларын тартып карарга теләп, сорап куйды:

– Абдулла кәбәм, ни дип әле ул казакъ алдында шултикле энҗе чәчтең?

– Синең өчен килгән кеше ич. Затлы, зыялы, укымышлы казакълардан икәне күренеп тора. Нечкә җанлы. Искитмәле: йөрәк сызлавы да йөзенә үк язылып куелган. Күркәм ир-егет, һичшиксез, хатын-кыз күзе төшәрдәй... Гөлсем күзләрен тутырып, Абдуллага озак кына карап торды да:

– Кызылъярга килмәсәм, иремнең бу чаклы оста психолог икәнен белми дә калган булыр идем, валлаһи, – диде дә, балалары белән беррәттән, Абдуллага сыенды.

– Менә шулай, Гөлем! – диде Абдулла, бу сүзләргә аерата тирән бер мәгънә салып. – «Син кайсы мөгаллимдә укыдың?» – дип тә сора инде.

– Рәхмәт, – диде Гөлсем, аның хәйләкәр елмаюына каршы сүзне уенга бора төшеп.

Абдулланы озатып җибәргәч тә, Гөлсем озак кына уйланып йөрде: «Көнләште, дисәм... Гомердә булмаганны... Ничек уйланмасын; йөрәгендә мәхәббәте, ихтирамы, тормышы булып тамыр җәйгән Абдулласы бит ул аның. Балаларының газиз атасы! Сүз дә юк, Магҗанның шигырьләре аны тетрәндерде. Алар кичкән сынауларны онытып, шигъри тылсым дөньясына кереп баруына ул үзе дә гаҗәпкә калды. «Көннән туган, һуннан туган Пәйгамбәр»гә сокланды да, аның белән бергә сызланды да.

Кап-кара төн. Хәсрәт тулы җир җыры,
Кап-кара төн. Иңрәп егълый төн улы.
Көнчыгышта ак алтын бер сызык бар:
Мин киләмен, мин пәйгамбәр – көн улы.
«Пәйгамбәр»[12]

(Әмма шагыйрьләр туган илләрендә Пәйгамбәр була алмаслар. Заманы

[12] Нури Арсланов тәрҗемәсе.

бүтән... Ә менә сөргеннәр, абакты-төрмәләр, лагерьлар, асу-атулар калган. Һәм Пәйгамбәр рухлы шагыйрьне дә 1938 елда атып үтерәчәкләр.)

...Магҗан исә бүген бар дөньяга, алай гынамы, Тәңренең үзенә дә үпкәле. Сыкраулары Сардалага сыйса гына инде... Ә тирә-якта күз ачкысыз кара буран, әллә җанында ил-даласы, халкы шулай илереп дулыйсы, елыйсы иттеме?! Акын хәзер шушы халәтен шигъри телгә күчермәкче. Күкләргә ирешерлек итеп бар тавышына өзгәләнеп сөйләмәкче иде. Тик тавышы чыкмас булды. Аның өчен бар көченә буран улады. Яңаклары буйлап аккан яше бер дигәнче бозланып катты. Ул үҗәтләнеп пышылдады.

Кичә күр, Тәңрем: бу сүз – бәндәчелек,
Әмма безгә золымың – ник? Юк гаделлек:
Рәхимеңнән шулкадәр дә буш калганбыз, –
Баласы алты Алашның – без ни кыйлдык?!
...............................................................
Безгә утсыз шул даланы урын кылдың,
Бәхет-дәүләт, һөнәр белемнән ким кылдың.
...............................................................
Бәхетсез казакъ каңгыра, зарлы-моңлы,
Тормышы башкага гыйбрәт-мәзәк булды.
...Бер пәйгамбәр күндермәдең, – әллә бездән
Шәрә чүлдә дөя баккан гарәп зурмы?!
«Тәңрегә үпкә»[13]

Тик Тәңресенә болар күптән мәгълүм иде. Ул аны өшүдән саклап, үзенә ялкын гына өстәде. Уттан туган һун улының эче-тышы ут. Ул янә бар дөньяны, бар даланы шигъри утта җылытмакчы...

Ут яндырып туганга,
Бугазымны буганга,
Караңгылык – дошманым.
Шул явызны юк итсәм,
Сукыр күзен ут итсәм.
Үтим Тәңре кушканын
Алып чыккан Алтайдан
Балкангача – Кытайдан –
Барган юлым шул булыр...
«Ут»[14]

...Бимазалаганы тагын шул: бу көннәрдә Магҗан өчен вакыт тукталды. Юкса инде бу атна күптән узып, яз башланырга тиеш иде.

...Ниһаять, ниһаять! Магҗан бүген мәктәпкә таңнан килеп утырды. Бүлмәсендәге ак чәчкә атып утырган бердәнбер яран гөлен дә кадерләп кертеп куйды. Тагын бер кат тактаны сөртеп: «Хуш килдегез, мөгаллимәбез!» – дип, өч-дүрт телдә сәламләде. Өстәлне уртагарак күчерде. Һәм пышылдап кына серен ачты: «Укучылар, бүген бездә бәйрәм! Бүген яңа укытучы гына түгел, бүген Гөл килә, Сөю килә!»

Гөлсем дә иртәләде. Китап, дәфтәрләр, каләмнәр, сызгычлар, акбурын, хәтта такта сөрткеченә тикле әзерләде. Укучылар килгәнче, һәрберсе алдына «бүләкләрен» тезеп чыкты. Уку-язу әсбапларын, кайбер кирәк-яракларны алуны Абдулланың апасы Гөлсем, ире – атаклы финансист Мостафа

[13] Рәдиф Гаташ тәрҗемәсе.
[14] Мөдәррис Әгъләм тәрҗемәсе.

Тюменевтан үтенде. Абдулла бу юлы нигәдер тоткарланды. Исән-имин генә йөрсен. Гөлсемнең йөрәге әлегә бигүк урынында түгел. Ә Магҗанның күңелендә озын кыш буена беренче кат кояш чыкты. Гөлсем укучыларның исемлеге язылган калын гына журнал эчендә яткан шигырьләрне дә күреп үтте, әмма әлегә күрмәмешкә салышты.

Инде дәрес башланыр вакыт та җитте. Магҗан укучыларны яңа укытучы белән үзе таныштырды. Аның Петербургта Бестужев югары курсларында укуын, талантлы математик булуын ассызыклады. «Язмыш безнең бәхеттән бу якларга китереп чыгарган», дигәнне дә әйтергә онытмады. Таныштыру тәмам, әмма мөдир чыгып китәргә ашыкмады. Артка буш урындыкка барып утырды да түземсезлек белән Гөлсемнең сүз башлавын көтте.

Гөлсем әүвәл аеруча бер җылылык белән танышып чыкты: кем кайдан, гыйлем дәрәҗәсе нindирәк. Һәрберсен игътибар белән тыңлады һәм «рәхмәт» дия барды.

– Әйдәгез, хәзер математика дигән чиксезлек һәм гаҗәеп серләрдән торган фән дөньясына сәяхәт итеп кайтыйк. Мөгаен, һәммәгез дә бихисап йолдызлардан «тукылган» күк гөмбәзенә сокланып, гаҗәпләнеп карыйсыздыр? Шулаймы?

– Әйе, шулай, шулай! – дип, дәррәү шаулашып, мөгаллимәнең әйткәннәрен җөпләделәр һәм бер-берләренә карап елмаешып алдылар.

Зөләйха исемле чибәре торып ук басты.

– Апа, безнең Сардала өстендә йолдызлар шундый эре, шундый якты, берәмтекләп санарга була, – диде.

– Санарсың, бар, – дип, берничә егет шунда ук каршы төште.

– Зөләйха искиткеч матур итеп әйтте, математика телендә әйтте! – диде мөгаллимә. – Ни өчен шулай дидемме? Атаклы Галилео Галилей фикеренчә: «Математика теле ул – табигать китабы язылган тел белән тәңгәл». Ә менә Гаус атлы алман галиме бәяләвенчә: «Математика – фәннәрнең патшабикәсе, ә арифметика исә – математиканың патшабикәсе». Беләсезме, минем үземә ошаганы нинди?! Бик күп акыл ияләренең: «Математик булу өчен беркадәр шагыйрь булу лазем», – дигәне. Димәк, Зөләйха шигъри күңелле математик. Ә хәзер мин иң кыю, иң хыялый математикны такта алдына чакырам. Йәгез, кем чыга?

– Зөләйха инде безнең, кем булсын тагын, – диде егетләр, елмаешып.

– Бик яхшы. Бу юлы Зөләйха, ә аннан калганнар чыгар. Тик сез беркайчан да аңламаганыгызны сорарга кыенсынмагыз. Мин дәрестән соң да калып аңлатырга әзер. Аннан, кызыксынучыларга француз теле күнекмәләре дә бирә алам. Зөләйха, тәнәфестә теләүчеләрнең исемлеген алуны синнән үтенәм.

– Беренче укучы итеп мине яз, Зөләйха, – диде Магҗан.

И-и, дәфтәргә генә язар анысы, бу исем күптән инде кызның йөрәгенә үк язылган иде. Зөләйха инде «ә» дигәнче мисалны чишеп тә куйган. Кулын очарга җыенган кош кебек җилпеп-талпынып торучы Мәрьям дә көчле укучылардан иде.

– Афәрин, кызлар! – диде Гөлсем, алар өчен сөенеп.

Магҗан да: «Безнең Кызылъяр кызлары шундый!» – дип куйды.

– Болай булгач, берәр кичтә Зөләйха белән Мәрьям безне йолдызлар санарга алып чыгар. Барыбыз да ризамы?

– Барыбыз да, барыбыз да! – дип, шунда ук балаларча кулларын чәбәкләргә тотындылар.

Гөлбаһәр исемле тагын бер гүзәле чыгып, әкрен генә Гөлсемнең колагына пышылдады:

– Мин Магҗан абыйның «Йолдызлар» дигән шигырен яттан беләм.

– Күрегез, монда гел математиклар гына җыелган икән, – дип, кызларны тәмам үсендерде мөгаллимә апалары.

– Аңламаган сорауларыгыз булса, иртәгә язып килегез. Ә бу мәсьәләләрне барыгыз да чишәргә тырышыгыз.

Дәрес тәмамланды. Әмма яңа мөгаллимә яныннан берсенең дә китәсе килми иде. Ә хәзер рус теле дәресе. Магҗан абыйлары укытачак. Аны да яраталар яратуын...

– Апа, – диде Зөләйха, чак кына сыена төшеп, – ике көннән тулган ай. Беләсезме, ай нинди сихри нурга күмә Сардаланы. Әйдәгез, берсекөнгә үк чыгабыз.

Зөләйханың сүзләрен егетләр ишетми каламыни инде?!

– Апа, учак ягыйк. Без сукмак ясап куярбыз.

– Учак мәйданын сайларбыз.

– Коры-сары, утын кирәк булыр.

– Барысын да үзебез эшләрбез.

Кызлар да, ризалык белдереп:

– Апа, беләсезме, даладагы ут теле нинди сихри көчкә ия, – диде һаман мөгаллимәдән аерыла алмаган Зөләйха.

– И-и бала, синдә сөю теле сөйли ич, – дип, әкрен генә колагына пышылдады. Зөләйха, Гөлсемнең иңенә маңгаен тидереп алды да йөгереп чыгып та китте. Ниһаять, бу ятимәнең дә йөрәген аңлаучы табылды. Кыз качып кына үксеп-үксеп елады.

Барысы да адарынып көткән, Сардалага һәм җаннарга көмеш нур койган, баш очында миллиардлаган йолдызлар кабызган сихри кич керде. Тирә-якны, күңелләрне җылытып, очкыннары белән күктә уйнап, төнге учак янды. Гөлсем апаларының аналарча кайгыртып, чиләк тутырып алып килгән кайнар пәрәмәчләре барысын да шаккатырды.

– Минем туган ягым Чистай күгендә дә хәзер тулган ай йөзәдер. Исәпсез-хисапсыз йолдызлар җемелдидер. Әнкәем сагынадыр... – диде Гөлсем, чак кына моңсулана төшеп.

– Чистай... Әйтәм аны, сез ай кызы икәнсез ич, апа, – диде гел йөрәге белән уйлаучы Зөләйха.

– Зөләйха, син адым саен хәйран итәсең, – дип, Гөлсем дә кызны күңел бозларын эретерлек җылы карашына төрде.

Биредә һәммәсе Гөлсемгә олы ихтирам, соклану белән карады. Яңа мөгаллимәләре аларга кайбер атаклы математикларның дөньякүләм ачышларын сөйләп узды. Кар өстендә мисаллар чишелде. Тукай шигырьләре укылды. Бүгенге учак янында һәркемнең язмыш җиле җылынып китте. Иң көчле, иң кайнар учак булып Магҗанның йөрәге янды.

Беразга аңа кушылып, Гөлсемнең сөю учагы да ялкынлана-ялкынлана дөрләп алды. Шәүләсе йөзендә биеде. Нәрсә бу? Әлеге фаҗигаи заманның бар сынау-кичерешләр авырлыгын онытып, чит мәхәббәткә уралу түгелме соң бу?! Язмаганны, булмаганны, килешмәгәнне... Инде ничә көннәр, ничә төннәр шулай хис белән акыл көрәшә. Акылы гына җиңә күрсен!.. Шулай булмый ни тагын...

Чират акынга җитте.

Йолдызны – йөзек,
Айны алка итеп...[15]

– Бу – мәхәббәт шигыре. Мин бүген сезгә аның бер өлешен генә укырмын, – диде Магҗан. Иртәме-соңмы сезнең һәрберегезгә шундый сөю киләчәк...

Иркәтаем, килсәң әгәр каршыма,
Сөюемнән ялкын капса башыңа,
Күз яшемнән гәүһәр муенса тезим,
Кил, карама күздән аккан яшемә.
Иккүзем, кил, Көн нурына күмелим,
Сөйим дә – үлим, «нигә үләм?» димимен,
Килеп җит тик, агып кына, ефәк күк,
Йолдыз-йөзек,
Ай-алка... сиңа бирим?!

– Рәхмәт, Магҗан әфәнде, искиткеч шигъри бүләк. Бүген һәрбер кыз бала, шул исәптән мин дә, Сардаладан «Йолдыз-йөзек, Ай-алка» белән китәрбез. Кызлар, шулаймы?!

– Шу-у-ла-ай!

– Инде Гөлбаһәр безгә вәгъдә иткәнчә, казакъ халкының зур, талантлы шагыйре Магҗан Җомабаевның «Йолдызлар» шигырен укысын. Һәм без күк-асманда бүген үзебезнең иң серле, иң якты йолдызыбызны билгеләп китик. Һәм Табигать-анага, бар Галәмгә, бер-беребезгә рәхмәтләр әйтеп таралышыйк. Борынгы далада ак эзләребез, ак теләкләребез, күңел җылыбыз калсын! (Әлеге минутларда Гөлсем яратып күккә бакса да, аның «сихерле йолдызы» янында иде.)

Һәрберсе иң элек мөгаллимәгә килеп сарылды. Магҗан исә, зыялыларга хас булганча, сүзсез генә Гөлсемнең кулын үпте. Дөньяда бу игелекле, нәфис кулларның җылысыннан да кадерлерәк тагын ни-нәрсә булуы мөмкин?!

Гөлсем дә өйгә дулкынланып кайтты. Тик Яхъя белән Сафура аны бик тиз күктән җиргә төшерделәр. Әниләрен килеп кочакладылар да: «Әттәм юк», – дип елый да башладылар. Абдулланың Омски-Омбыга киткәненә күпме вакыт, бер хәбәре-хәтере дә юк. Гөлсем ни диярргә дә белми. Алла гына сакласын. Замана турында уйлый башласаң, чәчләрең үрә торырлык. Мостафа абыйсының элемтәләре зур зурын, тик ул да әлегә өздереп кенә берни дә әйтмәде. Бер уйны икенчесе кысрыклады. Әллә соңгы вакытларда иренең кадерен дә белеп бетермәдеме Гөлсем? Исән-имин кайтып кына керсен ире. Җаны-тәне белән сарылачак. Үзенә багышланган шигъри мәхәббәт ялкынын да өстәп сөяр.

Әлегә бөтен Кызылъяр диярлек шул кечке җыенны һәм Абдулла Акчуринның хатынын сөйли. Бер ишесе мактый, бер ишесе гаеп итә. Ярый, эт өрә торыр, бүре йөри торыр, дигәндәй. Кемнәргәдер сөйләргә дә сүз кирәк, дип, үзен тынычландырды Гөлсем.

...Мең шөкер, ниһаять, Абдулла кайтты! Гөлсемне мәхәббәт һәм бәхет пьедесталына күтәргән, газизләренең газиз әткәләре кайтты! Тормыш тагын үз җаена төште. Абдулла да, читкә-чотка чыкмыйча, ай буе Кызылъярдагы эшләрен генә карады. Ә балалар, җай чыккан саен: «Әттәм, әттәм», – дип, тизрәк алдына менеп утырдылар. Менә ул Абдулланың җан рәхәте, җан дәвасы кайда!

Ә бер төнне ул әнкәләренең «Шифам минем» дигән, сулкылдап елаган

[15] Рәдиф Гаташ тәрҗемәсе.

тавышына уянып китте. Бер дигәнче Гөлсем үзе дә торып утырды да үксеп-үксеп еларга тотынды. Абдулла курка калды.

– Гөлем, син төш күрдең, сөйләштең. Тынычлан, зинһар. Бер-бер хәл булмагандыр бит, – дип, чәчләреннән сыйпады, хатынын яратып күкрәгенә кысты.

– Абдулла – мин... без... Калны урманнарында йөрдек.

Абдулла шунда ук төшенде.

– Гөлем, син анда учлап-учлап мүк җиләге ашадыңмы?

Гөлсем башын гына какты. Ә күзләреннән кайнар яшь коелды.

– Син мине ак чәчәкле аланда кулларыңда күтәреп йөрдең. Шунда бер ак күбәләк кулыма кунды да: челтерәп торган бер тавыш белән: «Мин килдем!» – диде.

– Син шул күбәләккә: «Шифам минем!» – дип дәштең инде алайса.

– Әй-йе, – диде Гөлсем, елавыннан тыелырга тырышып.

– Гөлем, нинди сөенеч, безнең тагын бер кызыбыз туачак...

– Безнең Шифабыз...

– Әйе, безнең Шифабыз! Мин хәзер ак күбәләгебезнең әнкәсенә бал белән тәмле чәй китерәм. Син ялыктың, арыдың, сиңа хәзер ял кирәк, Гөлем, ял...

Гөлсем чак кына уйлады да Магҗанның зур бер конвертка җыеп барган шигырьләрен нәкъ бүген, шушы минутта бирергә карар кылды.

Бута күз[16], сихерле сүз, ханым Гөлсем,
Күктә Көн[17] көлмәсен, Гөлсем көлсен,
Гөлсем – Кояш, күктә әкрен йөзүен белә,
Сөйдереп, көйдергәнен каян белсен?!

«Гөлсем ханымга»

***

Җан ордым, җаннан телдем – кайрылмадың,
«Кит әле!» дигәнеңнән айрылмадым.
Күз алларыңда дөрләп уттай яндым –
Җәлләп, хәтта сүз белән кайгырмадың.

Хуш, күз нурым! Бәхетсез бер Мәгъшугың күр.
Саубуллашыйк, мин китәем, кулыңны бир.
Алдымда – колач җәеп каршы алучы
Миһербанлы сөйгән ярым – ул кара җир!

«Сөйгәнемә»

***

..................................................
Кояш кызының җан җырын,
Йөзендәге якты нурын
Эзләп йөреп әлсерәдем.
Йөрәгемне, кулым биреп,
Кан аралаш яшем түгеп:
«Юлым – сиңа, килче!» – дидем.
Кайрылып та карамады,
Җан-йөрәгем яралады.

«Мин – үлгән бер җанмын, – диде, –
Фәрештәләр күмгән инде».

[16] Матур, кара күз.
[17] Кояшның төркичә синонимы.

Керфек какты – китеп барды.
Йөзендәге балкыш нуры,
Аузындагы моңлы җыры
Йөрәгемә сеңеп калды.
Йөрәгемнән китмәс бу җыр,
Үзгәрсә дә меңгә гомер.
«Гөлсемгә»

– Болар миңа атап язылган шигырьләр.

– Беләм, – диде Абдулла, чак кына елмая төшеп.

– Беләсең, ә бер сүз дә дәшмисең?! Башка ирнең хатыныңа гашыйк булуын белү бигүк күңелле хәл түгелдер. Ә син бер сүз белән дә белгертмисең...

– Шагыйрь мәхәббәтенә, шигъри мәхәббәткә ни әйтеп була, Гөлем?!

– Башыңа шикләнү, көнләшү уе да килеп карамыймы?

– Гөлем, мин синең кемлегеңне, ниндилегеңне белмәсәм иде. Әйдә, шагыйрь мәхәббәтен дә, үзебезне дә түбәнсетмик. Әнә минем – сине, синең мине яратуыбызның дәлилләре. Бак, ничек матур итеп йоклап яталар. Бәлкем, Ак күбәләгебез дә хәзер алар янындадыр. Яратып, аларның кулларына кунадыр. Әнә төшләрендә ничек елмаялар.

– Абдулла кәбәм, минем сиңа сокланудан һәм рәхмәттән башка бер сүзем дә юк. Алай да бер үтенечем бар. Уку елы тәмамланганчы, миңа мәктәптә калырга рөхсәт ит.

– Гөлем, синең теләгеңә һичкайчан каршы төшкәнем булмады. Үзеңә генә авырга туры килмәсен, – дип, Абдулла хатынының күзләренә озак кына тутырып карап торды. Бу әйтеп бетергесез моңсу караштан Гөлсемнең күңеле тагын да тулып түгелде.

...Һаман бер ашкыну, яну белән көннәр, айлар, язлар, җәйләр үтәр. Мәктәптән дә, укучыларыннан да, Магҗаннан да Гөлсем зур бер ярату, моңсулык белән аерылыр.

Көз керер. Сардала өстендә тулган ай балкыр, исәпсез-сансыз йолдызлар янар. Һәм ак карлы дөньяга: «Мин килдем!» – дип, ак күбәләк аваз салыр. Шифа туар. Язмышның көртле-буранлы, бормалы юллары янә туган илләр ягына борылыр.

Ә Магҗан?! Шагыйрь җаны нишләр?! Нишләсен, тагын янар, ялкынланыр, ут чәчәр.

Белдем, бүген мине ташлап китәсең,
Көмеш сулы Иделеңнән үтәрсең...
Бута күзлем[18], үтереп кит кулыңнан,
Тере килеш ничек ташлап китәсең?!
«Аерылганда (Г...гә)»

***

Былбыл гөлсез,
Былбыл өнсез – гади кош.
Ай, кояшсыз,
«Гөл»сез, өнсез – гомер буш!
Бута күзлем,
Ефәктәй сүзлем – гарешкә
Китте очып,
Зарым кочып, алыста[19]

[18] Яшь дөя күзенә тиңләү.
[19] Еракта.

Калдым ялгыз,
Тере җансыз – кем белән?! –
Чиргә түзәм,
Киңәшәмен моң белән.
Дустым ерак,
Сүнде чырак,
Сүнәмен.
Сүнәдер Ай,
Мин дә тиздән үләрмен.
«N альбомына»[20]

***

Кыен һаман күз яшемне тыюым,
Алҗытты кич-көндез янып-көюем.
Аның ниләр уйлавы миңа нигә? –
Элеккедән мең кат артты сөюем.

Аерылуны уйлап алмыйм исемә, –
Ни кылыйм шул уйга салган кешемә?
Тәңре – иям, йокы бирче тизрәк, дим,
Җан ярымны бер сөйимче төшемдә!
«Җан ярымны сөйимче бер төшемдә»

«Җан ярым», «Ефәк сүзлем». Магҗан Гөлсемне шулай дип атый. Әйе, җаннар аңлашу, шигъри рухның бөеклеген тою һәркемгә дә бирелми. Гөлсемдә исә менә шундый нәфис җан. Ә иҗади шәхесләр андый аңлауга һәрчак мохтаҗ. Ни өчен аның юлында җанын шулай ярып-бүлеп бирердәй кешеләр очрап тора икән? Ә бу җанны ничәгә бүлеп була соң?!

Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ («Җан сүзе» дип аталган китапның төзүчесе) кереш сүзендә болай дип яза: «...мин Гөлсем ханымны романнарга лаек шәхес дияр идем. XX гасыр иҗтимагый-мәдәни тормышындагы багланышларны күзаллап.

Әнә шул атаклы ханымның Магҗан белән мөнәсәбәтләре, шагыйрьнең аңа атап язган гаҗәеп көчле лирикасы – әлеге язылачак романның иң калку битләредер, бәлки. Комментарийларда язылганча, «Гөлсемнең дә башы буш булмый»: ягъни зур шагыйрьнең җан дөньясын аңларлык, аның Тәңре, Муса, Гайсә һәм соңгы Мөхәммәд пәйгамбәрләр, Тур тавы һәм Туран турындагы шигъри хыялларын тирән кичереп, аңлый, кушыла белгәндер, мөгаен. Тарихи бу очрашу мизгелләре – үзләре үк шигырь өчен кыска һәм утлы хатирәләр өчен җирлек булгандыр. Гөлсем ханым үзе дә, шигырь көче белән ачылып:

Йөрәкләр Тәңресе – утлы,
Күзеңнең шөгъләсен *(ялкынын – Р.Г.)* миннән
Күчер бер үзгә агулга *(объектка? – Р.Г.)*,
Сихерле йолдызым, тиздән! –

дип юкка гына кисәтмәгән бит. Мәхәббәтнең бөек сәхифәсе бу! Ә тормышның үз Тәңресе, аларны ул (язмыш!) болай да тиз аерачак. Үлемсез шигырьләрдә калачак бу кыска вакытлы ялкынлы күңелләр – аңлашу тарихы! Тиздән Гөлсемне ире, шигырьдәгечә, «ак Иделләрне кичеп», туган ягына, аннан Мәскәүләргә алып китәчәк. Ә Магҗан тугры яры булачак Зөләйхасы белән кавышачак...

[20] Рәдиф Гаташ тәрҗемәсе.

...Сихри көчкә ия сүз остасы була Магҗан. Һәм чын мәгънәсендә милли шагыйрь ул: казакъның бай тел-рухи дөньясын чагылдыруы белән бергә ул төрки дөнья берлеге җырчысы, хәтта туранчы. Һәм замандашы М.Әүэзов әле 20 нче елларда язып калдырганча, «киләчәккә әсәрләре барып җитәргә лаек дөньяви колачлы-омтылышлы бердәнбер казакъ шагыйре!» Юкка гына бүгенге казакъ әдәбиятчылары Магҗанны: ул «безнең Пушкин, безнең Шекспир», – дип язмыйлар бит».

Инде шагыйрь сүзләрен куәтләп, бу бәяләмәнең асылында нәкъ менә шушы гаҗәеп көчле мәхәббәт лирикасы да күздә тотылгандыр, дип фаразлыйсы килә.

...Ә Сардаланың йолдызлы, тарихи хәтере ул кышларны һәм күңелләрнең аклыгын, язмыш җилләре җылынган учакларның кайнарлыгын, йөрәкләрнең серле шигъри ялкынын әле һаман да булса саклыйдыр. Шулайдыр...

## «Сөйләттерде миңа йөрәгем...»

*Вакыт исә сүтә-сүтә*
*Сүтелепләр бетмәс сер...*
*Кайчан килдең?*
*Кай сәгатьтә*
*Тәмамланырсың, гомер?*

***

*«Сөйләмәсәң, туктыйм!» –*
*Диеп, моны*
*Сөйләттерде миңа йөрәгем.*

Зөлфәт

Гасыр белән гасыр арасы... Революцияләр. Репрессияләр. Сугышлар. Миллионлаган корбаннар. Сулыш алырга куркып торган дөнья. Чәлпәрәмә килгән язмышлар. Туктаусыз эзәрлекләүләр, тетрәнүләр, җан яралары. Уйласаң, уелыплар китәрлек.

Шушы гасырның күп сынау-әрнүләрен кичкән 92 яшьлек Шифа апа Акчуринаның исән-имин Мәскәүдә яшәп ятуын ишеткәч, куанычымнан нишләргә дә белмәдем. Әлбәттә, кичекмәстән Мәскәүгә китәргә! Тик телефон трубкасында гөрелдәп ишетелгән тавыш очрашуны хуп күрмәде. Шулайдыр, Шифа апаның инде йөрәк яраларына кагылдырасы килмидер. Сызланулары болай да хәттин ашкандыр... Уй-теләкләр шулай беразга тынып тора да тагын үҗәтләнергә тотына: «Ничек кенә булса да очрашып сөйләшергә!» Ниятемне кабат-кабат дәлилләргә тырышам.

– Булды! Яздылар инде... җитәрлек булды, – диде ул телефоннан, тагын шактый кырыс, каты тавыш белән.

Беркадәр вакыттан соң, тагын тәвәккәллим.

– Шифа апа, Ходай хакы өчен, кабул итегез, – дим.

Ул һич тә көтмәгәндә челтерәп көлеп ала да:

– Ходай хакы өчен, дигәч, бик тартышып булмастыр. Мин бит ишан оныгы. Килегез! – дип, күңелгә канатлар куя.

...2012 елның чатнама суык декабрь ае. Җитмәсә, ачы җил өтеп ала. Ахрысы, язмыш җиленең дә үзен искә төшереп үтүе булса кирәк... Мәскәүнең данлыклы түрәләр яши торган Кутузов проспектына якынлашам. Эчемә: «Акчуриннар кайда да Акчуриннар булып калганнар, – дигән җылы уй йөгерә.

– Әнә бит нинди урында яшәп ята икән Шифа апа». Әмма фатирга килеп кергәч, минем гаҗәпләнүемнең, йөрәк чымырдауларының чиге булмады. Коммуналканың ун квадрат метрлы бүлмәсендә Шифа апа берьялгызы гомер итеп ята. Хәер, Ленинград блокадасын кичергән кешегә, яшәүнең кыйммәтен, үлем ачысын күргән, бер кабым ипи, бер йотым суның кадерен, могҗизасын аңлаган көчле рухлы кеше өчен бу алай борчылырлык та түгелдер. Иң мөһиме – кадерле кешеләр йөрәккә сыйган, яшьлек еллары фотоальбомнарда сакланып калган.

– Шифа апа, бу кадәр чибәр кызга гашыйклар да аз булмагандыр?

– Сез игътибар иткәнсездер, безнең нәселдә барыбызның да мәхәббәте фаҗига белән уратылган. Мин институтта икенче курста укыганда, сугыш башланды. Журналист, язучы кеше, сез Ленинград блокадасын күзаллыйсыз булыр. Без бервакытны, өч көн буена институтның эскәмияләрендә ачлыктан хәлсезләнеп, торалмыйча яттык. Мине бик яраткан яһүд егете бар иде. Ул үзенең карточкага алган паёгын (көнлек норма – 125 грамм) миңа ашатып торды. Нигәдер аның: «Мин ач түгел», дигәненә ышанасым килде. Мин исән калдым, ә ул берничә көннән дөнья куйды. Минем хакка! Мәхәббәт хакына! Аның якты истәлегенә хыянәт итә алмадым. Минем йөрәгемне аның дәрәҗәсендә аңлаучы башка ир-егетләр дә очрамады.

Әтисе белән әнисе турында сорашам.

– Әтиме?! Әти обожествлял маму! Әнине шултикле яратты. Әти шундый йомшак күңелле иде ки, каршы әйткәне булмады. Күзенә генә карап елмая иде. Мин күбрәк әти кызы!

Абдулла Акчурин гаиләсе Кызылъярдан Мәскәүгә 1921 елда күчеп кайта. Абдулла йон эшкәртү буенча зур белгеч санала. Яңа министрлык оеша. Аны шунда төп белгеч итеп чакыралар. Бу нисбәттән аңа дәрәҗәле Дебердиевләр, Хәсән абыйсының уллары да булыша. Аларга Мәскәүнең Преображенская застава ягыннан җыйнак кына ике катлы йорт бирәләр. Гөлсем балалар белән өйдә. Шифа – ак күбәләккә әле бер генә яшь. Тормышлар янә җайга салынгандай була... Әмма заманның усал, үчлекле җилләре һич тә аларны тынгылыкта калдырырга җыенмый.

Утызынчы еллар башында Акчуриннар Ленинградка күчә. Анда Абдулланың сеңлесе Гайшә ялгызы яши. Гайшә дә Бестужевканы тәмамлаган, укымышлы гүзәл зат. Хәзер аңа да ярдәм кирәк. Бәлкем, «эз» дә югалып торыр. Абдулланы инде әллә кайчаннан бирле «яшерелгән» алтын-көмешләрен таптырып интектерәләр. Аны да «Себер елап көтә».

Шифа апаның йөзенә гасырларның авыр, сагышлы күләгәсе ята.

– Әтине 1932 елда кулга алып, Ерак Көнчыгышка озаттылар. Ходай Тәгаләнең берәр рәхмәтле бәндәсенә очрадымы, лагерьда аны: «Хаксызга утыра», – дип азат итәләр. Әмма тәкъдир дигәне дә «якадан ала». Кайтыр юлга чыккач, аягында гангрена башлана... Әти поездда үлә. Янәшәсендә мәрхәмәтле бер татар кешесе туры килеп, аны Новосибирск шәһәрендә җирләп калдыра. Үзе үлгәннән соң, әтинең: «Миңа тагылган гаепләрнең берсе дә расланмады... Тәмугтан кайтып киләм. Минем кадерлеләрем, озакламый күрешербез», – дигән хатын алдык.

Шифа апа, башын иеп, бераз сүзсез тора да дәвам итә.

– Мин бит сезгә берсеннән-берсе ачы тәкъдирләр турында сөйләргә тиеш булам. Бәхетсезлек арты – бәхетсезлек, әтидән соң, озак та үтмәде, 18 яшьлек Яхъяны

«халык дошманы» улы, дип, ишегалдында аяктан екканчы кыйнап ташлыйлар. Аннан, пролетар балаларына көн юк, дип, милициягә барып әләклиләр.

...Абыебызга төрмәдән чыгу насыйп булмады инде. Кыйнап үтерделәр. Әни бу кайгылардан тәмам сыгылып төште. Нишләргә, ничек юатырга?! Бу чарасызлыкның авырлыгын сүзләр белән аңлату мөмкинме соң?! Ул елларда «халык дошманы» хатынына эш табулар да дөньялыкта сират кичүгә бәрабәр диярлек. Әни көч-хәл белән генә, институтта бергә укыган танышы аша, газета-журналлар киоскына эшкә урнаша алды. Хәзер аның өчен иң мөһиме – безне җил-яңгыр тидермичә саклау һәм укыту иде.

* * *

1938 ел. Ленинградка, кара елларга карамыйча, ак төннәр иңгән чак. Ә иртәгә алар, табигатьнең бу тылсымын, хыялларын калдырып, Оренбургка китәчәкләр. Гөлсем сөрген исемлегенә кергән өч шәһәр арасыннан Оренбургны сайлады. Татарның асыл шәхесләре булган Фатих Кәримиләр, Дәрдемәндләр, Рәмиевләр, Хөсәеновлар истәлеге итеп сайлады. Әле кайчан гына Гөлсем Гаяз әзинең Варшавадан язган хатына сөенеп бетә алмаган иде. Менә хәзер аны шуның өчен «ышанычсызлар» төркеменә кертеп куйдылар. Шәфкать туташының Балкан сугышы вакытында Төркиягә ярдәмгә килүен дә «исенә төшереп» үттеләр. Шулай итеп, «гаепле» Гөлсем Акчурина гаиләсе ике көн эчендә Ленинградтан чыгып китәргә тиеш булды.

Соңгы кичтә ул бар сагышларын Нева ярында «сөйләп» калдырмакчы. Нева исә аның үткәндәге очсыз-кырыйсыз уйларын дулкын-дулкын итеп ярга чыгара торды. Ә менә төньяк пайтәхете Сарай-Диварлары ярыннан искән су җиле, язмыш җиле аны кочып, бөтенләй туңдырып җибәрәсе итте... Кайчандыр ул ак төннәр яктысында Тукайга Нева ярларын күрсәтергә хыялланып йөргәнен исенә төшерде. И-и гомерләр... Гөлсем үзалдына нидер әйтмәкче булган иде дә, аны каршысыннан узып баручы, чырае да, җаны да кара шәленнән дә карарак кайгыга төренгән ханым җәлеп итте.

Гөлсем аның үтеп китүеннән куркып, тизрәк сәлам бирергә ашыкты:

– Анна Андреевна, хәерле кич, исәнмесез?!

Шагыйрә теләр-теләмәс кенә күтәрелеп карады да сорап куйды:

– Без танышмы?

Гөлсем бер мизгелгә уңайсызланып та калды, аннары:

– Безнең институтка очрашуга килгәч, Сез мине Джокондага охшаткан идегез, – диде.

– Менә ничек... – «күрәзәче»-шагыйрә бу юлы текәлебрәк карады. – Күрәм, сезне дә кайгылар читләтеп үтмәгән.

– Әйе, ирем дә, улым да – репрессия корбаннары. Үземә дә биредә көн бетте. Иртәгә Оренбургка күченәбез.

– Кайгыгыз зур... Сабырлык телим.

– Ә үзегездә ни хәлләр, Анна Андреевна?

– Минем улым да төрмәдә. Инде икенче мәртәбә утырттылар. Ул анда тилмерә, мин монда ут йотам. Язмыш әнә Невадагы аерып куйган күперләр шикелле. Соңгы выкытта аларга карап тору күңелемә шом сала. Менә шулай күперләрнең кушылганын көтеп йөрим. Алар белән бергә Ленинградның үзәге, Васильев утравы гына түгел, җирләр, күкләр, җаннар да тоташа төсле... Әнә, күперләрне кушалар. Хәзер инде кайтырга да була. Ә сезгә хәерле юллар... һәм гомерләр, Джоконда. Татарчасын – Гөлсем Акчурина, дидегез бит әле. Шигъри исем.

Алар кочаклашып аерылыштылар. Шагыйранә җанлы бу ике ханымның дуслыгы әнә шулай башланып китте.

– Зур шәһәрләрдән соң Оренбург бик кечкенә, хәерче, котсыз булып күренде. Безгә ярым подвал бинадан бер карават куярлык кына урын бирделәр. Әни башта ашханәдә ипи кисүче булып эшләде. Аннан ипи заводына бухгалтер-кассир булып урнашты, – дип дәвам итә сүзен Шифа апа. – Ә беркөнне, әни базардан кош тоткандай сөенеп, бик нәфис челтәрләп бәйләгән ап-ак Оренбург шәле күтәреп кайтты. «Анна Ахматовага! – диде ул. – Теге кара шәлен салып, шушы ак шәлне ябынса, кайгылары китмәс иде микән», – дип хыялланды.

* * *

– Казанга кайту әнинең гомерлек хыялы иде. Аның шулчаклы ашкынуы миңа да тынгылык бирмәде. Казан – аның яшьлек эзләре, Тукайлар, Әмирханнар хатирәсе, татар мохите, татар моңнары, шигырь кичәләре... Ниһаять, 1948 елны без Казанга кайтып урнаштык. Монда да фатирсызлык, кеше өстендә яшәүләргә карамастан, әнигә җан тынычлыгы иңгәндәй булды. Әни танымаслык булып үзгәрде. Элеккеге дуслары, танышлары белән очрашып йөри башлады. Үзен аңлаучы кешеләрне тапты. Бигрәк тә, ирле-хатынлы яшь галимнәр – Нуруллиннар гаиләсе белән дуслашты. Әни аларга кирәкле, кадерле икән ич. Мин үзем өчен әнине өр-яңадан ачтым.

* * *

2013 елның гыйнварында мин Мәскәүгә Шифа апа янына кабат бардым. Бу ел аның йөзенә тагын сызлану сызыклары өстәлгән. Алай да, ул әле үзенең тәгәрмәчле урындыгына таянып, балконга чыга һәм икешәр сәгать тәрәзә артындагы шау-шулы дөньяны күзәтә. Янына Сафураның оныклары һәм социаль тәэминат кешеләре килеп тора. Шифа апа, язмышларның үзәкләргә үтеп калган елларына кайтып, башыннан кичкәннәрен янә искә төшерә. Ул сөйли, ә мин шул язмышлар эченә кереп чумам.

– Әнигә кайгылар өелеп килде инде. Шәмсениса апа да яшьли үлгән. Ире белән улы Равил дә – төрмәдә. Ярый әле кече улын Җәваһирә апа Свияжскида үзе эшли торган балалар йортына урнаштырган. Әнинең инде Муса Бигиев белән Әсма апа өчен, балалары өчен зар елауларын әйтеп кенә бетерерлекмени?!. Аларны бит, эзәрлекләүгә чыдый алмыйча, этиләре чит илгә китеп баргач, «илне сатучылар» дип атыйлар, олы бабаларын төрмәгә утырталар, кечеләре белән Әсма апаны Вологдага сөрәләр.

– Үкенечләр зур, – дип кабатлый Петербургның яшь галимәсе, атаклы дин галиме, фәлсәфәчесе, язучы Муса Бигиевның Мөхәммәд атлы оныгының җәмәгате Альмира Таһирҗанова. Аның 2009 елда дөнья күргән «Книга о Мусе эфенди, его времени и современниках» дигән китабын титаник хезмәт дими, ни дисең? Татар җанының чиксез өзгәләнүләрен сурәтләү өчен, Муса Бигиевның хатыны Әсма ханымның көндәлекләрен генә уку да җитәр иде кебек...

– Мин ун классны Оренбургта тәмамлап, Ленинградта тимер юл транспорты инженерлары хәзерли торган институтка кердем. Беренче курсны тәмамлауга, сугыш башланды. Өчебез – өч якта. Әни – Оренбургта, Сафура – Ленинград фронтының күчмә госпиталендә. Аз гына мөмкинлек булу белән, ни дә булса

ашарга юнәтеп, институтка, минем яныма килә. Яшьсез генә елыйбыз, икенче тапкыр очрашырбызмы, юкмы?!

Сафура сугышка чаклы, медицина училищесын тәмамлагач, Харьковта эшли башлаган иде. Анда Юра исемле украин егетенә кияүгә чыкты. Ике кызлары туды: Лилия белән Аэлита. Сафура хирург ире белән 1942 елда сугышка киткәндә, балаларын Харьковтан алып кайтып, әни янында калдырды. Балалар ашарга бик тилмергәннәр. Әни аларны җаныннан артык күреп карады. Сугыш беткәч, ире Сафураны ташлап китте. Балаларны әни үстереште. Сугыштан соң Сафура Казан медицина институтына укырга керде. Аннан гомере буе Лениногорск районында баш табибә булып эшләде. Кызлары да медицина өлкәсен сайладылар.

1943 елны безнең институтны Казакъстанга, Алма-Ата шәһәренә эвакуацияләделәр. Исән калганнарыбыз шунда күчте... Сугыш тәмамлангач, Ленинградка кабат кайттык. 1945 елда институтны тәмамлап, башта Свердлауда, аннан Оренбургта тимер юл төзү инженеры булып эшләдем.

Шифа апага карап, тыңлап торам да сокланууымны яшерә алмыйм. Бу яшьтә дә затлы асылын, дворянлык сыйфатларын югалтмаган. Эчке бер нәзакәтлелек, кемлегеңне тоеп-белеп тору тышка бәреп чыга. Мин сорап куям:

– Шифа апа, сезнең үз-үзегезне тотышыгызда да, тавышыгызда да җитәкче урында эшләгәнегез сизелеп тора.

Ниһаять, Шифа апаның йөзенә чак кына серле елмаю йөгерә.

– Министрлыкта минем кул астында егерме ике ир кеше эшләде.

Бу юлы Шифа апа миңа бик кадерле фотоларын һәм Җәваһирә апаның оныгы Гөлнар Әмирханованың телефоны белән адресын биреп җибәрде.

* * *

Гөлнар апа ишеген шактый озак торып ачты. Аңа да 86 яшь шул. Алай да үз-үзен тотышында үзгә бер затлылык, нәфислек күзгә ташлана, хәтта балерина Галина Уланова чалымнары да чагыла төсле. Адым саен сагалап, күзенә генә карап торган зур эте генә башта сәеррәк тоелган иде.

– Тавышыгызга караганда, сез дә бик күркәмсездер, – дигәч кенә, аның бөтенләй күрмәвен абайлап, тәмам югалып калдым. «Рәхмәт» дияргә дә өлгермәдем, Гөлнар апа тезде дә тезде:

– Сез инде Чистай әбиебез Бибифатыйманың, чибәр әбиебезнең сигез кызы булганын беләсездер дип уйлыйм.

Мин дә, белгәнемне күрсәтергә теләп:

– Әйе, әле исемнәре генә ниндиләр: Әминә, Камиләтенниса, Гарифә, Җәваһирә, Әсма, Шәмсениса, Хәтимә, Гөлсем һәм яраткан бердәнбер абыйлары Ибраһим, – дим.

– Ә мин менә Җәваһирәнең оныгы булам инде. Дәү әнием Свияжскида балалар йортында рус теле укыткан. Мин үзем гомер буе санитария врачы булып эшләдем.

– Медицина фәннәре кандидаты булуыгыздан да хәбәрдарбыз.

Гөлнар ханым тыйнак кына елмаеп куйды да сүзен дәвам итте:

– Язмыш дигәнең адәм баласының гел башыннан гына сыйпап тормый инде ул. Безнең нәсел өстенә дә сынаулар аз килмәде... Сезне бигрәк тә Гөлсем кызыксындыра инде. Шифа апа шулай диде.

– Сез бит Гөлсем апаның иң якын сердәшчесе булгансыз.

– Сөйләрлек вакыйгалар җитәрлек.... Менә бер истәлек сезнең өчен

кызыклы булыр дип уйлыйм. Гөлсем апа Казанга күчеп кайткач, бервакытны Гарифә апа, Җәваһирә дәү әни, Гөлсем апа Уфага, Әсма апа янына «Тукай» пароходында баралар. Шунда шагыйрь һәм галим Мостафа Ногман белән танышалар һәм, билгеле инде, Тукай турында сөйләшеп китәләр. Менә шунда Гөлсем апа Тукайны «шагыйрьләр солтаны» дип атый һәм Мостафа Ногманнан аңа багышлап җыр язуын үтенә. «Син – шагыйрьләр солтаны!» Үзе һәйкәл булырлык сүзләр ич!

Тынмый сазың, моңлы сазың,
Кем тыя алсын аны!
Син яшәрсең, мең яшәрсең,
Син – шагыйрьләр солтаны.

Гөлсем апа үзе дә Мостафа Ногманның бик нечкә күңелле, ихлас кеше булуын сокланып сөйләгән иде. Әмма ләкин ниндидер сәбәпләр аркасында җыр соңрак туган. Гөлсем апа Рөстәм Яхинның бу гаҗәеп музыкасын ишетмичә китеп барды.

– Әле композиторның Гөлсем апаның үзенә багышлаган җыры да бар. Шифа әйткәндер, бәлки. Исеме хәтеремнән чыгып китте. Картлык. Искә төшү белән әйтермен, – диде Гөлнар ханым, онытуына үкенеп. Ни кызганыч, без башка очраша алмадык. Озак та тормый, шул елны ул мәңгелек йортка күчте.

Ә мин бөек композиторыбызның бар иҗатын, симфонияләрен, җырларын, романсларын күңелдән кичереп, бик озак биһуш бер халәттә йөрдем. «Апрель таңы» җырының музыкасы киң симфоник колачлы, Тукай бөеклегенең, халык мәхәббәтенең бер көчле кайтавазы булып яңгырады. Мин легендар Чистай кызының, бик күпләрне сокландырган, үзе дә шигърият багындагы бер гөл булган Гөлсем Камалова-Акчуринаның язмыш симфониясен дә, гасырлар авазын да тыңладым шикелле.

* * *

1951 елның кояшлы сентябрь иртәсе. Казанның Бауман урамына урнашкан Матбугат йорты янында яшь галим Ибраһим Нуруллинны таныш булмаган бер ир кеше туктата:

– Иптәш Нуруллин, – ди ул, аңа якынрак килеп, – борчуым өчен гафу үтенәм. Мин Салих Хәкимов дигән кеше булам. «Таткнигоиздат»ның дәреслекләр бүлеге редакторы. Сезнең бөек Тукаебыз иҗаты белән кызыксынуыгызны белгәнгә күрә, бик тә әһәмиятле бер мәгълүмат җиткерәсем килә үзегезгә.

– Әйдәгез, әйдәгез, тыңлыйм, – ди галим, түземсезләнеп, күзлеген рәтли-рәтли.

– Күптән түгел безнең күрше фатирда Оренбургтан күченеп килгән аналы-кызлы Акчуриналар яши башлады. Кыскасы, иң бай татарның хатыны һәм кызы. Әнисе Гөлсем ханым сөйләвенә караганда, ул Тукайны бик якыннан белә. Теләсәгез, мин сезне аның белән очраштыра алам.

Теләмиме соң инде Ибраһим? Соңгы вакытта шагыйрьне якыннан белгән кешеләр белән очрашу аның өчен изге гамәлгә әйләнде. Тукай турында берәр яңа мәгълүмат алу өчен, ул тау-таш ярырга да риза.

– Кайчан? Әллә бүген үк?

– Бүген үк булмас.

* * *

Очрашуларның тагын берсе, күңелдә тирән эз калдырганы – Казан дәүләт университетының журналистика кафедрасы доценты, тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, күренекле галимә Розалина Шаһимәрдан кызы Нуруллина белән иде. Олпат язучы, профессор Ибраһим ага Нуруллинның «44 ел буена яктылык нуры», сөекле хәләл җефете, олы таянычы, ярдәмчесе булган Розалина ханым янына без аның иң яраткан студенты һәм журналисты Филисә Хәкимова белән бардык. Бирегә дә безне Тукай һәм Гөлсем-Джоконда эзләре китерде.

Һәм без килеп керүгә үк, гаҗәеп бер дөньяга – рухи, мәдәни, тарихи хәтер дөньясына чумдык. Һәр җирдә пөхтәлек, чисталык, киштәләрдә, шкафларда уяу торган (безгә нәкъ шулай тоелды!) исәпсез-хисапсыз фәнни, әдәби, тарихи китаплар, Ибраһим ага үзе исән вакыттагыча сакланган эш, иҗат бүлмәсе... Без Розалина ханымны тыңлый-тыңлый, шактый вакыт аннан күзебезне ала алмый торабыз – барысы да сокландыргыч! Төс-бит, гәүдә, кигән кием, сөйләгән сүз, тавыш – һич тә сиксәннең теге ягы димәссең. Ә хәтер! Кыскасы, камиллеккә шаклар катарлык. Без чәйләп, рәхәтләнеп, озаклап сөйләшәбез. Розалина ханым һәрнәрсәне аңа хас якты бер елмаю белән сөйли:

– Бервакытны хәтта мин дә көнләшә башладым. Ибраһим: «Мин Гөлсем ханым янына барам», – дип чыга да китә, чыга да китә. «Һаман нинди Гөлсем инде ул, мин дә синең белән барам», – дидем беркөнне. Гөлсем апа безне шундый ачык йөз белән каршылады, үземнең уйларымнан оялып куйдым. Кунакчыллыгына хәйран калдым. Шундый тәмле итеп шулпалар, пәрәмәчләр пешергән. Көн озынына сөйләшеп утырдык. Шуннан соң гына Гөлсем апаның Ибраһим өчен ни дәрәҗәдә якын, абруйлы икәнен аңладым.

Алар Сембер якларына Акчуриннар утарларын карап кайтырга да бардылар. Тик Ибраһим бик теләсә дә, әсәрләрендә бу гаҗәеп ханым турында бер иң кирәкле сүзне әйтә алмады. Ул заманнарда, атаклы ишан кызын, «халык дошманы» хатынын Тукай янәшәсенә куярга ярыймы соң?! Дөрес, Ибраһимның «Тукай Петербургта» дигән пьесасында ул Гөлсем ханымны Тукайга гашыйк курсистка образында бирергә тырышып карады. Әмма цензура нык уяу булып чыкты. Алар тикшергәннән соң, пьесада Тукай белән Гөлсемнең әңгәмәсеннән берничә җөмлә генә калды шикелле.

«Тукай Петербургта» пьесасы рус телендә телевизион спектакль рәвешендә күрсәтелде. Ул вакытта тапшырулар турыдан-туры гына алып барыла иде. Тукай ролен күренекле артист Николай Провоторов уйнады. Ул гәүдәсе, кыяфәте белән дә Тукайга бер дә охшамаган булса да, кичерешләрен тулы аңлап башкарды, һәм без аны Габдулла Тукай дип кабул иттек. Пьесаны университетның драма түгәрәге дә әзерләде. Аны академия театры сәхнәсендә күрсәтте. Хәтеремдә: Гатаулла Баязитовны – Миркасыйм Госманов, Джоконданы – Кояш Тимбикова (ул да Чистай кызы, булачак талантлы журналист һәм язучы), Тукайны Рим Кәримов уйнаган иде.

1955 елда әлеге пьеса «Совет әдәбияты» журналында басылып чыккач, Гөлсем апаның сөенүләре!

«Ишан кызларына да Тукайны яратырга рөхсәт ителә икән», – дип шаяртканы да хәтеремдә. Әгәр Ибраһим Гөлсем апа белән очрашмаган булса, аның «Тукай» һәм «Фатих Әмирхан» романнары шулай тиз арада язылмас иде

кебек: Гөлсем апа Ибраһим өчен чын мәгънәсендә зур табыш булды. Кайчак ул аңа «Хәзинә апа» дип тә эндәшкәли иде.

Ибраһимның «Тукай» романы «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә 1977 елда 100 мең тираж белән Мәскәүдә рус телендә, аннары татар һәм башка телләрдә дә нәшер ителде. Бу романы өчен Ибраһим Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Ибраһим Нуруллин – Тукайны, Тукай Нуруллинны киң дөньяга танытты.

Ибраһим Фатих Әмирханны тикшерүне дә һәрчак күз уңында тотты. Аның бу юнәлештәге эшчәнлек нәтиҗәләре шулай ук «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә 1988, 1991 елларда татар һәм рус телләрендә аерым китап рәвешендә басылып чыкты, һәм ул Гаяз Исхакый исемендәге премиягә лаек булды. Ә Гаяз Исхакыйга килгәндә, болай: ни гаҗәп, Гөлсем апа аның илгә кайтасына ышанып яшәде. Ибраһимга бик күп мәгълүматлар бирде. Әгәр Ибраһим тагын бер-ике генә ел яши алган булса да, аның «Тукай», «Фатих Әмирхан» романнары кебек, «Гаяз Исхакый» романы да дөнья күргән булыр иде. Һәм, әлбәттә инде, төп хатын-кыз образларының берсе Гөлсем ханым булыр иде. Ни кызганыч, Ибраһимның бөтен көче әдипнең исемен кайтаруга китте. Үкенечләр зур...

Гөлсем апаны сурәтләп, тагын шуны әйтә алам: ул барыбер бездән аерылыбрак тора иде. Киенүендә дә, үз-үзен тотышында да аристократлык, зыялылык ярылып ята. Мөгаен, Бестужевкада укулары да эзсез үтмәгәндер, иң зур татар байлары булган Акчуриннарның да йогынтысы зур булгандыр. Ул үзенә бик күп асыл сыйфатларны туплаган һәм аны язмыш сынаулары да, авырлыклар да үзгәртә алмаган.

...Без шулай озак утыруыбызга уңайсызлана төшеп, олы рәхмәтләребезне әйтеп, ниһаять, саубуллашабыз. Розалина ханым безгә үзенең гаҗәеп олы хезмәте булган «Тарих яза каләмем» һәм Ибраһим ага турында җентекләп, чын хакыйкатьне ачып салган, гаять һиммәтле китапларын бүләк итә. Тагын шушы araларда Ибраһим аганың архивыннан карап, кайбер мәгълүматларны әйтергә вәгъдә итеп кала. Инде икенче көнне үк телефоннан шалтыратып: «Ибраһимның көндәлекләрен карадым: «Тукай» романын язганда, 260 кеше белән очрашкан. Иң кызыклы, иң күп мәгълүматны Гөлсем ханым бирде», – дигән юллары бар, дип, безне тагын сөендерергә ашыга.

Шулай сөенергә дә өлгермәдек, бер көн үттеме, икеме – ушны алырлык хәбәр: Розалина ханым Нуруллина вафат... Инде ничә ел вакыт үтте, әмма әле бүген генә күрешеп сөйләшкәндәй, затлы онытылмас очрашу һәм җаннарны тетрәткән әлеге хәбәр күңелдән китми. Үкенечебез зур. Хушлаша да алмый калдык лабаса. Озак та үтмәде, тагын авыр хәбәр алдым. Бу юлы Мәскәүдән. Шифа апа да мәрхүмә булган... Урыннары оҗмахта булсын!

* * *

И-и гомерләр...

Һәм без Гөлсем Мөхәммәдзакир кызы Камалова-Акчуринага да, аның якты истәлеге алдында тагын бер кат баш иеп: «Урыныгыз җәннәттә булсын!» – дип, сүзебезне тәмамларга тиешбездер.

...1957 ел. Яз. Яңа Бистәнең татар зираты. Мөгаен, ул көндә дә өстә, ак болытлар сурәтенә кереп, фәрештәләр сакта торгандыр. «Кара төннең ак фәрештәсен» күрергә Тукай да күкләр катына күтәрелгәндер. Ул көндә

дә Җирләр – Күкләргә, Күкләр Җирләргә сәлам биреп җавап тоткандыр. «Дөньялыкта шәфкать иясе булган Өммегөлсем Мөхәммәдзакир кызын шәфкать берлә каршыладык», – дигәннәрдер. Алдында Мәңгелек йортның рәхмәт ишекләре ачылгандыр. Шулай булгандыр...

Менәниләр хакында сөйләттерде миңа йөрәгем. Бәлки, нокта куярга кирәктер. Шулай да гасыр кичкән вакыйгаларга тагын берсен өстәми булмый.

2006 елда, Тукайның тууына 120 ел тулган көннәрдә, Петербургта шагыйрьгә бәйләнешле тагын бер кадерле урын пәйда булды. Шәһәрнең Кронверкский проспекты белән Зверинская урамы кисешкән почмакта татарның бөек шагыйре Габдулла Тукайга һәйкәл куелды. Ул – Петербургка Татарстан хөкүмәтенең бүләге. Пётр I заманыннан «Татар бистәсе» саналган җирдә әлеге һәйкәлнең калкып чыгуын петербурглылар хуплап каршы алды. Һәйкәлнең авторлары – Әхнәф Зиякаев, Ян Нейман, архитекторы Станислав Одноваловның иҗаты чын мәгънәсендә югары бәягә лаек. Шагыйрьнең нурлы йөзе, илһамлы күз карашы әллә каян үзенә тартып тора. Бу безнең Тукай! Бирегә һәр килүемдә минем һәйкәл янына бармый калганым юк. Петербургка соңгы баруымда да шәһәр белән очрашуны шуннан башладым. Тукайга якынлашканда, трамвай тәрәзәсеннән һәйкәл янында басып торучы ак ландышлар тоткан яшь бер кызны күреп имәнеп киттем. Йа Хода, «Ак фәрештә» түгелме соң бу?

– Зинһар, мине биредә төшереп калдырыгыз әле? – дим мин, трамвай йөртүче ханым алдында өзгәләнеп. Тукталышка чаклы барсам, мин килеп җиткәнче, «Ак фәрештә» китеп өлгерергә дә мөмкин ич. Рәхмәт яугыры, трамвай йөртүче бер карусыз үтенечемне үтәде. Мин очып диярлек чыгам да, аңа рәхмәтләр укып, тота-каба һәйкәл янына йөгерәм. Кыз китмәгән. Һәйкәл янында. Татарның карап туйгысыз бер чибәре.

– Сез Гөлсемме? – дим кызга, ниндидер могҗизага өметләнеп.

– Юк, апа, мин Гөлнара, – ди ул, елмаеп, саф татар телендә.

Могҗизалар һәрдаим булып тормыйдыр шул. Ә нигә булмасын? Йөз елдан соң да шагыйрьгә тагын ак ландышлар китерәләр. Бу могҗиза түгелмени?!

Гөлнара бирегә Башкортстанның Бәләбәй шәһәреннән килгән. Петербургның данлыклы балет мәктәбендә укый. Аның бүген зур тамашада катнашасы бар. Ашыга...

– Икенче килүегездә һәйкәл янында ак ландышлар күрсәгез, биредә Гөлнара булган икән, диярсез, – ди ул, минем белән җылы итеп саубуллашып. Мин дә, «Ак фәрештә» хакындагы хикәятемнең кабатланмас бер мизгел белән тәмамлануына сөенә-сөенә, җәяүләп, Казанский урамына юл тотам.

...Ә Петербургка тагын сихри ак төннәр килә.

*Казан–Чистай–Мәскәү–Петербург.*
*2012–2018 еллар*



# Равил Рахмани

## Милләтебез яшәеше һәм фәлсәфи аңында «Хак» феномены*

ФӘННИ-ПОЭТИК ТРАКТАТ

Ислам дине белән тормыш-көнкүрешебезгә гарәп теленнән килеп кергән «хак» сүзе, төрки халыкларның яшәешендә үзәк урын алып, алга таба милләтебезнең дә бөтен киләчәк үзаңын формалаштыруда хәлиткеч роль уйнаган, рухи үсеш тарихында үзенчәлекле әхлакый нигез-кыйблаи көчкә әверелгән; бүген инде ул аның мең еллык үткән юлын, катлаулы язмышын, культура хасиятен аңлауга ярдәм иткән хикмәтле код-ачкыч булып тора. Бу сүзнең, телебездә нык таралып, универсаль кулланылышта йөрүе дә һич очраклы түгел, билгеле; әдәби мирасыбызга, халкыбызның сөйләм теленә, басылып чыккан сүзлекләргә игътибар юнәлтсәк[1], «хак» сүзе барлыкка китергән мәгънә төсмерләренең, дөньяви һәм илаһи яшәештә, дәүләт төзелеше, иҗтимагый аң, фәлсәфә, әхлак нормалары тудыруда, тармакланып, гаять киң диапазондагы кулланыш спектры хасил итүенә тап булабыз.

«Хак» сүзе 1) ***дөрес*** *(Хак сүзгә җавап юк. Мәкаль)*, ***туры*** *(Хак әйткән туганына ярамаган.* Мәкаль), ***гадел*** *(хак гамәл, хак мөнәсәбәт)*, ***чын*** *(хак дин)*, ***изге*** *(хак юлда)*, мәгънәләрен дә; *2)* ***бәя куюны*** да *(товар хакы)*, ***эш өчен түләү*** *(ни хакка башкарасың?)*; 3) ***катнашлык (пай)*** *(хакка керү)*, ***матди һәм рухи өлеш*** *(аның хакын да исәплә, сабый хакына кичерәм)*, ***шәхси мөлкәт, милек*** *(гаилә хакы, кеше хакына кагылма)*; 4) ***хокук*** *(үз хакың хаклау, Хакны әйтергә хакың булсын. Әйтем)*, ***вәкаләт*** *(аңа ул хак бирелмәгән)*; 5) ***ихтирам итү, игелек-хөрмәт күрсәтү*** *(күңеле китекләрне хаклый бел)*, ***олылау-дәрәҗәләү*** *(остаз хакын хаклау; бәйрәм хакына)* кебек төшенчәләрне дә; 6) ***бурыч, вазифаны да*** *(ата-ана хакы, Күрше хакы – Алла хакы. Мәкаль) белдерә*. 7) ***Илаһ*** мәгънәсе алып, ***Аллаһ, Раббы*** (гарәпчә), ***Хода, Ходай*** (фарсыча), ***Тәңре*** (төркичә), ***Туры*** (чувашча) сүзләренең синонимы булып та кулланыла (*Хак Тәгалә; Хак язганы*).

«Хак» сүзе катнашында барлыкка килгән тотрыклы сүзтезмәләр, идиомалар, әйтем-мәкальләр, шушы тамырдан ясалган мөстәкыйль яшәешле термин-төшенчәләр, табигый ки, аның мәгънә төрлелеген, психологик төсмерлелеген һәм чынбарлыкны колачлау масштабын тагын да киңәйтә. Аларның мәгънә аерымлыгын төгәлрәк аңлау-

[1] Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. – Казан: ТКН, 1965; Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда: 3 том. – Казан: ТКН, 1981; Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005; Татарча-русча сүзлек. – Ике томда: 2 том. – Казан: Мәгариф, 2007 һ.б.

* Журнал варианты

Равил РАХМАНИ (1949) – *шагыйрь, галим; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Шигъри бишек», «Канатлы дөнья», «Мең чакрымга мең чакрым» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

ачыклау һәм мәгънәви буталыштан качу өчен без биредә заман укучысына мисалларны аның рус телендәге тәрҗемәсе аша да тәкъдим итәбез:

***Хаклы*** – ценный, дорогой, стоящий; уместный, обоснованный, справедливый; хаксыз – бесплатный, даром; несправедливый; бесправный; ***хаклык*** – истина, правда, справедливость; ***хакы юк*** – не имеет право, недостоин; ***хаксызлык*** – несправедливость; беззаконие, произвол; безправие; ***хак-нахак*** – необоснованный, клевета.

Телебездән алынган әлеге ***хикмәтле*** сүзләрне бергә тезгәч, алар аркылы дөньяны күзаллавыбыз тагын да иркенәеп китә. Нәкъ реаль тормыштагыча, җәмгыяви чынбарлык барышы, контрастлык алып (*хаклык–хаксызлык*), **икегә аерыла**. Шушы кырыс каршылык бөтенлегендә, нәкъ яшәүнең үзендәгечә, үзәккә туплау кодрәте салынган.

Бу очраклы түгелдер, күрәсең, чөнки әлеге тамырдан ясалган мөстәкыйль мәгънәле сүзләр дә бит безнең бөтен тарихи үткәнебезгә барып тоташа:

***Хакан*** – каһан (титул императора в тюркоязычных государствах); ***хаканлык*** – каһанат (империя); ***хаким*** – судья; правитель, господин, властелин, повелитель; ***хакимият*** – государственная власть; ***хакимлек*** – господство; ***хәкарәт*** – оскорбление, поношение; глумление, посрамление; ***хәкыйрь*** – униженный, оскорблённый; презренный, подлый; жалкий, ничтожный; ***хәкыйрьлек*** – угнетённое состояние; покорность, смиренность; ***хәким*** – учёный, мудрец, философ; ***хакыйкать*** – истина, правда; ***хакыйкатән*** – искренно, от души; на самом деле, в действительности; ***хакыйкый*** – подлинный, истинный; полноправный, действительный.

«Хак» сүзе телебезнең лексик мәгънәсенә генә түгел, фикерләү рәвешен билгеләгән сүз төркемнәренә кадәр үтеп кереп, тел-сөйләмнең психологик рухына да бердәй сеңеп, табигый тармакланышлы яшәешен тапкан: Хак (исем); хаклау (фигыль); хакыйкый (сыйфат); хакыйкатән (рәвеш); ***хакта, хакында*** – *аның хакында*, ***хакына*** – *Җиңү хакына* (бәйлек). Күргәнебезчә, бу сүзнең потенциаль кодрәте хәтта бәйлекне дә мәгънәви яктан үзәкләштерә, максатчан итә сыман!

Җыеп әйткәндә, ***«хак»*** феномены ул халкыбызның үткәне генә түгел, бүгенгесе һәм киләчәк язмышы да!

Инде китабыбызга кайтып, «Кеше хакы» яисә «Алла хакы» дип фикер йөрткәндә, без бу сүзнең янәдән дә төрле мәгънә спектры: **өлеш, язмыш, вөҗдан** (син хаклымы?), **хокук, бурыч, вазифа, дәрәҗә** (хаксызлар), **абруй** (хакка ирешү), **бәһа, таләп** (хаклый белү), **максат юнәлеше** (шул хакта уйлану) һ.б. төшенчәләр төсмере белән ачылып китүен күрәбез.

Шул рәвешле, «моң» сүзе милләтебезнең дөньяга **психологик көйләнеш** менталитетын күрсәтсә, әлеге **«хак»** сүзенең мәгънәви тармакланышы исә халкыбызның дөньяны аңлау һәм күзаллавындагы тулы бер **фәлсәфи системаны** чагылдыра:

1) Илаһ, Илаһи яратылыш (Тәңре, Туры, Аллаһ, Раббы, Ходай);
2) өлеш (пай, кешенең катнашуы), язмыш;
3) бәя (товар, хезмәт, кеше бәясе);
4) хокук, вәкаләт;
5) яшәеш дәрәҗәләре (олылау, кимсетелү);
6) вөҗдан, бурыч, вазифа;
7) дөрес, туры, гадел, чын, хакыйкать.

Халкыбыз дөньяга әнә шундый «җиделе үлчәм» яссылыгыннан чыгып күз ташлаган, тулы комплекслы җиделе (бербөтен) яшәү аспектыннан чыгып эш итәргә омтылган. Шуңа да, безгә калса, **Моң** һәм **Хак** төшенчәләре ул татар һәм, гомумән, төрки кавем яшәешенең, аның аз дигәндә дүрт-биш мең еллык тарихы төпкеленнән үсеп чыккан рухи кыйбласының, сәнгатенең, менталитетының үзенчәлекле ачкычы сыйфатында, милли җанын һәм язмышын аңлауда төп күрсәткеч-код булып саналырга хаклы. «**Моң**» һәм «**Хак**» сүзләре аның тәненә һәм җанына үтеп кергән алыштыргысыз яшәү байлыгы. Милләтебезнең дә үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген бергә китереп тоташтырган төп рухи-әхлакый күпере әнә шул хикмәтле сүз-символларга нигезләнгән. Шуңа әлеге төшенчәләрнең, димәк, затлы яшәү кредосының башка чит милләтләр

менталитеты тәэсирендә юкка чыга баруын күреп, киләчәк буыннар тәрбиясен ятлар кулына биргәнлектән, гаять зур (әйтергә кирәк, нигездән) бозылган нәтиҗәне күреп җан әрни. Милләт кенә түгел, бөтен кешелек шушы гаять зур – төрки кавемнәр тарафыннан табылган, сыналган кабатланмас әхлакый-фәлсәфи кыйммәт мирасын югалта бара. Моңа бүген битараф калу мөмкин түгел.

Хикмәт шунда: Аллаһы Тәгалә кешеләрнең бәхеткә омтылышын һәм хокукын тигез итеп яраткан. Бу яктан алар Ходай каршысында бар да бертигез. Шул ук вакытта адәм баласының тумышыннан үлгәнчегә кадәр булган бөтен тереклеге гаять төрле шартлар эчендә дәвам итә. Язмышы белән генә түгел, тормыштагы яшәеше белән дә Кеше җәмгыятьтә үз урынын, үз дәрәҗәсен билгеләүдә зур активлык күрсәтә. Табигый ки, аның башлангыч яшәү статусы да гомер дәвамында әледән-әле нык үзгәреп тора. Шуңа да дәрәҗәләре белән кешеләр үзара һич кенә дә бертигез түгел. Бу аларның язмышлары (ятимнәр, зәгыйфьләр, аерым континент-регион, контингент, милләт вәкиле булу һ.б.), табигый сәләт төрлелеге (даһилар, талантлар, эпигоннар), яше һәм тормыш тәҗрибәсе (сабыйлар, балалар, үсмерләр, өлкәннәр, картлар), канкардәшлек җепләре (ата, ана, әби, бабай, бала, абый, апа, туганнан туган, чыбык очы), хезмәте, кәсеп-профессиясе, рухи-җәмгыяви мохите, заманы, яшәеш урыны, яшәү рәвеше (күрше, кунак, юлчы, халкы, Ватан-иле), Тәңре каршысында күрсәткән гамәле белән дә (аерым дәрәҗәле затлар) аерыла.

Шәхес булырга омтылган адәми зат әлеге катлаулы мөнәсәбәтләр арасында югалып калмаска, кеше, милләт һәм кешелек дәрәҗәсен үзәккә куеп, үзенең урынын төгәл белергә, Тәңре һәм ата-ана абруен уяу сакларга тиеш. Тормышыбыздагы бик күп фаҗигаләр кеше хокукларын югалтудан, үз өстеңә йөкләнгән бурыч-вазифаларны онытудан һәм кеше дәрәҗәләрен белмәү (яки күз йомудан) – кыскасы – дистә мең еллар буена тупланган иң кыйммәтле Хәзинәбез – Алла һәм Кеше хакларын исәпкә алып бетермәүдән башлана.

Табигатькә карата корткычлык сәясәте, денсезлек, ата улны, ана кызны белми яшәү, телсезлек, милләтсезлек, Ватансызлык, үз ләззәтең өчен генә дөнья куу яки, үз хокукын яклауны онытып, коллык психологиясеннән чыга алмау, кан-кардәшлекне танымау яки, киресенчә, аны алга куеп, гади кешене, ятим, мохтаҗларны оныту һ.б. тискәре күренешләр – кызганычка каршы, безнең заманның типик бер фаҗигасенә әверелеп бара.

Бүгенге тәрбия системасында иң зур җитешсезлекләрнең берсе, миңа калса, электә халкыбыз яшәешенең аерылгысыз бер компоненты булган Кеше хакын саклау принцибының юкка чыгарылуы, олының олы, кеченең кече була белмәве белән бәйле.

Әмма төрки мөселман цивилизациясенең берничә мең елга сузылган үз үсеш традицияләре бар. Безнең карашыбызча, киләчәк буыннар бәхетенә бәйле күтәрелгән бу проблемалар, һичшиксез, кешелекнең бүгенге үсеш юнәлешен принципиаль кире кагу һәм аның тәрбия системасына **кардиналь төзәтмә кертү** кирәклегенә ишарәли.

Соңгы елларда нык пропагандаланган һәм дөнья халыкларының аңын яулап килгән ирекле Американың акча культын идеаллаштыруы, Европаның әхлак иреген алга сөрү гамәлләре кешелек цивилизациясенең алга китүе түгел, ә бәлки, кешелектән алга йөгереп чыгып, адашып, кабат үзләренең башлангыч үсеш дәрәҗәләренә әйләнеп кайтуыннан гайре нәрсә түгел. Кеше яшәешен акча-табыш алуга кору һәм, дөнья ләззәтенә чамасыз бирелеп, тиешле әхлак нормаларын оныту – үзеңне абсолют ирекле дип күрергә хыяллану – теләгән бәхетне бирә алмый. Кешелекне ул акча колына әверелдерәчәк, тотрыксыз хайвани инстинктларга китерәчәк. Хәер, мәхлук хайваннар яшәеше бүген үк инде бик күп адәми затлар өчен әхлак ягыннан үрнәк булып куела алыр иде. Көнбатыш пропагандалаган тәрбия тенденциясе исә ничә дистә ел инде яшь буынның аңын-психикасын агулый, һәм бу юл котылгысыз рәвештә кешелекнең чираттагы фаҗигасенә, катаклизмга алып киләчәк. Моны бүген бу илләрдәге хәлләр дә бик ачык күрсәтеп тора.

Төрки-мөселман халыклары күңеленә әлеге яшәү рәвеше һәрчак ят һәм кыргый гадәт булып тоелды. Гомумкешелек культурасы шартларында тәрбияләнгән ул-кызларыбыз язмышының милләтебезгә бәхет китерә алмавы да гаҗәп түгел. Европа

ирегенең һәм Көнбатыш банклар системасының асылда ни булуы (сүз рибачылык, ягъни процент белән акча эшләү турында бара) кешелекне кая илтеп җиткерәчәге хакында Коръән Кәримдә бик ачык кисәтелгән.

Европа халкының, техника прогрессының тәгәрмәч уйлап табудан, барча фәннәрнең үсеше әлифба иҗат итүдән башлануын танып та, кешелек цивилизациясе нигезендә барыннан да элек әдәп ятарга тиешлеген онытуы, культуралылык дәрәҗәсенә санап, бу үзәк принципны еш кына тупас бозуы, рухи кыйбласын гадәттә аларга ияреп билгеләгән урыс әдәбиятының да «литер» (литература), ягъни хәрефне алга куеп эш итүе, төрки халыкларның әдәбияты исә баштан ук «әдәп» сүзенә (әдәбият) нигезләнгән булуы һич очраклы түгел, әлбәттә.

Тәкъдим ителгән **Хаклар системасы** – яңа заман таләпләреннән йөз чөереп, искелеккә-үткәннәргә борылу түгел, ә бәлки, киләчәкне кайгыртып, төрки-мөселман халыкларының меңьеллык традицияләренә кайту! Бу – кешенең ирегене буу түгел, киресенчә, чын яшәүнең, олы мәхәббәтнең нигез принципларын киләчәк буыннар өчен дә саклап калу омтылышы. Дөнья педагогикасы өчен исә ул, һичшиксез, **яңа сүз, яңа адым, яңа казаныш**, дөресрәге, халык педагогикасының сыналган принцип-кануннарына котылгысыз рәвештә кабат кире әйләнеп кайту буларак бәяләнергә тиеш. Әгәр дә без милли үзенчәлегебезне һәм милләтебезне, шул исәптән кешелекнең алыштыргысыз үзкыйммәтләрен саклап калырга уйлыйбыз икән, кичекмәстән әлеге **Кеше Хакының** үзәк принципларын гамәли тәрбия нигезенә куярга-кайтарырга тиешбез.

**Автор**

# КЕШЕ ХАКЛАРЫ

*Төрки халыкларның дистә мең*
*еллык мәдəниятенә багышлыйм.*

## Иманлы исем

Җиһанда һәрнәрсә исемле,
Исемсез туса җан – югала.
Сиңа да, зурлап, ат куштылар:
Гомерле булсын, дип, бу бала!

Әтиең-әниең дога күк
Теленнән төшерми исемең;
Тик шушы баш сүздә ачыла
Сөйдергеч әфсене кешенең!

Кабатлый урамнар, җил, яңгыр...
Теркәлдең җирләргә, күктә син;
Китерер исемең һәр таңда
Бәхтеңнең өр-яңа нөсхәсен!

Үзсенеп, яд итәр тиңнәрең,
Күпсенеп, ят итәр кемнәрдер...
Зур сөю кабызган ярыңа
Бу исем – дөньяда бердәнбер!

Милләтнең ул – Өмет-Вөҗданы...
Ул – җитмеш буыннан Әманәт;
Исмеңә аркадаш булалсаң,
Кералмас арага яманат!

Яңарыш – үстерү тапканны!
Теләктән максатка – юл ерак...
Исемнән җисемгә җиткәнче,
Мең тапкыр адаша бу йөрәк:

Калырсың язларда – түгелеп,
Җәй – кибеп, көзләрдә – күмелеп...
Ачылсын асылың – халкыңа,
Калкырсың кышларда гөл кебек.

Чутлама яшьлегең көннәрен,
Ел белән – яшимгә саналып...
Кушылма заманга, тоткындай –
Исемең урынына сан алып.

Әүрелмә күмәклек исемгә –
Туган тел түзмәс бу җәбергә!
Булма буш кушымта паспортта[2] –
Ил белән туганнар кабрендә...

[2] Сүз Татарстанда милләтне күрсәткән паспорт кушымтасы бирелү хакында бара *(авт. иск.)*.

Йөзе ак киләчәк каршында,
Күңле киң хөр Идел-йортының!
Дога күк ишетелә телләрдә
Иманлы исеме токымның.

Таш түгел, тәкъдиргә җөй сыман
Уелган мөһерле тамгасы –
Чын исемең гасырлар түрендә
Бер Хакка дан булып яңграсын!

## Ата-баба, нәсел, шәҗәрә хакы

Сабый көннән газиз күргән әби-бабам:
«Балам!» диеп аваз салды җан-тәрәзгә...
Хәтер терелеп, дистә буын кан-кардәшем
Тирәк булып үсеп чыкты ак кәгазьдә.

Күккә ашкан ябалдашлар – сокландыра,
Яши нәсел – күз алдында... яфрак яра.
Бу кодрәтле зур тирәкнең
тамыры кайда?!
Юк, күренми... җир астында алар бар да...

Дәшми тора... мин белмәгән әби-баба...
Белмәгәнгә бары – язмышлары кара...
Җан иңдергән, үстергәннәр... ишле иткәннәр –
Шыбырдаша күпме яфрак, әнә, кара!

Аңлыйлармы туфрак аша тамыр телен? –
Җан сизгечең белән сүлне барлау кыен;
Ник көз кергәч... үкенечле – сары дөнья,
Октябрьдә[3] ... ник түгә күк
зарлы көен?!

Торыр иде сафта иңне-иңгә терәп,
Бердәм типсә җирдә-күктә
милли йөрәк;
Сабантуйга кайтып төшкән кардәшләр күк,
Җир шаулатып гөрләр иде миллион тирәк!

Түгелсә дә күпме кардәш каны җиргә...
Сугаралмый нәсел тамырын җир астында;
Әби-бабам безне саклап чыга алган
Лаек яшәп ай һәм кояш яктысында!

Кушылган ул каннар
яшьлек ялкынында,
Мең тармаклы сөю-нәфрәт, холык булып...
Шәҗәрәңдә – синең җиңү… коллык… хурлык...
Җитди бәя... җир өстендә халык зурлык!

Юк, шауламый-үсми – үчә милли урман...
Гәрчә саны арта бара... куакларның;
Кай катламда...
бабайларның илләр корып,
Кодрәт сипкән яшәү-хикмәт учаклары?!

[3] Татар милләтенең фаҗигале Хәтер көне, Хәтер ае *(авт. иск.)*.

## Туган җир

Нурланып чәчкән йолдызлар
Сөю-дәрт очкыннарын, –
Раслап җир-күкнең галәмдә
Бер булып кушылганын!
Бу төннең изге мөһере –
Кендек каным тамган җир;
Иң беренче күкрәк тутырып
Яшәү-сулыш алган җир!
Урман-сулы тугайларың
Үз итте бишегемнән;
Чыгып чаптык кояш нуры
Уйнарга төшү белән.
Качышлы уйнап, кәккүкнең
Урманда санаулары;

Бакалар һәм былбылларның
Узыштан сайраулары
Иртә-кич сеңгән күңелгә –
Хөрлектә ишләр идек;
Алар телен белми калсак,
Җыр-моңсыз нишләр идек?!.
Талчыбыктай бергеп үстек,
Таралдык кошлар сыман...
Әкияттәге төпчек улга
Өч сынау кушкан сыман –
Эзләп югалткан бәхетне,
Чикне ничә урадым;
Һәр кайтканда өсти тордың
Вазифаңның зуррагын!

***

Син белгәнсең:
                үсмереңне
Читкә озату кирәген;
Тик еракта вакыт
                нечкә
Телә кеше йөрәген!
Шат, гамьсез гомер урынына
Алдым зарыгу әчесен;

Ничә гасыр...
        бәхтең көтеп,
Халкым, төштә яшисең!
Бәгырьләргә күчеп иңри
Җитмеш бабам гозере:
«Каның тартыр җирең булсын,
Җаның тартыр үз илең!»

***

Дөнья ачык төшендерде
Бөек хаклык-чынлыкны:
Сөеп була хөр яшәүне,
Сагынып булмый коллыкны!

Синең эздә... яндым-көйдем,
Суга төштем, батмадым...
Югалтканың – йөрәгемдә:
Ул – ирекле Ватаным!

***

Туган җир, рәхмәт, җай таптың
Улыңны кисәтергә:
Ир-егет йөрмәс, сокланып,
Буй-сынын күрсәтергә!

Бәләкәйдән сеңде аңга
Кырыс Җир әлифбасы:
Ир-егет кайта йортына
Үтәп зур вазифасын!

***

Өскә сиблер йолдыз гөле –
Синдә минем тумышым!
Кайтыр иркен тәүге сулыш –
Соңгы рәхмәт сулышым!
Син дип ут йоткан төннәрем
Нурга әйләнсен иде;

Милләт гамен меңгә телеп,
Таңнар шәйләнсен иде!
Ятар идем колак салып
Былбыллар тавышына;
Кушылып ирек чишмәсенең
Җәй-кышкы агышына!

## Сабыйлык

*И күңелнең шаулап аккан чишмәдән сафрак чагы!*
*И гомернең нурланып үскән яшел яфрак чагы!*
Г.Тукай. «Сагыныр вакытлар»

Тәңресенең мәхәббәтле
Тылсымыннан иңгән бу;
Әти-әни, туганнарга
Кояш белән тиңнәр бу!

Милләтенә канат куйган –
Мең ел көткән шаһзадә:
Өздерер коллык ятьмәсен –
Фәрештәдәй ак, садә!

Ансат булмас үтәр юлы:
Җиһанда ул – яңа Хак;
Җир-кояшка – уртак сөю,
Мең ялкында яначак!

Тигез булыр тиңе белән,
Өстен күрер олыны...
Җир-тугайда иркен җуймас
Горур милләт колыны!

## Балачак

Урамнарда тездән кара сыек балчык,
Ындыр артлап, ат аз йөргән мүкле юлдан,
Эздән эзгә калмый атлап –
беренчеләр,
Чөкердәшеп кайтып киләбез укудан.

Кемдә резин... баулы галош кемдә… минем
Әткәйнең эш ботинкасы аягымда;
Ул нык – кирза; фил табаны – балчык саргач,
Эчтән чолгау белән үзе таман гына.

Күрше Гайшә әпти ашыга шулай кая?..
Үтешли ул, туктап, мине күреп ала;
Шомлы сүзе өскә салкын су койгандай:
«Бар, тизрәк кайт, нәнәм, эткәң үлде анда...»

«Ә» хәрефен әле бүген үткән идек...
«Ә»не зурлап – шатлык, бәхет көткән идек...
«Әткәй», «әнкәй»,
«әбкәй», «әлхәм»,
«әкийәт», «әфсен»...
Дога сыман, һәрберсенә
җан җылысын керткән идек...

Каударланып, йөгереп кайтып житим, дисәм,
Артка тарта үзле туфрак аякларны;
Ник җилкенәм ятимлегем каршысына? –
Кайнар яшем өтә җилдә яңакларны.

Яңгырда да якты, җылы иде көннәр,
Кояшны күз, шыксыз болыт урап алса...
Тоташ нурда йөзгән гамьсез сабыйлыгым
Ничек юлын салыр кара буран аша?!.

Сабакташлар никтер арттан калмый йөгерә –
Яудагыча бергә! – Ялгыз кеше җиңелә...
Бер йодрыктай авыл башы малайлары
Бакча артлап томан баскан
зур урамга төшеп килә.

## Үсмерчак

Борылыр хәл юк: тәртип, закон, кысалар...
«Сыегыз!» – дип… «Кагыйдә!» – дип…
җан сулышын кысалар;
Ахры, безне кыршауларга кертмәкчеләр –
Кисмәкләрдә генә төртеп йөртмәкчеләр?..

Узган тормыш – калган кием… кирәкми!
Тик яңа дәрт, тәвәккәллек җилкендерә йөрәкне!
Яшәү очыш, экстрим-супер булсын!
Бу заманга кем килгәне күренеп торсын!

Бар ил белән юл адашып йөргәнсез...
Акыл төше сызлап чыга – түзгәнсез;
Безгә дә әле азрак акыл керә башлар –
Күрмәгәнне шуңа бүген күрә башлар...

Чыгарганнар мөхтәрәм зат – хакимнәр
Тимер кыршау – кырыс указ-законнар…
Акыл җыйсын, диптер, безне кисмәкләргә кертмәкчеләр, –
Җәмгыятькә Диогендай[4] яхшы кеше итмәкчеләр.

## Яшьлек

Күңелгә нур чәчелеп,
Китте офык ачылып –
Үсмерчакның урманында
Торган тылсым яшренеп:
Аны җанлы шаулы тормыш
Үзенә дәшеп ята;
Дөнья картасы өстендә
Җиһан ачылып ята.
Җилпеп хыял каурыйларын,
Вакыт ашыгып ята:
Күзләр – көндә, койрык – төндә,
Канат – таң чыгып ята.
Илһам тузгып, санак тулы
Хәреф-чәчүлек ята…
Иҗат кыры сөрелмәгән –
Бәхет чәчелеп ята!

Пошаманга калып, йөрәк
Гыйшкын чакырып ята;
Татлы балкыш, ачылмыйча,
Газап качырып ята.
Яшәү кыры – утлы яра:
Сөю, көнчелек, хата;
Тышы – тарих, эче – гыйбрәт,
Чынлык яньчелеп ята.
Кавем-кавем язмыш кайта –
Нәфрәт-яхшылык сайтта;
Кеше гаме... сүз табалмый
Җирдә басылып ята.
Күпме яңа дөнья ачты
Яшьлек-шагыйрь төн ката…
Алда – шәхес сукмаклары
Яшренеп көтеп ята!

[4] Диоген – кисмәк эчендә яшәгән грек философы *(авт. иск.)*.

## Ир-егет хакы

Бала чакта әй үсәсе килә!
Алда кебек бөтен яшәү кызыклары;
Башны чөеп өйдә, ишек яңагына
Күпме уйдык җиңү сызыкларын!

Үлчәмнәре – җанда ир-егетнең!
Милләт гаме эчке үсеш-шкалада...
Ул баш имәс кемнәргәдер ошаганга,
Борын чөймәс – үзенә тик ышанганга.

Иңдә исә авыр илтер мирас йөге,
Туктар ялга – туган йорты тупсасына...
Юк, өстәлмәс сызык ишек яңагына,
Артыр сырлар бары маңгай уртасында.

Йөрәгенә уелыр аның яңа эзләр
Әле Тәңре, әле Иблис исеменнән...
Кергән чакта ачып өмет ишекләрен,
Чыккан чакта ябып нәфрәт ишегеннән.

## Хатын-кыз хакы

Килгән язмыш – бергә, –
Адәм туган көннән...
Бер туфрактан, бер сөяктән – гомерегез;
Уртак ләззәт җимешләре тәмен татып,
Оҗмахлардан бер җан булып сөрелдегез.

Ничә мең ел Җирдә – яшәү таганында...
Иңгә иңне терәп тормыш кичердегез;
Җавап тотып киләчәге каршысында...
Хак алдында терәк булды
берегез өчен берегез!

Каршы торыр тиң көч бармы гүзәл затка?
Дөнья гамен гыйшкый утта яндырды ул;
Илһам биреп... үлмәс шигырь яздырды ул,
Кодрәт биреп... сүнмәс шәһәр салдырды ул!
Дәүләтләрне дер селкеткән яу ирләрен,
Патшаларны тоткын – әсир калдырды ул.

Ул-кызларын гел яктыга илтте сөю!
Ана булды гүзәл затлар –
бүләк итте халкын,
патша,
пәйгамбәрен...
Оҗмахкача нур түшәлде аяк асларына,
Мәгънәле итте Хак каршында
яшәү ямен!

***

Үзегезне тәмам онытып...
Ир булырга керештегез;
Бурлак бавын иңгә кигәч,
Нык үзгәрде йөрешегез...

Кырыс гаилә чыгырында,
Артык тамы кысылдыгыз?..
Өйдән качып... мең холыклы
Зур көтүгә кушылдыгыз.

Көндәшлекме... бунт идеме?..
Күмәк чирме йокты шунда... –
Чалулап китте холкыгыз,
Авып шайтан коткысына...

«Тигезлек һәм өстенлек!» дип,
Халыкара шигарь элде...
...Гүзәл затлар күп өлкәдә
Түрдә хәзер – лидер инде!

Килешмәүчән ярыш ачты
Белем, иҗат, идеалларда...
Вазифа, хокук, бәясен...
Уздырды... әллә кайларга!

Өйдә, эштә... бер дигән ат –
Үзе хатын, үзе ир-ат!

Булдырдыгыз!.. Инде бер сүз
Әйтер идем – тыңласагыз:
«Зинһар... кабат булсагыз ла
Чын хатын-кыз! – була алсагыз...

Тик көчсезләр... ярыш ача!
Алла бер дә – тиңсез Хак ул!
Җирдә горур кабатланмас
Бөек Ана – изге зат бул!»

## Өлкәннәр хакы

Яшәү юлы җиде еллап
Җиде тапкыр үлчәнгән...
Маңгаена буй-буй эзләр
Тикмәгә бит кучмәгән?!

Кысанлыкта – канат җәйгән,
Сынауларда – чыдаган;
Ярты гасырлык гомеренә
Кырыс хөкем чыгарган!

Уе – дәрья, сабырланган,
Хыялы – тын карурман;
Сөенече, көенече –
Меңәр еллык тамырдан...

Өметләре – оныгында,
Газиз канда укмашкан;
Күзләреннән кичке шәфәкъ –
Моң агыла тоташтан.

Тормыш гаме – узар болыт...
Җан Тәңрегә төбәлгән!
Сүзе – дога, кизләү булып
Бәреп чыга тирәннән.

Бездән алда килеп алган
Үз өлеше – көмешне...
Сиңа гыйбрәт – алтын калган, –
Аңа хөрмәт тиешле!

## Картлык хакы

Күп яшәде, күпне күрде, күп гамәлгә иреште…
Җилләр исте, сулар кипте, ком күчте…
Гомер атлы шарлавыкны ул кичеп –
Инде…
    җилгә, комга, нурга
            таралырга хокуклы.

## Ир-хатын, гаилә хакы

Икәү бергә кушылганда,
Уртак сөю җилкеткән;
Нурын өстәп, Хак каршында
Изге никах беркеткән.

Күчеп гаилә учагына,
Җылы бирсен хис-ялкын;
Яшәсен өйне яктыртып
Хатын хакы, Ир хакы!

Ир-егетнең «Халкым!» дигән
Булсын олы бурычы!
Буш кәеф-сафа корырга
Түгелдер бит тумышы?..

Янып... төш-үзәк була алса,
Ул таба алыр иярчен;
Юкса, юлы юк кешегә
Кем ышанып иярсен?!.

Хәләл җефете – илһамчысы –
Горур бассын янына:
Гаилә дигән серле учак
Зур максаттан кабына!

Сугылыр заман җилләре
Төрле яклап...
ул – сынар;
Аркадашың булмаганда,
Бер җан – көчсез ул сыңар...

Гаилә – ыру әманәте,
Төшермәгез хакын сез!

Яклаучысы ир-ат булсын,
Саклаучысы – хатын-кыз, –

Ул өстәсен сөю уты!
Ә балалар тугачмы?..
Инде хәзер Алиһә зат –
Гаиләнең кояшы!

Әти кеше – зур галәмдә
Гаиләгә төп терәк!
Чын кояшка җитми бөртек –
Өч, дүрт, биш бала кирәк!

Менә шунда санлар Ходай
Хатын-кызны, ир-атны;
Вакланмас милләт каршында
Хатын хакы, ир хакы!

Әби-бабайлар кодрәте
Сездән күчсен яшьләргә;
Җирдә язсын «мин» дип түгел,
«Без» дип, «Ил» дип яшәргә!

## Бала хакы

Ераклардан килгән әнә
Нәни яңа кеше:
Кайтты йортка үзе белән
Җиде буын төсе!

Әти, әни – җиде күктә...
Җанда кодрәт сизә;
Тик икесе белгән тиңсез
Сер ич – бу могҗиза!

Кул-аякта булмаса да
Гәүдә тотар көче...
Кыланмышы хәйран моның –
Нәкъ патшалар төсле!

Якыннарын, дәрәҗәләп,
Зур хезмәткә куйган;
Һәммәсенең йөрәгенә
Олы сөю уйган!

Елап, көлеп, җырлап, биеп...
Күңелне җилкетә;
Беркем белән исәпләшми –
Өйне дер селкетә!

Хакын белә: Тәңре аңа
Җан һәм яшәү биргән;

Һәр ике дөнья эчендә
Тигән өлеше тирән!

Сабый гына – җиһан зурлык
Олы сөю көтә!
Юк, бу көтми, күпкә кырыс –
Катгый таләп итә!

Бир син аңа һич калдырмый
Җанда булганыңны!
Һәм өстәп бир – карап тормас
«Кыска юрганыңны...»

Актар рухи хәзинәңне,
Берсен-бер кызганмый;
Син кайчандыр алган кебек,
Ул да бушка алмый!

Чыгып китәр бер иртәдә
Эзләп үз бәхетен...
Патша икән, димәк, патша –
Табар үз тәхетен!

Хаслап үстергән сөюен
Бирер оныкларга!
Булган хәзинә югалмый –
Бер дә курыкма ла...

Ходаеңнан шуны сора:
Күбәү тусын алар;
Берне алып – биш кайтарыр
Кавем булсын алар!

Милләт казаны сүнүен
Берүк күрмәсеннәр!
Читтә, сыңар көчек булып,
Шыңшып йөрмәсеннәр!..

## Туган йорт

*Оясында ни күрсә, очканында шул булыр.*

***

Әй Туган йорт! Син – кешенең
Җиргә килгән сабыйлыгы:
Бөреләнәчәк таланты,
Табигый җан сәерлеге.

Сабый рухы исән икән,
Адәм юмарт, көр, мөлаем;
Ул – буыннар арасында
Нечкә үткелдер, мөгаен.

Һәр бүрәнә ярыгының
Эзе сыкрар язмышларда...
Идән асты капкачында –
Тамак, тарих, ялгышлар да!

Туган йортың – синең телең,
Әдәп, динең, шигъриятең;
Бүрәнәдә ярык-эзләр –
Тарихтагы чик-дәүләтең.

Мең баулы кояш нурлары,
Алгы юлга төшә барып,
Чәчрәп йолдыз атылгандай,
Хәтер-җепкә күчкән бары!

Әй Туган йорт! Син – кешенең
Онытылмас сабыйлыгы:
Талант-кодрәтен туплаган
Кабатланмас язмыш иле.

***

Бер заманны карга баткан әткәй кайта,
«Әти!» диеп йөгреп чыккач... ул шаярта:
«Әти түгел, сезгә әпи кирәк!» – дигән була,
Күтәреп үк ала үзе безне ике якка.

Ипиләре өшегәннәр: ап-ак, тәмле –
Килә аннан чын туңдырма тәме.
Әткәй кайткач, ут кабына – ялт итә өй,
Тормыш бөтенәя, арта дөнья яме!

Табын янына җыелу – җаваплылык,
Чират тора бер-бер артлы түземсезлек;
Хисап тота җиңү арты җиңү,
уңышсызлык –
Юкка чыга күңелдәге тынычсызлык.

Уртак хуплау өсти җанга нур-яктылык,
Читтә торсын олы, купшы бәйрәмнәрең;
Сагынышып бер йодрыкка туплануы –
Иң мөкатдәс бер мизгеле гаиләнең.

***

Синдә узды, Казан, илле еллап гомерем,
Тик илле көн тыныч, горур уянмадым;
Чал галимең, шагыйрь, дворнигың булдым, –
Гәрчә җанга Туган йортым булалмадың.

Шәһәр халкы ул – тамырын бик тиз оныта,
Хәсрәт чикми гореф-гадәт, йола юкка;
Гомеренең иң зур җиңүе санап –
Кереп утыра кыйбласы юк гомум йортка.

Китап тотмый өйдә – сөйми аның исен,
Түр башында ике эте аның өчен;
Иртә-кичен йөртә аларны саф һавада
Һәм тәрбия кыла салып барлык көчен.

Телен белми, гәрчә хәйран телдәр үзе...
Уяу саклар өчен, күрәм, үз аурасын;
Ярата ул бабаларын изгән халык телен,
Һәм яртылаш сеңдерә алган культурасын.

Ә үсеш зур милләтара багланышта,
Уңышларын көн дә себерәм... һәм шаккатам:
Элек атсалар төпчекне мич башыннан,
Болар ата тәрәзәдән, өске каттан.

Юкка түгел үз якташы, кардәшенә
Кырын карый, чит-ят булып – сыену тапмый;
Йомшак ягын барыбыр өстен чыгармакчы –
Хәкарәтләп аны «дерёвня» дип атый.

Казан тулы ыспай түрә һәм сәүдәгәр,
Юккамыни алар шагыйрь күрсә кыза?!.
Горурлыгы – канун үтәү, хезмәт итү,
Кешелеге кибәк кебек: үссә – туза.

Мин генәме – һай, күп килеп адашканнар,
Ямь табалмый милләтеннән киселә яшьли;
Моңсу күзен төбәп, басып җан сыкравын,
Гомре буе туган ягын җирсеп яши.

Елдан елга арта бара шәһәрләшү...
Үсә илдә кыйбласызлык, шәрә «мин»лек;
Тукайга тиң даулы, шанлы гасыр китә,
Илһам китә... кала утырып «мәдәнилек».

Әрне, мактан, оялт, сүк син, хет вәгазьлә –
Халкыңның юк үсү, яшәү бәрәкәте...
Милләт өчен Казан – боз-тау каршысында –
Шапрынулы зур «Титаник» һәлакәте.

***

Күнегәсең ата-анаң, сабыйлыгың юкка...
Килешеп булмый!
Бу җиһанда Илең-телең юкка;
Биш йөз еллык миллиард теләк калса туктап –
Әверелмичә
Туган йортлар Идел-йортка...

## Ата-ана хакы

### *Әткәй*

Тере мирас – ата-баба канын
Алып чыгып кырык үлемнән...
Әманәт күк, нәфсен вакламыйча,
Саклап килә алган бүгенгә!

Туфрагына гашыйк игенчедәй,
Вазифаның тоеп зурлыгын...
Ак күңелдән җир куенына биргән
Бәрәкәтле нәсел орлыгын!

Без туганга әнкәй бер сөенсә,
Аннан узып күбрәк шатланган:
Гади тормыш ямен зурлый белгән
Сыңар түгел, җидәү канатланган! –

Сүзсез генә ихлас сөя белгән,
Төчелектән һәрчак сак торган;
Тормыш кырыс була төшкән саен,
Җан җылысын безгә арттырган!

Кагылып-сугылып үткәнгәме гомере,
Әнкәй сүксә, бик еш яклаган...
Тәрбиядә кылыч ике яклы –
Бербөтенлек шулай саклаган!..

Бронь изде сугыш мәхшәрендә,
Көн-төн тракторлар әзерләп,
Барын бирдең илгә... шефың йолдыз такты,
Син илледән кердең кабергә...

Яз-көз, җәй-кыш... эштә – ерак булдың...
Рухың торды һәрчак янәшә;
Идеалымда кабат сиңа кайтам,
Күңелең аша көнгә эндәшәм.

Телә бәгырь: бөек Ата хакын
Хәзер менә хаклар идек тә...
Гадәтеңчә, син ерракта... читтә –
Гел йөрәктә, үзең – биектә!

### *Әнкәй*

*Җәннәт – аналарның аяк астында!*
Хәдис

Әннә, әни, әнкәй, әнекәем...
Ничә төрле сөю биргәнсең;
Кабат-кабат кайтып, алларыңа
Баш куюым... алдан белгәнсең!
Яшәгәнбез уртак бер кан белән,
Тоеп бер үк йөрәк тибешен;
Бер сулышның иркен татыганбыз,
Мин – өзелгән бәгырь җимешең!
Бер Ходамнан син җан сорап алган,
Сөюеңнән тәнгә нур тулган;
Мәңгелектән килгән яралгыма
Кояшым да, Җир дә – син булган!
Дөнья тәмен белдем сөтең аша,
Бүләк иттең бишек телемне:
«Аның аша инде табарсың, – дип, –
Дөньялыкта калган гыйлемне!»
Мин җиденче төпчек бала идем, –
Калдырмадың бер дә артыңнан;
Гаиләнең нечкә кыллы сазы
Йөрәгеңә бер-бер тартылган...
Өзелде кыл – әткәй китеп барды...
Тукталды җыр,
галәм,
жир,
вакыт;

Бер өй ятим – әрнү җыеп калдың –
Мөнәҗәтең торды юатып.
Күтәрелдек алыш дөньясына
Әтиләрсез калган холыктан;
Авырлыклар... юк, измәде җанны,
Гаделсезлек булды куркыткан.
Хокукларны никтер яшерен тотты,
Вазифасын артык еш күрдек;
Рәхмәт, язмыш, җирдә чын бәхетнең
Милләт хакы булуын төшендек.
Безне, әнкәй, җиде йолдыз санап,
Күз нуры итеп күккә очырдың;
Өмет-гамьне җидегән балкышыннан
Чүмечләп син безгә эчердең...
            Икегезгә – ике җидегән йолдыз...
Аерылгысыз бергә әйләнә;
Ике йөрәк... җиде бала... уртак язмыш
Сөю үзәгенә бәйләнгән.
            Онытмадык Ана хакы кадерен,
Гомер буе җанда йөрдең син...
Әнкәй, әнкәй... һаман безгә бирдең, –
Кайтардыкмы меңнән бересен?..
            Әннә, әни, әнкәй, әнкәем лә...
Йөз ел буе балкып яшәдең!
Әверелдең милләт анасына, –
Горур тама сагыну яшьләрем...
Син җирдәге якты Кояш идең,
Син булганда – бар да яхшыга...
Синең арттан йөгерәм яланаяк –
Җидегәнле язмыш каршына!

## Туган хакы

*Без үскәндә үскән идек*
*Тал тамырлары кебек;*
*Үсеп җиткәч, таралыштык*
*Кош балалары кебек.*

Халык җыры

Әткәй-әнкәй, өч-дүрт әби-бабай...
Уртак юллар... бетте...
                    онтылган;
Яңа эскиз – һәркем күзалдында:
«Сездер, – диләр, – ахры, бертуган?!»
Бер атаның орлыгыннан күчеп,
Бер ананың карынында үсеп,
Зур тарихи озын дәвер кичеп
Яралганбыз бергә яшәргә дип!

***

Мин беренче өйгә кайту белән,
Ялгызлыгың инде җуйгансың;
«Кире алып китмәсеннәр...» – өчен,
Өч көн, өч төн саклап кунгансың.

Хан тирмәсе – бишегеңә кадәр
Өч көнгәчә биреп торгансың...
Һәм, билгеле, сөю сүрелә төшкәч,
Чатыр кирәк булган шуннан соң!
Һәм тирбәлгән ике бишек өйдә,
Бергә җиңел – ярышып үскәнбез;
Урман-сулы җирнең сандугачлы
Таганына тизрәк төшкәнбез!
Майунында[5] Зөя буйларында
Каршыладык яшьлек бәйрәмен;
Туган җир ул сала белгән җанга
Онтылмаслык итеп ямьнәрен!
Печән чаптык, кырда иген суктык...
Хыялландык ташкын язларда...
Ярлар сөйдек, бизәп хыял белән...
Монысы калсын роман язарга!

***

Бер тамырның аеры кәүсәсе без,
Аерым ботак, аерым яфраклар;
Токым уртак – тик бер түгел гамьнәр,
Тартылышта төрле тарафлар.
Канатланып очып киттек өйдән
Ике якка – язмыш каршына;
Ходай безгә ике җан иңдергән,
Төрле холык, бурыч тапшырган!

***

Ничә еллар: үткән һәр көн белән
Йорттан читкә китә барабыз...
Бәхет эзләү – җанга әрнү сала, –
Ерагая һаман арабыз.
Ялгыз уңыш – читтә шатлык түгел,
Күңелдә гел – илгә кайтулар...
Җитми җанга язгы ташулардай
Юшкыннарны юып атулар!
Сүндерәм! дип өстән яңгыр койсын,
Әче җилләр чыксын каршыга...
Хыял уты сүнми кырыс көчтән,
Эчтән сүнү – хәтәр барсыннан!
Бу вак тормыш – түгел безнең өчен,
Селкеп атыйк иңнән кибәкне;
Кабат кабын дөрләп – күрсен җиһан
Азаккача янган йөрәкне!
Без милләтнең күтеп алган буыны, –
Очкын салыйк яңа заманга;
Терәк булу яхшы егылганда, –
Көрәш рухы җитми каннарда!

[5] Майуны – Татарстанның Тау ягы авылларында элеккедән үткәрелә торган язгы бәйрәм. Безнең Буа районы Толымбай авылы халкы әле узган гасырның 80нче елларына кадәр һәр елны май аенда (искечә майның унында), чәчүдән соң, алмагачлар чәчәк аткач, бөтен авыл бердәм кубып – атлар белән, җәяүләп өч атна рәттән Зөя буендагы урманга яңа табигать белән хозурланырга, ял итәргә, уенга – күңел ачарга чыга иде.

Гомер сөрсәк матди бәхет эзләп,
Бастырмасмы соңгы адымда
Бездәй игез, якын бертуганны
Көндәш итеп ата малына?!.

***

Сабый чакны кайтып күрик әле,
Каеннарга менеп тирбәлик;
Зәңгәр күкләр анда биек иде,
Тирән иде күктә тирәнлек!
Якын идек әти-әниләргә...
Һәм үзрәк хәтта Ходайга:
Исән чыктык барлык сынаулардан
Бит догабыз кабул булганга!
Элеккечә... ал да мине кулдан,
Яланаяк
        камыл өстеннән...
Кайтып керик арыш баш сикерткән –
Шау чәчәкле гомер эченә!

## Әби-бабай

Ул заманны китаплардан
Өйрәтәләр дәрестә;
Әби-бабай сөйли өйдә,
Тирәнәйтеп, дөресләп.

Әти белән әни үскән
Чорга кереп китәләр;
Шул көнгә кайтып... аларны
«Балалар» дип йөртәләр.

Кайчак горур, кайчак сыкрап:
«Яшь буын» – дип куялар;
«Тишек хәтер булмагыз!» – дип,
Искә төшереп торалар.

«Төп кыйммәтләр төшеп кала
Буыннар алмашында, –
Тапмый, – диләр, – интегәсез
Замана арбасыннан».

«Туган телдән, туган җирдән
Нигә, – диләр, – бизәргә?..
Үзең теләп – илдә тиңсез
Нәсел тамырын өзәргә?!.»

...Әби-бабай бүгенгегә
Карый шулай тирәннән;
Эшне алар төптән уйлап
Хәл итәргә өйрәнгән!

Мине дә бит алар сөя
Биреп бөтен җаннарын;
Килми «буш чүлмәк» буласым –
Мин – аларның дәвамы!

Җыр өйрәнәм, әкият тыңлыйм,
Керешәбез догага...
«Кеше, – диләр, – чын кеше ул –
Эчтә иман булганда!»

Һәр җанлыга, һәр җансызга
Алар изге теләктә;
Сөюләрен әби-бабай
Сала белә йөрәккә!
...Гасыр аша хак-дөреслек
Күренәдер еракта?!

## Туган тел үлчәме

Кешелеккә баба тел ул –
Атам-анам теле;
Ун мең еллык хикмәт анда,
Йөз гасырлык белем!

Расланусы – гамәлендә:
Шушы тел аркылы
Үткән, чордан чорга күчеп,
Киң җиһан акылы!

Бак – бабамның ым-аваздан
Телгә килүенә;
Бер иҗекле гади сүзгә
Мәгънә иңүенә!
  Күзаллаган тирә-юнен:
  *Тау, күл, кыр, саз, чүл, юл...*
  Ачык билгеләп кыйбласын:
  *Ас, өс, ал, арт, уң, сул...*
Вакыт – дисбе тезлеп тора:
*Ай, ел, көн, төн, таң, кич...*
Ел фасылы – дүрт могҗиза:
*Җәй, көз, яз, кыш!*
  Бабам үзен танып белгән:
  *Баш, ми, чәч, төк, бит, йөз,*
  *Каш, күз, тел, теш, миң, иң, кул, уч,*
  *Эч, сын, сан, ян, бил, тез...*
Әйтеп биргән халәтен ул:
*Рух, дәрт, хис, шик, моң, уй...*
Аннан фәлсәфәсен тапкан:
*Тән, җан, кан, аң!*
  Фикерләве шушы телдә –
  Моңа аналог юк:
  Шәрык фәлсәфәсе нигезе –
  *Җир, су, күк, ут!*
Өлкәнлеккә дәгъва итеп
Йөргән «мин-мин кем?!»нәр,
Кил, үлчәшсен тәрҗемәдә –
Күпне сөйләр телләр!
  Бит шушы гамьле авазлар
  Югары ялкында
  Эртеп коелган, корычтай,
  Гармоник законда[6].
Баба сүзне бернинди ут
Инде йоталмаган;
Тамырдан узып кушымча
Алда буталмаган[7].
  Телгә тирән сулыш иңгән,
  Нечкә уй яралган...
  Бишек җырың көнчыгыштан
  Нур булып таралган.
Мәгънәле татар җөмләсе –
Азакта тик фигыле[8];
Уйлап эшләнмәгән эшнең
Газабы билгеле!
  Хикмәтле һәм аһәңле ул –
  Зур шагыйрьләр теле!
  Кол Галиләр безнең чорга
  Алып чыккан тере!
Чичән һәм батыр телендә –
Иманлы нигездә
Төзи алдың олы дәүләт
Диңгездән диңгезгә!
  Әчесен дә, төчесен дә
  Күп күргәнсең, телем!
  Утына да, суына да
  Горур барып кердең...
Һәр сынаудан исән чыктың,
Отыры ныгый төштең;
«Кухня теле»дер... әлегә
Тере суы эчтең!
  Туган телемдә ниятлим
  Һәр укыган догам;
  Бөек Коръәнгә күчеп тик
  Баш иям, сәҗдә кылам.
Тәңрем, синең эндәшүең
Үз телемдә тоям;
Иң якты, татлы теләгем
Шунда очлап куям!

## Милләт хакы

Мине эзләп әнкәм тавышы булып килдең,
Бишегемне тал-тирәкле җырга төрдең;
Авазлары – челтер-чишмә,
                    җанга сеңде,
Сугара ул канны мең-мең еллар инде...

Иң кадерле өч сүзеңнән[9] мәгънә табып...
Кереп киттем тел дөньяңа чатыр чабып;
Күк әүрелде шау йолдызлар балкышына,
Яшәвемә йөз мең сүзле чаткы салып!

---

[6] Төрки телләрдәге гармониялелек, аһәңлелек, ягъни сингармонизм законы.
[7] Төрки телләрнең агглютинатив (сүз һәм сүз төрләренең үзгәрешсез тамыр-нигезгә кушылып) мәгънә ясау үзенчәлеге.
[8] Чагыштыр: Ул урманга китте – Он пошёл... в лес.
[9] Әннә, әттә, мәммә.

Ай-йолдызлы күл буйлары, алсу таңың
Алып килде ихлас яну – мәхәббәтем...
Югалтсам да җан сөйгәнем, сөю хакын...
Калдырмадың ялгызлыкта мине ятим!

Сөйми милләт чибәрләргә рәнҗегәнне...
Бер белмәсә, бер белерләр кадерләрне!..
Шигъри җанны ачкыч итеп әзерләдем,
Ачар өчен ун мең еллык хәзинәңне!

Язмышымны телеп үтте ут чаткысы,
Һәм ачылды милләтемнең күк капусы:
Тозлы дәрья – үткәннәрең күз тамчысы,
Якты офык – өметеңнең нур балкышы.

Гомер үтә – балачагым, сиңа чабам,
Кая барсам – Ватанымны иңдә табам;
Кайткан саен йөрәгемә әрнү алам –
Син, милләтем, бәхетемә тиңдәш ярам!

Әткәй-әнкәй мәңгелеккә күчеп китте,
Ятим бәгырь...
яшь аралаш сөенәмен:
«Әле дә ярый... син милләтем булган!» – димен,
Сабый төсле кат-кат сиңа сыенам мин.

«Милләт нигә?» дип йөргәннәр күбәләктәй
Яши алар чүгәләп тә, үрмәләп тә...
Йортсыз-җирсез детдом баласыдай,
телдә
Урын тапмый – тамырын җуйган дүңгәләкләр.

Саклап килдең гомрем буе буш яшәүдән:
Иңнән тартып туктатуың – уйлатырга...
Һәр адымда – аркадашым,
әзер тордың,
Бәла килсә, коткарырга, юатырга!

Әрнү-януларны бәхтем диеп саныйм...
Яши алдым бар гомремне суга салмый;
Милләт хакын иңдә тойган – утта янмый,
Ялгыз-ятим һәм бәхетсез була алмый!

Орлыкларың читләр туфрагына төшә...
Йортта – әрем... бәгъбрең ничек өзелмәсен;
Утлы яшем булып күчтең җырыма син,
Якты өмет салган улым-кызым да син!

Алда язмыш син дип ничек кыйнамасын,
Тормыш йөгең җанны ничек сынамасын...
Бер Аллама адаштырмый туры илткән –
Мең сыналган ышанычлы Кыйблам да син!

Ялтыравык бизәкләрдән бизгән күңел,
Керә барам яшәү асылы, җирнең кыйммәтенә;
Таянычы булыйм илдә милләтемә,
Тугры калыйм, Раббым, һәрчак өммәтемә!

## Изге китап эчендә сакланган бабам васыяте

Тарих хәтре безне яттан белә, –
Аттан төшеп,
ишәкләргә атланмагыз!
Тик Алыплар үтәп чыгар бурыч алда –
Вакланмагыз!

Ходай йөрәк, куәт, акыл биргән:
«Булдырдык!» дип, ярты эштә мактанмагыз...
Бер-бергезнең юлын бүлеп – тапталмагыз –
Вакланмагыз!

Ир – ир булсын,
хатын – һәрчак хатын!
Чыр-чулы дип замананы акланмагыз;
Сиблеп, чәчелеп... зур вазифа төшми өстән –
Вакланмагыз!

Үр менәргә ныклы иман кирәк,
Тәти күреп, тизрәк барып капланмагыз...
Тәңре бер ул! Җирдә кырык Алла табып –
Вакланмагыз...

Милләт яши – җиңеп алга барса,
Бер урында тора – сырхау,
Таптанмагыз...
Мескен халык хатасына кат-кат баса...
Вакланмагыз!

## Күрше хакы

*Күрше хакы – Алла хакы!*
Татар халык мәкале

Әни әйтә: «Күршеләр, – ди, –
Үзебездән яхшырак!»
Күрше апа безне мактый...
Белмим, кайсы хаклырак?

Күрше – бездән, без күршедән,
Дөрестән дә, әйбәтме?..
Үз-үзеңнән шәбрәк булу –
Теләктерме, гадәтме?!.

Җирдә шундый күршең юклык
Аянычтыр кешегә;
Күрше хакын хаклап яшәү
Һәркемне дә үстерә!

Нигә тарих китабында
Талау һәм үлем генә?
Өйрәтсеннәр дәресләрдә
Күрше булу гыйлеменә!

Бар милләтләр, бөтен илләр
Булса әйбәт күршеләр,
Рәхәтләнеп, иркен сулап
Яшәр иде кешеләр!

## Ятимнәр хакы

*Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!*
*Азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем.*
Г.Тукай. «Дошманнар»

Бәләкәй бер сабый йөрәгендә
Тирән яра әрнеп ачылган;
Уенныннан туктап ул ачынган:
«Ник мин ятим... шушы яшемнән?!.»

Сөеп әйткән сыңар җылы сүздән
Боздай туңган күңеле эрегән;
Боз тәрәздә кояш нуры күргән,
Хыялына гөлләр үрелгән.

Милләтенең утлы һәр сулышы
Җилкендергән шигырь язарга;
Яшьлек алып кайткан ул Казанга,
Рухи кыйбла – килер язларга!

Ябык ишек күреп үскән ятим
Язмыш көлен төптән актарган;
Һәр очкынын ялкын итеп янган,
Җанын ягып, әҗрен кайтарган!

Җылылыкны мең кат күбрәк алып,
Туклык тоеп үскән балалар –
Милләт туңган чакта... кайда алар,
Нигә аңа кырын багалар?!

И милләтем! Синең әче язмыш –
Шул кичәге ятим сулышы;
Ничә гасыр синең бу тумышың,
Ким булмаска күпме тырыштың!

Дошманыңның арба көпчәгеннән
Түбән торып гомер алгансың;
Далаларга сибелеп таралгансың,
«Казан ятиме»нә калгансың...

Ятимнәрнең язмыш уртактыр ул:
Киң дөньяда – тарлык, кимсенү;
Сулышыңда хокук, тын кысылу,
Карашыңда өмет киселү...

Рәсүлебез ятим бала булган...
Сөеклесе иткән Раббыбыз!
Аның юлын хаклап без атлыйбыз,
Юк, куркытмый ятим хакыбыз!..

Бир утыңны, Тәңрем, милләтемә,
Ятимлекнең бозы эресен;
Тукай булып язда ул терелсен,
Даһи асылы җирдә күренсен!

## Ватан хакы

Милләтләр күп... дәүләт корып,
Ил булганы сирәк;
Йөрәктәге акыл-җегәр
Тигез түгел, димәк!

Дәүләт арты дәүләт төздек –
Алмаганбыз гыйбрәт:
Канда җегәр – кайный тизрәк,
Акыл кала – чиерәк...

Малмы – җанмы? дигәч баскын...
Өстен күреп малны,
Ил күрке булыр затлары
Саткан синең җанны!

Мең ел, куяр урын тапмый,
Корбан иттек кемгә
Бәргәләнгән милләт бәгърен? –
Төштек коллык көнгә.

Дөрес әйткән борынгылар:
«Чыпчык үлми илдә!..»
Тик нәселең әманәте –
Әппә[10] ул чит өндә...

Тереләй җиргә күмлеп калган
Бабаң васыятьләрен
Кем илтер еллар каршына,
Җуймый хасиятләрен?..

Моның өчен алар телен
Белгән Ватан кирәк;
Һәм шул телдә типсен йөрәк:
«Без, дип, кемнән кимрәк!»

...Килү, китү – үле телдә,
Яшәү – кара көнгә...
Тамыр, чәчкәсез сабаклар, –
Без соң кемнәр җирдә?

[10] Әппә – телсез-чукрак.

Лакей гомерең – чәйлек акча,
Ятлар хуҗа түргә!
Балаларың – көтү-кавем, –
Солдат кирәк... илгә!

Дәүләт арты дәүләт җуйдык...
Инде гыйбрәт булсын;
Үз җырыңны җырлый торган
Ул-кызларың тусын!

Хак сөюен өстәп тулсын
Күкрәкләргә ялкын;
Үзе өчен – бөҗәк яши...–
Зурла милләт хакын!

Милләтләр күп... кыйбла тотып,
Ватан корган сирәк;
Йөрәктәге иман, акыл
Тигез түгел, димәк...

## Кешелек хакы

*Үткәннәргә... инде юк кайтасым!*
*Киләчәк тә никтер куркыта...*
*Санактагы өнсез кадр сыман,*
*Буш елларга эл(е)неп... ут йотам!*

Томырылды егет-заман бүз атында...
Яшьлек дәртен болгап сөю камчысында,
Җан-фәрманга куды, белми уңны-сулны,
Чибәркәе – кырыс Язмыш каршысына!

Алны-артны белми инде кире чаба,
Җәяү йөгерә – аргамагын яндырган ул...
Сөйгәненең җан йозагын ачар өчен,
Хак ачкычы – милләт гозрен
онытып калдырган ул.

## Хакыйкать хакы

Яшьлек ул – чәчәге язмышның,
Соңыннан өлгерә җимеше...
Йозактай келт итеп ачыла булмышың –
Йә бар син, йәки юк син, Кеше!

Үстерә милләтең тиң күреп:
Җир сөреп, тир түгеп, дин биреп...
Һәм сынар үзенә хезмәттә иң элек:
Бармы ул, юкмы ул ир-егет?!.

Булсын дип бәхетең канатлы,
Бәгъреңне, азмы йә... канаттың?
Чынбарлык яз белән, көз белән аңлатты:
Йә бар ул, йә ул юк... Ярату!

Лауреат дәрәҗәң кыйбла ит дүрт тараф...
Җәй тавис койрыгың, башканы сүк-каралт;
Куштанлык куыгын өр-кабарт – мең кабат –
Йә бар ул, яки юк ул...Талант!

Сорамый Мәккәдә булганың,
Хөкемгә тартыла вөҗданың;

Үлчәнә ниятең, гамәлең, кылганың –
Йә бар ул, йә юк ул Иманың!

Бетәрме үгилек халәте,
Ник начар күренә әйбәтең?..
Якларга атаң күк биреп җан гайрәтен
Йә бар ул, йә юк ул Дәүләтең!

Һәр туган яңа көн тозаклы,
Кабызган һәр өмет учагың газаплы...
Кызарып баеган һәрбер кич азаккы:
Йә бар ул, йә ул юк... Азатлык!

Камиллек үрнәге Табигать,
Ә тормыш – йә коллык, йә җиһад!
Син, Кеше, көрәштә үз бәяң хакын әйт:
Йә бер ул, йә юк ул Хакыйкать!

Исән ич этисе-энисе, үз халкы –
Ник үсә чит телдә мең ятим?..
Чыгарыр хөкемен чал тарих –
чын хаким:
Бармы ул, юкмы ул Милләтең?!.

## Хәтер хакы

Яр буйлары куак кына –
Оя-оя чатыр...
Дала иңләп илгә кайта
Шәҗәрәле Хәтер.

Сары-кызгылт яфраклары –
Безгә дигән хаттыр;
Һәрберсе – йөрәк...
җөйләрен
Ятлап укыр чактыр.

Тиздән барсы, сибелешеп,
Җиргә төшеп ятыр...
Җыерчыклы тарих сере –
Җәрәхәтле Хәтер.


Өсләренә яңгыр явар,
Кырау, чык чылатыр;
Фани дөнья гамьсезлеге
Сагыш-моң кузгатыр.

Тынып калыр аннан җиһан,
Кабат ак кар балкыр...
Язылмаган ап-ак кәгазь
Кемгә нәрсә әйтер?!

...Сулар акмый тормас җирдә,
Кайтыр язлар, кайтыр;
Бозны тишеп чыгар сабак,
Тамырларда – Хәтер!

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Дамир
Гарифуллин

# ҮТКӘН БЕЛӘН СӨЙЛӘШТЕРӘ ЧЫН ТАРИХ...

РОБАГЫЙЛАР

***

Әлмисактан безнең хәлләр тарихта,
Чынын күрик, тарихны актарыйк та.
Бабайларның данын-шанын кайтарыйк,
Чүп-чарларны чүплеккә аткарыйк та.

***

Тарих бит ул чын могҗиза, уйласаң,
Гафу итми, аның белән уйнасаң.
Ялган белән корсаң, ава бинасы,
Җимерелә, хакыйкатьтән коймасаң.

***

Үткән белән сөйләштерә чын тарих,
Киләчәкне көйләштерә чын тарих.
Горурлыкны ныгыта да дөньяда,
Халыкларны берләштерә чын тарих.

***

Безнең халык чып-чын Алып халык бит,
Моны илгә раслаучы да тарих бит.
Шул тарихны бозудан һәм сызудан
Бөтен халык күптән инде гарык бит.

***

Туган яктан алам дәрт тә, дәрман да,
Туган якта бетә талган-арган да.
Бүректәге бүре баласыдыр мин –
Кайда гына йөрсәм дә, күз – Сарманда.

---

Дамир ГАРИФУЛЛИН (1939) – *шагыйрь, археограф; «Чыгарсыңмы каршы алырга», «Сарман энциклопедиясе», «Җырларым, шигырьләрем...» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Сарманда яши.*

***

Хәләл булса тапканың, яхшы инде,
Хәрам булса, дәрәҗәң какшый инде.
Хәләл белән хәрамны аермаган
Җәмгыять ул мәңгегә аксый инде.

***

Алдый-алдый юатадыр бу дөнья,
Йокы бирми уятадыр бу дөнья.
Тыштан гына көлдергәләп тормышта,
Эчтән һаман елатадыр бу дөнья.

***

Барыбыз да фани дөнья иленнән,
Һәркемгә дә үз тактасы эленгән.
Тигез булсак та, җирдәге нәрсәләр
Кемгә бик аз, кемгә бик күп бүленгән.

***

Кемнәрдер бу җирдә энҗе тезгәннәр,
Ә кемнәрдер шул тезгәнне өзгәннәр.
Өзгәннәрдән бөтенесе бизгәннәр,
Яхшы-яман ни икәнен сизгәннәр.

***

Дуслар белән төннәре дә яктырак,
Дуслар белән эчкән сулар татлырак.
Моны миңа якын дуслар әйтәләр,
Дуслар исә һәрчак миннән хаклырак.

***

Язмыш минем кесәләрне буш иткән,
Аңа гына юк ла инде һуш киткән.
Шунсы гаҗәп: көн-төн чабып дөньяда,
Язлар көтеп йөри-йөри кыш җиткән.

***

Авырлыктан чын ир төшмәс коелып,
Морадына барыр, калмас тыелып.
Ил кайгысын үз кайгысы иткән ир
Калыр халыкның җанына уелып.

***

Кайтып киләм челтер чишмә буеннан,
Юл кырында чәчкә-гөлләр – муеннан.
Керфек сирпеп узып китте бер чибәр –
Чыкмаганмын икән әле уеннан...

***

Күпме кеше дөньяда яшәп киткән,
Яшен кебек күбесе яшьнәп киткән.

Шөкер, без дә яшәдек тә яшьнәдек, –
Яшьлегебез барыбер ташлап киткән.

***

Картлык нигә маңгайларны сырлыйдыр? –
Сырлыйммы, дип, бер дә сорап тормыйдыр.
Җырлыйммы, дип сорау кая инде ул,
Бертуктамый үлем җырын җырлыйдыр.

***

Хатирәләрдән гыйбарәт гомерләр,
Яд итәрлек ни туплаган күңелләр?
Сагынып сөйләр истәлегең булмаса,
Туксанда да гомер – гомер түгел лә.

***

Вәгъдә – иман, диләр безнең халыкта,
Вәгъдәңдә тор, авырлыкта калып та.
Гарьлеге ни, кайтармасаң кешегә
Кирәк чакта нәрсәләрдер алып та.

***

Мәрхәмәт кыл – яшәвең тулы булыр,
Хезмәтеңә хөрмәте олы булыр.
Ут-йөрәгең ачык булсын һәркемгә,
Барчасына яныңда җылы булыр.

***

Яшәешкә карау кирәк ап-аек,
Яшәеш ул менә шуңа бик лаек.
Кояш үзе яшәешкә көч бирә,
Һәр кешенең офыгына ак каеп.

***

Дөнья булса ышанычсыз кулларда,
Афәт арты афәт көтәр юлларда.
Кайгы-хәсрәт ишеп китәр кешегә
Шатлык кына төяп килгән еллар да.

***

Яши-яши яктыга баглап өмет,
Караңгыга бетәбез тәмам күнеп.
Болыт каплый таңыбыз атар-атмас,
Кояш та барамы соң әллә түнеп?

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Раушан Шәриф

# МИН СИНЕ МӘҢГЕ СӨЯРМЕН

МОҢСУ КОМЕДИЯ

*Икенче Бөтендөнья сугышында һәлак булган дәү әтием Нурмөхәмматкә һәм гомере буе аңа тугры булып, сагынып, көтеп яшәгән дәү әнием Фазиланың якты истәлегенә багышлыйм.*

Автор

**Катнашалар:**
Карт
Карчык
1нче егет
2нче егет
3нче егет

*Җәй узып бара. Әйе, бар нәрсә дә уза, узып бара. Шәһәр бакчаларының берсе. Бөек илебезнең һәрбер почмагындагы кебек, монда да үзенчәлекле тормыш бара. Агачлар арасында, аулак урында, иске генә утыргыч, һәм, әлбәттә, утыргычларның аерылмас юлдашы чүп-чар савыты, ул да күрәселәрен күргән. Бу манзараны тагын да тулыландырып, шул утыргычта буш сыра шешәсе тора.*

*Сәхнәнең ике ягыннан* Карт *белән* Карчык *чыгалар. Аларга карасаң, сукбайларча киенгәннәр, ләкин бик пөхтә. Карт та, Карчык та берьюлы сыра шешәсенә ябышалар да тарткалаша башлыйлар.*

Карчык. Нишлисең?

Карт. Тире җыеп, көн эшлим. Ә син нишлисең?

Карчык. Мин беренче күрдем. *(Шешәне үзенә тарта.)*

Карт. Күрсәң соң! Мин беренче алдым. *(Шешәне үзенә тарта.)*

Карчык. Алырсың? Кызыл кар яугач! Бирделәр ди сиңа!

Карт. Бакчадагы карачкылар сөйләшмиләр иде!

Карчык. Кем карачкы? Син,

Раушан ШӘРИФ (1963) – *драматург, артист, режиссёр, сценарист; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

карт алаша, авызыңны чамалап ач. *(Тартышалар.)*

Карт. Ә синең тешләрең юк!

Карчык. Синекен коеп төшермим тагы.

Карт. Койдырттылар ди, хәзер. Табаныңны ялтырат, бу минем территория.

Карчык. Кайдан килгән черек бай, алпавыт, территориясе, имеш. Территорияң зиратта көтеп тора.

Карт. Син, койрыксыз саескан, авызың ни сөйләгәнне колагың ишетми бугай, әллә чукракмы?

Карчык. Бир шешәне, диләр сиңа.

Карт. Хәзер! Мин гел монда йөрим, ә сине беренче тапкыр күрәм. Бу якта да тормыйсыңдыр әле.

Карчык. Син минем прописканы тикшермә...

Карт. Тикшерәсе юк, күренеп тора, кем икәнең дә, кайда торганың да.

Карчык. И-и-и! Үзеңне күр. Хәчтерүш, йолкыш, албасты! Бир шешәне.

Карт. Бирмим! Принципиально!

*Карт белән Карчык сугыша башлыйлар. Хәлләре бетеп, икесе дә егыла.*

Карчык. Башыңны сугып ярам.

Карт. Син яра торган баш түгел ул, аны немес булып, немес тә яра алмады.

Карчык. Берәр җирдә качып яткансыңдыр әле.

Карт *(ачуы чыгып)*. Кем? Минме? Мин, беләсең килсә, рейхстагны... өч осколочный ранение алган кеше. Мин кавалер ордена всех степеней... качып яткан?!. *(Шешәсен җибәрә дә, йөрәген тотып, утыргычка барып утыра.)*

Карчык *(шешәне букчасына салып)*. Менә яхшы, әллә кайчан шулай итми.

*Карчык китә башлый. Картның, йөрәген тотып, утырганын күреп туктый.*

Карчык. Авыртамы?

Карт. Нәрсә?

Карчык. Авыртамы, дим?

Карт. Синең ни эшең бар? Кызганды бүре бәрәнне, кирәгеңне алдың, тай!

Карчык. Китәм, китәм *(берничә адым атлый да Карт янына кире килә)*. Үлсәң, территорияң хуҗасыз кала, әллә миңа дарственный язып калдырасыңмы?

Карт *(усал караш ташлап)*. Мыскыл итеп тора бит, кансыз!

Карчык. Мал әрәм калмасын, диюем.

Карт. Кит моннан!

Карчык. Әйдә, бартер. Мин сиңа шешә, ә син миңа территорияңне. Йә, ничек?

Карт *(хәлсез генә)*. Китәсеңме, юкмы?

Карчык. Йә, әйдә, бир әле букчаңдагы шешәләреңне, сдавать итеп килим.

*Карт букчасын алмакчы була, Карчык эләктереп өлгерә.*

Карт. Кагылма, хакың юк!

Карчык. Нәрсә, теге дөньяга алып барасыңмы, анда шешәләр кабул итә торган җир юк, диләр.

Карт. Әле мин тиз үлмим, сине көтәм.

Карчык. Юньле кеше син яшәгән кадәр яшәми.

Карт. Ай, әтрәк.

Карчык. Йә, ярый, мә, шешәләреңне, йә чынлап торып аягыңны сузарсың. Мин гаепле булып калырмын.

Карт *(шешәләрне аягы белән этеп куеп)*. Кирәкми.

Карчык. Ай, нинди горур без, чүплектә!

Карт. Горур шул. Синең кебек вак җаннарны күралмыйм.

Карчык. Аһ, мин вак җанмы? Бир әле шешәләреңне?

*Карчык Картның букчасын ала да аны этеп җибәрә, Карт утыргычка ава.*

Карт. Нишлисең, баба яга!

Карчык. Хәзер күрерсең? *(Картның шешәләрен сәхнә алдына тезә. Утыргыч янында яткан ташны ала.)* Интегеп, күтәреп йөрмә. Сине кызгану йөзеннән хәзер ватам... кырам...

Карт. Тимә шешәләргә, ишетәсеңме?

Карчык. Юк, чукрак мин.

Карт. *(Утыргычтан тора. Шешәләрен гәүдәсе белән каплап).* Тимә... *(Елый.)*

Карчык. Кем вакчыл инде, минме, синме, бер пыяла шешә өчен ни кыланасың?

*Карт кинәт тора, йөрәген тота.*

Карчык. Син чынлапмы әллә?

Карт. Юк, уйнап.

Карчык. Йөрәк даруың бармы?

Карт. Кичә бетте.

Карчык. Мә, миндә бар!

Карт. Әйтер идем ул таблеткаң белән ни эшләргә кирәкне...

Карчык. Нәрсә? Ит яхшылык, көт яманлык. Мин тагы аны кызганып... (*Даруны Картка суза.)*

Карчык. Соңгы тапкыр сорыйм?

*Карт дару төймәсен ала, тиз генә авызына каба, чапылдатып суыра.*

Карчык. Шулкадәр кыланма. Синдә генә булган йөрәк.

Карт. Тагын башладыңмы?

Карчык. Бетте, бетте! Шул ранениеләре, авырткан йөрәге белән аяк терәп тарткалашкан була бит, җәфа.

Карт. *(Әзрәк хәл керә. Җайлап утырып).* Кем җәфа? Ярар, хәзер даруың өчен акча бирәм.

Карчык. Ай, ай! Серкәң су күтәрми икән. Кирәкми, синең акчаң көненә калмаган.

Карт. Алай икән, мыскыл итмә, үзең дә фәрештә түгел.

Карчык. Нәрсә, хәл кердеме? Әрләшәсең киләме?

Карт. Кара әле, шешәңне алдыңмы? Шулай булгач, шагай моннан. Алдыңнан артың яхшырак.

Карчык. И, мәгънәсез, рәхмәт юк, ни юк...

Карт *(авызындагы дару төймәсен төкереп).* Ник каптым, никләр генә каптым. Үлгән булсам, сине күрмәс, ишетмәс идем.

Карчык. Син мине шулкадәр кансыз дип уйлыйсыңмы? Карап торып кеше үтерергә?

Карт. Уф, гарык. Үзем китәм. *(Карт китмәкче була, ләкин хәле бетеп, утыргычка кабат утыра.)*

Карчык. Үзем китәм. Китә алсаң – китәрсең. Әйдә, ерак тормасаң, озатып куям. *(Карт аны этеп җибәрә.)* Ярар, күңелең булсын, үзем китәм.

Карт. Букчагызны оныттыгыз!

*Карчык кире килә, йөзен читкә бора. Карт букчаны кулына ала.*

Карт. Синең дә йорт-җир җиһазларың үзең белән бугай.

Карчык. Юк, сез нәрсә...

Карт. Мин бернәрсә дә түгел, сез нәрсә?

Карчык. Миңа китәргә кирәк.

Карт. Нишләп әле, кинәт кенә, ут капкандай кабалана башладыгыз?

Карчык. Соң инде... Сезне дә...

Карт. Нинди сез ул тагы?

Карчык. Букчаны... бирсәгез иде.

Карт *(Карчыкның букчадагы шешәләрен үзенекеләр янына тезеп).* Юк, инде хәзер минем чират. Китәсең килсә, бар кит. Тик шешәләрең, букчаң миндә кала.

Карчык. Каравыл, талыйлар!

Карт. Катырак кычкыр! Көчлиләр, диген, хәзер килеп җитеп, телефонга төшерә башларлар.

Карчык. Син карт маньяк, бир хәзер үк букчамны.

Карт. Әйдә, шешә тәгәрәтешле уй-

ныйбыз. *(Бер шешәне ала да сәхнә уртасына чыга.)* Шешә башы миңа борылса, шешәләрең барысы да миңа. Әгәр дә сиңа чыкса, син мине битемнән үбәсең.

Карчык. Кара әле, бу доходяганы, ничек мыскыл итеп тора.

Карт. Юк, бу әле баласы, мичтә аның анасы. Тәгәрәтәм. *(Шешәне әйләндереп җибәрә.)* Сиңа чыкты, әйдә, кил, үп.

Карчык. Хәзер, туфлиләремне үтүклим дә...

Карт. Килештек бит.

Карчык. Кем килеште, минем килешкәнем юк.

Карт. Ярый алай булгач, шешәләр дә минеке.

Карчык. Сызгыра беләсеңме?

Карт. Беләм!

Карчык. Сызгыр!

Карт *(сызгырып карый, чыкмый)*. Что-то чыкмый.

Карчык. Тешсез авызы белән сызгырып маташа.

Карт. Ә син сызгыра беләсеңме?

Карчык. Син тумыштан шулай җүләрме, әллә контузиядән соңмы?

Карт. Сине күргәч, контузияләрем кузгалды.

Карчык. Кит юлдан.Синең белән чүп-чар бутап торырга минем вакытым да, теләгем дә юк.

Карт. Әллә китәсеңме? Сау бул!

Карчык. Бир букчаны.

Карт. Мә?

*Карчык алырга килә, Карт бирми, икенче кулына күчерә.*

Карчык. И-и! Сакаллы сабый!

Карт. Ник алмыйсың?

Карчык *(Картның букчасын алып)*. Ярар, пока!

Карт. Бир букчаны!

Карчык. Син бир!

Карт. Мә!

Карчык. Мә!

*Букчаларына ябышалар да тарткалаша башлыйлар. Шешәләре авып бетә. Полиция сыбызгысы тавышы. Карт сикереп тора, утыргыч артына кача. Карчык торып баса, авызында сыбызгы. Сызгырта, Карт утыргыч астына керә. Карчык утыргыч өстенә менеп баса да кычкыра.*

Карчык. Иптәш милиционер, монда килегез!

*Карт утыргыч астыннан башын чыгара. Карчык сыбызгы сызгырта, Карт ныграк кача. Карчык көлә. Карт башын күтәрә.*

Карчык. Чык, камыр батыр.

Карт. Нәрсә кеткелдисең? Карт кешене шулай мыскыл итмәсәң?

Карчык. Кыланган була, «мин, мин!» Ә үзе... Бу ирләрне әйтер идем, кыланышлары. Ә үзләре хатын-кыздан башка бер адым да атлый алмыйлар.

Карт. Мине алар рәтенә кертмә.

Карчык. Син особыймы?

Карт. Мин үз көнемне үзем күрәм.

Карчык. Ялгызыңмы?

Карт. Әйе.

Карчык. Карчыгың?

Карт. Дөнья куйды.

Карчык. Авыр туфрагы җиңел булсын. Күптәнме?

Карт. Күптән.

Карчык. Мин дә менә ялгыз!

Карт. Син дә ялгыз, мин дә ялгыз. Атка печән кем салыр?

Карчык. Һе, шаярган була тагы.

Карт. Әйе, үлгән артыннан үлеп булмый. Язганны яшисең.

Карчык *(Картка карап)*. Әйе, анысы шулай...

Карт. Балаларың бардыр бит?

Карчык. Аларның булмавы артык.

Карт. Алай димә! Аллам сакласын.

Карчык. Кызым – ничек диләр әле – ближний зарубежда, ә малаемны атып үтерделәр. Дуслары белән нәрсәдер бүлә алмаганнар. Баласы, хатыны калды. *(Кулъяулык ала, күз яшьләрен сөртә.)*

Карт *(тынычландырып)*. Йә инде, йә. Дөньясы буталды бит, ни хәл итәсең? Ата улны, ана кызны белми.

Карчык. Әйе шул... буталды.

Карт. Ә киленең, оныгың?

Карчык. Килен икенчегә кияүгә чыкты. Кесәсендә өчәр телефон, бик зур машина белән йөри торганга. Мин аларга кирәк түгел.

Карт. Картайгач, кемгә кирәк без.

Карчык. Менә шулай баланы үстерәбез, үстерәбез дә...

Карт. Кара әле, синең ашыйсың киләме?

Карчык *(Картның букчасына карап ала)*. Юк, мин ашадым...

Карт. Йә, тартынма, кил! Аш – ашка, урыны башка. Әллә нәрсә булмаса да. Бер танышымнан бурычка акча алып торган идем.

*Карт ипи, сөт, кечкенә колбаса кисәге чыгара, пәке белән кискәләп икегә бүлә, тимер кружкага сөт сала, Карчыкка бирә.*

Карчык. Синең монда барысы да кул астында.

Карт. Ир-егетләрнең шулай булырга тиеш.

Карчык *(Картка текәлеп карап)*. Килешәм.

*Карт белән Карчык акрын гына ашыйлар да әйберләрен җыеп куялар.*

Карт. Менә азрак хушландык.

Карчык. Кружкаңны чайкатырга иде.

Карт. Соңыннан.

Карчык. Рәхмәт, тәмле булды.

Карт. Әллә ни түгел лә, шулай да ярый.

Карчык. Юк, әйбәт, рәхмәт.

Карт. Болай утырмаганга инде...

Карчык. Минем дә...

*Сүзсез утыралар. Кинәт икесе дә берьюлы сүз башлыйлар. Туктап калалар.*

Карчык. Шуны сорамакчы идем: бу чынлап та синең территориямe?

Карт. Әйе, монда шешә булган бөтен җир безнең территория.

Карчык. Син, ветеран башың белән, нигә болай йөрисең?

Карт. Сөйли башласаң, бик озак. Аннары, йөрәкне бозасы килми.

Карчык. Ярый, сөйлисең килмәсә сөйләмә.

*Сүзсез утыралар.*

Карт. Беләсеңме? Кайвакыт бушанасы, ачылып, эч серләрен сөйлисе килә. Беркемдә беркемнең гаме юк, һәркем үзенә бикләнгән. Күңелеңне ачсаң, аңлау түгел, мыскыл итеп көләләр генә.

Карчык. Йә инде, үпкәләмә. Үзең мондагымы соң?

Карт. Авыл малае мин, сугыштан соң ранениеләр борчыды, дәваланырга, йөрәк әрнүләрен басарга кирәк иде. Монда күчеп килдем дә калдым. Туганнарымнан авылда беркем дә калмады. Эх, узган гомер, аккан су... *(Танырга тырышкандай, Карчыкка текәлеп карап ала. Уйланып утыралар.)*

Карчык. Минем дә тормышым шәптән булмады. Сугыш вакытында, елата-елата, ФЗӨгә җибәрделәр, ул паровоз мичe өчен урман тураулар, ашарга җитмичә качып кайтулар. Торфка «вербовать» итүләре. Нормаң тулса – биш йөз грамм ипи. Кайберәүләр өйләреннән алып килгән запаслар белән... Ә мин япа-ялгыз... Күрде инде башлар...

Әйләндек калаларны.
Вербовщиклар яллый икән
Бәхетсез балаларны.

Җырлары да шул – минем кебек бәхетсезләр турында булган.

Карт. Ул чакларны мин дә бик еш искә алам. Менә, ничектер, яшәүнең нindидер мәгънәсе булган дип әйтимме?!

Карчык. Яшь булганбыз, шуңа күрә мәгънәсе дә булган.

Карт. Юк, нindидер ышаныч, өмет бар иде...

Карчык. Өмет хәзер дә бар ул...

Карт. Әйдәле, төшенкелеккә бирелмик, үз-үзебезне кызганып утырудан ни файда? Әнә кара, яшь җилкенчәкне. Яшьлек шул, яшьлек...

*Карт шул якка, Карчык аңа карап тора.*

Карчык. Әйе, яшьлек!

*Сүзсез утыралар, һәркем үз уенда. Карт, азрак утыргач, җыр башлый.*

Карт.

Кара, кара, кара күзләремә,
Алар сине генә күзлиләр.
Сөю утларында янам, көям.
Синең күзләр генә күрмиләр,
Йөрәк әрнүләрен сизмиләр.

Карчык *(Картка сәерсенеп карап)*. Тукта! Син кайдан беләсең бу җырны?

Карт. Яшь чакта җырлый идек! Ә нәрсә?

Карчык. Әйе, яшь чакта бит әле...

Карт. Нигә сәер генә сорап куйдың?

Карчык *(үз-үзенә)*. Әйе, сәерсенерсең монда. Юк, болай гына. Борынгы җырлар алар бер-берсенә охшаш.

Карт *(үтәли карап)*. Бик борынгы, димәс идем.

Карчык *(кинәт кабаланып җыена башлый)*. Йә, ярый, озак утырылды. Кайтыйм әле... Рәхмәт... Сау булыгыз! *(Үз шешәләрен тотыра.)*

Карт. Минекеләрне...

Карчык. Калдырдым, борчылма!

*Карт тора. Карчыкның бер алдына, бер артына чыгып күзәтә. Карчык аның карашын сизә.*

Карчык. Синекеләргә тимим. Нәрсә шыгырдатасың?

*Карчык утыргычка утыра. Карт үз шешәләрен букчага тутыра. Карчык аңа сәерсенеп карап тора.*

Карчык *(үзалдына сөйләнеп)*. Юк, булмас...

*Карчык тиз генә җыена да сиздермичә генә китмәкче була.*

Карт *(түземлеген җуеп)*. Тукта! Утыр! Тынычлан.

Карчык *(үзе дә сизмәстән утыра, аннан сикереп торып)*. Әтәч, нигә миңа кычкырасың?

Карт. Сөйләшүем шундый минем. Йә Алла, үзгәрмәсә дә үзгәрмәс икән адәм баласы. Кыргыйлыгың тәки бетмәгән.

Карчык. Үзең, үзең шундый ук... Кырыс!

*Карчык утыргычның бер як читенә утыра. Карт аңа карап тора.*

Карт. Исәнме?

Карчык. Исән!

Карт. Нихәл?

Карчык *(аңа карап)*. Нәрсә? Менә нәрсә дип ыржаясың, ә? Нәрсә, карчык булган, картайган, танып та булмый, дип көләсеңме? Үзең бик җегетләр асылы.

Карт *(дәшми генә карап тора, аннан карчык янына утырып)*. Хәлләрең ничек, дидем?

Карчык *(йодрыгын төйнәп)*. Якын килмә! Ничу монда!

Карт *(ачуы килеп)*. Нәрсә кыланасың? Көпә-көндез бөтен мир алдында кочакларга җыена дип уйлыйсыңмы әллә? Өметләнмә.

Карчык. И-и. Оятсыз! Сакаллы сабый, нәрсә сөйләп утыра бит.

Карт. Да-а! Сине дә күрер көннәр бар икән.

Карчык. Менә, күрдең.

Карт. Күрдем, күрдем! Барыбер очрашырга тиеш идек без. Ничек кенә күз алдына китерми идем. Тик менә болай очрашырбыз дип уйламадым да.

Карчык. Нәрсә, яшь җилкенчәк кебек, муеныңа ташланыр дип көттеңме? Өметләнмә!

Карт. Юк ла! Дөресен генә әйткәндә, баштарак танымадым.

К а р ч ы к . Үзең бик танырлык инде...

К а р т . Күзләреңдәге очкын гына...

К а р ч ы к *(йомшара төшеп)*. Бу яшьтә нинди очкын, әллә кайчан сүнделәр ул очкыннар.

К а р т . Юк, ул күзләрне гомерем буе онытa алмадым, күңелемдә гел йолдыз кебек янып торды.

К а р ч ы к . Бигрәк оста сөйлисең! Мондый сүзләр ишетмәгәнгә...

К а р т . Минем дә сөйләгәнем юк. Син үзгәрмәгәнсең...

К а р ч ы к . Тагын мыскыл итәсеңме?

К а р т . Нәрсә син күкерт кебек кабынырга торасың?

К а р ч ы к . Көлмә соң. Ничә ел үтте. Мин нәрсә, көзгегә караганым юк дип уйлыйсыңмы?

К а р т . Ярар! Күңелең булсын, үзгәргәнсең.

К а р ч ы к . Бик ныкмы?

К а р т . Бик нык, ыстрашны!

К а р ч ы к . Нәрсә аңлыйсың син?

К а р т . Моның кадәр, ирләр кебек, холыксыз карчык күргәнем юк иде әле.

К а р ч ы к . Кем карчык, үзең син... әйтер идем...

К а р т . Әйт!

К а р ч ы к . Әйтмим, йә хәтерең калыр. Гомумән, нормальный хатын-кыз күргәнең бармы?

К а р т . Нигә күрмәскә, монда нинди сорт күрергә телисең – муре!

К а р ч ы к . Кем карасын сиңа? Икенде күләгәсенә.

К а р т . Карадылар һәм карыйлар. Мин әле oh-ho-ho!

К а р ч ы к . Бик шатмын! *(Карчык китә башлый.)*

К а р т . Йә, көнләшмә, шаярдым гына.

К а р ч ы к . Кем көнләшә? Минме?

К а р т . Кешечә сөйләшәбезме без, юкмы инде бүген?

К а р ч ы к *(үзалдына)*. Көнләшә, имеш, көнләшер кеше булса иде.

К а р т *(сабыр гына)*. Җитте инде, бигрәк кабындың. Әй Алла, яшь чакта кыланмаганны, хәзер килеп...

К а р ч ы к *(әрнү белән)*. Авыр... аңлыйсыңмы, авыр! Ярты гасыр узып киткән бит.

*Карчык акрын гына елый. Карт аның иңнәреннән тотып, утыргычка утырта.*

К а р т . Йә, йә. Язмыштыр, нишлисең. Аллаһы Тәгалә шулай язгандыр.

К а р ч ы к *(Картның җилкәсенә башын куеп.)* Мин көттем бит сине.

К а р т . Ә мин эзләп-эзләп карадым да аннан ары өметне өздем.

К а р ч ы к . Кызык! Гомер тегеләй дә үтә, болай да...

К а р т . Дөнҗа без уйлаганча гына түгел, Алла теләгәнчә бара.

*Карчык белән Карт сүзсез утыралар. Карчык җыр башлый.*

К а р ч ы к .

Сибелә чәчем, сибелә чәчем,
Сибелә чәчем, тарала.
Йә утка сал, йә суга сал,
Йә кайгыдан арала.

Уйсу җирнең агым суы
Ага икән таң белән.
Узар, ахры, яшь гомерем
Гел сагыш, гел моң белән.

Сандугачлар су эчәләр,
Агыйделгә тезелеп.
Нигә болай сагынам икән,
Үзәкләрем өзелеп?

*Соңгы юлларны бергә җырлыйлар. Карт Карчыкны иңеннән кочаклый.*

К а р ч ы к . Уф, йөрәгем сикереп чыга хәзер.

К а р т *(күкрәгенә кысып)*. Чыкса, мин монда, ерак җибәрмәбез.

*Алар шулай тын гына утыралар. Карчык кинәт сикереп тора, өс-башын төзәтә.*

К а р ч ы к . И-и Алла, шушы яшькә җитеп, көпә-көндез кочаклашып утыр, күпме кеше йөри… Син дә...

К а р т . Ул кешеләрдә безнең кайгы

түгел, аларның үз мәшәкатьләре, бөкрәеп үлсәң дә, килеп карамаячаклар.

Карчык. Син бигрәк...

*Карт кинәт йөрәген тота да егыла. Карчык нишләргә дә белми. Аны селкетеп карый. Янында йөгереп йөри.*

Карчык. И Алла, и Ходаем, нәрсә соң бу? Әй, ярдәм итегез, кеше үлә. Әй, кешеләр…

*Беркем дә аның кычкыруына игътибар итми. Карт тора, өсләрен кага, утыргычка утыра. Карчык аптырап карап тора.*

Карт. Менә, күрдеңме?

Карчык *(төртеп җибәреп)*. Җүләр, куркыттың.

Карт. Күр! Ачы хакыйкать бу.

Карчык. Син усалланган.

Карт. Тормыш тузаны миңа да кунган... Ачуым килә. Гомерем буе бил бөктем, чирләргә дә вакыт булмады, эшләдем дә эшләдем. Картайган көнемдә урамда калыр өченме?

Карчык. Шуны сорамакчы идем. Син ветеран башың белән нигә болай йөрисең? Сезне бит хәзер бик каты күтәрәләр. Соң сиңа бит положено.

Карт. Положенныен малайга калдырдым.

Карчык. Тагын сора.

Карт. Син нәрсә, уңайсыз, кеше нәрсә әйтер...

Карчык. И-и, әнә, кеше әйткәнгә карап торалар...

Карт. Юк, сугыш кырында ятып калганнарның рухы рәнҗер бит… Юк, тиешлесен алдым, алар өлешенә, аларның ятим калган балалары өлешенә керәсем килми.

Карчык. Үзең турында сөйләмисең?

Карт. Нәрсәсен сөйлисең инде аның, яшәдем шунда... Әллә яшәдем, әллә яшәмәдем.

Карчык. Балаларың бардыр бит?

Карт. Бар.

Карчык. Хатының әйбәт идеме?

Карт. Әйбәт! Мин аңа рәхмәтләмен, начар яшәдек, дип әйтә алмыйм. Иртәрәк китте. Хатыныңнан алдарак китәргә кирәк бу дөньядан. Авыр ялгыз ир-атка.

Карчык. Әйе, бала кебек бит сез! Ә балаларың ярдәм итәме соң?

Карт. Һе, балалар. Аларда минем кайгы түгел. Күреп торасың ич дөньясын, әле үзләренә ярдәм итәргә туры килә. Карчык исән чакта кадер бар иде, хәзер артык...

Карчык. Торуың кайда соң?

Карт. «Хрущёвка», кечкенә бер бүлмәдә. Күршеләр яман: эчәләр, сугышалар, көн дә бәйрәм, көн дә туй. Үземнең фатирны малайга калдырдым. Менә шулай. Ә үзең, үзең ничек соң?

Карчык. Сөйләдем бит инде.

Карт. Кайда торасың?

Карчык. Бер бик якын ахирәтем бар. Шуның бер бүлмәле фатирында яшибез.

Карт. Авырдыр кеше өстендә тору?

Карчык. Чирле ул, түшәк өстендә ята. Шуны карыйм. Бер кешесе юк, пенсиясе даруларга китә, дарулар бәясен беләсең...

Карт. Миңамы белмәскә! *(Көрсенеп куя.)*

Карчык. Хәер сорашырга гарьләнәм, менә шешә җыям.

Карт. Ярар, җитте бу турыда, мин синнән шуны сорамакчы идем, ник авылда калмадың?

Карчык. Председатель Шакирҗан сугыштан бронь белән калды. Күпме ялгыз тол хатыннарны зар елатты, кабахәт. Ә миңа ничек кенә бәйләнмәде! Түземлегем калмагач, качып киттем.

Карт. Сугыштан соң, мин кайткач, ник кайтмадың?

Карчык. Сине сугышта һәлак булган, диделәр.

Карт. Ничек һәлак булды? Кем әйтте?

Карчык. Ахирәтем Саҗидәгә

синең турында сорап хат яздым, ул шулай дип җавап язды.

Карт. Ничек алай? Соң ул үзе мине каршы алды. Ялгызым гына булгач, өйгә килеп ярдәм итеп йөрде.

Карчык *(аптырап)*. Кем, Сәҗидәме?

Карт. Әйе...

Карчык *(кызып читкә китә)*. Ах, кара елан... Әле син аның беләнме? Мин, сугыштан кайтмады, дип, елап сукырая яздым, ә ул анда Сәҗидә белән.

Карт. Тукта, нигә тузынасың? Ул үзе килеп йөрде бит.

Карчык. Син шуңа риза булып тордыңмы? *(Карт янына килә.)*

Карт. Моның белән нәрсә әйтмәкче буласың?

Карчык. Нәрсә ишеттең, шуны.

Карт. Әйтәм бит, үзе миңа бәйләнеп йөрде.

Карчык. Нигә сиңа, нигә башкаларга түгел. Әйбәт! Кайтмады дип хат яза да, ә үзе... *(Елый.)*

Карт. Соң ул болай гына, безнең арада берни дә булмады.

Карчык. Әйе, мин Сәҗидәне белмим ди. Әле үзең бая гына, карадылар һәм карыйлар, мин әле oh-ho-ho, дип кәпрәйдең.

Карт. Соң, кызып киткәндә әйтәсең инде аны.

Карчык. Боргаланма, сиңа минем белән йөргәндә дә кызлар карыйлар иде, Сәҗидә бигрәк тә.

Карт. Нәрсә, сиңа карамыйлар идеме? Ул турыда мин дәшмим бит.

Карчык. Сүзне икенчегә борма.

Карт. Тагын мин гаепле. Бигрәк әллә нинди син. Акай заманындагы нәрсәләр өчен хәзер килеп җәнҗал чыгарасың.

Карчык *(утыргычка утырып)*. Чыгармыйм ла, Сәҗидәгә ачуым килә.

Карт *(Карчык янына килеп.)* Йә, булды, узган эшкә салават.

Карчык. Әйе, әйе, булды. Уф! Эчәсем килә. Якын-тирәдә су юкмы?

Карт. Әнә тегендә киоск бар. Син утырып тор, мин хәзер үзем алып киләм.

Карчык *(букчасын алып)*. Акчаң бармы?

Карт. Син бигрәк тагы.

Карчык. Йә, йә, җегетләнмә, булмаса бирәм.

Карт. Бар, бар! Мин хәзер.

*Карт китә. Кире керә, Карчыкка үз букчасын бирә. Китмәкче була.*

Карчык. Тукта! *(Аның янына килә, күлмәк якасын төзәтә.)* Кеше арасында йөрисең.

Карт. Ярар ла. *(Китә башлый.)*

Карчык. Сиңа әйтәм.

Карт *(кире килеп)*. Тагын нәрсә булды? Җегетләр бәйләнәме әллә үзеңә?

Карчык. Юк ла. Әллә акча әрәм иткәнче, берәр краннан гына агызып алабызмы?

Карт. Саранланма, бүген бәйрәм. Гүләйт тек гүләйт.

*Карт китә. Карчык аның артыннан карап кала.*

Карчык. И-и, кыланчык! Җегетләнгән була. Әйе, җегет чакларың бар иде. Сабантуйда ул көрәшкә чыкса, яшь булуына карамастан, мәйданга керергә куркалар иде. Ә биегәндә, барысы да аяктан егылып бетәләр. Ә ул бии, ничек кенә бии, he-he-he. Печән чапканын карап торырга ярата идем. Дулкын ерып барган кораб диярсең. Күпме йөрде артымнан. Барыбер үзенә каратты бит, хәерсез. И-и, нәрсә дип онытылып утырам.

*Карчык букчасыннан көзге ала да карап төзәтенә. Карт килгәнне күреп, көзгесен яшерә. Карт пластик савыт белән су алып килә.*

Карт. Менә алып та килдем!

*Суны утыргычка куя. Куенынан бер чәчәк чыгара.*

Карчык. Әллә сатып алдыңмы? Бар, илтеп бир дә акчасын кире ал.

К а р т . Юк, борчылма, әнә тегендә бик күп үсәләр алар.

К а р ч ы к . Күрсәләр, яхшы түгел.

К а р т . Курыкма, күрмәделәр. Тәк шту ал.

К а р ч ы к . Рәхмәт!

К а р т . Зур үс.

*Карт букчасыннан пластик стаканнар чыгара, әз генә су салып, чайкап, чүп-чар савытына түгә. Карчыкка һәм үзенә су сала.*

К а р т . Менә булды, хәзер сусауны басабыз. Әйдә, очрашу хөрмәтенә.

*Шаярып чәкештерәләр, эчәләр.*

К а р т . Тагын?

К а р ч ы к . Аз гына.

К а р т *(Карчыкның стаканына су салып).* Бәлки, ашыйсың киләдер? Әйдә! *(Букчасын ала.)*

К а р ч ы к . Ю-у-ук! Үзеңә кайткач та ашарга кирәк.

К а р т . Анысы өчен борчылма.

К а р ч ы к . Ничек борчылмыйсың, ир-ат ул әзерләргә яратмый. Шул коры-сары белән туена.

К а р т . Мин пешеренәм.

К а р ч ы к . Айга бер.

К а р т . Юк, нигә алай дисең? Мин үзем...

К а р ч ы к . Йә, шаярдым, үпкәләмә.

К а р т . Үпкәләмим...

*Карчык стаканны куям дигәндә, калган суы ялгыш өстенә түгелә. Карт кесәсеннән кульяулык чыгарып сөртмәкче була, шулвакыт кесәсендәге орден-медальләре җиргә коела. Карчык өстен-башын кулы белән сыпыра да, Карт янына килеп иелеп, орден-медальләрне кулына ала.*

К а р ч ы к . Йә Аллам, ничек исән калдың соң син? Болар бит болай гына бирелмәгән.

К а р т . Ярар ла, син бигрәк. Алар синең белән минем өчен генә кадерле. Башкалар өчен зур акча.

К а р ч ы к . Җүләр, нигә үзең белән йөртәсең, югалтсаң?

К а р т . Ә югалса, тегендә баргач, медальләрең кайда, дип сорамаслар әле. Бүлмәдә калдырып булмый, фатир хуҗалары мин юкта кереп актарыналар. Аннан, күрше йорттагы бер хатынның баласына бик катлаулы операция ясаганнар, хәзер өйдә, тик терелеп бетсен өчен кыйммәтле дарулар кирәк, менә мин, әз-әзләп боларны сатып, шул балага дарулар алам.

*Карчык орден-медальләрне күкрәгенә кыса да елап җибәрә. Карт аның янына тезләнә.*

К а р ч ы к . Кая, кая бара бу дөнья?

*Карт җилкәсен сикертә. Карчык як-ягына карана, Картка медальләрен бирә.*

К а р ч ы к . Күр инде, көн кичкә авышкан. Миңа кайтырга кирәк бит. *(Торып җыена башлый.)*

К а р т . Тукта, ашыкма. Әле рәхәтләнеп сөйләшеп тә булмады.

К а р ч ы к . Ахирәтемне карыйсым бар.

К а р т . Син ерак торасыңмы?

К а р ч ы к . Әнә теге ун катлы йортны узгач, тугыз катлы артында.

К а р т . Ә ничек без моңарчы очрашмадык икән?!

К а р ч ы к . Минем бу якларга бөтенләй килгәнем юк. Бер килгәч, исерек мужиклар бәйләнделәр дә.

К а р т . Аның каравы мин ул якларда йөрдем.

К а р ч ы к . Соң минем кебек карчыклар дөнья тулы, ничек барысын да күреп-танып бетерәсең.

К а р т . Анысы да дөрес.

К а р ч ы к . Ярар, китим.

К а р т . Тукта, ашыкма. *(Юлын бүлә.)*

К а р ч ы к . Мине көтәләр.

К а р т . Аңладым. Сау бул!

К а р ч ы к *(Карчык китә башлый. Туктый).* Китәм бит.

К а р т . Китәсең шул.

Карчык. Әйтер сүзең юкмы?

Карт. Бар.

Карчык. Әйт.

Карт. Китәсең бит.

Карчык. Китмим. *(Карт янына килә.)* Бирде дөнья кирәкне, еламаска өйрәтте.

Карт. Иртәгә нишлисең?

Карчык. Ә нигә?

Карт. Очрашсак диюем.

Карчык. Кайчан?

Карт. Үзең кайчан диясең? Минем вакыт бар.

Карчык. Уникеләр тирәсендә.

Карт. Килештек.

Карчык. Иртәгәгә кадәр.

Карт. Сау бул!

Карчык. Сау бул!

Карт. Иртәгә...

Карчык. Уникедә...

Карт. Шушында...

Карчык. Утыргычта... Иртәгә бер кызык булачак.

Карт. Нинди кызык?

Карчык. Килгәч күрерсең.

*Карчык китә. Карт утыргычка утырып уйга кала. Карт янына яшь егетләр килеп утыра.*

1нче егет. Ну что, бабай, Джульетта тю-тю...

2нче егет. Бабай, за аренду скамейки акча түләргә кирәк.

Карт. Нинди акча?

3нче егет. Кәгазь акча, чәчәк өчен дә.

1нче егет. Без үстерәбез, су сибәбез, ә кемдер килеп өзеп ала...

2нче егет. Безгә, яшьләргә, нинди үрнәк күрсәтәсең?

Карт. Егетләр, минем бүген иң бәхетле көнем, үтенәм сездән, бозмагыз!

3нче егет. Бәхетне юарга кирәк, акча бир, алып киләбез. *(Картның кесәсенә керә башлый.)*

Карт. Егетләр, туктагыз... Югыйсә...

1нче егет. Нәрсә югыйсә?

Карт. Милиция... *(Тора башлый.)*

2нче егет. Беренчедән, милиция түгел, полиция... *(Картның күкрәгенә сугып ала. Карт утыра. Күкрәген тота.)*

3нче егет. Икенчедән, яшисең килсә, тик кенә утыр.

*Карт хәлсезләнеп авып төшә.*

1нче егет. Син нәрсә, ахмак, шулкадәр сугасың?

2нче егет. Ә нәрсә ул – милиция...

3нче егет. Беттек, үтердек, яхшы чакта таярга кирәк...

*Китмәкче булалар.*

1нче егет. Тукта, кесәләрен кара.

*2 нче егет Картның кесәләрен актарып, акчасын, кулъяулыкка төрелгән орден-медальләрен ала.*

2 нче егет. Oho, сез боларның күпме торганын беләсезме? Болар бит... Гуляем!

3 нче егет. Бетәбез, китик тизрәк.

1 нче егет. Җитте, шыңшыма, әйдәгез!

*Чыгып йөгерәләр. «Ашыгыч ярдәм» сиренасы. Сирена тавышы тормыш-көнкүреш тавышлары белән кушылып юкка чыга. Ут сүнә.*

*Ут кабат кабынганда, көз җиткән. Шул ук бакча, шул ук утыргыч, анда теге өч егет сыра чөмереп утыра, нәрсәдер бүлешә алмыйча сугышып китәләр, утыргычны җимерәләр, чүп савытын тибеп аударалар. Аннан дуслашып, кочаклашып чыгып китәләр. Сәхнәдә кеше юк. Бераздан Карт керә, ул таякка таянып атлый. Өстендә искерәк плащ, башында эшләпә, кулында зур чемодан. Карт утыргыч янына килә, туктый, озак кына карап тора. Кире чыгып китә. Бераздан икенче яктан Карчык керә.*

*Шулай ук ел фасылына карап киенгән, кулында кулчатыр белән төенчек. Утыргыч янында туктый, карап тора, тирә-якны күзәтә. Карт килгәнен күреп чыгып китә. Карт керә, тирә-якка карана да китә башлый, Карчык керә. Карт аны күреп туктап кала. Карчык керә дә Картка арты белән баса. Карт килә, аның алдына чыга. Карчык борылып баса. Карт аның иңенә кагыла.*

Карчык. Оятсыз! *(Читкә китә.)*

Карт. Болыт каплый май кояшын...

Карчык. Ялагайланма!

Карт. Нәрсә булды?

Карчык. Нәрсә булды? Булды шул.

Карт. Нигә яшь җилкенчәк кебек турсаясың?

Карчык. Ә кем гаепле?

Карт. Кем?

Карчык. Ачу китереп сорап торган була бит.

Карт. Тагын мин гаепле! Гаебем нидә икәнен белмәсәм дә, гафу ит!

Карчык. Фәрештә булып кыйланма! Мин сине үтәли күрәм.

Карт. Син әле экстрасенс тамыни?

Карчык. Җитте! Туктат мыскыл итүеңне.

Карт *(ачуланып)*. Кем мыскыл итә?

Карчык. Кем мыскыл итә? Иртәгә очрашабыз, диде дә юкка чыкты.

Карт. Соң...

Карчык. Ничек бүген килергә булдың әле?

Карт. Аңлатырга ирек бирәсеңме?

Карчык. Аңлат, нәрсә уйлап чыгарырсың?

Карт. Тынычланасыңмы, юкмы?

*Карчык дәшми тора.*

Карт. Алай булгач, тыңла.

Карчык. Йә, сөйлә әкиятеңне?

Карт. Әкият?

Карчык. Әкият булмый, нәрсә булсын?!

Карт. «Әкият» икән, әкият, тыңла! «Борын-борын заманда Совет илендә яшәгәннәр ди бер кыз белән бер егет. Кызы кире беткән усал булган, ә егет...»

Карчык. Җитте, тукта, дим.

Карт. Мин ашкынып синең янга киләм.

Карчык. Бик каты ашыккансың. Хәтта бер ай узып киткән.

Карт. Җибәрмәделәр бит.

Карчык. Ах, шулай укмы? Кемнәр инде, сер булмаса? Саҗидә түгелдер бит?

Карт. Юк, койрыклы җеннәр. Йә Алла, түземлегем калмады, туйдым, гарык. *(Чемоданына килеп утыра.)*

Карчык. Шулай укмыни, гарык инде алай булгач.

Карт. Ни кыланасың син?

Карчык. Әһә, мин кыланам булып чыга.

Карт. Сөйләргә бирәсеңме, юкмы?

Карчык. Син сөйләмисең, мыскыл итәсең.

Карт. Нишлисең, ә, ник...

Карчык. Саташасың, дип әйт. Әйт!

Карт. Нинди корт чакты сине?

Карчык. Менә, менә, акылың зәгыйфьләнгән, диген.

Карт. Дәшмим!

Карчык. Әһә, сөйләшәсең килмимени минем белән. *(Карт дәшми тора.)* Ник очрадың, тыныч кына яши идем бит. Рәхәтләнеп үз җаема бу дөньядан китәргә дә ирек бирмисең бит син. *(Елый. Карт дәшми.)* Сиңа әйтәм, ник дәшмисең? Кайда йөрдең, ник килмәдең?

Карт. Бер хатын-кыз ун нимескә тора, дип юкка гына әйтмиләр икән. Дөреслегенә ышандым.

Карчык. Йә Аллам, тагын көлә.

Карт. Ярар, озын сүзнең кыскасы – бел, мин качтым!

К а р ч ы к . Качтым! Ничек качтың? Кайдан качтың?

К а р т . Билгеле инде, безнең яшьтә кайдан качалар.

К а р ч ы к . И Ходаем, и Аллам. Нинди җинаять эшләдең?

К а р т . Кем?

К а р ч ы к . Син?

К а р т . Кайчан?

К а р ч ы к . Нәрсә башымны катырасың, качып чыктым, дисең бит?

К а р т . И-и! Соң аннан гына качалар димени?!

К а р ч ы к . Ә тагын кайдан?

К а р т . Бүлнистән!

К а р ч ы к . Әй, үтерәсең син мине. *(Карт янына чемоданга утыра.)*

К а р т . Юк, тиз генә үлмибез әле!

К а р ч ы к . Нәрсә булды? Йөрәкме? Кайчан?

К а р т . Сорауларыңны берәрләп кенә бир, хәтер юк, склероз.

К а р ч ы к . Әйдә, утыргычка утырыйк та, бәйнә-бәйнә сөйлә.

*Икесе дә торалар, утыргыч ягына борылып басалар.*

К а р т . Утырып булмый шул, җимерелгән.

К а р ч ы к . Кызганыч, матур урын иде.

К а р т . Дөнҗасы җимерелгәндә, утыргычы гына исән калмас. Менә күр, бу безнең тормыш, менә бу безнең язмыш, менә бу безнең киләчәк.

К а р ч ы к . Ярый, борчылма, кирәкми. Бүлнистә нишләдең?

К а р т . Ял иттем.

К а р ч ы к . Шаярма.

К а р т . Шаярудан узган.

К а р ч ы к . Йөрәк белән яттыңмы?

К а р т . Йөрәк белән...

К а р ч ы к . Сакламыйсың үзеңне.

К а р т . Өйрәнелмәгән! Гомер буе үзебезне кызганмадык, сакламадык, хәзер генә булмас.

К а р ч ы к . Әйе шул, тәрбия. Кара әле, шуны сорамакчы идем.

К а р т . Сора!

К а р ч ы к . Нигә чемодан күтәреп йөрисең?

К а р т . Күченәм! Яңа фатир алдым.

К а р ч ы к . Кит аннан, зурмы!

К а р т . Арча кыры хәтлек. Биш тәрәзәле, тәрәзәсенең пыяласы юк, капка кебек ишекләр, ишекләренең тоткасы юк, тик бәдрәфе урамда.

К а р ч ы к . Тукта, нинди йорт соң ул?

К а р т . Син беләсең.

К а р ч ы к . Ничек беләм?

К а р т *(ватык утыргычка күрсәтеп)*. Беләсең. Әнә бит!

К а р ч ы к . Аңлашылды! Сөйлә, нәрсә булды?

К а р т . Нәрсә булсын?! Хәерчегә җил каршы, диләрме әле. Бүлнистә ятканда, мин торган фатирда, әйткән идем бит, күршеләрем тынгысызлар дип. Менә шул. Эчеп, пожар чыгарганнар. Комиссия килеп караган. «Восстановлению не подлежит», дигән. Алар – яңа фатирга, ә карт... Мин бит анда фатирант кына, угловой жилец на птичьих правах, ягъни мәсәлән.

К а р ч ы к . Әйе, күңелле хәл түгел.

К а р т . Киресенчә, күңелле. Ха-ха-ха!

К а р ч ы к . Хәзер нишләргә җыенасың?

К а р т . Иң элек менә моны төзәтәм.

*Карт чемоданын ала да утыргыч янына килә. Инструментлар чыгара, утыргычны җайлый башлый. Карчык килә, чүп савытын торгызып куя.*

К а р ч ы к . Барыбер җимерәчәкләр.

К а р т . Тот теге башыннан.

К а р ч ы к *(ул кушканнарны эшли)*. Барыбер ватачаклар.

К а р т . Чүкечне бир әле.

К а р ч ы к . Беркемгә кирәкми бит ул.

К а р т . Тотып тор.

К а р ч ы к . Барыбер рәхмәт әйтмәячәкләр.

К а р т . Менә, булды.

*Карт үзе төзәткән утыргычка утырып елый. Карчык нишләргә белми, аның янында басып тора.*

К а р т . Юк, мин зарланмыйм. Аллам сакласын. Кыенрак чаклар да булды. Без күрәсен кеше күрмәде. Ни өчен, нәрсәгә, шултиклем шәһит китүләр, кан коюлар, толлар, ятимнәр күз яше?! Без бит якты киләчәккә ышандык. Шуны якынайтыр өчен үзебезне кызганмадык. Хәзер нәрсә... Болар барысы да бушка булганмы?! Мин бушка яшәгән булып чыгаммы? Шушындый тормыш өчен кан койдыкмы? Кемгә, нәрсәгә ышанырга, ничек яшәргә? Өмет белән яшәдек, ышандык, өметен дә, барысын да алдылар, ә алмашка нәрсә бирделәр?! *(Карт утыргычка күрсәтә.)* Менә нәрсә!

К а р ч ы к . Йә, җитте, тагын йөрәгең белән бүлнискә ятасың киләме.

К а р т . Юк, йөрәгем түгел, җаным әрни, чыкмаган җан бар бит әле.

К а р ч ы к . Айга якын гына күрешмәдек, син бөтенләй үзгәргәнсең.

К а р т . Юк, мин үзгәрмәдем. Хәзер үзгәрергә дә соң. Дөньяның асты өскә килде.

К а р ч ы к . Рәтләнер, җайга салыныр.

К а р т . Өмет, әле ярый шул өмет бар.

К а р ч ы к . Әтәч, ул да булмаса, яшәүнең мәгънәсе юк дигән сүз бит инде.

К а р т . Миңа бик күп кирәкми. Миндә, барысындагы кебек, гади кеше теләге. Үз өемдә, үз түшәгемдә җан бирәсем килә. Барлы-юклы калган гомеремне тыныч кына яшәп бетерәсем килә, нигә изәргә. Миннән зыян да, файда да юк. Син әйт, әллә бик күп сорыйммы?

К а р ч ы к . Юк, юк. Тынычлан гына.

К а р т *(читкәрәк китеп йөренеп килә)*. Тукта, син нигә төенчек белән?

К а р ч ы к . Синеке кебек чемодан булмаганга.

К а р т . Шаярмыйча гына аңлат.

К а р ч ы к . Менә үзеңә пропискага кертмәссеңме дип килгән идем.

К а р т . Аңламадым.

К а р ч ы к . Мин хәзер ирекле кош, кая телим, шунда очам, кайда телим, шунда кунам.

К а р т . Ахирәтең ни хәлдә?

К а р ч ы к . Дөнья куйды!

К а р т . Авыр туфрагы җиңел булсын.

*Утырып дога кылалар.*

К а р ч ы к . Амин! Котылды бичара.

К а р т . Бәхетле кеше!

К а р ч ы к . Әйе, бәхетле...

К а р т . Тукта, димәк, синең торыр урының бар?

К а р ч ы к . Юк шул.

К а р т . Аның бер кешесе дә юк, диден түгелме соң?

К а р ч ы к . Бар икән шул. Чыбык очы туганнары табылды. Миңа – ишеккә таба күрсәттеләр. Авырып түшәк өстендә ятканда, берәү дә күренмәде, мал-мөлкәт бүлешергә көтү кебек җыелдылар. Алар талашып калды, мин чыгып киттем. Әле ишек төбендә тентү ясадылар. Гарьләнеп үләрсең.

К а р т . Нәрсә эзләделәр?

К а р ч ы к . Нәрсә эзләсәләр дә таба алмадылар.

К а р т . Син пропискага керәм, дисең дә. Минем бит жилплощадь не позволяет, утыргыч кечкенә.

К а р ч ы к *(уенны кабул итә)*. Нишләргә соң?

К а р т . Иң элек хосусыйлаштырып, аннан соң пропискага кертсәм генә. Ләкин бик күп вакыт үтәчәк.

К а р ч ы к . Көз, урамда салкын.

К а р т . Ә без кайда утырабыз.

К а р ч ы к . Синең жилплощадьта.

К а р т . То-то! Икенче юлы да бар, анысы бик тиз.

К а р ч ы к . Нинди юл?

Карт. Син миңа кияүгә чыгасың.

Карчык. Тилермә, гариза биргәннән соң да кәтәргә кирәк.

Карт. Болар үлгәнче тизрәк бергә яшәп калсыннар, дип, көнендә үк язылыштыралар.

*Көлешәләр.*

Карчык. Мин үләргә җыенмыйм.

Карт. Ә кем җыена? Синсез үткән гомерләремне бергә яшиселәр бар әле.

Карчык. И-и, кыланчык. Сөйләп торулары!

Карт. Миңа кияүгә чыгасыңмы? *(Карчыкны иңнәреннән тота.)*

Карчык. Син нигә бүлнистән киттең, азрак ятасы иде, җылы, баш өстеңдә түбәң барые.

Карт. Коридорда ятып туйдым, мондагыдан ким түгел анда, үтеп-сүтеп йөреп торалар. Аннан, саргаеп үлә яздым.

Карчык. Нидән?

Карт. Сине сагынудан.

Карчык. И-и-и-и!

Карт. Бер дә «и-и», түгел. Күрәсем килде. Мин югында икенче яшьрәк бабай табарсың дип курыктым.

Карчык. Сөйләмә юкны!

Карт. Юкмы, бармы, анысын белмим. Ә сүзне икенчегә бордың.

Карчык. Кем?

Карт. Кем, кем, мин! Йә, чыгасыңмы, юкмы? Үзең әйтмешли, соңгы тапкыр сорыйм.

Карчык. Йә, булды, бер дә кызык түгел.

Карт. Кызык өчен өйләнә торган яшем әллә кайчан узган. Башыма апак кар яуган.

Карчык. Ул кар миңа да төшми калмаган.

Карт. Шулай булгач?

Карчык. Син бүген ничектер яшәреп, матураеп киткәнсең. *(Сокланып карый.)*

Карт. Яшәрмичә, кырындым бит. Үзең дә, сөбханалла, күз генә тия күрмәсен!

Карчык. Йә, йә, тагы башлама.

Карт *(көйгә салып)*. Хәмдиягә сүз әйтмәгез, зиһене таралган чагы.

Карчык. Тарату гына түгел, чуалтып бетердең, хәерсез!

Карт. Син теге вакытта «бер кызык» була, дигән идең?

Карчык. Кайчан?

Карт. Соң, саубуллашканда?

Карчык. Ә-ә! Аны әйтәсең? Мин хәзер!

*Карчык төенчеген ала, чишә дә чигелгән ап-ак ирләр күлмәге чыгара.*

Карт. Әһә?!

Карчык *(күлмәкне Картка күрсәтеп)*. Менә! Ничәмә-ничә еллар үзем белән йөртәм. Син кайткач кидертермен, дигән идем.

Карт. Димәк, туйга әзерләнгәнсең? Аңлашыла!

Карчык. Әйдә, әртисләнмичә генә киеп кара, өстеңдә күрәсем килә.

Карт *(тирә-ягына каранып)*. Монда килешерме?

Карчык. Кем миңа «кешенең кешедә эше юк», диде?

Карт. Алай да...

Карчык. Ничу, ки хәзер үк.

*Карт, өстен салып, күлмәк кия. Карчык төенчегеннән чиккән түбәтәй алып кидерә, читкә китеп карап тора.*

Карт. Йә, ничек?

*Карчык килеп төзәтә.*

Карчык. Матур! Килешеп тора үзеңә!

Карт. Булды! *(Кыланып)*. Бар кызлар да безнеке! Фью-ю-ют!

Карчык. Бирермен мин сиңа кызлар. Сал хәзер үк!

Карт. Бетте, бетте. Шаярдым! Син дә утыр.

*Карт чемодан янына килә, ача, аннан зур ак шәлъяулык ала.*

Карт. Монысы сиңа!

*Шәлне Карчыкның иңенә сала.*

Карчык. Ай, бигрәк затлы! *(Шәл бөркәнеп, акрын гына әйләнә.)*

Карт. Тәк-тәк! Сак булырга кирәк, урлап алып китүләре бар.

Карчык. Кемгә кирәк мин?

Карт. Алай димә, белмәссең!

*Карчыкның йөзе ачылып китә, һәм ул үзе генә ишеткән көйгә яшь чагындагы кебек акрын гына биеп китә. Аңа Карт кушыла һәм алар дөньяларын онытып биилләр.*

Карт. Бүләкләр бирештек, никахлашасы гына калды.

Карчык *(биюдән туктап)*. Өзмисең дә, куймыйсың да.

Карт. Мин тимерне кызуында сугарга күнеккән.

Карчык. Никахлашып, кайда торырга җыенасың? Яшь булсак, шалашта да җәннәт, дияр идек. Хәзер безнең чирләр, ривматизлар белән, белмим шул.

Карт. Менә монда түбә ясатабыз. Ә ябынырга шәлең бар.

*Карчык шәлен әйләндереп карый.*

Карчык. Бу бик кыйммәттер бит. Нинди акчага алдың?

Карт. Мин аны сугыштан сиңа алып кайттым.

Карчык. Ничек? Шул гомер саклый алдыңмы?

Карт. Тукымасы яхшы, хәзергеләр түгел, шуңа әйбәт сакланган.

Карчык *(Карт янына килә, күкрәгенә башын куя)*. Рәхмәт! Мин бит беркайчан да сине онытмадым. Үлүеңә дә ышанмадым. Гомерем буе көттем. Күлмәкне ала идем дә, алдыма салып, аның белән сөйләшә идем. Ә ул миңа син булып җавап бирә. Кияүгә чыгуым да кызганып кына. Фронттан зәгыйфьләнеп кайткан бер кешегә бардым. Соңгы сулышына кадәр аны тәрбияләдем. Мин аны кызгандым, ә ул ярату көтте. Йөрәгем үзем белән түгел иде бит. Аны да аңларга була, бу дөньяга килгән һәр адәмнең яратып, яратылып каласы килә.

*Карчык Картның күкрәгенә сыена төшә. Карт аны иңнәреннән коча.*

Карт. Бәхет күрмичә, бу дөньядан китәрмен дип уйлый идем. Язмышыма рәхмәт! Миңа хәзер бернәрсә дә куркыныч түгел.

Карчык. Көз дә җитте...

Карт. Юк, көзебезнең язы килде!..


*Карт Карчыкның кулчатырын ача, икесе дә шул чатыр астына кереп, бер-берсенә сыеналар. Бу ике изге җанның йөрәк тибеше, күңелләренең сафлыгы, пакьлеге, бар җиһанга нур сибеп, өмет чаткылары таратып, чын мәхәббәткә мәдхия җыры булып агыла.*

Кара, кара, кара күзләремә,
Алар сине генә күзлиләр.
Сөю утларында янам, көям.
Синең күзләр генә күрмиләр,
Йөрәк януларын сизмиләр.

Кара, кара, кара күзләремә,
Алар сине генә эзлиләр,
Газап утларында янам, көям,
Синең күзләр шуны белмиләр,
Шашып сөюмне сизмиләр.

Кара, кара, кара күзләремә.
Синең йөзләреңдә – күзләрем.
Сагыш утларында янам, көям,
Әрнүенә ничек түзәрмен.
Мин мәңгегә сине сөярмен.

*Пәрдә.*



Идият
Аширов

# УЙЛАР ГЕЛ ТУГАН ЯКТА...

## Кычытканнар

*Нигез елый, диючеләр хаклы:*
*Елый икән нигез тавышсыз...*
Шамил Маннапов.

Кешеләре киткән, авыл беткән,
Урыны гына ята каралып.
Кычытканнар тора еламсырап,
Нигез ташларына сарылып.

Кычытканнар исән, ни хәлдә дә
Нигезләрен ташлап китмәгән.
Үз кадерен белеп яшәгәнне
Туган туфрак ятим итмәгән.

Туган җиргә тугры кычытканнар
Бала чакта азмы елаткан!
Кычытканга чагылып үткән еллар
Бәхетлерәк булган күп яктан.

Кычытканнар! Әрсез кычытканнар!
Шифалы да, усал, хәтәр дә.
Беткән авыл рухын саклап торган
Кычытканнар чыкмый хәтердән.

## Бары бер сүз

Бер сүз җитә
Кеше күңелен бозу өчен.
Бер сүз җитә
Юктан гына кызу өчен.

---

Идият АШИРОВ (1947) – *шагыйрь; «Гомер юллары», «Урал аһәңнәре», «Күзләр балкышы» исемле китаплар авторы. Пермь краеның Барда районы Барда авылында яши.*

Бер сүз җитә
Ялгышларны төзәтергә.
Бер сүз җитә
Язмышларны үзгәртергә.

Ә кайчакта
Күңел өчен бер сүз җитми.
Бары бер сүз...
Йөрәк өчен эзсез үтми.

## Җир-Ана

Яратабыз кабатларга:
Җир-Ана!
Шулай булгач, бурычлыдыр
Без аңа.

Тик әлегә җибәрәбез
Без хата.
Үзен кеше иткән җирне
Кем сата?!

Җир эшкәрткән, иген иккән
Отылмый.
Әй, Җир-Ана!.. – Ә Ана ул
Сатылмый.

## Авылыма кайтам

Кайларда йөртсә дә язмыш,
Уйлар гел туган якта.
Таныш юлларым мине еш
Авылыма алып кайта.

Кадерлеләрдән кадерле
Туган авылым минем.
Җыр-моң тулы күңелемә
Илһам бирүче җирем.

Туган авыл, туган нигез,
Яшәү сулышың башка.
Якынлыгың, җылылыгың
Тоям күңелем аша.

Сагынуларым чиктән ашып,
Җанымны сагыш басса,
Кайтамын хәтер буйлап та,
Кайтам җырларым аша.

Ашкынып тибә йөрәгем
Авылыма кайткан чакта.
Тулы шатлык, тулы бәхет
Була тик туган якта.

## Исемдә

Беренче күргәч тә,
Күңелгә кергәч тә
Авылның бер айлы кичендә,

Кош кебек куанып,
Хисләргә уралып
Йөргәннәр исемдә, исемдә.

Озата килүләр,
Шаяру-көлүләр
Җәйләрнең җылы, тын кичендә,
Сөйләшеп, серләшеп,
Вәгъдәләр бирешеп
Йөргәннәр исемдә, исемдә.

Бу тәүге сөюләр,
Янулар, көюләр
Калса да томаннар эчендә,
Язларымнан уңып,
Хыялларга чумып
Йөргәннәр исемдә, исемдә.

Яшьлек тиз узганга,
Ахрысы, шуңа да
Кадерледер кемнәр өчен дә.
Сандугачлы кичләр,
Иң изге саф хисләр
Исемдә, әле дә исемдә.

## Биеклек

Сәхнә тулы йолдыз туе,
Карап күзләр камаша.
Белмәсәк тә бик якыннан,
Танышабыз җыр аша.

Көй язучылар күбәйде,
Биш җыр туа көн аша.
Халык күңеленә алар
Керә, диләр, моң аша.

Күпме җырчы, көйче, шагыйрь... –
Бай икәнбез ләбаса!
Һәрберсе дан-шөһрәт даулый –
Менә шунысы тамаша.

Даһи булалмый һәр шәхес
Мин җырчы, диеп кенә,
Мин көйче, диеп кенә,
Мин шагыйрь, диеп кенә.

Күтәрелеп булмый никтер
Илһам биеклегенә,
Сәйдәш биеклегенә,
Тукай биеклегенә...

## Ява карлар...

*Ява карлар, яңа карлар,*
*Яңа елның кары ява.*
Разил Вәлиев

Ява карлар, яңа карлар –
Яңа ел кары.
Ак төсләргә, пакь хисләргә
Урап дөньяны.

Аклыклардан, сафлыклардан
Җылына җаным,
Онытып торам бик азга
Яшьлек узганын.

Ява карлар, яңа карлар –
Йомшак бигрәк тә.
Моң тулы хыял-өметләр
Кабына йөрәктә.

Тагын бер елы гомернең
Тарихка күчә.
Кичә генә булган кебек
Иде югыйсә.

Ява карлар, яңа карлар
Бизәп дөньямны.
Муллык, бәхет алып килсен
Яңа ел кары.

## Тукай паркы

Гашыйк иттең, ахры, мине,
Бармыйм, димен, үзем киләм.
Синең каршы төшмәсеңне,
Кире какмасыңны беләм.

Борчылып та, шатланып та,
Уйланып та сиңа киләм.
Күңел тулы хисләремне
Уртаклашам синең белән.

Янәшәңдә тыныч, рәхәт,
Бер кайгым юк, уйныйм-көләм.
Гомеремнең күп еллары
Үтсә иде синең белән.

Бер сүз язалмыйча йөрсәм,
Ташлап торса әгәр илһам,
Тәүлекнең кай чагында да
Мәҗнүн сыман сиңа киләм.

Кочагыңа шәп егетне
Сыендырганыңны беләм.
Тик барыбер, яратып та,
Сокланып та сиңа киләм.

Һич аңлый алмыйм, нигә соң
Тартып торасың шулчаклы.
Дәрт, кодрәт, илһам бирүчем,
Нурлы почмак – Тукай паркы.

## Гомер кыска

Гомер кыска. Китә тора
Ил карты – ветераннар.
Тарих битләренә күчкән
Алар көрәшкән таңнар.

Гомер кыска. Китә тора
Яшь кенә егет-җаннар.
Чечня җирендә ни өчен
Кан койганын кем аңлар?!

Гомер кыска. Бер сәбәпсез
Түгелмәс иде каннар.
Ут эчендә корал тотып
Сугышмый түрә-җаннар.

## Авыл өсләрендә икмәк исе

Авыл өсләрендә икмәк исе,
Алтын төстәдер басу өсте.
Тук бөртекләр, җил иссә дә аздан,
Коелышып төшәрләр төсле.

Авыл матур иген кыры белән,
Үссә күкрәп бодай, арышы.
Иртә яздан соң көзгәчә монда
Тынмый торса мотор тавышы.

Авыл өсләрендә икмәк исе,
Туган туфрак, туган җир исе.
Көз муллыгын күреп, хозурланып,
Яши шулай авыл кешесе.



*Розалина Тимербулатова 1997 елда Башкортстан Республикасының Миякә районы Олы Кәркәле авылында туа. Урта мәктәптән соң Башкорт дәүләт университетының Стәрлетамак шәһәрендәге филиалына укырга керә. III курс студенты.*

*Хикәяләре «Иделем акчарлагы» бәйгесендә икенче урынга лаек булды.*

Розалина Тимербулатова

# САГЫНУ

ХИКӘЯ

Әле дә булса исемдә: утызынчы октябрьнең суык, яңгырлы көне. Ничек кенә тырышсам да, бу көнне хәтеремнән чыгара алмадым мин...

Тышта җил дулый. Әле тәрәзәләргә, әле өй кыегына каты итеп китереп суга, әйтерсең лә ул аларны җимерергә тели. Әмма өй бирешми, ул нык, горур тора. Никтер, менә шушы көнне мин үземне ялгыз, бәхетсез, ятим бер бала итеп тойдым.

Ул көнне әниемнең иртәдән үк кәефе кырылган иде. Баштарак моңа никтер игътибар итмәдем. Аннары янына зур бүлмәдән, кызу-кызу атлап, матур итеп киенеп куйган әтием килеп чыкты. Аның йөзе бик кырыс күренсә дә, урынымнан сикереп тордым да кулларына барып ябыштым:

– Әтием, без кунакка барабызмы әллә? Сез нигә кичтән үк әйтмәдегез, ә? Мине үзегез белән аласызмы соң? – дип, теңкәсенә тия башладым.

Гадәттә, иртән әтием мине кулына күтәреп ала торган иде. Ә бүген ул, мин көтмәгәнчә, хәтта уйламаганча да җавап бирде: башта читкә этәрде, соңыннан, теләмичә генә:

– Син генә җитмәгән идең! Югал бар моннан! – дип, каты тавыш белән кычкырды. Мондый сүзләрдән сискәнеп киттем, ә үзем әниемнең итәге артына яшерендем. Ул вакытта иң тыныч урын шунда булгандыр, ахрысы. Күп тә үтмәде, эти сумкасын күтәреп, ишекне каты бәреп чыгып китте...

Чыгып китте... Юк, өебезнең ишеген түгел, ә минем күңелемнең ишеген япты, мәңгегә япты...

Ул өйдән чыгып китүгә, тәрәзәгә барып ябыштым. Әти, артына да әйләнеп карамыйча, эре-эре адымнар белән, күз алдымнан югалырга ашыкты. Шулай күздән җуйганчы аның килешле киеменә, горур атлап барган гәүдәсенә карап тордым. Минем башымда бер генә сорау иде: «Нәрсә булды бу?»

Әниемнең күрше бүлмәдә елап утырганын ишетсәм дә, янына кермәдем, чөнки аннары без икәү елар идек... Ә мин еламаска, көчле булырга тырыштым. Шушы көчемне соңгы тамчысына кадәр әниемә бирергә теләдем ул чакта.

Әйе, бу иртә башка иртәләргә охшамаган иде. Моңарчы без әтием белән гел дә иртән торып әнием пешергән кайнар коймакларны каба-каба чәй эчә идек. Шул вакытларда

ул, мине аркамнан сөеп: «Син, улым, ныклап аша. Сиңа бүген көч кирәгәчәк әле, чөнки эшебез күп», – дия торган иде. Бу вакытта аның кулы каты, авыр булса да, ниндидер рәхәтлек тоям. Аннары йортка чыгып, барлык эшләрне бергәләп эшлибез. Әтием мине йорт хайваннарын яратырга, тирә-яктагы матурлыкны күрә генә түгел, ә тоя белергә, вак-төяк эшләргә: кадак кагарга, агач белән эш итәргә өйрәтте. Кичләрен без китаплар укып, төрле уеннар уйнап үткәрдек. Алтынга тиң киңәшләре миңа бик ярдәм итсәләр дә, аның безне ташлап чыгып китүен кичерә алмадым шул... Бу көнгә кадәр безнең тормышыбыз бөтенләй башкача булганын бик яхшы аңладым. Шулай да баштарак, иртәләрен әтиемне бик нык сагынып уяна идем. Менә хәзер бүлмәмә керер дә, мине күтәреп алыр кебек тоела иде. Әмма, үсә-үсә, үземдәге бу сагыну хисләрен тыярга өйрәндем.

Икенче көннең иртәсе артык салкын булмаса да, ниндидер болытлы, тонык иде. Җил тынган, әмма яңгыр, менә хәзер ныклап явам, дигән сыман, торып-торып сибәләп киткәли иде. Мондый көн минем болай да китек күңелемне тагын да ныграк кыра. Агач яфраклары күптән инде коелып беткән. Тәрәзә каршындагы имәннең соңгы кызгылт-сары яфраклары гына җиргә төшәргә үз чиратын тыныч кына көтә кебек.

Ә инде төшке аштан соң безгә бераз яшәргә әбием килде. Ул әниемә ярдәм итте. Ир-ат эшләре авыр булса да, алар барлык эшләрне икәү башкардылар. Аларга җиңелрәк булсын дип микән, әллә инде үземне чын ир-егетмен дип уйлапмы, алар тотынасы эшкә алдан барыпябыша идем. Әтием турында ничек кенә сорыйсым килсә дә, сорашмадым, чөнки аларның йөзләреннән үк барысы да аңлашыла иде. Ә шулай да йорт капкасы ачылган саен, мин әтием кайткандыр, дип, урамга йөгереп чыгарга күнектем...

Әби килгәч, безнең тормыш үзгәрде, әйтерсең лә елга агымы кискен борылыш алды. Хәзер инде йоклар алдыннан әкият-хикәяләрне миңа әбием белән әнием икәүләп сөйли. Әнием китаптан укыса, әбием хәтердән илебезнең, авылыбызның тарихын, әкият-бәетләрен һәрчак кызыклы һәм аңлаешлы бәян итәргә тырышты. Күрәсең, теле шундый назлы, татлы булгандыр, минем аны һаман тыңлыйсым килә иде.

Урамга да без гел әбием һәм әнием белән бергә чыктык. Шунда мин еш кына күрше малайларын әтиләре белән күрәм, көнләшә дә идем. Ул чакта: «Әнә аларга ничек кызык, алар бәхетле, чөнки әтиләре бар. Әтиләре белән бергәләп туп тибәләр, йөгерешле уйныйлар... Ә минеке? Кая китеп югалды икән соң? Күпме көтәргә була инде? Ул берәр кайчан элеккечә өебезгә кайтыр микән?» – дигән сораулар борчыды.

Янымда әтием кебек һәрвакыт киңәш биреп, өйрәтеп торучы булмаса да, үсә-үсә ир-ат эшләренең күбесенә төшендем. Үсеп, эш рәтен белүем аркасында, әнием белән әбиемә дә җиңелрәк була башлады. Хәзер инде алар өйдәге хатын-кыз эшләрен генә башкаралар.

Әнием дә, әбием дә этинең юклыгын сизмәсен, дип үстерделәр мине. Ләкин моны тоймый мөмкинме соң? Мине алдан әйдәп баручы ир-ат юк бит! Нинди генә эшкә тотынсам да, башка малайлар кебек, әтиемнән түгел, ә әниемнән киңәш сорыйм. Ә кайчак уемда әтиемнең җавабы нинди булыр иде икән, дип, аныңча үз-үземә акыл бирәм. Әнием исә гел дә хатын-кызлар аңыннан чыгып җавап эзли. Бәлки, шуңа күрә дә мин нечкә күңелле, хисләргә тиз бирешә торган малай булып үскәнмендер.

Мәктәптә яхшы укырга, тәртипле булырга, әнием белән әбиемнең йөзенә кызыллык китермәскә тырыштым. Әнә бит, әтиле малайларның да кайберәүләре тәртипсезлекләр кыла, тәмәке тарта...

Әнием белән әбием янында балачагым бәхетле һәм тиз узды. Гомерем буе әтиемне сагынып үсмәсәм, бәлки, иң бәхетле балачак миндә булды, дип әйтә алыр идем. Ничек кенә көтсәм дә, ул кайтмады. Әнием соңыннан, үсеп җиткәч кенә, аның яңа гаиләгә чыгып киткәнлеген әйтте.

Әнием сүзләренә тиз төшендем һәм әтиемне онытырга тырыштым. Үсеп җиттем, уку йортын тәмамладым, эшли башладым. Әнием һәм әбием ярдәме белән кеше булдым, аякка бастым. Мин аларга бик рәхмәтле идем. Чөнки әнием белән әбиемнән башка югалып та калыр идем, яшәргә омтылышым да булмас иде. Ә алар үзләрен җәлләмичә, барлык көчләрен, түземлекләрен миңа салдылар. Моның кадерен беләм, әлбәттә. Ләкин күңелдәге авыр таш кына тынгы бирмәде. Күңел һәрчак әтиемне күрү

хыялы белән яшәде. Күп тапкырлар күз алдымнан аның белән очрашу мизгелләрен кичердем. Ә очрашу һич көтмәгәндә, уйламаганда килеп чыкты.

Ничә еллар элек булган, шундый ук салкын көзге бер көндә ул безнең ишекне какты. Мин аны танымадым. Каршымда егерме ел элек безне ташлап киткән әтием түгел, ә ниндидер чит-ят кеше басып тора иде. Картайган, чәчләренә чал төшкән, горур буе да чүккән. Ишектән кергәч, ул озак дәшмичә торды да, аннары: «Гафу ит мине! Мин барысын да аңладым, улым...» – диде. Ә мин, нәрсә дияргә дә белмичә, урамга чыгып йөгердем. Дөресен генә әйткәндә, качтым, аның каршында күз яшьләремне күрсәтмәс өчен качтым...

Ничә еллар буена аны көтеп яшәдем бит, тәрәзәдән күз дә алмадым, тормыш кыенлыкларын үзем генә кичерергә мәҗбүр булганда, их, әтием янымда булса иде, дип уйладым. Ә хәзер, үсеп җиткәч, ул картаеп, ярдәмсез калгач, аның исенә төшкәнменме?! Бу сорауга җавапны ул вакытта тапмасам да, еллар үткәч, яхшы аңладым.

Һәммәсе эти-әниле гаиләдә үссә, бу җирдә бәхетле балалар, бәлки, күбрәк булыр иде. Әти-әниләрне дә бәхетле картлык каршылар иде...

---

*Җәһәт тәнкыйть*

## РОЗАЛИНА ТИМЕРБУЛАТОВА. «САГЫНУ»

Кечкенә генә текст, сөйләп бирүгә корылган. Хикәяләүче – ир-егет, моннан егерме ел элек әтисенең, гаиләсен ташлап, башка хатынга китүен һәм менә кайтып гафу үтенүен бәян итә. Гаиләсен ташлаган ир еллар узгач гаебен таный, шуны сөйләгән текст мондый әхлакый нәтиҗә белән төгәлләнә: «Һәммәсе эти-әниле гаиләдә үссә, бу җирдә бәхетле балалар, бәлки, күбрәк булыр иде. Әти-әниләрне дә бәхетле картлык каршылар иде...»

Тирә-ягыбызда мондый хәлләр очрыймы? Әлбәттә. Кино-телевидениедә мондый гаиләләрне күрсәтү тагын да күбрәк. Ә хикәя кайда соң?

Тормышның гадәти күренешен сәнгать әсәренә әйләндерү өчен, уйланма кирәк була. Шул гадәти-табигый тормыш күренешен үз күңелендәге иҗади уйланма белән кушып, язучы әдәби әсәр иҗат итә. Уйланма аерым бер очрактан – күп кешеләргә кагылышы булган закончалыкны китереп чыгара. Ул язучының тормыш күренешеннән югарырак күтәрелеп, шуңа шәхси бәясе, гадәти булмаган яктан килеп караш ташлавы, башкаларга да шулай карау мөмкинлеген күрсәтүе кебек тә аңлатыла ала.

Әдәби уйланма – яза торган әсәрнең жанрына, иҗат методына бәйле. Гадәттә, мондый кече күләмле әсәрләрдә шул уйланманы укучыга сиздерә, кайчак ассызыклый торган элементлар, өлешләр була. Аларны «көчле позиция» дип йөртәләр.

Көчле позиция иң мөһим мәгънәләрне укучыга җиткерергә ярдәм итә. Беренче чиратта, әсәрнең исеме, башламы һәм йомгагы «көчле позиция» дип санала.

Әсәрнең исеме тормыштагы күренеш белән уйлап табылган дөнья арасындагы чикне тоташтырырга ярдәм итә. Хикәядә аның кыска формага китерелгән эчтәлек, җыеп кына теманы әйтү кебек булуы әйбәт дип санала. Ягъни хикәянең исеме эчтәлекне гомумиләштереп, аңа бирелгән бәягә укучы игътибарын юнәлтергә тиеш. Чөнки ул – укучы белән язучы арасындагы беренче мәгълүмат алмашу мөмкинлеге. Алга таба, текстның үзен уку барышында, укучы әлеге беренче мәгълүматны киңәйтә бара.

Шушы яктан Розалина Тимербулатова хикәясенең исеменә игътибар итик: «Сагыну». Әсәрне укып чыккач, бу тарихны сагыну тарихы дип атыйсы килми, киресенчә, ул гафу итә алмау тарихы булып күз алдына баса. Текст эчендә сүз

кабатлана: «Шулай да баштарак, иртәләрен әтиемне бик нык сагынып уяна идем. Менә хәзер бүлмәмә керер дә мине күтәреп алыр кебек тоела иде. Әмма, үсә-үсә, үземдәге бу сагыну хисләрен тыярга өйрәндем». Һәм кабатлау ярдәмендә хикәяләүче әтисен сагынып үткән балачагына ишарә ясамыймы, дигән фикер дә уяна. Әмма ул балачагының бәхетле булуын тәкрарлады бит: «Әнием белән әбием янында балачагым бәхетле һәм тиз узды. Гомерем буе әтиемне сагынып үсмәсәм, бәлки, иң бәхетле балачак миндә булды дип әйтә алыр идем». Сагыну шул бәхетне киметүче дип кенә күрсәтелде...

Димәк, кечкенә күләмле әлеге хикәягә исем дөрес сайланмаган. Шушы исемгә туры килсен өчен, аны яңадан язарга: яки ташлап китү күренешеннән соң сагыну белән бәйле берничә яңа күренешне искә төшерү рәвешендә кертергә, яки текстның ахырын очрашу күренеше белән тәмамламаска кирәк.

Гадәттә, герой исеменнән сөйләнә торган кече күләмле хикәяләр арасында «ачыш хикәясе» дип йөртелә торган төр еш кулланыла. Бу жанрда иң тәэсирле, кызыклы хикәяләр шуңа карый. «Ачыш хикәясе» – кешенең зур психологик үзгәреш кичерү мизгелен (аны тупса, чик, юллар алдында тору, дип тә атыйлар) сурәтләү, аның карар кабул итүен күзәтү, әлеге карарны сайлауның укучы өчен көтелмәгән булуы һәм шулай итеп кеше холкы-аңының үзенчәлеген күрсәтеп гаҗәпләндерү сыйфатларына ия. Бу текстта да «ачыш хикәясе»нә әйләнү мөмкинлеге бар: моның өчен хикәяләүне геройның егерме елдан соң көтмәгәндә үз бусагасына килеп баскан әтисе белән очрашуыннан башлап, калганнарын – искә төшерү рәвешендә бердәм агым (аң һәм кичереш агышы) итеп формалаштыру сорала.

Исем – көчле позициянең тагын ике элементы: кереш һәм башлам белән тыгыз бәйләнештә булырга тиеш. Керешне тагын бер тапкыр күздән кичерсәк, анда онытa алмау, хәтердән җуеп ташлый алмау белән бәйле мотив күзгә ташлана: «Әле дә булса исемдә: утызынчы октябрьнең суык, яңгырлы көне. Ничек кенә тырышсам да, бу көнне хәтеремнән чыгара алмадым мин...» Әмма хәтердән чыгара алмау белән сагыну арасындагы аерма – җир белән күк арасы. Кереш тәге әлеге фраза әсәрне башкача җыярга һәм башкача атарга кирәклекне тагын бер тапкыр искәртә.

Йомгак – текстның чиге, соңгы ноктасы, мәгълүматны тәгәлләп кую. Әхлакый чыгармага игътибар итмәстән, тагын бер тапкыр йомгакны искә төшерик: «Ничә еллар буена аны көтеп яшәдем бит, тәрәзәдән күз дә алмадым, тормыш кыенлыкларын үзем генә кичерергә мәҗбүр булганда, их, әтием янымда булса иде, дип уйладым. Ә хәзер, үсеп җиткәч, ул картаеп, ярдәмсез калгач, аның исенә төшкәнменме?! Бу сорауга җавапны ул вакытта тапмасам да, еллар үткәч, яхшы аңладым». Йомгак гаиләсен ташлаган ирнең адымын бәяли – хикәяләүченең сагынуына аның катнашы юк.

Инде кабат әхлакый нәтиҗәне искә төшерик: «Һәммәсе әти-әниле гаиләдә үссә, бу җирдә бәхетле балалар, бәлки, күбрәк булыр иде. Әти-әниләрне дә бәхетле картлык каршылар иде...» Бу очракта да, хикәяләүченең үз балачагы бәхетле булганны сөйләгәненнән чыгып, соңгы җөмләнең укучыга аталганын аңлыйсың. Әмма гаиләдән киткән һәр кешенең язмышы бәхетсез тәгәлләнми бит. Димәк, көчле позициягә чыгару өчен, текстның эчендә дәлил кирәк...

Инде кабат уйланма төшенчәсенә кайтыйк. Ул – әдәбилек билгесе, тормыштагыдан аермалы буларак, күренешнең күңел аша уздырылуын аңлата. Язучылар үзләре дә аңа билгеләмә һәм шәрехләү эзлиләр. Хикәянең «төше» (изюминкасы) дип атау гомумбилгеле. Әдәбилекне сер, көтелмәгәнлек эффекты белән бәйләү дә мәгълүм: беренче абзацны укыгач ук, текстның ничек тәмамланачагы күренеп тору осталык билгесе түгел бит. Розалинага да үз текстларының төшен – иң «тәмле» үзәген яки яшерен серен табуда уңышлар телим.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*



Гөлнур
Айзат

# САФ ЧИШМӘ

хикәя

Сорау алулар клиникада башланып китте.

– Нигә елыйсың? Син гаеплеме? Йә, бала-чага төсле мышкылдап торма, мә, сөрт күзләреңне! – дип, тикшерүче өстәл өстендәге ак кәгазь салфетканы Нәркискә сузды.

Хатын бите буйлап агып төшкән күз яшьләрен киптерде дә:

– Ничек еламаска? Миннән дә бәхетсез тагын кем бар икән? Гомерем буе сынау арты сынау! Берсен җиңеп кенә чыгам, икенчесе аяк-кулларыма урала... Өстемдә җиде йөз мең кредит тора, аны кем түләсен?! Мин бит тормышны гел ялгызым тарттым... Хәзер дә шулай... Кызларымны кем аякка бастырыр? – диде дә, Нәркиснең буасы кабат ерылды.

Тикшерүче, ни гаҗәп, аңа башка сорау бирмичә, шәфкать туташының елап бетергәнен, тынычланганын көтте.

– Йә, елап туйдыңмы, инде кеше төсле сөйләшәбезме? – диде ул, йөзенә кырыс төсмер чыгарып.

– Сорагыз, – диде хатын.

– Син гаеплеме? Гаепле булмасаң, нигә балавыз сыгасың? Аңлат яхшы итеп! Кайчан, ничек юк булган ул акчалар? Кем алырга мөмкин? Кемнең буразнасына аркылы яттың икән син? Күрдеңме син ул акчаларны?

Өстенә шулкадәр сорау ишелеп төшүдән Нәркис беравык аптырап торды. Тикшерүче аның алдына ук килеп утырды. Хатынның күз яшьләреннән чыланган салфетканы өстәлгә алып куйды.

– Нәркис ханым, сөйләшәбезме? – дип, кабат хатынга сынап карады.

– Мин иртән эшкә килдем. Бүген мин җирдә хезмәт күрсәтергә тиеш идем. Шәхси клиника бит, штатлар күп түгел. Администратор да мин, процедура бүлмәсе, кассада да – берүзем.

– Шуннан, сез килгәндә, биредә кеше бар идеме?

– Юк. Кичә бу урында Гөлсем эшләде. Ул хатын мине бик яратып бетерми. Баш табиб янында да мине гел чагарга гына тора иде. Җае чыкса, чыкмаса да, әллә нинди ялган хәбәрләр уйлап таба, хәтта ясаган чәемә дә чебен булып төшә иде.

– Шуннан?

– Шуннан шул, кичә мин эштән киткәндә, аның касса артында бер төргәк акча санап утырганын күрдем. Үзе телефоннан кем беләндер кызып-кызып сөйләшә, үзенең бармаклары күз иярмәс тизлек белән акча саный. Мин аңа сүз катып тормадым, өйгә кайтып киттем. Иртән аның урынына эшкә килдем, ләкин кассаны тикшермәдем.

– Менә анысын дөрес эшләмәгәнсез!

– Терсәк якын да бит, тешләп булмый. Хәзер инде үкенүдән ни файда?! Акча табылмаса, мине нишләтерләр икән?

– Әлегә берни дә әйтә алмыйм. – Тикшерүченең үзенә сынап түгел, ә ничектер теләктәшлек белдереп, якын итеп каравыннан хатынның теле ачылды.

– Минем бер гаебем дә юк, алмадым мин ул акчаларны, валлахи-билләхи, тиененә дә кагылмадым.

– Сөйләшүнең асылына кире кайтыйк, ханым!

– Мин эшкә килүгә, бер-бер артлы авырулар керде. Дистәләгән кешегә система куйдым, уколлар кададым һәм түләү вакыты җитте.

Нәркиснең чырае тагын үзгәреп китте. Керфекләре кабат дымланды, тавышы калтырады. Тикшерүче якын ук килеп утырып, Нәркиснең ярдәм сорап өзгәләнгән күзләренә карады һәм «бигрәк чибәр, риясыз икән бу шәфкать туташы», дип уйлап алды Сабит Гафурович.

– Тыңлыйм.

– Шул, кассаны ачып җибәрдем, түләүләрне кабул итәргә кирәк иде бит. Ә анда, ә анда...

Нәркис кабат елап җибәрде. Тикшерүче Сабит Гафурович хатынга графиннан стаканга су салып бирде.

– Тынычланыгыз! Болай барсак, без хәлне кичсез дә ерып чыга алмабыз. Бигрәк йомшак күңелле булдыгыз әле!

– Шундый инде мин, тормышымда шатланырлык хәлләр сирәк була. Шуңа чишмә кебек гел җырлап торам менә! Елыйм да җырлыйм, елыйм да җырлыйм...

– Шуннан?

Нәркиснең йөзе өстендәге ак халаты төсенә кергән. Теленә бер потлы гер асып куйганнармы – һич әйләндереп бер сүз әйтә алмый, тамак төбендәге «аптырау төере» бугазында кысылып калган кебек.

– Дәвам итегез, Нәркис ханым!

Хатын, теге төерне төшереп җибәрмәкче булып, кат-кат тамагын кырды, дулкынланудан әле колакларын, әле муенын ышкыды. Аннары, уң кулын күкрәк өстенә куеп, кырт кискәндәй әйтеп куйды:

– Тимәдем мин ул акчаларга!

– Ышанам!

– Ә ышангач, ник мине газаплыйсыз?

– Дөрес аңлагыз, Нәркис ханым, сезнең гаепсез булуны расларлык фактлар кирәк бит, аңлыйсызмы шуны, дәлилләр кирәк! – диде тикшерүче. Аның бу мөлаем, гөнаһсыз карашлы шәфкать туташына бик тә, бик тә булышасы килә иде кебек.

Ниһаять, Нәркис бераз тынычлана төште:

– Мин кичә Гөлсемнең акча санаганын күрдем. Акчалар пачкалап иде. Йөзәрлекләр дә, иллелекләр дә... Тик аның ул акчаларны кассага куеп калдырганын гына күрмәдем. Бүген кассаны ачкач кына өнсез калдым. Кассада Гөлсемнең калдырган язуы бар, ә акчалар юк иде. Касса бүлмәсенең тикшермәгән җирен калдырмадым. Шуны гына көтеп торган, диярсең, баш табиб үзенә чакыртты. Кичәге выручка белән кызыксынды, мин аңа акчаларның югалуын сөйләп бирдем... Калганын беләсез, сезгә шалтыратканнар, миңа эштән соң китмәскә куштылар. Инде нишләрмен, ничек, кайдан алып түләрмен?! Эшемнән генә кыскартмасыннар иде. Гөлсемдә генә инде ул акчалар, аңарда гына! Ул өч көннән Грециягә ялга җыена иде. Тикшерүче әфәнде, тикшерү бетмичә торып, Гөлсемне җибәрмәскә мөмкинме?

– Сабит Гафурович мин!

– Гафурович?

– Исемем танышмы?

– Әтиегезнеке таныш! Минем әти дә Гафур исемле булган.

– Ә-ә-ә! Сирәк исем. Булган, дисез, әтиегез исән түгелме? – дип, тикшерүче сүзне бөтенләй икенче якка борып җибәрде.

Нәркис тә үзенә карап тыныч кына сөйләшкән бу кешегә ачыласы итте.

– Исәндер, күргәнем юк!

– Әтиегез сезнең белән яшәмәдемени?

Тикшерүченең бу соравы хатынны ерак елларга алып китте. Холкын тормыш авырлыклары, юклык кырыслаткан әнисе, һәрчак җимерек чырайлы үги әтисе, аннары сеңлесенең «җиңеләюе», мәхәббәтнең ни икәнен белмәгән һәм белергә дә, аңларга да теләмәгән ире, Нәркиснең бар хәсрәтләрен үзенең салкын сулары белән бергә агызып алып китүче Көмешсу чишмәсе... Бер мизгелдә Нәркис гомер дәфтәренең әллә ничә битен ачып карарга өлгерде.

– Минем әтине бөтенләй күргәнем юк. Үз әтиемне, дим. Әнине корсаклы чакта ук ялгызын гына калдырган... Бала тудыру йортыннан мин аның фамилиясен алып чыкканмын, мәктәптә дә Хатыйпова булып йөрдем. Балачагымда үз әтием белән очрашырга туры килмәде. Әнием дә күрешүебезне теләмәде. Дөрес, үги әти үлгәч, мин үз әтиемне эзләтеп карадым, исәнлеге турында хәбәр дә килде, бер аягын кисүләре, каты авыруы, коляскада гына йөрүе турында да ишеттерделәр, әмма әти янына барырга кыюлыгым җитмәде. Аның инде башка гаиләсе, зур урында эшләүче улы бар икән. Дәрәҗәле туганнарга минем ише гади медсестра кирәкме икән соң?!

Сабит Гафурович никтер тамак кырып куйды, аннары кесәсеннән кульяулык алып, маңгай тирләрен сөртте. Нәркис, тикшерүченең нидән шулай дулкынлануын аңларга тырышып, аңа карап тора башлады. Ул, Нәркиснең чибәрлегеннән каушыйдыр дип, башына да китерә алмады.

– Чәй ясамассызмы, нишләптер тамак кипте, су гына басмас кебек, – дип, ир Нәркисне бөтенләй аптыраашта калдырды. Эш урынына кунаклар килгәндә, чәй өстәле әзерләргә кирәкле бар нәрсә махсус шкафта торганга, хатын тиз генә торып, электр чәйнегенә су агызды да кайнарга куйды. Тәм-томны өстәлгә тезде. Тикшерүче, Нәркиснең онытылып табын коруын зур игътибар белән күзәтте. «Кем булыр бу ханым? Миңа таныш нindидер чалымнар бар аңарда!» дигән уйлар тынгы бирмәде аңа.

– Ул да түгел, чәйнектәге су кайнап чыкты да, Нәркис миләш тәлгәшләре төшкән чынаякка чәй ясады.

– Мөмкин булса, бал кашыгы бирмәссезме? – Нәркис, затлы бал кашыкларының баш табиб бүлмәсендә торганын белеп, ишеккә юнәлде. Ләкин Сабитның тавышы яшен тизлеге белән хатынны ишек төбендә куып җитте.

– Әтиегез кайсы авылдан иде әле, Нәркис ханым?

– Наратлыдан!

– Ә кем булып эшләгән?

– Кем булып дип?.. – Хатын, «әйтимме икән, юкмы?» дип тынып калды.

– Кем булыптыр эшләгәндер бит инде әтиегез? Бәлки, мин сезгә аны табып бирә алыр идем, – диде Сабит.

– Әтинеме?

– Әйе, әтиегезне!

– Вор в законе булган ул!

Сабит Гафурович, селәүсен тизлеге белән, хатынны куып тотты да алдына ук килеп басты.

– Вор в законе?

– Әйе. Ә нигә аптырадыгыз? Андый кешеләрнең хатыны да, балалары да булмаска тиеш дигән берәр канун бармы әллә?

– Юк, юк! Бу беркайда да тыелмаган, әмма...

Тикшерүче тамагын кырды да, Нәркисне кулыннан эләктереп, кабат өстәл янына алып килде. Зур тәрәзә яктысында ул Нәркисне әле уңга, әле сулга боргалап карады. Аннары алтын тапкан кеше сыман:

– Точно! Точь в точь!

Тикшерүченең болай җентекләп каравын Нәркис нәрсәгә юрарга да белмәде.

Шулчак кесә телефоны шалтырады, һәм Сабит Гафурович, тәрәзә каршына басып, телефоннан сөйләшергә тотынды. Нәркис, аның үз эше белән мәшгуль булуыннан файдаланып, бүлмәдән чыгып китте дә баш табиб бүлмәсенең ишеген шакыды.

– Гөлминур Әкрамовна! Тикшерүче чәй эчәргә тели, бал кашыкларын алыйм әле, – диде ул кыюсыз гына.

– Эше беттемени?

– Юк бугай, телефоннан кемдер бүлдерде.

– Дөресен әйтеп, акчаларны китереп куй да, бу процесс тизрәк бетәр, Нәркис Гафуровна!

– Сез дә миңа ышанмыйсызмы? Алмадым мин ул акчаларны, җир йотсын, әнием белән ант итәм, алмадым.

– Әниләрне кыстырмагыз монда. Акчалар үзләре очып чыкмагандыр бит инде, бикле тартмадан тем более!

– Ничек кенә раслыйм соң гаепсезлегемне?!

– Сезнең гаепсез булуны тикшерүче расласын әнә, ә миңа бүген акча бик кирәк. Китерегез!

Ул табиб бүлмәсеннән чыкканда, тикшерүче һаман телефоннан кызып-кызып сөйләшә иде. Нәркис, бүлмә ишеген ябарга онытып, ишек төбендә туктап калды.

– Картлач, телисеңме-теләмисеңме, син аны күрергә тиеш! Ничә еллар үзеңне гаепләп йөреп, соңгы юлга киткәндә акланмасаң, рәнҗеш ташын үзең белән алып китәчәксең...

Тикшерүче, борылып, кыюсыз гына басып торган Нәркискә эндәште:

– Ни булды тагын, чыраегыз мәетнеке сыман булган?

– Баш табиб акча таптыра... куар инде ул мине бу эштән...

– Әле тикшерү бетмәде, чын гаеплене тапмый торып, кумас, курыкмагыз! Мин моны ышандырып әйтә алам, сеңел, – диде Сабит, соңгы сүзгә аеруча басым ясап. Миңа хәзер үк бүлеккә кайтырга кирәк, иртәгә дәвам итәрбез. Ир, эшне вакытлыча тәмамланганга санап, китәргә җыена башлады. Нәркис ясаган чәйне чөмереп куйды да, хатынның кулын кысып:

– Ышаныгыз миңа, барыбер ышаныгыз! – дип, бүлмәдән чыгып китте.

Нәркиснең көне буе эше эш булмады. Күз йомган килеш тә система куя, укол ясый торган бармаклары тыңламады. Авырулар, Нәркиснең бу халәтенә аптырасалар да, артык сорау биреп теңкәсенә тимәделәр.

Клиникада эшләрен бетереп, кассага көне буена җыелган акчаларны санап, тартманы бикләргә торганда, ишектә Гөлминур Әкрамовна күренде.

– Күпме?

– Егерме биш мең!

– Китерегез, калганын үземнән өстәп торырмын, – дип, ул акчалы конвертны, чебеш эләктергән тилгән сыман, тиз генә тартып алды да чыгып китте.

Бөтенләй үк начар кеше түгел баш табиб. Әнә, хәлемә керә бит әле! Мине участокка алып китмәделәр, заказчикларга үз акчасын куеп тора, эштән кумады. И Раббым, мең рәхмәт сиңа! Бу бәла-казалардан исән-имин чыксам, әтиемне эзләп табар идем дә аңардан башка гына узган бар тормышымны сөйләп, пешергән ризыгымны авыз иттерер идем. Бәлки әле мине ташлап китүендә бер гаебе дә булмагандыр, аны мәҗбүр иткәннәрдер. Бәлки, ул гомере буе мине уйлап яшәгәндер, мин генә сизмәгәнмендер?! Нәркис авыз эченнән шулай сөйләнеп, поликлиникадан чыкты.

Тышта вак кына яңгыр сибәли. Тамчылар хатынның маңгаена килеп бәрелә дә бите буйлап агып төшә. Тормышның ачы җилләре җанын туктаусыз камчылап үзәгенә үтеп торса да, Нәркис бирешми, тырыша-тырмаша, үзе җигелгән арбаны тарта. Бер генә тапкыр булса да дилбегәне ир дигәненә тоттырасы килгән чаклары күп булды аның, әмма алырга атлыгып торучысы гына күренми. Фәрваз инде хатынының бар эшне үзе эшләвенә күнгән, «юк, кирәкми, теләмим, белмим» сүзләре белән бар йөкне

үз өстеннән төшереп яшәде. Әйтерсең лә ул: «Ирең бармы?» – дип сораучыларга: «Бар!» – дип җавап бирер өчен генә яратылган бер адәм иде.

Соңгы вакытта хатын: «Кайда ялгыштым соң мин?» – дигән сорауга җавап эзли. Тәүге кат Шыгырданга килен булып төшкән вакытларын күз алдына китереп, еш кына узган гомер юлын барлый һәм, йөрәген парә-парә телгән хәлләрне исенә төшерүгә, күңеле карала башлый. Андый чакларда ул чишмә суы белән битләрен юа, уйларын тузгытып җибәрерлек җырлар тыңлый.

Нәркис, кибеттән азык-төлек күтәреп кайтканда, ире өйдә йоклап ята иде. Телевизоры бар тавышка акыра, зал диванында центнерлы гәүдәсе белән ике мендәрне бер итеп изгән ир. Ишекне ачып кергән тавышка да уянмады.

Кем белән бүлешергә бу көннең авыр хәсрәтен? Иренә сөйләсә дә, тыңламас йә Нәркиснең үзен сүгәргә тотыныр. Олы кызына сөйләр иде – бала табар вакыты җитеп килә, борчу ярамас. Кече кызы Алсуга сөйләсә, ничек булыр? Алсу яшьтән бик төпле, акыллы киңәшче, ярдәмче булып үсте-үсүен.

Нәркис, көндезге авыр хисләрдән арынырга теләгәндәй, өстендәге киемнәрен алыштырды. Йөрәкне телгәләгән хәсрәтле уйлардан әйтерсең лә күлмәкне салып атып кына котылып була! Театрда эшләүче Алсу әнисенең уйларын сизгән диярсең, чәйнек сызгыруы белән бергә кушылып, Нәркиснең телефоны да зеңләде.

– Алло, әнием! Кара күлмәк киеп яр башында нинди ир белән басып тора идең син?

– Хәерле кич, кызым! Нинди кара күлмәк, нинди ир?

– Менә мин дә шуны белергә телим, әнием!

– Минем гардеробта, гомумән, кара күлмәк югын беләсең ич, кызым!

– Беләм, әнием!

– Төшләрең белән башымны катырма әле, балам, болай да бүген телем аңкавыма ябышкан, йөрәгем урынында түгел.

Нәркиснең тавышы калтырап чыкты. Чигәләре чыңлады.

Зең-зең, зең, зең... Алсуның тавышы кинәт өзелде. Нәркис кызына кабат шалтыратмады. Чынаягына кап-кара иттереп чәй агызды. Баш авыртуларын каты чәй белән булса да юып аласы килде аның.

– Кайда йөрдең шул гомер? – Кухня ишеге төбендә ире күренде.

– Эштә. – Нәркиснең авыз ачып иренә сыңар сүз әйтәсе килмәсә дә, җавап кайтарырга кирәк иде.

– Эштә? – Синең эшең икедә бетә бит! Ә хәзер кичке биш!

– Фәрваз, ичмасам, син игәмә, болай да күңелемнең өзелмәгән кылы калмады бүген.

Ир кухняга узды.

– Миңа да чәй яса! Мин көне буе ашамаган!

– Соң мин сиңа аш пешереп калдырдым бит, җылытып ашыйсың булган! Аңа да мин кирәкме инде? Бәлки, сиңа кашыклап ашатыргадыр? Синең өчен үзем йотыйм дамы?! Менә мине утыртып куйсалар, эчәрсең баба шулпасы!

– Бусы нинди сүз тагын? Утыртып куйсалар, имеш? Ни булды? Чәчтер әйдә серләреңне!

– Выручканы урлаганнар... Бар акчаны Гөлсем санап калды... Иртән килгән төшкә акчадан җилләр искән!

– Соң Гөлсемнән сорасыннар! Кая куйган соң ул акчаларны?!

– Гөлсем юк шул менә! Бүген миннән көне буе сорау алдылар... – Нәркис көндезге хәлләрне искә төшерүгә, кабат күңеле тулып, үксеп елап җибәрде.

– Ник мин шушы кадәр бәхетсез җан булдым икән? Бер генә көн дә хәсрәтсез яшәгәнем юк бит!

– Син үзең бар кешегә дә хәсрәт ясап йөрисең! Сыгылып, мине кызгандыра алмассың! Синең өчен түләргә дигән акчам юк минем! Әнә, берничә кешедә сиделка булып йөрерсең дә җыярсың!

Фәрваз газ плитәсе өстендә торган кәстрүлдән шулпаны чүмеч белән генә чөмерде дә кухнядан чыгып китте. Нәркиснең күңеле тәмам кителде. «Йа Раббым, шушы битараф адәмгә уналты яшемнән кияүгә чыгып, тормышның күпме тозлы шулпасын эчтем?! Нишләп шушы кадәр каты бәгырьле бу Фәрваз? Иртәгә ничекләр җавап тотармын?»

Хатынның кулы бернинди эшкә дә бармады. «Урланган илле мең акчаны каян табарга?» дигән уйдан котыла алмады ул.

Караңгы төн авыр булса да узды. Таң атты. Керфек очларында калган күз яшьләре иртәнге чәйгә коелды.

– Ни булып бетәр? Әгәр мине ябып куйсалар, сиңа хәбәр итәрмен, – дип, иренә сүз кушты да эшкә җыена башлады.

***

Баш табиб бүлмәсендә, Гөлминур янында кассирша Гөлсемне, Сабит Гафуровичны бергә күреп, хатын өнсез калды.

– Узыгыз, Нәркис Гафуровна!

Нигәдер, баш табибның тавышы калтырап чыкты. Бер төн эчендә ни дә булса үзгәргәнме, Гөлсем нишләп монда икән?..

Тикшерүченең күз карашы бүген, нишләптер, җылы, хәтта серле кебек тоела.

Бүлмәдәге тынлыкны Сабит Гафурович бозды:

– Йә, кемнән башлыйбыз? Кайсыгыз, үз иреге белән капчыктагы серне тартып чыгара? – Ул Гөлсемгә боерды:

– Әйдәгез, ничек бар – шулай сөйләгез!

Гөлсем кылган төсле җилфердәп торган чәч бөртекләрен кирәксә-кирәкмәсә дә, әле бөтәрләп, әле тартып сүз башлады, дулкынлануын яшерә алмый.

– Миндә түгел ул акчалар... – Хатын туктап, тирән итеп сулыш алды, тамагын кырды, сүз йомгагының очын таба алмады. – Мин аларны... санадым да...

Гөлсем, Гөлминурга карап, әйтергәме-юкмы дигәндәй, берничә минут җавапсыз торган арада аны тикшерүче куәтләде:

– Санадыгыз да кая куйдыгыз?

– Кая булсын инде – конвертка! Ике конверт иде бит! Берсенә сумманы яздым да, буш килеш калды, икенчесен Гөлминур Әкрамовнага бирдем.

Шулчак баш табиб корбанын эләктерергә җыенган карчыга сыман:

– Син нәрсә, Гөлсем, акылыңдамы, яла ягарга?! – дип җикеренде.

– Сабыр, сабыр, Гөлминур ханым! Сезгә дә вакыт җитәр, сабыр булыгыз! – Сабит Гафурович Гөлсемнең алдына ук килеп басты. Кассирша, йөзенә «миңа хәзер барыбер, барын да сөйләп бирәм» дигән төсмер чыгарып, сүзен дәвам итте.

– Конвертны илле мең акчасы белән Гөлминур Әкрамовнага бирдем. Ул шунда ук акчаны сумкасына салып куйды да минем ялга китәргә сорап язган гаризама имза сырлады. Берничә көн ялындым: «Бер атнага гына ялга китим әле!» – дип, гаризамны ала да ерта, ала да ерта иде. Теге көнне дә янына мин гариза тотып кердем. Шунда Гөлминур Әкрамовна миңа бер «эш» тәкъдим итте. – Табибә утырган урыныннан кузгалып куйды.

– Гөлсем! Чамасын бел! Үкенергә туры килмәсен!

– Куркытмагыз мине, Гөлминур Әкрамовна, минем башка түзәр хәлем калмады, китәм мин бу клиникадан. Бөтенләйгә! Мин бит мондый түгел идем, сез мине нинди хәшәрәткә әйләндердегез, хәзер үз-үземне күралмыйм.

– Дәвам итегез! – Сабит Гөлсемнең иңбашына кулын куеп, аңа утырырга кушты. Хатын калтыранган бармаклары белән өстәлдәге графиннан су салып эчте. Нәркис бүлмәдәгеләрнең һәркайсын игътибар белән күзәтте.

– Эш сәгате беткән иде инде. Минем акча санаганны Нәркис тә күрде, тик аларны тартмага салганны гына күрмәде ул, мескен! Шулчак, Гөлминур Әкрамовна чакыртты. «Гаризаңа кул куячакмын, тик син миңа бер эштә булышырга тиеш.

Мин Нәркисне эштән кумакчы булам, ә сәбәбе юк», – диде. Мин нишли алам соң, дигәч, «бүлдермә, тыңла. Әллә ни эшләргә кирәкми, выручка урынына буш конверт калдырасың. Синең эшең бик җиңел. Үзең ялга китәсең, шәһәрдән югаласың... вакытлыча, әлбәттә», диде.

Мин инде күңелем белән әллә кайчан Грециядә идем, шуңа күрә бу юлы да ризалаштым.

– Гафу итегез, Гөлсем, бу юлы да дигәнегезне төшенеп бетмәдем, – диде Сабит Гафурович.

– Ә нәрсәсе аңлашылмый? Гөлминур Әкрамовнаның улы наркоман бит! Ә егеткә көн дә акча кирәк! Дозага! Әнисе улын тынычландырыр өчен гел шулай акча эшли, каян алып бетерсен?!

Гөлминурның бөтен тәне дерелди, бармакларын туктаусыз бер-берсенә кыйнап, үз-үзен тынычландырырга тырышып карый. Тик инде тикшерүчедән берни дә яшереп булмаслыгы көн кебек ачык иде.

– Гөлсем!

– Нәрсә сез, Гөлсем дә Гөлсем?! Күпме кешенең күз яшен күтәреп йөрүе әллә миңа җиңел дисезме?!

– Дәвам итегез!

– Клиникадан шулай киткән шәфкать туташлары гына да алтау инде! Барысы да шул акча аркасында. Берничәсе, үзләре алмасалар да, акчаны врачка үз куллары белән кертеп бирде, эштән чиста документ белән китү бәрабәренә. Менә Нәркис кенә!

Нәркис, миңа да чират җиттемени, дигәндәй, торып басты. Тик аны тикшерүче кире урынына утыртты.

– Әлегә сезгә сүз бирмәдек. Сабыр итегез! Ә Нәркис Гафуровнага ник каныкты табиб?

– Никме? Әлеге дә баягы, шул, улы аркасында инде!

– Аңламадым, – диде тикшерүче.

– Монда аңламаслык берни дә юк. Төнлә улының өянәге башланган. Егеткә тиз генә система куймасаң, кыйнала, бәргәләнә, йә доза бирергә, йә система куеп, бу хәлдән «откачать итәргә» кирәк. Уйлап тора да, Гөлминур Әкрамовна «Ашыгыч ярдәм»гә шалтырата. Ә машинада, система куярга кем килә дип уйлыйсыз? Нәркис Гафуровна фатирга килеп кергәч, өнсез кала ул. Кире борып та җибәрә алмый. Улына ярдәм итәргә кирәк. Төне буе шулай егет янында газапланып утырып чыгалар икәү. Улының наркоман булуы турындагы сер ачылгач, Гөлминур Әкрамовна, ничек тә Нәркисне клиникадан куарга уйлый. Башкаларны да шулай озатты ул. Тик менә, нишләптер, миңа гына тимәде.

– Сине иң беренче куарга кирәк булган икән, хәшәрәт! – дип ярсыды Гөлминур.

– Кулыгыз кыскарак, Гөлминур Әкрамовна, чөнки мин сезнең бөтен махинацияләрегезне беләм.

– Дәвам итегез!

– Ә башка сүзем юк. Мин бит инде икенче көнне аэропортта идем, анда менә сез көтеп торгансыз... Миңа хәзер китсәм дә буламы, иптәш следователь?!

– Азрак сабыр итегез! Гөлминур Әкрамовна ни дияр бит әле?

– Ни дия алам соң инде? Баласы хакына ярдан да ташланырга әзер кеше инде мин. Күрәсең, үземә дә зур җәза алыр көн җиткәндер! Ни өчен, ни өчен?

Хатын, үзе биргән сорауга үзе җавап таба алмыйча, үксеп елап җибәрде.

...Нәркис, Гөлсем, Гөлминур... Өчесенең дә күз яшьләре саф иде...

*«Татарстан. Тарих. Шәхесләр»*
*әдәби очерклар конкурсы*

# ОНЫТЫЛМАС ЕЛЛАР ХАТИРӘСЕ

ОЧЕРК

Көн артыннан көн, ел артыннан ел үтә. Бөек Ватан сугышы тәмамланганга да 74 ел булды. Янә сугыш кырында ятып калганнарны искә төшерәбез, аларның фронттан килгән, инде саргаеп беткән хатларын укыйбыз.

1941 елны әти фронтка китә. Аны, гомумән, күпләгән авылдашларыбызны озаткан көн бүгенгедәй күз алдымда. Авыл шау-гөр килә. Кемнәрдер елый, кемнәрдер юата. Гармун тавышына кушылып, моңсу гына җырлаулар ишетелә.

Кыр капкасын чыккан чакта
Күтәрелде томаннар.
Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз,
Сау булыгыз, туганнар!

Бу – китүчеләрнең саубуллашуы. Әтиебез абыем Дамирны һәм мине җитәкләп кибеткә алып керә дә мандолина сатып ала: «Мин кайтканчы уйнарга өйрәнеп куегыз!» Без аның бу васыятен үтәдек. Абыебыз да, шушы көнне өйдә бабасы янында калган бер яшьлек Энгель дә, үсеп җиткәч, мандолинада уйнарга өйрәндек.

Менә китүчеләр, аларны Кләүле стансасына кадәр озата баручылар кибет каршындагы олауларга төяләләр. Әниебез дә этине озата бара. Арбалар кузгала. Без елыйбыз. Әтиебезнең өлкән туганы Кыям абзый безне юата: «Еламагыз, балалар, еламагыз», – ди, ләкин үзенең күзеннән дә яшь ага. Мәрхүм озакламастан үзе дә фронтка китте һәм шул китүеннән әйләнеп кайтмады.

Әтиебез романтик рухлы, татар моңы белән сугарылган кеше булган. Бик матур җырлаган. Бездә аның сугыш кырларыннан язган хатлары сакланган. Кайвакыт аларны алып, кат-кат укыйбыз. Һәрберсе сагыну хисе белән тулы. 1943 елның 19 мартында язган хатын үзе яратып башкара торган:

«Урал суы, болын буе,
Сандугачлар сайрый болында,
Ташлар ватып, таулар кичкәндә дә,
Сез булырсыз минем уемда», –

дигән сүзләр белән тәмамлаган. Шушы җырны мин үзем генә калганда, әтиебезне искә төшерә-төшерә җырлап йөрим.

Мәрхүм олы абыебыз Дамир белән дә махсус хатлар алышып торган ул. Абыебыз бер хатында: «Әти, мин сиңа бик күп хатлар язсам да, ала алмадың, ахры. Без сине бик нык сагындык. Өч елдан бирле сине – әтиебезне күрергә, кочакларга тилмердек бит инде, әни һәм иркәләрем сине төштә күрсәк тә шатланабыз», – дип язган.

Хатларның сугыш сәбәпләре аркасында шактый тоткарланган чаклары да була. Бездән хәбәр алмагач, әтиебезнең борчылып, рәнҗешен белдереп язган хаты да бар. Билгесезлектән аптырап елавын да яшермәгән: «Айга якын хат алмагач, еламый буламыни?» – дигән ул.

Сугыш башлангач, әниебезне ул вакыттагы Шөгер районының иң зур

авылларыннан булган Түбән Чыршылыга мәктәп директоры итеп билгелиләр. Без сугыш елларын шунда үткәрдек. Мәктәптә биш йөздән артык бала. Барысының да диярлек әтиләре һәм туганнары фронтта. Авылда күпчелек хатын-кыз һәм бала-чага. Ятимлек, ачлы-туклы тормыш хөкем сөрә. Әнине партия оешмасы секретаре итеп тә сайлыйлар. Аның өстенә халык арасында агитация эшләрен оештыру да йөкләнә. Укытучыларның барысы да аның тирәсендә. Алай гына түгел, үзешчән сәнгатьтә дә шулар ук. Концертлар оештыралар, фронттагы һәм илдәге хәлләр белән таныштыралар. Халыкка яшәү көче биреп торалар.

Әниебезнең бертуган апасы Минзифа Шагали җизнәбез белән Ярославльгә китеп яшиләр. Аларның Марс, Хурия, Җитез һәм Лена исемле балалары була. Бөек Ватан сугышы вакытында фашистлар Ярославльне бомбага тоталар. Апабызның Җитездән гайре һәммә баласы һәлак була. Җитез апабыз шин заводында эштә булганлыктан исән кала. Үзе теләп фронтка китә, аннан хатлары да килгәләп тора. Фронттан әниебезгә язган бер хатында мондый сүзләр бар: «Апакаем! Кайбер чакта шулкадәр Ярославльне сагынам, ташларын, җирен, әти-әни йөргән җирне үбеп елыйсым килә. Баш иеп, дошманга кайгымны күрсәтергә теләмим, алар минем яшемне күрмәсләр. Бу – беренчесе. Икенчесе – ни өчен минем Ярославльдә калмавым. Ата-анасы үлде, ә ул ялангач түгел, тамагы тук, дип әйтерләр, дим. Кул-аягым бар, башым исән әле. Әти-әниемнең үлеменә дошман шатланмас, мин аларны ачы яшь белән елатырмын». Чыннан да, ул үзен-үзе аямастан, каты сугышларда катнаша.

Менә аның фотосы. Аны җибәргән хатында мондый сүзләр бар: «Апа, мин сиңа үземнең карточкамны җибәрәм. Ул бик куркыныч, мин урыс кызына охшаганмын. Мин андый түгел».

Тагын бер, 1945 елның 5 мартында әниебез исеменә язган хатында мондый сүзләр бар: «Апа, минем өчен борчылма, үлсәм-үләм, ләкин әти-әниебезнең һәм сезнең йөзегезгә гарьлек китермәм».

Ул Белоруссиядә партизаннар хәрәкәтендә дә катнаша. «Участнику партизанского движения» дигән беренче дәрәҗәле орден белән бүләкләнә.

Сугыш беткәч, безнең яныбызга кайту уе белән яши. Безгә үзенең кием-салымнарын җибәргән посылкасындагы хатында мондый сүзләр яза: «Исәнмесез, кадерле Әминә апа һәм бәләкәй туганнарым Дамир, Индүс, Энгель. Барыгызга да нык сагынычлы сәлам. Шушы көннәрдә авылда булырмын дип уйлыйм. Шуның өчен күп яза алмыйм. Үзем исән-сау. Сезне дә шул хәлдә дип беләм. Әминә апа, сезгә кайсыбер әйберләремне җибәрәм. Алар сиңа да, балаларыңа да булыр. Кайберләрен төзәт. Балалар үскәндер инде. Йә үзең бишмәт тегәрсең, йә Дамир, Индүскә, Энгельгә нәрсә булса да чыгар. Хат көтәм, ничек торуыгыз турында яз, апа. 10.VIII.1945.»

Ләкин шуннан соң Җитез апабыз хәбәрсез югалды. Эзләтеп карадык. Бервакыт Лукашенко белән очрашканда, аның ярдәмен дә сораган идем. Ләкин нәтиҗәсез.

Хатлар, хатлар! Аларны укыганда, тарих җанлана сыман, инде мәңгелеккә киткән якыннарыбыз терелгән кебек тоела. Ләкин безгә әти белән дә, Җитез апа белән дә күрешү насыйп булмады. Әтиебез, рота командиры Риза Шәйхетдин улы Таһиров, Латвияне фашистлардан азат итү өчен барган дәһшәтле сугышлар вакытында һәлак була. Шул кайгы кәгазен алгач, әниебез ничәмә көннәр буе без, балаларына да әйтмичә, ут йотып йөргәндер. Елагандыр, ләкин ялгызы, берүзе. Беребезгә дә белдермәстән. Әйе, шушы онытылмас еллар көндәлеген бүген дә тыныч кына укып булмый. Аларны барлаганда, ничәмә-ничә туганыбызның үле хәбәре килгән кәгазьләргә дә юлыгабыз.

Әтиебез хакындагы шушы кечкенә генә, ләкин эченә зур кайгы сеңдергән кәгазьдә рота командиры Риза Шәйхетдин улы Таһиров 1944 елның ноябрендә Латвияне азат

итү өчен барган каты сугышларда батырларча һәлак булды һәм Ауц өязенең Звани хуторында җирләнде, дип язылган. 1967 елның августында мин шушы хуторны эзләп Ригага килдем. Аннан автобуска утырып Ауцка юнәлдем. Автобустагы юлдашларым латышлар, минем кая һәм нигә барганым белән кызыксындылар. Мин аларга шушы җирләрдә һәлак булган әтиебезнең каберен эзлим, дидем. Алар миңа уңышлар теләделәр. Ауцта миңа бу шәһәрнең беркайчан да өяз үзәге булмаганлыгын әйттеләр һәм тулы белешмә алу өчен Ригага – республика хәрби комиссариатына барырга тәкъдим иттеләр. Анда кемгә мөрәҗәгать итәргә икәнлеген аңлаттылар, бер полковникның исемен атадылар. Һәм янә автобуска утырып, Ригага юнәлдем. Ни күрим, автобуста минем шул ук юлдашларым кире кайтып киләләр икән. Алар да, мин дә шатланыштык. Эшнең нәрсәдә икәнлеген сөйләп бирдем.

Рига военкоматына килеп җиттем. Өске катлардан ашыга-ашыга офицерлар аска агыла. Каршыма очраган һәрбер офицердан, гафу үтенә-үтенә, фамилияләрен сорыйм. Янәсе, аларның миңа кирәге кырыемнан үтеп китмәсен. Шуларның берсе борылды да, өстән төшеп килүче берсенә күрсәтеп: «Әнә ул, сезгә кирәк кеше», – диде. Мин исә, шулай ук гафу үтенеп, аны туктаттым һәм йомышымны сөйләп бирдем. Ул кулымнан тотты да кабинетына алып керде. Бик күп кәгазьләрне тикшереп карап чыкканнан соң, әтиебезнең җәсәде Салдус шәһәренең туганнар каберенә күчереп күмелгәнлеген әйтте. Шатлыгым эчемә сыймый. Мин шушы мәрхәмәтле полковникка рәхмәтемне әйтеп, аның белән саубуллаштым һәм тимер юл вокзалына юнәлдем.

Икенче елны янә Латвиягә киттем һәм, Ригада поездддан төшү белән үк, Салдуска бара торган автобуска утырдым. Андагы военкоматта ныклап исемлекләрне тикшергәннән соң, әтиебезнең исемен табып, мондагы туганнар каберлегендә җирләнгәнлеген әйттеләр. Туганнар каберлегенә бардым, ләкин меңләгән исем арасында үземә кирәген күрмәдем. Һәм янә военкоматка килеп, исемлектә әтиебезнең фамилиясе күрсәтелмәгәнлеген әйттем. Шушы эшләр өчен җаваплы старшинадан бу хатаны төзәтеп, мәрмәр таштагы исемнәр тезмәсенә әтиебезнең исемен яздыруны, фотосын төшереп, миңа җибәрүен үтенеп, аңа чыгымнары өчен акча да биреп калдырдым. Ул үтенечемне үтәячәгенә вәгъдә биргәч, тынычланып, Казаныбызга кайтып киттем. Старшинадан хәбәр булмады. Ләкин эшен эшләгәндер, тик фотосын гына эшләтә алмагандыр дигән өмет белән, 1987 елны энем Энгель белән әниебезне Салдуска алып бардык. Әнине кунакханәдә урнаштырып, үзебез туганнар каберлегенә киттек. Ләкин мәрмәр таштагы исемлектә әтиебезнең исеме юк. Теге старшинаны таптык. Ык-мык килсә дә, хатасын төзәтергә җыенмаганлыгын аңладык. Ул вакыт әле партия системасы җимерелмәгән. Киттек райкомга. Безне беренче секретарь кабул итте. Аңа хәлебезне аңлаттык. Ул шул ук мизгелдә военкоматка шалтыратып, кемнәрнедер пыр туздырды һәм хәзер үк әтиебезнең исем-фамилиясен нәкъ аларның үзләрендәге исемлектәге кебек итеп мәрмәр ташка язып куярга дип әмер бирде. Әмернең үтәлешен барып тикшердек һәм, әтиебезнең исемен күргәннән соң, әниебезне каберлеккә алып килдек. Ул анда намаз укыды, шуннан җир алып кайтып, аңа гөл утыртып үстерде. Әниебез исән чагында гөл ел саен чәчәк атты һәм әтине искә төшереп үсте.

Инде бүген әниебез дә гүр иясе. Без, аларның балалары, оныклары әкрен искән йомшак таң җилләре аша аларның һәр икесенә сәламнәребезне, якты тормыш юлына бастырганнары өчен иксез-чиксез рәхмәтләребезне юллыйбыз. Авыр туфраклары җиңел, урыннары җәннәттә булсын.

**Индүс ТАҺИРОВ,**
*профессор, академик*

# «ХАЛКЫМ ҖЫРЫН САКЛЫЙ АЛСАМ ИДЕ...»

ОЧЕРК



*Рөстәм Зәкуанов һәм Фәния ханым.*

Моннан шактый еллар элек, редакция эше белән Азнакайга барган идем. Шагыйрь җанлы Әнәс Исхаковның хакимият башлыгы булып эшләгән чагы бу. Университеттан соң хезмәт юлымны башлаган район булганга, Азнакайга еш килдем, юлларын такырайтып бетердем. Шулай бер баруымда Әнәс Гатуф улы: «Слушай, Риман, гаҗәеп бер егет белән таныштырыйм әле. Синең коллега да, журналист кеше. Шигырьләр дә яза, җырлый да». Исхаков бу егетне заманында бер колхозның бригадасы булган Илбәк авылына җитәкче итеп куеп, шул җирлектә «Янтарь» совхозы оешкан иде. Колхоз-совхозлар таралган бер чорда аны әлеге дә баягы журналист, шагыйрь һәм җырчы Рөстәм Зәкуанов оештырды, үзе шуның директоры булды. Хуҗалык җитәкчеләре арасында иң яше иде ул. Совхоз берничә ел эчендә аякка басты, халык, үзен чын хуҗа итеп тоеп, муллыкта яши башлады. Азнакайга Татарстан районнарыннан гына түгел, Россиянең кайбер төбәкләреннән килгәннәрне дә, тәҗрибә уртаклашу өчен, Илбәккә алып бара башладылар. Рөстәм, эше белән горурланудан, үзе турында уйлаудан бигрәк, авыл халкы өчен шатлана иде.

Хатыны Фәниянең сөйләгәннәре истә калган. «Совхоз директоры хатыны булуның үз нечкәлекләре бар. Безгә – хатыны, балаларына вакыты аз кала дип үпкәлисе килгән чаклар да булды. Дәшмәдем, чөнки холкын беләм. Рөстәм, кешегә кирәк булса, чатыр чаба, гозер белән өйгә төнлә дә киләләр, авыл халкы өчен ишек гел ачык булды», – дигән иде ул.



*Рөстәм Зәкуанов хатыны Фәния, кызлары Айгөл, уллары Айваз белән.*

Сүземнең «бисмилла»сы озынгарак китте бугай, әмма «урау юллар» белән язуымның хикмәте бар. Бер күрешүебездә мин Рөстәмнән: «Син үзеңне яратасыңмы?» – дип сорадым. Инде җавабын сүзен-сүзгә хәтерләмим, ни дисәң дә, чирек гасырдан артык вакыт узган. Менә шул япь-яшь җитәкче:

«Бәй, абзый, ничек яратмыйм инде?! Үзен-үзе яратмаган кеше халыкны да ярата алмыйдыр», – дигән иде. Ул чакта әлеге сүзләргә артык игътибар бирмәгәнмен, асылына төшенмәгәнмен, җитәкче авызыннан чыккан «тәти» сүз дип кабул иткәнмендер. Инде менә бүген Рөстәмнең «үз-үзен һәм халыкны ярату» фәлсәфәсен аның яшәү рәвеше дип кабул итәм. Баксаң, Рөстәм Зәкуанов бөтен барлыгы белән халык улы булган икән бит.

Нинди генә гамәлләрен искә төшерсәм дә, алар, Рөстәм үзе әйтергә яратканча, «татарымыз» хакына эшләнгән. Аның хәтта Илбәк авылын чәчәк аттырып яшәтүе дә татарны саклап калу өчен булган. Бүген төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр, сәясәтчеләр авызыннан еш чыга торган «авыл бетсә – татар да бетә» дигән акыллы сүзләр моннан чирек гасыр элек Рөстәм күңеленә кылынасы гамәлләр булып кереп утырган.

Үлгәнче «авыл-авыл... татар, татар...» дип яшәде ул, шигърияте дә милли хисләрдән мөлдерәмә тулы. Аның 2008 елда миңа бүләк иткән китабы да «Авыл моңы» дип атала иде. Инде шактый вакыт «кала кешесе» булып яшәсә дә, күңеле авыл урамнарын айкап йөрде.

Китапның беренче бүлегенә эпиграф итеп язган дүртьюллык аның бу җиргә нигә килүен аңлата.

Олы юлда калган эзләремне
Сагынганда салам көйләргә.
Халкым җырын саклый алсам иде
Бездән соң да җиргә килгәнгә.

Үзе язганча, «авыл урамында балачагын кочагына аласы» килгән көннәре бик еш була иде. Кайбер язмаларымда инвесторларны мактабрак телгә алсам, итагатьле генә итеп: «Абзый, фикерләрең бик үк дөрес түгел», – дип куя иде. «Дәүләт әллә нинди матавыклар китереп чыгармаса, киресенчә, ярдәм итсә, авыл үз көнен үзе күрә, бөтен илне ашата ала», – ди торган иде.

## Ир еласа, ил хакына елый

2004 елны Зәкуановны 39 нчы Азнакай сайлау округыннан депутатлыкка тәкъдим иттеләр. Мандат алды егетебез, әмма кулга тотып эшләргә күнеккән кешегә, үзе әйтмешли, «хәреф чүпләп утыру» ошамый иде. Депутатлыктан киткәч тә, аның авызыннан «сезнең Дәүләт Советыгыз...» кебек сүзләр ычкынгалады. Икенче яктан, парламенттагы эшчәнлеген «тормыш мәктәбе узу» дип тә бәяли иде. Иң әһәмиятлесе, Дәүсоветта ул үзенә фикердәшләр тапты. Шуларның берсе Туфан ага Миңнуллин



*Сулдан уңга: Рөстәм Зәкуанов, Туфан Миңнуллин, Лотфулла Шәфигуллин, Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев.*



Туфан Миңнуллинның музей-утары.

булды. «Җеннәре килеште» аларның, Зәкуан чынлап торып иҗатка кереп китте, шигырьләр җыентыгы чыгарды. Туфан ага исә: «Талантың бар, яз!» – дип, күңелен үсендереп торды һәм, «Рөстәм дуска...» дип язып, берничә китабын да бүләк итте. Бу ике шәхесне иҗаттан кала, авыл һәм татар язмышы турында уйлану да якынайтты дип беләм.

Тора-бара язмыш Рөстәмне тагын бер шәхес белән очраштырды. Ул «Таттелеком» элемтә компаниясе генераль директоры Лотфулла Шәфигуллин иде. Депутатлыктан соң Рөстәмне үзенә эшкә чакырды ул, оешманың матбугат идарәсе җитәкчесе итеп куйды. Шуннан соң милли хисләр тагын да куәтләнеп, «элемтәче» Рөстәм Зәкуанов халкыбызның үткәне, атаклы шәхесләребез рухы белән «элемтә урнаштырды». Лотфулла Шәфигуллинның милли-мәдәни, тарихи мирасыбызга кагылган бетмәс-төкәнмәс идеяләрен тормышка ашыруда җигелеп тартучы затка әйләнде. Аларның изге омтылышлары миңа да күчте, һәм «Таттелеком» егетләре белән берничә ел буе бер юлда йөрдек. Тагын да йөрергә язсын. Тик менә бүген Рөстәм Зәкуан юклыгы сизелә, бик сизелә.

Милләт, шәхесләребезгә бәйле изге гамәлләргә бөтен күңелен биреп тотынды ул. Бер елны, инде Туфан абыйның вафатыннан соң өч еллап вакыт узгач, Рөстәм әдипнең авылы – Олы Мәрәтхуҗага барып кайтты. Лотфулла Нурислам улы: «Туфан абыйның йорт-җирләре ни хәлдә икән, белеш әле, дип җибәргән идем, Зәкуан бик ачынып кайтып керде», – дигәч, Рөстәмнең үзеннән дә сорадым: «Шулкадәр үк үзәккә үтәрлекме?» – дидем. «Абзый, ни дәрәҗәдәге олпат шәхесләребезнең шулай онытылуына йөрәк әрни… Кайчандыр Туфан ага йөргән ишегалдында кеше буе чүп үләне, әрем, кычыткан үскән. Йорт-җирләре, үзе карап торган чишмәсе дә кызганыч хәлдә. Кеше китте дә онытылды. Туфан абый торган, иҗат иткән урыннар бит ул... Гаделсезлек түгелмени?» – дип, миңа төбәлеп карады. Мин аның үтә дә нечкә күңелле икәнен белә идем. Элемтәче егетләрнең эшләре турында язган саен, газетага бирер алдыннан аңа укыта идем, янәсе, «сәяси хаталар» юкмы?



Арча районы Хәтнә авылындагы атаклы Перцовларның яңартылган утары.

Язма ошаса, телефоннан шалтыратып: «Абзый, булган бу. Кайбер туң йөрәклеләрне уйландырырлык, уятырлык», – ди иде. Бу минем өчен иң зур бәягә әйләнде. Ярый, монысы башка мәсьәлә. Ә менә тарихыбызны барлау, мәңгеләштерүгә омтылуда эш алымнары кызыклы иде элемтәчеләрнең. Нәрсәгә генә тотынмасыннар, иң әүвәл архивларда казыналар, галимнәр белән киңәшәләр. Лотфулла Шәфигуллинның да, Рөстәм Зәкуанның да эш өстәлендә төрле китаплар, кульязмалар өелә башлар иде. Музейлар ачумы, истәлек ташлары куюмы, чишмәләрне төзекләндерүме, борынгы зиратларны тәртипкә китерүме – барысы да зур иҗади хезмәткә әйләнде. Бер уйлаганда, алар – элемтәчеләр – техник хезмәткәрләр генә, ә Тукайчарак әйтсәк, «күзләре күпне күрә, колаклары күпне ишетә» иде. Хәтта кайбер галимнәр, әдипләр белмәгән мәгълүматларны да табып дөньяга чыгардылар. Укылырга чират көтеп яткан кульязмаларны, теге яки бу тарихи вакыйгага яисә шәхескә кагылган төрле истәлекләрне, җыеп-барлап, китап итеп бастырып, музейларга куя килделәр.

## Сәерлек

Элемтәче егетләр Иске Казан каласы урынында музей тыюлыгы коргач, Туфан ага Лотфуллага: «Сәер кеше син, Лотфулла», – дигән булган. Ничә еллар бергә эшләгәч, кая барасың – сәерлек Рөстәмгә дә йоккандыр.


Хәер, бу сыйфат анда элек тә бар иде кебек. «Нормальный» кеше беренче күргән кызга: «Всё, минем хатын буласың, бетте-китте», – дип әйтәмени инде, җә! Хатыны Фәния бу хакта бер елны елмаеп-көлеп сөйләгән иде. Бер уйлаганда, инде алтмышка якынлашкан Рөстәмнең: «Өйгә кунарга гына кайтыла инде, абзый», – диюе дә сәер. Олыгайган кеше, гадәттә, «өй тавыгына» әйләнә бит инде ул. Ә Рөстәм, мин кайчан шалтыратсам да: «Абзый, эш күп», – ди торган иде. Аның бу сүзләренә мәшһүребез Марсель Галиев тә, сәерсенеп: «Илдә күпме эшсез бар, ә Зәкуан эштән бушый алмый, нормаль хәл түгел бу», – дия иде.

«Таттелеком»ның иҗат төркемен, ягъни Лотфулла Шәфигуллин белән Рөстәм Зәкуанны Республикабызның Тукай бүләгенә тәкъдим иттеләр.

Мин, элемтәче егетләргә ияреп, бөтен Татарстан буйлап йөргән журналист буларак, Рөстәмгә шалтыраттым: «Сезнең турыда да берәр язма әзерләргә кирәктер бит», – дидем. Ул: «Бәй, үзегез карагыз инде», – диюдән узмады.

Егетләрнең милли-мәдәни, тарихи мирасыбызны саклауга үзләрен тарихка кертү өчен тотынмаганын беләидем. Газетага язма әзерләгәч тә, Рөстәм: «Гәҗиткә биргәнче карап чыгыйк инде, абзый (Лотфулла Шәфигуллин. – *Р.Г.*) үзе турында язганны бик яратмый бит», – дия иде, һәм, гадәттә, оешманың да, җитәкчеләрнең исемнәрен дә сызып ташлыйлар иде. Тукай бүләген алырга җан талашу башланган бер вакытта, Рөстәмнең үзләре башкарган күркәм гамәлләр турында гәҗиттә язма күрергә атлыгып тормавы да сәер тоелды. Хәтерлим, Тукайның тууына 130 ел тулган 2016 елда кайбер «җаваплы» иптәшләр: «130 ел – юбилей булып исәпләнми», – диделәр. «Таттелеком» исә аны «Тукай елы» дип игълан итте. Монысы да сәер иде. «Юбилей мәшәкатьләре илә» галәмәт зур эшләр дә башкарды егетләр.

Рөстәм Зәкуан исә Тукайның «Онытылу, тибәрелү – үлемнән дә яман» дигән сүзләрен еш искә алды. «Бар уем кичен-көндезен синең хакта, милләтем», дип гомер кичергән шагыйрьнең, әлеге юлларны язганда, үзен генә түгел, җир йөзендә татар дигән милләт язмышын күз алдында тотуын кат-кат әйтә иде.



*Шиһабетдин Мәрҗани музееның эчке күренеше.*

Аннан соң: «Бетү, онытылу куркынычы татарга гомер буе янаган, бүген дә яный. Шуңа күрә тарихыбыз, олпат шәхесләребез онытылмасын өчен, үзебез күбрәк эшләп калыйк, шулай бит, абзый», – дип, күзләремә карый. Фикердәше икәнемне белә үзе, әмма барыбер бер-бер сүз ишетәсе килә иде. Мин дә Тукайчарак әйтеп куям: «Милләт мәнфәгатьләрен корсак файдасыннан өстен итә торган милләт арысланнары инде сез», – дим. Салпы якка салам кыстырганга үпкәләми, бары тик, алай ук түгел инде, дигән сымак уңайсызланып куя.

Мин «Таттелеком»ны тарихыбызны, шәхесләребезне барлау буенча эзлекле фәнни эш алып бара торган оешма дип кабул итәм. Мәсәлән, Шиһабетдин хәзрәтне кем дип белә идек? Шул юнәлештә эшләүче галим-голамәне күз алдында тотмыйм. Халык аны дин әһеле буларак кына күзаллый иде. «Сәер» егетләр Мәрҗанине борынгы грек галиме, фәйләсуфы, «тарих атасы» дип тарихка кереп калган Геродот дәрәҗәсенә күтәрделәр. Әле «Татар Геродоты» дигән китап та чыгардылар. Мәрҗанине башка халыклар да белсен, дип, рус телендә бастырдылар.

Егетләргә Тукай бүләген тапшырдылар, әмма... Хәер, бу турыда соңрак әйтеп китәрмен.

## Апуш коесы

Бер елны Кырлайда, Сәгъди абзыйның бакча башындагы инеш буенда басып торабыз. «Рөстәм, – мәйтәм, – бу инеш буенда кайчандыр чишмә булган, кечкенә Апуш та, күрше-тирәләр дә шул чишмәнең суын эчкән. Хәзер ул томаланган, чишмә юлын ачып, аны язгы ташу вакытында ләм күмеп китмәслек итеп, берәр нәрсә эшләп булмас микән?» Рөстәмнең, алдан кычкырып: «О-о... эшлибез аны!» – дип, буш вәгъдә биреп куярга яратмаганын беләм инде. Бу юлы да: «Җаен китереп, абзый белән сөйләшермен әле», – диде. «Абзый» дигәне әлеге дә баягы Лотфулла якташ була инде.

Күп тә үтмәде, Сәгъди абзый, ягъни Тукайны уллыкка алган Сәгъдетдин Салихов биләмәсе төзелеш мәйданчыгын хәтерләтә башлады. Инеш буйлары чистартылып, таш җәелде, чишмә «Апуш коесы»на әйләнде, монда килгәннәрне кое янындагы эскәмиядә «тузгыган сачын тарап» утырган Су анасы каршы ала. Ә бәрәңге бакчасында Апушны җитәкләгән Сәгъди абзый «йөри». Бу бакча хәзер ачык һавадагы музей кебек. Элемтәче егетләр каралтыкураны да рәткә китерделәр. Сәгъди абзый шунда күмелгән дип фаразланган урында яңа кабер ташы куярга да куллары җитте. Онытылып барган Сәгъди абзыйның яңартылган йорт-җирен карарга Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов та, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә килде. Фикерләре бер: биредә үзен татар дип санаган һәркем булырга тиеш.

Чишмәдән генә башланган сүз әнә шулай сокланырлык олы эшкә әверелде.

Эш барган көннәрдә Зәкуан шунда кунып-төнеп ятты. Телефоннан шалтыратып: «Син кайда соң?» – дип кайчан сорасаң да, «Бәй, кайда булыйм, синең Арчаңда инде», – дип кенә куяр иде. Кайчак: «Арча синеке, минеке генә түгел, бөтен татарныкы инде ул», – дип тә өсти иде.



*Яңа Кырлайдагы Сәгъди абзый бакчасында «Таттелеком» егетләре тарафыннан булдырылган әдәби-архитектура паркын ачу тантанасында. Әлеге чарада ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев (рәсемдә – уңнан икенче) катнашты. Фотода сез шулай ук Арча муниципаль районы башлыгы Илшат Нуриев (сулдан уңга), «Таттелеком» элемтә компаниясе генераль директоры Лотфулла Шәфигуллин һәм Рөстәм Зәкуановны да күрәсез.*

Милли-мәдәни мирасыбызны тергезү, татар рухын саклау өлкәсендәге гамәлләре Рөстәм Зәкуан тормышында якты бер сәхифә булып язылып калды. Татарстанның төрле районнарында күпме музейлар ачылды, шәхесләр рухына күпме истәлек такталары куелды! Чишмәләре исә челтерәп ага бирә.

Кушлавычта Тукай нәселе су эчкән «Мулла коесы» шулай ук кадерле тарихи ядкарь. Кызганыч, Рөстәм Зәкуан әлеге эштә үзе турыдан-туры катнаша алмады, ул бу вакытта яман авыруга каршы көрәшә иде. Әмма Тукай исемендәге бүләкнең акчасын егетләр «Мулла коесы»н тергезүгә тоттылар, димәк, Рөстәм монысында да катнашты. Чишмәләргә битараф түгел иде ул. Океан-диңгезләрне, инеш-елгаларны – тереклекнең нигезе, ә чишмәләрне олы суларның башы итеп саный иде. Иҗатында чишмәләрне еш телгә алуы да тикмәгә түгелдер. Хәтта Азнакайда яшәгәндә язган беренче шигырьләре дә чишмә турында.

Йөз чишмәсе Азнакайның,
Дәвер сүзләрен сөйләп,
Киләчәккә китеп бара,
Синең җырларны көйләп, –

дип язган иде ул.

Шигырь Азнакайның элекке башлыгы Әнәс Исхаковка багышланган булса да, чишмәләргә табигать могҗизасы итеп карады Рөстәм, гасырлар агышы белән чагыштырып, аларга мәңгелек юрады. Халкына да мәңгелек сорады, сорап кына калмыйча, шул «мәңгелек»кә үзенең дә өлешен кертте.

Рөстәм Зәкуан туган ягында, туган халкы күңелендә рух чишмәләре калдырып китте. Ул чишмәләр әле бик озак еллар буена кешеләрнең күңеленә шифа биреп торачагына иманым камил.


**Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ**

*Фотолар Фәния ЗӘКУАНОВА архивыннан*

# *«Казан утлары» архивыннан*



*«Казан утлары» журналы редакциясендә. Сулдан уңга: Ренат Харис, Хатыйп Миңнегулов, Зиннур Хөснияр, Миркасыйм Госманов. 2004 ел.* *Фото Равил Фәйзуллин архивыннан.*



*«Казан утлары» журналының даими авторлары, Татарстан язучыларының X съезды делегатлары (сулдан уңга): Рашат Низами, Марсель Галиев, Камил Кәримов, Роберт Миңнуллин, Рәдиф Гаташ һәм Фәиз Зөлкарнәй. 1984 ел.* *Фото Камил Кәримов архивыннан.*



*Беренче рәттә (сулдан уңга): Рәдиф Гаташ, Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Рифат Җамал. Икенче рәттә (сулдан уңга): Шаһинур Мостафин, Рашат Низами, Мансур Вәлиев. «Казан утлары» журналы редакциясе, 1996 ел.* *Фото Рашат Низами архивыннан.*



*Җиңү бәйрәме алдыннан. Беренче рәттә (сулдан уңга): Мөршидә ханым (Сибгат Хәкимнең җәмәгате), Сибгат Хәким, Габдрахман Минский, Риза Ишморат, Афзал Шамов, Госман Бакир, Гомәр Бәширов, Гариф Галиев, Тихон Журавлёв. Икенче рәттә (сулдан уңга): Атилла Расих, Мөхәммәт Садри, Геннадий Паушкин, Сафа Сабиров, Юрий Белостоцкий, Әхмәт Исхак, Әмирхан Еники, Кояш Тимбикова, Лирон Хәмидуллин. Өченче рәттә (сулдан уңга): Мәхмүт Хөсәен, Сәет Шәкүров, Мәгъсүм Насыйбуллин, Сара Садыйкова, Габдулла Шәрәфи, Нәби Дәүли, Мәҗит Рафиков, Габдулла Шамуков, Кави Латыйп, Резеда Вәлиева. Дүртенче рәттә (сулдан уңга): Нил Юзиев, Аяз Гыйләҗев, Туфан Миңнуллин, Әхмәт Рәшитов, Гариф Ахунов, Ләбибә Ихсанова, Рәйсә Ишморатова, Гөлшат Зәйнашева, Мәхмүт Хәсәнов. 7 май, 1980 ел. Фото Лирон Хәмидуллин архивыннан.*

# ХАТИРӘЛӘРНЕ ЯҢАРТУЧЫ ШИГЪРИЯТ

Узган гасырның талантлы шагыйре, прозаигы, драматургы, публицисты һәм тәнкыйтьчесе Фатих Кәрим кызы Ләйлә ханым катнашындагы бер әңгәмәне кайчандыр архивыма салып куйган идем. «Әтием турында» дип исемләнгән әлеге язмада шундый юллар бар: «Тукай, Такташ, Байрон, Горький, Маяковский, Пушкин, Лермонтов әсәрләрен үз иткән ул. Аларның әсәрләрен укудан тыш, кайбер өзекләрне күчереп тә ала торган булган».

Ләйлә ханымның әйтүенә караганда, Ф.Кәрим, төрмәдә утырганда, кайчак әсәрләренең авторы итеп алда саналган күренекле шәхесләр исемен язган, дөньядан киткән шагыйрьләргә тикшерүчеләр бәйләнә алмый дип уйлаган. Әгәр фронтовик шагыйрьнең әсәрләре үз вакытында дөнья күрмәсә, барланмаса, ачыкланмаса, яңадан аның исеме белән теркәлмәсә, кайсыдыр ничектер югалса… Бик озак еллардан соң гына табыла калса, галимнәрне, укучыларны «алдарга» да мөмкин булганнар лабаса! Нахак яла белән төрмәгә ябылган шагыйрь бу хакта уйламаган икән, димәк, тоткынлыктан бер чыгасына, яшисенә, иҗатының халыкка барып җитәсенә бик нык ышанган.

Әйе, Ф.Кәримнең поэзиясеннән дә, прозасыннан да, публицистикасыннан да тормыш дәрте, яшисе килү теләге бөркелеп тора. Иҗат шартлары начарланганнан начарлана барганда, әлеге хисләр тагын да көчәеп кенә китә анда. Ул, бу сыйфаты белән, әле яшь, әле оптимизмын тамчы да югалтмаган Тукайны хәтергә китерә. Икенче яктан, аның исемен ишеттеңме, искереп, таушалып беткән букчасындагы лекцияләре янында китапларын, кулъязмаларын саклаган укытучыбыз Зәет Мәҗитов искә төшә. Башкача була да алмый. Әдәбиятны, бигрәк тә шигъриятне бик нечкә аңлаган Зәет ага Ф.Кәрим иҗатына шулкадәр мөкиббән иде ки, аның хакында, башын мәгънәле кага-кага, нечкә зәгыйфь бармаклары белән тоткан тәмәке төпчеген бәрәкәтле суыра-суыра, сәгатьләр буе сөйли ала иде. Фронтовик шагыйрьгә фанат дәрәҗәсендә гашыйк һәм үзе дә талантлы каләм иясе булган мөгаллим аның мирасын өйрәнүгә бөтен гомерен багышлады. Зәет аганың үз әсәрләренә дә Ф.Кәрим йогынтысы сизелерлек иде.

Ф.Кәрим, Тукай кебек үк, көрәш рухына күмелгән чор, моң-кайгылары күңел төпкелләренә яшеренгән, әмма җай белән, тышка да атылып чыккан, әйдаман шәхесләргә зур ихтыяҗ кичергән халык баласы. Юкка гына ул 1939 елгы куен дәфтәренә:

*Мин Тукайдан үрнәк алам, дисең,*
*Бу түбәнлек түгел, һич түгел.*
*Чөнки Тукай халык моңнарының*
*Бакчасында тибрәп үскән гөл, –*

дип язмаган. Бу фикер шагыйрьнең 1940 елда иҗат кыйбласын ачыклап иҗат иткән «Берәүгә» шигырендә яңадан да кабатлана.

Чыннан да, Тукай белән Фатих Кәрим поэзиясе халык авыз иҗатына меңнәрчә җепләр белән бәйләнгән. Икесендә дә кеше хәсрәтенә, татарның уй-хыялларына урын җитәрлек бирелгән, ата-ананың балага бәйле өметләре дә, милләтнең бәхетле тормышка омтылышы да, һәрберсе алдына шул юнәлештәге хәрәкәттә калыккан каршылыклар да сурәтләнә.

Фатих Кәрим, иң беренче чиратта, Тукай һәм Такташ әдәби мәктәбен уза, алар язганнар аша татар шигъриятенең бөтен мөмкинлекләренә төшенә, ирешкән уңышларын кабул итә. Ул поэтик иҗекләре бер-берсенекеннән аерылыбрак торган сүз гигантларының иҗат алымнарын гармоник үрүгә ирешә, нәкъ менә шуңа күрә шигъриятенә строфа һәм әдәби алымнар байлыгы хас.

Ф.Кәрим чор модасына ияреп тә, сугыш чоры таләбен үтәп тә, бөек поэзия тудырганга да, алман телен өйрәнә. Ул, димәк, әлеге әдәбият белән оригиналда танышырга тели. Ф.Кәрим Байрон, Лермонтов шигырьләрен һәм хәтта бөтенләй

башка төрле иҗатларны да үз итә, әмма каләм иясенең язу алымы, нигездә, классик шигърият кысаларында үсә-камилләшә.

Элегрәк поэзия мэтрлары сыйфатында, заман тәэсиренә бирелеп, яңа төр әдәбият төзергә керешүчеләрне атаса да, иҗат принципларын ныклап ачыклагач, Ф.Кәрим, Тукай кебек, гасырлык традицияләргә таянып танылган талантлар алдында баш ия башлый. Адәм хатадан хали түгеллек хактыр. Ф.Кәрим дә, вульгар социологизм белән чирләп алганда, яраткан шагыйрьләре иҗатына ревизия ясый. Әйтик, әдәбият кешене пролетар интернационализм рухында, көрәшче, шат күңелле, иҗтимагый тормыш белән яшәүне алга куйган шәхес итеп тәрбияләргә тиеш дип санаганга, аларның язганнарын шул яссылыкта һәм дингә мөнәсәбәттә бәяли. Мәсәлән, «Балалар әдәбияты турында»гы мәкаләсендә, Фәрит Ибраһимовка «тибеп үтә»: «... балаларга җәйге таңны ничек тасвир итә, шул матурлык эченә үзенең дини агуын ничек салып, ничек бирергә тырыша:

*Таң һавасын ярып, өзелеп-өзелеп*
*Яңрый әкрен генә моң азан;*
*Нечкәртәләр моңнар күңелләрне,*
*Үткәрәләр башны дөньядан».*

Татар әдәбиятында Ф.Ибраһимовныкы кебек таңны тасвирлаган йөзләгән гүзәл мисаллар бар. *«Тәрәзәгә төшә таң шәүләсе, / Җил ышкылып үтә өйләргә»*, – дип яза Ф.Кәрим («Тавышлы таң»). Ә Тукайда соң, Тукайда! Анда да бар аның гаять матур үрнәге:

*Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата;*
*Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата.*

*Бер-бер артлы юк булып, күкләрдә йолдызлар сүнә;*
*Таң җиле куйды исеп, яфраклар аз-аз селкенә.*
(«Җәйге таң хатирәсе»)

Ф.Кәрим әлеге дә баягы 1934 елның 25-29 июлендә Татарстан язучыларының I съездында ясаган «Татар балалар әдәбияты» докладында, бөек шагыйребезгә мөнәсәбәтле, түбәндәге юлларны сөйли: «Габдулла Тукайның балалар өчен язылган әсәрләренең бер өлешен без хәзерге көндә дә файдаланабыз. Ләкин икенче бер өлеше хәзерге көндә шундый ук зарарлы әсәрләрдән тора. Без инде аның:

*Бәйрәм җитсә, минем дә исемә төшә*
*Корбан ите, төрле тәмле аш өстенә,*
*Гает укып көлә-көлә кайткан чагым –*

кебек әсәрләрен һичбер төрле балаларга тәкъдим итә алмыйбыз».

1938-1939 елларда Ф.Кәримнең Г.Тукай иҗатына карашы тамырдан үзгәрә. Моны алдарак телгә алынган һәм үзе белән йөрткән дәфтәрдәге дүртьюллыкның ни өчен нәкъ менә шул вакытта иҗат ителүе дә күрсәтеп тора.

Ф.Кәримне, Тукай кебек үк, балалар өчен язылган әсәрләрнең эчтәлек-формасы, яшь үзенчәлекләрен исәпкә алуы, тәрбияви проблемаларны ничек чишүе борчый. Ул шулай ук аларга атап басылган китапларның ниндилеге турында да уйлана: «Телнең саф, аңлаешлы булуы аеруча балалар әдәбиятында зур урын тота.

...Балалар әдәбиятын басып чыгару турында берничә сүз: ВКП(б) Үзәк Комитетының балалар китабын яхшы кәгазьдә, яхшы оформление белән басып чыгару турында ныклы күрсәтүләре булуына һәм: «Балалар нәшрияты балалар китабын басып чыгару эшенә иң яхшы язучы көчләрне (балалар өчен язучыларны гына түгел), художникларны, педагогларны һәм пионер хәрәкәте эшчеләрен тартырга тиешләр» (ВКП(б) ҮК карарыннан) дигән күрсәтүе булуга карамастан, Татгосиздат бу юлда күренекле борылыш ясый алганы юк әле. Балалар китабы һаман начар кәгазьдә, начар

оформлениедә һәм соңга калып чыгуда дәвам итә. Инде моңа чик куелырга вакыт».

Тукайның да, Ф.Кәримнең дә чорлар узгач та популярлыгын югалтмый торган шигырьләре-поэмалары бар. Шуларның берише, һичшиксез, балалар әдәбиятына карый. Инде пионерлар оешмасы да таралды, әмма заманыбыз укучылары һаман да «Пионерка Гөлчәчәккә хат»ны яратып укый. Сәнгатьле сөйләнгән «Кыңгыраулы яшел гармун», «Гармунчы аю белән җырчы маймыл» әсәрләре бүгенге бәйрәм-тамашаларны да бизи. Укытучы әнисенә ияреп мәктәпкә йөрүче бер кечкенә малайдан (хәзер инде ул танылган табиб) көн саен сөйләтәләр иде аны. Ул поэманың шушы җиренә җитүгә, бар кеше кычкырып көләргә тотына, тагын кабатла әле, кабатла, дип котырта:

*Маймыл, бармат шартлатып,*
*Урманны яңгыратып,*
*«Их-ма!» – ди итән,*
*... җырлый итән:*

Көлмәсләр иде дә, сабыйның сөйләшергә өйрәнгән вакыты – «к»ны әйтә алмый, «т»га алмаштыра.

Әле бала чакта мандолинада да бик матур уйный торган әнием ничәдер җыр өйрәтте. Шуның берсе – Г.Тукайдан «Бала белән күбәләк». Кечкенәләргә тамаша рәвешендә башкарырга җиңел булганга сайлагандыр, күрәсең. Икенчесе бөтен кешегә дә таныштырмы-юкмы, белмим. Инде бихисап җырлар онытылып бетсә дә, көн саен булмаса да, ай саен хәтергә килә ул минем. Кызны да, оныкны да йоклаткан җырларымның берсе – шул. Үсә төшкәч, без аны Таңгөлем белән йөзләрчә тапкыр бергәләп җырладык. Шул җырга бик тиз йокыга киткән оныгымны алай ук яраттыра алмадым кебек…

Озак кайта алмыйча торганда, әнине сагынсам, ягымлы елмаеп, яңгыравык тавышы белән шул җырны җырлаган көннәрен дә искә алам. Үземнең күбәләк булып биеп торганымны да. Тукайныкын искә алып та язылган кебегрәк әлеге җырның авторы Фатих Кәрим икәнлеккә мин ул вакытта игътибар да бирмәгән идем. Бүгенге яшь әниләр ул җырны беләме, балаларына җырлый микән? Минем менә әле дә тел очымда бөтерелә:

*Кызым, синең эшең бик күп:*
*Бакчага барасың да*
*Күбәләк куып йөрисең*
*Чәчәкләр арасында.*

*Чәчәккә кунган күбәләк*
*Күзен йомып утырмый,*
*Канат җәеп очып китә,*
*Еласаң да, тоттырмый.*

*Кума, кызым, күбәләкне,*
*Бакчабызда йөрсен ул,*
*Кунсын йомшак чәчләреңә,*
*Бантик булып торсын ул.*

Мин аның, яңа, читрәк мотивлар өстәлгәнгә булса кирәк, җырлардан төшеп калучан соңгы строфасына да юлыктым. Тукайның кайбер әсәрләренә охшаш икән әлеге шигырь:

*Сагынырсың күбәләкне,*
*Җил-яңгырлы көз җиткәч...*
*Язгы таң кебек ягымлы*
*Иркә яшьлегең үткәч.*

Тукайны XX гасыр башын иң тулы чагылдырган каләм иясе, дип атыйлар. Баксаң, С.Хәким шул ук фикерне Фатих Кәрим турында әйткән икән: «Дөнья хәлләре кискенләшкән саен, нигәдер Фатих Кәрим кебек кешеләр искә төшә. Ә бит Фатих Кәрим – Бөек Ватан сугышы чоры шагыйре. Бүгенге дөнья белән узган сугышның арасы нигә шулай якыная? Ике кырыс чор. Татар совет поэзиясендә шул чорны Фатих Кәримнән дә тулырак чагылдырган башка бер шагыйрь дә юк».

**Рифә РАХМАН**

# ТАШ КЫЯЛАРГА ЯЗЫЛГАН ТОРМЫШ ҖЫРЫ

## ФӘРИТ ЙОСЫПОВКА 80 ЯШЬ



Фәрит Йосыф улы Йосыпов кебек шәхесләр турында сөйләгәндә: «Алар туган халкы, милләте өчен яши һәм эшли», – дип әйтәләр.

Татар тел белеменең күптөрле тармакларында, этнография, халык мәгарифе, педагогика һәм методика фәннәре өлкәләрендә бүген дә киң кырлы фәнни эшчәнлек алып баручы галим, дүрт йөздән артык фәнни хезмәт, балалар бакчалары, урта мәктәпләр өчен күпсанлы программалар, дәреслекләр, уку әсбаплары авторы, филология фәннәре докторы, профессор Фәрит Йосыповның исеме тел белеме өлкәсендә эшләүче галимнәргә генә түгел, бәлки укытучыларга, укучыларга һәм ата-аналарга да яхшы таныш. Шулай да ул, иң беренче чиратта, тел белгече, әлеге өлкәнең гыйлемле профессоры, талантлы диалектолог, бу фәнне төрки телләр арасында беренчеләрдән булып яңа баскычка күтәрүче, шушы өлкәдә бөтенләй яңа бер юнәлеш ачып җибәргән галим санала.

Фәрит Йосыпов 1939 елның 15 маенда Казан артының бай тарихлы, елъязмаларда һәм халык санын алу кенәгәләрендә «Алат юлы», «Гәреч юлы» дип аталып йөртелгән төбәктә – хәзерге Татарстан Республикасының Яшел Үзән, Биектау районнары чигендә урнашкан Олы Карауҗа авылында туып үсә. Авыл халкы тарафыннан иң мәртәбәле һәм абруйлы кешеләрнең берсе буларак искә алынучы этиләре Йосыф ага сугышта батырларча һәлак була. Берсеннән-берсе кечкенә сабыйлары белән тол калган әниләре Асия апа аларны, тәрбияләп, олы тормыш юлына бастыра.

Булачак галимнең язмышына Камали бабасы зур йогынты ясый. Чөнки әйләнә-тирә авылларда иң өлкән яшьтә булган бу ил агасы буыннардан-буыннарга тапшырылып килгән тарихи вакыйгаларны яхшы хәтерли, еш искә ала һәм алар турында бәләкәй Фәриткә дә сөйли торган була. Өлкән буын тарихчы һәм этнографлар да Камали агай янында еш булганнар һәм аннан күпсанлы риваятьләр язып алганнар.

Туган төбәгенең үзенчәлекле тарихы белән кызыксыну Фәрит Йосыповны Казан дәүләт университетына алып килә. Биредә ул татар теле галимнәренең күбесе өчен остаз булган Латыйф Җәләйнең татар диалектологиясе, татар теленең тарихи грамматикасы буенча лекцияләрен йотлыгып тыңлый. Шул елларда ук яшь студент һәм атаклы галим арасында бик җылы мөнәсәбәтләр урнаша.

Икенче курста укыганда, Фәрит Йосыпов танылган галим Диләрә Тумашева җитәкчелегендә Себер татарларының телен өйрәнүгә багышланган фәнни экспедициядә катнаша. Утыз ел үткәннән соң, танылган галим буларак, ул бу юлларны кабат уза.

Диплом эшен яшь егеткә, үзе хыялланганча, диалектология буенча язарга насыйп булмый. Фәнни җитәкчесе Әнвәр Әфләтүнов аның алдына Сталин репрессиясенең аяусыз корбаны – күренекле тел белгече һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Шәрәфнең фәнни мирасын барлау, аның архивын эзләп табып өйрәнү бурычын куя. Мәшһүр шәхеснең намуслы исеме, шул рәвешле, Казан университетының гади генә бер студенты тарафыннан татар халкына кире кайтарыла.

Университетны тәмамлагач, булачак галим берничә ел Кама Тамагында чыга торган

«Кызыл байрак» газетасының җаваплы сәркатибе вазифасын башкара, бер үк вакытта Татарстан радиосы һәм телевидениесе белән хезмәттәшлек итә. 1962 елда аны СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият, тарих институтының фәнни хезмәткәре итеп кабул итәләр. Шул рәвешле, язмыш аны кабаттан остазы Латыйф Җәләй эшләгән җиргә кайтара. Биредә ул Мирфатыйх Зәкиев, Диләрә Тумашева, Ләйлә Мәхмүтова кебек атаклы галимнәр белән бергә 1969 елда Мәскәүдә рус телендә дөнья күргән академик «Хәзерге татар әдәби теле» хезмәтен язуда катнаша.

1964 елның көзендә Фәрит Йосыповка Көньяк Урал һәм Урал арты территориясендә таралган татар сөйләшләрен фәнни яктан өйрәнү эше тапшырыла. Шушы мизгелдән башлап диалектологның бөтен тормышы халык арасында, җанлы сөйләш үрнәкләрен туплауга багышланган фәнни экспедицияләрдә үтә. Соңыннан тупланган тел материаллары җентекләп эшкәртелә һәм, нәтиҗә буларак, татар диалект теленең тулы бер системасы төзелә. Әлеге фәнни проблема татар һәм төрки телләр диалектологиясе өлкәсендә беренчеләрдән булып татар галиме Фәрит Йосыпов тарафыннан куела һәм уңышлы рәвештә хәл ителә. Аны хәл итүне галим Көньяк Урал һәм Урал артының урманлы-далалы киңлекләрендә чәчелеп урнашкан бихисап татар авылларының тел үзенчәлекләрен өйрәнүдән башлый һәм фәндә моңа кадәр билгеле булмаган эчкен, сафакүл, нагайбәк татарлары дип аталган этник төркемнәрне ача.

Дүрт ел дәвам иткән киеренке фәнни-тикшеренү эшләре кандидатлык диссертациясен яклау белән тәмамлана. Шул чорда иҗат иткән башка яшь диалектологлар белән бергәләп, Фәрит Йосыпов фәнгә зур яңалык алып килә – диалект һәм сөйләшләрне географик лингвистика (тел географиясе) алымы белән өйрәнүне башлап җибәрә. Бу ысул тел күренешләрен шартлы билгеләр белән картага төшереп, аның таралыш чикләрен төгәл билгеләргә ярдәм итә.

Алга таба галим теленең мөстәкыйль диалектлары, сөйләшләре формалашуның тарихи этапларын ачыклый һәм һәр сөйләшне аерым мөстәкыйль тел статусы югарылыгы дәрәҗәсендә тасвирлый.

Фәрит Йосыповның төрки телләр диалектологиясенә керткән яңалыгына килгәндә, ул барлык диалект-сөйләшләр өчен хас күптөрле вариантлылыкны, нинди генә кыйммәткә ия булуына карамастан, бер тәртип бөтенлеген (систематика) тәшкил итә торган вак системалар төзелеше буларак карарга тәкъдим итә. Галим кулланган әлеге методика иксез-чиксез киңлекләрдә таралган татар теленең территориаль үзенчәлекләрен гомум милли тел кысаларында карарга, аны барыбыз өчен дә уртак туган телнең бер варианты итеп санарга мөмкинлек бирә.

Студент вакытында остазы Диләрә Тумашева җитәкчелегендә себер татарларының телен өйрәнү максатында Себергә сәяхәте галим күңелендә гомер буе гүзәл бер хатирә булып саклана. Әлеге уңайдан аның тарафыннан төзелә башланган «Себер татарлары халык әдәбияты антологиясе»н телгә алып китми мөмкин түгел (бүгенге көндә инде дүрт томы дөнья күрде). Беренче томда тобол-иртыш татарлары халык әдәбияты жанрларыннан дастаннар, мөнәҗәтләр, бәетләр урын ала. Икенче том элекке заманнарда халык арасында аеруча популяр булган йомак-масал жанрына багышлана. Өченче томда хикәят (халык хикәяләре) жанрына киң урын бирелә. Галим фикеренчә, килеп чыгышы буенча борынгы һинд, фарсы әдәбиятларына барып тоташкан әлеге жанр себер татарларына Ислам дине белән бергә килеп керә. Бу томда шулай ук күптөрле риваятьләр, борынгы мәҗүсилек чорында халыкның дөньяны танып белү барышында туган мифларга да зур урын бирелә. Дүртенче том музыкаль мирас әсәрләренә багышлана. Биредә себер татарларының музыкаль жанрларга караган 400 гә якын әсәре нота язмалары белән тәкъдим ителә.

Фәрит Йосыпов – милли мәгариф үсешенә дә зур өлеш керткән шәхесләрнең берсе. Кандидатлык диссертациясен уңышлы яклаганнан соң, Алабуга педагогия институты ректоры Тәлгат Галиуллин яшь белгечне чит телләр факультетының деканы вазифасына чакыра. Биредә аның алдына фәнни дәрәҗәле бер генә хезмәткәре дә булмаган факультетны тиз арада шул ук институтны тәмамлап чыккан фәнни кадрлар белән тәэмин итү бурычы куела. 1970-1980 елларда факультет Россиядәге бу төр институтлар арасында иң абруйлыларның берсенә әверелә.

Галимнең әлеге өлкәдә туплаган тәҗрибәсе алга таба илләр арасындагы тимер

пәрдәләр ачылгач кирәк була. Узган гасырның 90 нчы еллар башында Татарстан белән рәсми мөнәсәбәтләре булмаган Төркия үз югары уку йортларына татар егет һәм кызларын алырга теләк белдерә. Төркиянең элеккеге президенты Тургут Озал киңәшчесе Казанда милли мәктәпләр институтын җитәкли башлаган Фәрит Йосыпов белән бер әңгәмәсендә студентлар алмашу эшен башлап җибәрергә тәкъдим итә. Озак та үтми, галимнең Төркиягә сәфәре вакытында килешүгә кул куела һәм 1992 елның 29 августында сиксәннән артык татар баласы Казаннан Истанбулга юл тота.

Төркия җәмәгатьчелеге Фәрит Йосыповның тугандаш халыкларны бер-берсе белән якынайтудагы хезмәтен югары бәяли. Төркия зыялылар җәмгыятенең («Aydınlar Ocağı») элеккеге президенты, «Төркия» газетасы шурасының җитәкчесе, Истанбул университеты профессоры Нәүзәт Ялчынташ галимнең Төркиядә башкарган эшләрен хәтта Садри Максуди, Гаяз Исхакыйларның фидакарь эшчәнлеге белән бер дәрәҗәгә куя. Төркиянең төрле фондлары үзләренең утырышларында татар галименең катнашуын зур шәрәф итеп саный.

Фәрит Йосыповның тормышында Милли мәктәпләр институтында эшләү чоры аерым урын алып тора. 1984 елда аны Алабугадан РСФСР Милли мәктәпләр институтының Татарстан филиалы директоры итеп күчерәләр. Шул вакыттан башлап 90 нчы еллар уртасына кадәр республиканың барлык методик мөмкинлекләрен үз тирәсенә туплаган әлеге оешма җитәкчелегендә татар теле һәм әдәбияты буенча яңа эчтәлектәге программалар төзелә, күпсанлы дәреслекләр, хрестоматияләр, уку-укыту әсбаплары языла.

Шуның белән бергә бу чорда Фәрит Йосыпов күпсанлы җәмәгать эшләре дә башкара. Аерым алганда, «Мәгариф» журналының редколлегия, Мәгариф министрлыгы каршындагы укыту-методик советы әгъзасы булып тора. Ун елдан артык Казан шәһәре татар теле укытучылары семинарына фәнни яктан җитәкчелек итә.

80 нче еллар уртасында кырым татарларының проблемаларын өйрәнәчәк дәүләт комиссиясе төзелә. Аның күпсанлы комитетлары арасында халык мәгарифе мәсьәләләре белән шөгыльләнүче төркемнең җитәкчесе итеп татар галиме Фәрит Йосыпов билгеләнә. Ул, иң беренче эш итеп, кырым татарлары яши торган төбәкләрне ачыклый. Алар – Казакъстан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан республикалары. Баштарак кырым татарлары Мәскәү тарафыннан билгеләнгән Казан татары белән аралашудан катгый рәвештә баш тарталар. Әмма берникадәр вакыт үткәч, галимнең тирән эрудициясе, бу халыкның ачы язмышын үзенеке буларак кабул итүе гаделсезлектән таш булып каткан йөрәкләрне дә эретә. Озак та үтми, кырым-татар балалары мәктәпләрдә туган телләрен өйрәнә башлый. Ташкент педагогия институтында кайчандыр бу халык өчен эшләп килгән тел-әдәбият бүлеге яңадан аякка бастырыла, һәм ул кырым-татар яшьләрен кабул итү эшенә керешә.

Мәгариф өлкәсендәге хезмәтләре өчен профессор Фәрит Йосыпов «Фидакарь хезмәт өчен» һәм Д.М.Ушинский исемендәге медальләр белән бүләкләнә. Ул – Россиянең мәгариф отличнигы, Бөтенроссия укытучылар съезды делегаты, Россия тюркологлар комитеты, Шәрыкны өйрәнү ассоциациясе, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклау советлары әгъзасы булып тора. Төрки телләр, педагогика, методика өлкәсендәге нәтиҗәле эшчәнлеге өчен ул, Англиядәге автобиографик үзәкнең карары нигезендә, XX гасырның иң атаклы кешеләренең берсе итеп танылды.

80 яшен тутырып килүче остазыбыз Фәрит Йосыф улы Йосыпов бүгенге көндә дә актив иҗади һәм фәнни эзләнүләрен дәвам итә, яңа проектлар өстендә эш алып бара. Шуның белән ул үзенең хезмәттәшләренә һәм шәкертләренә үрнәк булып тора. Форсаттан файдаланып, без аны гомер бәйрәме белән чын күңелебездән тәбрик итәбез. Аңа алдагы тормышында ныклы сәламәтлек, яңадан-яңа фәнни ачышлар телибез.

**Олег ХИСАМОВ, Бәхтияр МИҢНУЛЛИН, Рифат МИРХӘЕВ,**
*филология фәннәре кандидатлары*



*Диңгездә. 1960 нчы еллар.*



*Абыйсы Шәүкәт (Шәфигуллин) белән.*



*Туган ягында печән өсте.*




*Хатыны Эльмира, кызлары Раушания, Резеда белән. 1979 ел.*



*«Казан утлары» редакциясендә. Фаил Шәфигуллин икенче рәттә сулдан икенче. 1970 нче еллар башы.*



*Шәйхи Маннур янында.*



*Зәки Нури хозурында.*



*Остазы Нури Арсланны тыңлаганда.*



*«Чаян» журналы редакциясендә Мәгъсум Хуҗин белән бергә эшләгән еллар истәлеге.*

*Фотолар Эльмира Шәрифуллина архивыннан.*

# ХӘРБИЛӘРГӘ ДАН!

Татарстанның халык артисты Айдар Хафиз Казан театр училищесында укыган вакытта Г.Камал театрының музыка бүлеге җитәкчесе Рәис Сәфиуллин аны Сара Садыйкова белән таныштыра. Алтмышынчы елларда Бауман урамындагы Горький клубында Сара апаның танылган халык хоры эшли. Айдар Хафиз баянда оста уйнаганга, армиягә киткәнче үк, хорда эшләп өлгерә. Сара Садыйкова үзе җитәкләгән хорның аккомпаниаторын бик хөрмәт итә. Айдар Хафизны армиягә озатырга да килә. Хәрби хезмәткә китеп өч ай үтүгә, ул аңа «Солдатым» дигән җыр юллый. Җырның сүзләрен дә башта үзе язган була. Әмма төп текстны Мостафа Ногманнан язарга соравын искәртеп үтә. Озак та үтми, Мостафа Ногман сүзләренә тулы клавир Айдар Хафизга килеп ирешә. Совет гаскәрләренең Польшадагы группасы ансамбле әлеге җырны рус теленә тәрҗемә итеп башкара. Ансамбльнең солисты Светлана Левашова оркестрга кушылып җырлаган бу җыр солдатлар тарафыннан бик яратып кабул ителә. Сара Садыйкованың үз кулы белән язылган ул хатларны, клавирны Айдар Хафиз әле дә кадерләп саклый.

## Солдатым

Кыр казлары китте
Диңгез буйларына,
Кыр казлары китте тезелеп.
Син дә, бәгърем, киттең,
Бик ямансу иттең,
Мин озатып калдым өзелеп.

Карлы салкын кышта,
Торасыңдыр постта,
Уйлыйсыңдыр туган якларны,
Ә мин иртә-кич тә
Онытмыймын һич тә
Бергә йөргән матур чакларны.

Хатлар язам сиңа,
Сәлам юллыйм сиңа,
Таң жилләре тизрәк илтсеннәр.
Нык бул хезмәтеңдә,
Мәхәббәтең көн дә
Сине генә көтә, дисеннәр.

Айлар агылып үтәр,
Кайтыр көнең җитәр,
Тормышыбыз матур, илдә тын.
Көрешербез тиздән,
Бәхет китмәс бездән,
Зифа буйлы батыр солдатым!



*Сара Садыйкованың үз кулы белән язган «Солдатым» җырының ноталары. Декабрь, 1963 ел.*

# ФАТИХ КӘРИМНЕҢ МУЗЕЙ-ЙОРТЫ

Башкортстан Республикасы Бишбүләк районы Ает авылында шагыйрь Фатих Кәримгә багышланган музей Бөек Ватан сугышы башлануга 30 ел тулу уңаеннан, ягъни 1971 елның 19 июнендә ачылды.

Музейга нигез салучы – Ает урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Халык мәгарифе отличнигы Хәтирә Сәмигулла кызы Гыйззәтуллина. Аны оештыру эшендә укытучылар Мәрьям Саниева һәм Лотфый Гыйззәтуллин, партком секретаре Нәҗип Әхмәтшин, колхоз рәисе Барый Гафуров, журналист Лотфи Гаделов, рәссам Наил Ваһапов һәм балта остасы Мәхмүт Идрисовлар зур тырышлык куя. Музейны ачу тантанасында шагыйрьнең кызы Ләйлә Кәримова, танылган шагыйрь һәм драматург Әнгам Атнабаев, Татарстан һәм Уфадан килгән язучылар, дәүләт эшлеклеләре катнаша.

Шагыйрьнең туган авылында ачылган әлеге бина беренче көннәреннән үк яшь буынга патриотик тәрбия бирү үзәгенә әйләнә. Анда заманы өчен актуаль агитация эшләре, пионер һәм комсомол җыеннары да үткәрелгән.

Төрле елларда музейның җитәкчесе булып Хәтирә Гыйззәтуллина, Рәзимә Сәмигуллина, Сәймә Хәйруллина, Рәшидә Латыйпова, ә 1992-1995 елларда һәм 2004 елдан Рәйсә Хафизова эшли.

1996 елда Бәләбәй шәһәре һәм районында, ә 1999 елда Бишбүләк районында, Башкортстан Язучылар берлеге белән берлектә, Фатих Кәрим исемендәге премия булдырыла. 1999 елда, Фатих Кәримнең тууына 90 ел тулу уңаеннан, музейның яңа төзелгән бинасы ачыла. Шагыйрьнең кызы Ләйлә Кәримова һәм башка иҗат әһелләре белән тыгыз хезмәттәшлек нәтиҗәсендә, музейга Фатих Кәрим хатларының төп нөсхәләре, кулъязмалары, шәхси әйберләре, бик сирәк данәдә генә сакланып калган китаплары кабул ителә. Экспонатларның гомуми саны 500 данәгә җитә.

2007 елда музей бинасы янына Фатих Кәрим бюсты куелды. Аның авторы – Башкортстан Республикасының атказанган сынчы-монументалисты, Башкортстанның Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Хәниф Хәбибрахманов.

2011 елда музейда – Аетның мәшһүр кешеләренә, Фатих Кәрим премиясе лауреатларына, 2012 елда Башкортстан Республикасының күренекле дәүләт эшлеклесе Илдар Гыймаевка багышланган махсус тематик экспозицияләр дә булдырылды.

2016 елда музей җитәкчесе Рәйсә Хафизова Башкортстан Республикасы Башлыгы грантына ия булды һәм «Башкортстан Республикасы авыл мәдәният учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәре» дипломы белән бүләкләнде.

2018 елда Фатих Кәрим музее Башкортстан Республикасының иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениесе дип танылды һәм Башкортстан Республикасы Башлыгы грантына лаек булды.

Фатих Кәрим музеена Башкортстан, Татарстан республикаларыннан, Оренбург өлкәсеннән туристлар даими килә. Шулай ук Төрекмәнстан, Япония, Үзбәкстан дәүләтләреннән, Мәскәү, Пермь, Кемерово шәһәрләреннән дә килүчеләр бар. Биредә патриот шагыйрьнең иҗатын пропагандалау белән бергә, татар халкының традицион мәдәниятен саклау һәм үстерү буенча да зур эшләр башкарыла. Әлеге музейда шагыйрьнең бертуган абысы, шагыйрь Ярлы Кәрим (Габдулла Кәримов) хакында да материаллар белән танышырга мөмкин. Экскурсияләр вакытында аның сүзләренә язылган «Назлы гөлкәем» җырын аеруча яратып тыңлыйлар.

*Сәхифәне* **Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН** *алып бара.*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**ҮЗЕ**

## Автарит

Нур Әхмәдиевнең әтисенә туксан алты яшь тулган көннәр. Чатыр таудан ерак түгел генә Әсәй авылында гомер сөргән Гариф агадан Марсель Гали сорап куйган:

– Чатыр тауны ничә яшеңдә беренче мәртәбә күрдең, Гариф ага?

– Алты яшьләр булгандыр. Әти белән җигүле атта яныннан үтеп киттек.

– Ә тау башына беренче тапкыр кайчан мендең?

– Быел. Улым машинасында алып менде.

Марсель Гали нык гаҗәпләнүдән сүзен әйтә алмыйча тора:

– Ничек инде... Гариф ага... Туксан ел буена бер дә менмәдеңме?!

– Ул дәвердә Чатыр тауның хәзерге кебек автариты юк иде бит, – ди Гариф ага тыныч кына.

**К.ШӘЛЕ**

## Ике шагыйрь, бер шагыйрь...

Автобус эченнән чыккач, Әхмәт Гадел як-ягына карамаска тырышты – болай да таныйрга тиешләр... Чулманның паром килеп төртелә торган җирендә көтеп торабыз, дигәннәрие. Чемоданнар белән бәреп, көянтәләр белән төрткәләсәләр дә, төшкән җиреннән кузгалмады ул, автобус ишегенә ябышып тик басып торды: читкәрәк китсәң, гади халык арасына чумып буталуың бар, анда инде синең шагыйрь икәнлегеңә беркем дә ышанмас, җитмәсә, Мәхмүт Хөсәен эче чыккан портфелен дә тоттырып китте, ояты ни тора! Бар бит дөньяның каруннары, 60 ел буе шигырь яза, юньле сумкасы да юк. Әнә Риф Гатауллин – Фәннур Сафин шигырьләренең музыкаль редакторы гына булып исәпләнсә дә, кулындагы дипломаты германский, бәдрәфкә кергәндә дә үзеннән калдырмый.

Бөтен нәрсәгә җен ачуы чыкты Әхмәтнең. Кәефе тәмам кырылды. Язучылар төркеме ясап чыгасы калмаган. «Социалистик Татарстан» корреспонденты булып йөрүгә ни җитә! Бервакыт шулай, Биектау яшелчә базасын «өшкерергә» дип сәфәр чыгарга торганда, тәрәз турысына «Көмеш кылган җыры»ның сигнал данәсе төсле өр-яңа «Волга» килеп туктамасынмы! Шофёры гына түгел, Биектауның өч дәрәҗәле түрәсе дә килгән иде. Әхмәт җиленнән дер калтырап торалар:

– Әхмәт Гаязович, сезне каршы алырга килдек, – диләр.

Каян ишетеп алганнар диген?! Биектау белән Казан арасы Туфан Миңнуллин «Волга»сы белән дә атна үтмәле юл бит әле ул. Вәт ичмасам, биектаулылар! Норлат ит комбинатын, Актаныштагы кәнфит заводын, Питрәчнең сөт-май комбинатын язганда да шулай булды... Мондый кунакчыл хуҗаларга ничек итеп тел-теш тидерергә кирәк!

Ә менә алексеевскилар Кама ярына килеп алырга да иренгәннәр. Ничава, Әхмәт Гаделнең кем икәнен соң булса да белерсез әле сез!

Алар дүрт кеше: Әхмәт Гадел, Мәхмүт Хөсәен, Риф Гатауллин һәм... (хәер, дүртенчесен танырлык түгел, ул әле яңа автор), попутный машина көтә-көтә, Алексеевск ягына җәяүләп атлый тордылар. Берәр багана арасын үткән саен, Әхмәт борын яулыгы белән ботинка йөзенең тузанын сөртеп-сөртеп алгалады. Ниндидер бер миһербанлы шофёр Мәхмүт Хөсәеннең кул астына килеп туктады. Авызы-борыны җимерелсә дә, «УАЗ»игы «аягында» шәп басып тора. Ялындырып тормадылар, менеп тә утырдылар.

Әллә гомер буе ялгыз яшәгәнлектән, Мәхмүт Хөсәен тынлыкны бик өнәп бетерми. Ул шофёрны сөйләндерде.

– Ник буш кайтып киләсең?

– Нindидер писательләрне каршы алырга җибәргәннәр иде, тапмадым.

– Без бит инде ул писательләр! – диде Әхмәт, ярсуыннан теге борын яулыгы белән күзләрен сөртә-сөртә.

***

– Нинди әдәби очрашу, нинди кичәләр ди ул тагын?! – Колхоз рәисе шагыйрьләргә күтәрелеп карамаска тырышты, бары тик каурый сыман болыт кебек озынча аксыл кашларын гына җилфердәтеп утырды. – Уттай янып торган кыр уртасына бер тамчы яңгыр төшкәне юк. Ә сез күңел ачып, кәмит оештырып йөрмәкче буласыз. Әнә, күккә карагыз – җәй башыннан бирле бер генә болыт әсәре дә күренгәне юк.

Әхмәт бу рәисне ирексездән кызганып куйды, нindидер юату сүзе әйтәсе иде моңа.

– Минем бәхет судан, – диде Әхмәт, көр тавыш белән, – авыл җиренә аяк басуым була, артымнан яңгыр килеп җитә... Теләсәм, кәнишне.

– Да-ну! Юкны сөйләп тормасана!

– Менә, ышанмасагыз, Мәхмүт Хөсәеннән сорагыз, ул белә.

Рәиснең каурый сыман кашлары йөнтәс болытка әверелде, күзләреннән яңгыр тамчысыдай күз яшьләре бәреп чыкты.

– Әгәр бүген яңгыр яудырсаң, мин сине шәраб диңгезендә йөздерәм, хәтта диңгезнең үги кызын да тотып бирәм.

– Күпме яңгыр кирәк?

– 250 миллиметр җитәргә тиеш.

– Граммга әйләндергәч, әзрәк икән шул...

Ә кичен көләч күк йөзенең кашы җыерылды, язучылар чыгыш ясыйсы клуб өстен генә түгел, хәтта бөтен авылны болыт каплап алды. Шыбыр-шыбыр, чыпыр-чыпыр яңгыр ява башлады. Сукмакларның тотнагы бетте, аякланып йөрерлек түгел, колхоз ашханәсенең банкет залыннан фатир хуҗасының өенә хәтле дүртаякланып кайтырга туры килде... И сөенде халык. И сөенде... Күргән бер кешенең авызы җырылып кына тора.

Яңгыр иртә белән дә туктамаган иде әле. «Алга» колхозыннан «Волга» колхозына хәбәр килеп җитте.

– Алло! Бездә яңгыр кoя бит әле!

– Башка анекдотың юкмы? – диде «Волга» рәисе, скептикларча гына.

– Ышанмасаң, тыңла! – Һәм «Алга» рәисе телефон трубкасын ачык тәрәзәгә якын китерде. Анда – шыбыр-шыбыр, чыпыр-чыпыр, чаптыр-чоптыр яңгыр тавышы...

«Волга»лылар тынсыз калды.

– Вообщем, – диде «Алга»ныкы, – мин сиңа Татариядән килгән яңгыр яудыручы егетне җибәрәм, шартын китереп каршы ал. Яңгыр бушлай яумый ул...

– Аңлашылды, – диде «Волга»ныкы. – Өемдә бер ящик алып куйганым бар.

– Егет дигәнем шагыйрь кеше...

– Алайса, тагын бер-ике ящик өстәрмен.

Һәм шагыйрьләрне «Алга»дан «Волга»га китереп бушаттылар. Анда да яңгыр яудыргач, «Энгельс», «Татарстан» колхозлары да коры калмады... Ә бер атнадан бөтен район яңгырга кинәнде. Коепмы коя! Сукмаклар елгага әверелде, инешләр дәрья булды, карабодай басулары майсыз боткага әйләнде.

«Алга»ныкылар Әхмәтне көчкә эзләп таптылар.

– Зинһар өчен, туктат яңгырыңны, агып китәбез бит...

Алар, артык бәхәсләшеп тормыйча, Казан юлына чыктылар. Чулман аръягында яңгыр коеп калды...

*«Тынгысыз каләм». 1982 ел*

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу – безнең сәхифә!

*Бәләкәйләр*

# БӘЛӘКӘЙ ХАТЫЙП*

## Кадерле әти-әнием...

Шөкер Ходайга, рәхмәт әти-әниләремә, минем дә башка кешеләрнеке кебек, кендек каны тамган, тәпи йөреп киткән, буй үстергән туган төбәгем бар. Бүтәннәргә ничектер, әмма минем өчен ул бик тә газиз, кадерле һәм матур. Аның, артык биек булмаса да, таулары да, тигез басу-болыннары да, як-ягында урман-әрәмәләре дә, ике тарафтан агып килеп кушылган (аларны «Кече Ирнә», «Олы Ирнә» дип атыйлар) кечерәк кенә инешләре дә бар. Туган авылымның рәсми исеме – Ирнә буе Сармашы («Сармаш по Ирне»). Әмма аның чын, халык телендәге атамасы – Апач.

Кеше кайда гына тумасын, кайда гына гомер кичермәсен, ул үзенең тереклеге, барлыгы белән барыннан да элек әти-әнисенә бурычлы. Мин 1939 елның 12 маенда гаиләдә өченче бала булып якты дөньяга аваз салганмын. Әтием Йосыф Миңнегол улы (1909-1944) тумышы, яшәеше белән Апачтан – атаклы Исрай, аның атасы Батырша нәселеннән. Туган авылның гына түгел, гомумән, безнең якларның шактый кешесе шушы нәсел белән бәйле.

Колхозлар төзелгәч, әти, махсус курсларда укып, авыл хуҗалыгы техникасын үзләштерә. Ул вакытта «Чыбыклы МТС»ы дип йөртелгән оешманың тракторчысы, комбайнчысы, трактор бригадиры сыйфатында тирә-юньдәге күп кенә авылларда хезмәт куя. Мөгаен, тырышып эшләгәндер. 1938 елның ахырларында булса кирәк, Казанда республика алдынгылары җыелышында да катнаша. Шунда Чаллы ягының Хатыйп исемле бер кешесе белән якыннан танышып китә. Бераздан шул дусты хөрмәтенә миңа Хатыйп исеме дә бирелә. Әтине якыннан белүчеләр, ул бик көчле, чын ир-ат иде, дип сөйлиләр. Эшен дә эшләгән, бик оста итеп биегән дә, җырлаган да. Сугышның тәүге елларында аны, механизатор дип, бронь белән калдырып та торалар. Бары 1943 елның башында гына әтине фронтка җибәрәләр. Хатлары килә... Аларда ул гел безнең хәл-әхвәлләрне сораша. Үзе киткәч туган кызының күзләре, чәчләре нинди төстә булуы да аны кызыксындыра. Әти 1944 елның 24 июнендә Белоруссия якларында батырларча һәлак була. «Өстенә бомба төшеп, күмәр җире дә калмый» диелгән иде «әтҗәвке»сендә, ягъни үлеме турындагы рәсми кәгазьдә. Утыз биш яшендәге тап-таза ир, гомер уртасына да җитмичә, балаларын ятим, хатынын тол, әнисен улсыз калдырып һәлак була. Әтидән аерылып калганда дүртенче яшем белән генә барганга, аны бик ачык хәтерли алмыйм. Ничектер, ул миңа томан арасындагы кебек шәүләләнеп кенә ала. Мине ат сыртына утырткач, әбинең ачулануын бераз гына хәтерлим. Әти мине арка кочарга яраткан. Мөгаен, мин бу гадәткә нык күнеккәнмендер. Сугышка киткәндә, әнигә: «Хатыйп улым мине бик юксынмасын өчен, аны арка кочкаларсың инде», – дип тә әйткән. Берсеннән-берсе кечкенә өч бала белән калган (дүртенчесе – корсакта), бөтен тормыш йөген тарткан әнкәйнең, ай-һай, мине арка кочып йөрергә бик вакыты да калмагандыр.

---

* Хатыйп Миңнегуловның «Озын гомерем хатирәләре» (2018) китабыннан аерым өзекләр.

Безгә җан, гомер биргән әни безнең өчен ана гына түгел, ата да, патша-президент та, хезмәтче дә, төп таяныч-терәк тә – кыскасы, дөньяның тоткасы иде. Ул – Гайнелхәят Шәйхелислам кызы (1912-1999) – тумышы белән Апачтан утыз чакрым ераклыкта булган зур гына Сарайлы авылыннан (ул хәзер Сарман районына керә). Сарайлы – минем өчен, Апачтан кала, бик тә якын, кадерле төбәк. Мин биредә күп мәртәбәләр булдым. Сугыштан соңгы ач елларда бу авылда минем балачагым чагыштырмача тук булды. Кечкенә генә өйдә үзләре дә берничә, өстәвенә (аеруча җәй көннәрендә) – дистәләгән онык булуына карамастан, алар һәрчак якты күңелле була белделәр. Фәхрелбанат әби белән Шәйхелислам бабайның безгә каты итеп дәшүләрен, караңгы чырай күрсәтүләрен мин һич тә хәтерләмим. Алар безгә гел ярдәм итеп торды. Тукай яшьтәше булган бабайның Апачка килеп, йорт-кураларны төзәтүләре, әнигә «Гайнелхәят кызым» дип йомшак итеп эндәшүләре әле дә исемдә. Бабай скрипкада уйнарга да ярата иде. Ә аның әтисе Шәйгалләм заманында, скрипкада уйнап, Карамалы, Мөслим базарларында җыелган халыкны таң калдыра торган булган.

## Беренче укытучым

Миңа үз гомеремдә дүрт мәктәптә укырга, ике мәктәптә эшләргә, Казан университетында биш ел белем алырга һәм шунда ярты гасырдан артык мөгаллимлек кылырга туры килде. Шушы вакыт эчендә, мөгаен, йөзләп педагог миңа белем-тәрбия биргәндер. Мактанып әйтүем түгел: укытучыларымнан уңдым. Аларның һәрберсе күңел җылысын, инсани, әхлакый тәҗрибәсен, белем-мәгълүматын биреп, минем үсешкә, яшәешкә ярдәм итте. Әгәр дә мин тормышымда билгеле бер уңышларга ирешкәнмен икән, моның өчен иң беренче чиратта үземнең укытучыларыма бурычлы. Аларның инде һәммәсе дә диярлек гүр иясе. Урыннары оҗмахтадыр дип уйлыйм.

Мәктәптә миңа белем-тәрбия биргән мөгаллимнәр арасында берсе аеруча мөһим урынны били. Ул – беренче укытучым Зәкия апа Галиуллина.


Мин Апач башлангыч мәктәбенә 1946 елда укырга кердем. Сугыштан соңгы авыр, ярым ач еллар. Әти фронтта һәлак булган. Кечкенә генә дүрт баланы карау тулысы белән әнкәй өстендә. Ул елларда без кар беткәннән алып көзге салкыннарга кадәр күбрәк яланаяк йөри идек. Мәктәпкә аяк киеме белән барырга кирәк. Әнкәй миңа төсле чүпрәкләр белән бизәлгән чабата ясап бирде. (Бераздан үзем дә бу эшнең остасы булып киттем. Күршедәге урыс авылларына барып, чабата сатып йөрүемне әле дә хәтерлим.) Өстә әни үзе суккан киндердән тегелгән күлмәк-ыштан. Башта абыйдан калган озын «кузыруклы» фуражка. Киндер букча да бар. Мәктәпкә килгәч тә, минем бизәкле аяк киемемнән, «хатын-кыз чабатасы» кигән, дип, кызлар көлә башлады. Мин, гарьләнеп, аяк киемен салып ташладым. Шунда Зәкия апа, каяндыр табып, миңа резин галош бирде.

Без сыйныфта ике дистәләп бала укыдык. Дәресләр авылдан киткән Игнат дәдәйнең йортында бара иде. Миче бар. Салкын вакытларда мич башына да менеп җылынып төшә идек. Ә Зәкия апабыз, гәрчә куллары күшексә дә, мич янына бик бармады. Аның кечкенә кызлары – Гөлсинә белән Нурсинә күп вакыт безнең белән мәктәптә иде, мөгаен, өйдә калдырырга мөмкинлек булмагандыр. Сабый Нурсинәгә бер яшь тә юк, Зәкия апа, бездән читенсенеп кенә, мич артына кереп, аны имезеп тә ала иде. Ул вакытларда бик фәкыйрь яшәдек. Ипине айлар буе күргән юк. Зәкия апаның шул кыен вакытларда аз-маз ипи кисәкләре бирүе дә күңелгә кереп калган. Ачлы-туклы булсак та, гаять мохтаҗлыкта яшәсәк тә, без тырышып укыдык. Кәгазь, кара, каләм булмаганда, каурый каләмнәрне корымга манып, иске-москы китап, дәфтәр битләренә яза идек. Әле күптән түгел генә, туган йортка кайткач, чормадан икенче сыйныфта язган дәфтәрем килеп чыкты. Хәзер минем почерк начар. Ә ул елларда ярыйсы гына язылган икән. Дәфтәремә кызыклы мәкальләр дә теркәлгән:

«Кешегә кое казыма – үзең төшәрсең», «Ялган сөйләсәң – тотылырсың, дөрес сөйләсәң – котылырсың», «Ялкауга йомыш кушсаң – ул сиңа акыл бирер» һәм башкалар. Шул елларда безгә гыйбрәтле сабаклар биргәннәр.

## Бер еллык каникул

Апачта башлангыч мәктәптә укыганнан соң, 1953 елда Пидәр җидееллык мәктәбен төгәлләдем. Алга таба укыйсы килә, әмма мәктәпләр ерак, торып укырга матди мөмкинлек юк. Укуны дәвам итәргә теләгем бик көчле булса да, мин Апачта калырга мәҗбүр булдым, колхозда эшли башладым. Бригадир нинди эшкә кушса, шунда йөгерәсең.



*Абыйсы Миргалим белән. Ленинабад. 1957 ел.*

Сугыштан соңгы елларда колхозда атлар бик аз иде. Алар өлкәнрәкләргә эләгә. Ә безнең кебек үсмерләргә үгез кала, аны җигеп йөрү – үзе мең бәла: кире, тукта дигәндә бара, куалаганда туктый. Бервакыт басуда чәчү вакытында йөге белән симәнә бодаен аударуын хәтерлим. Шулвакыт үземә бригадирдан бик каты эләкте. Җидене бетергәннән соңгы бер еллык каникулда мин ныклап ат өстендә – җайдак йөрергә дә өйрәндем (әлбәттә, бернинди ияр-өзәңгесез). Хәтта Сабан туенда чабышта да катнаштым. Әмма бу шөгылемне берничә елдан тәмам ташладым. Унны тәмамлаган елны ниндидер бәйрәм вакытында мин яңа гына өйрәтелгән тайда урамнан бик җилдертеп бара идем. Капка астыннан кинәт кенә бер эт чыгуга, ат, өркеп, янга ыргылды. Мин исә мәтәлеп төштем. Янәшәдә генә бүрәнәдә утырган кызлар рәхәтләнеп көлде. Мин бик гарьләндем. Өстәвенә кабыргаларым да шактый авыртып йөрде. Шуннан атта бик сирәк йөрдем.

## Кәшер юлларын таптап...

Җидене тәмамлаганнан соң, бөтен сезоннарын үз эченә алган мәҗбүри каникулым бер елга сузылды. Әмма бу вакытта колхозда эшләү дә, «егет булып йөрү» дә уку дәртен баса алмады. Ниһаять, Сарман районы Иске Кәшер мәктәбендә укуымны дәвам итәргә булдым. Әни дә бу фикерне хуплады. Бердән, бу авыл безгә күптәннән таныш, Сарайлыга әбиләргә барганда-кайтканда, Иске Кәшер аркылы йөрелде. Икенчедән, әнинең туган авылыннан ерак түгел: биш кенә чакрым. Кыен хәлләрдә әби-бабайларга таянырга мөмкин. Өченчедән, бик сирәк кенә булса да, Апачтан Кәшергә барып укучылар да очрый. Шулай итеп тәвәккәлләдем.

Урта мәктәптә белем алган елларым, Кәшергә бару-кайтулар, анда яшәү минем өчен үзенә күрә бер тормыш университеты да булды. Әйткәнемчә, ара шактый ерак: Апач белән Кәшер арасы егерме биш чакрым. Калын-калын ике урманны үтәсе бар. Атна саен кайтып киләсе килә. Кайтышлый еш кына төнгә калына. Күбрәк үзем генә, ялгыз йөрдем. Берничә мәртәбә бүреләргә дә очрадым. Шундый вакыйгалардан аеруча берсе хәтердә уелып калган. Тугызынчы сыйныфта укыган чак. Көз көне (октябрь ае булса кирәк), аякта чабата, аркада биштәр (капчык). Йөгерә-йөгерә алга барам. Караңгы төшеп килә. Бер урманны узып, икенчесенең кырыена җиттем. Юлның уң ягында берничә рәт агач, аннан – басу-кыр. Икенче тарафта – урман. Кызу-кызу барган чакта, миннән берничә генә метр ераклыкта, уңда – бүре. Таза,

елык-елык килеп тора. Карашы бик усал күренмәде. Нишләргә? Шулвакыт арттарак, урман тарафында, чыбык сынган тавыш килде. Борылып караган идем – янә бүре. Нишләргә? Өнсез калдым. Әнкәй, әби өйрәткән, үзем белгән догаларымны укый башладым. Йөгереп качып та булмый. Бүреләрнең гаять тиз йөгерү-чабуын һәркем белә. Икесе дә әлегә тик утыра. Менә каршыдарак кына торган бүре янәшәсеннән дә узып киттем. Адымнарны тизләттем. Бераздан йөгерә башладым. Борылып караган идем, ике бүре дә урманга кереп китте. Явызлык-ерткычлыклары белән даннары чыкса да, рәхмәт үзләренә: миңа тимәделәр; бәлкем, бу арык, ябык малайны ашаудан ни файда дип уйлаганнардыр. (Борынгы төрки бабаларыбызның бүрене тотем итеп алуы, изгеләштерүе, мөгаен, юкка гына түгелдер.) Мин шактый калын урманны караңгыда бик тиз йөгереп уздым. Аннан инде тауларны төшкәч – туган авыл. Өйдәгеләр көтеп торган. Әнкәй кайнар бәрәңгеләрне алга куйды. Катык белән аларны тәмләп ашадым. Шунда әнкәй: «Нәрсә булды, улым, чигәңдә ак чәчләр күренә», – диде. Мин инде: «Бернәрсә дә булмады», – дип кенә әйттем. Бүреләр белән очрашуны сөйләсәм, мәктәпкә кабат укырга җибәрмәс дип курыктым.



## Кыек атып, туры тидерү...

Сигезенче сыйныф ахырларында (мөгаен, тиешенчә тукланмаудан, витамин җитмәүдән) минем күз күреме начарланыбрак китте. «Военное дело»да мылтыктан ату да каралган. Ә мин мишеньне юньләп күрмим дә (ул вакытта әле күзлек юк). «Военрук» мөгаллимебез фронтовик Салих абый (без аны «Маликов абый» дип кенә йөртә идек), башка фәннәрдән әйбәт укуны исәпкә алып, үз предметыннан миңа чирек саен югары билге чыгарып килде. Шулай беркөнне япанга атарга чыктык. Алга мишеньнәр куелды. Мин дә, бик күреп бетермәсәм дә, башкалар кебек атып җибәрдем. Шунда укытучы абзабыз, мишеньне тотып, ашыга-ашыга минем янга килде дә: «Син, күз начар күрә, дип алдап йөрисең. Бу нәрсә?» – дип, көчле, йонлач куллары белән якадан тотып җилтерәтте. Баксаң, өч атуга мин 28 очко җыйганмын икән. Әүвәл моның сәбәбен аңламадым: моңа кадәр андый хәлнең булганы юк иде. Шул чакта Дамир Нариманов исемле сабакташымның мәгънәле генә елмаеп торуы хәтердә. Мин аңа кайвакыт дәрес хәзерләшергә булыша идем. Ул шуңа рәхмәт йөзеннән, үзенең мишененә атмыйча, минекенә җибәргән икән. Кыек атып туры тидерүемнең сәбәбен соңрак кына белдем.

## Шаулап аккан суларны кичтем

Кәшер юлындагы мәшәкать-маҗараларның берсен искә төшермәсәм, гөнаһ булыр кебек. Сигезенче сыйныфта укыганда, март ахырында көннәр кинәт җылытып, кар ныклап эри башлады. Безне язгы каникулга чыгардылар. Язгы көн: кояшлы, матур. Бөтен җир су, ташу ага. Мин ике авылдашымны – унынчы сыйныфта укучы Антанида белән Иринаны – үгетли торгач, кайтырга күндердем. Аларның аягында резин итек, минекендә – кәлүш. Киттек: Кәшербашы белән Төбәк (Николаевка) арасында җәен атлап чыгарлык кына инеш ага. Шунда килеп җиткәч шаккаттык: якын да килерлек түгел, су шаулап ага. Иптәш кызларым кире әйләнеп кайтырга ниятли. Шунда мин аларны инешнең башыннан әйләнеп узарга үгетләдем. Кар-су ерып шактый бардык. Тегеләр резин итек белән юешләнмичә генә атлыйлар. Ә минем кәлүш кигән аяклар манма су... Ниһаять, елганың аръягына чыктык. Аяк туңудан

мин калтырана башладым. Төбәк авылының юл кырыендагы өенә кердем. Монда элегрәк тә тукталган бар иде. Урыс әби белән бабай минем хәлне, күрәсең, бик тиз аңлап алдылар. Кайнар аш, чәй бирделәр. Бабай: «Пей, сынок, ато пропадёшь», – дип көчли-көчли, шактый зәһәр көмешкә дә эчерде. Толыпка төреп, мич башына яткырдылар. Уянып китсәм – шабыр тиргә батканмын, калтырануым да беткән. Мин бу рус карты белән карчыгына гомерем буе рәхмәтле: алар мине, үпкәгә суык тиеп, «чирләшкә» булудан (бәлкем, әле үлемнәндер дә) саклап калганнардыр. (Ни аяныч: бу әби-бабай үзләре генә түгел, ә яшәгән авыллары да инде күптәннән юкка чыккан.)

## Янә озакка сузылган каникул

Николай Чернышевскийның «Нәрсә эшләргә?» романының исеме кебек, урта мәктәптә белем алучыларның да күпчелеге алдына «Укырга кая барырга?» дигән сорау бөтен тулылыгы белән килеп баса. Кәшер мәктәбендә бу елларда, ничектер, КАИ (Казан авиация институты) югары бәяләнә иде. Мөгаен, иген игү, мал асрау кебек шөгыльләрдән яхшы хәбәрдар булган авыл балаларын үзе юньләп белмәгән, хәтта самолётка утырып та очмаган, серле авиация дөньясы, аның романтикасы ныграк кызыксындыргандыр. Мин дә КАИга укырга керү уен алдан ук күңелгә салып куйдым. Әмма без өлгергәнлек аттестаты алган елны югары уку йортына керү өчен әүвәл ике ел эшләү шарт дигән ниндидер бер рәсми карар чыкты. Безне эшләргә, колхозларда калырга ныклап өнди башладылар. Авыл баласы бит, гадәттә, законны бик тыңлаучан була. Соңрак белдем: күп кенә шәһәр, түрә балалары, ике ел түгел, бер-ике ай да эшләмичә, югары уку йортларына кереп, студент булып киткәннәр.

Мин исә урта мәктәпне тәмамлагач, авылымда калырга булдым. Әмма көтелмәгән хәл планнарымны шактый үзгәртеп куйды. Таҗикстанның Ленинабад (хәзерге исеме – Хөҗәнд) төбәгендә заводта эшләүче абый (соңыннан диңгез капитаны булып танылган Миргалим Йосыф улы) мине үз янына чакырды. Әни дә бу фикергә чатябышты. Башка чара юк, ризалаштым. Һәм менә мин, ниндидер искерәк чемоданны тотып, 1957 елның июль азакларында Әлмәт аркылы Бөгелмә тимер юл станциясенә килеп җиттем. Берничә сәгать көткәч, үз гомеремдә беренче мәртәбә поездга утырып киттем. Кызык та, ямансу да. Мәскәү – Чиләбе поезды иде бугай. Уфага җитәрәк Чишмә станциясендә төшеп, икенче поездга күчеп утырдым. (Бу уңайдан кемнеңдер «Теләсәк – Уфа гуляем, теләсәк – Чишмә сидим» дигән юмористик юллары да искә төшә.) Юлым Оренбург, Актүбә, Кызыл-Орда, Төркестан, Арысь һәм башка бик күп калалар, станцияләр аркылы узды. Очсыз-кырыйсыз казакъ далалары, күлләр, Арал диңгезе, Сырдәрья елгасы; вокзал янындагы кайнап торган базарлар (аеруча балык, җиләк-җимеш, яшелчә сатучылар), төрле кыяфәтле, төрле телләрдә сөйләшүче кешеләр. Июль-август айлары – җәйнең иң эссе чоры. Вагонда ятарга түгел, утырырга да юньләп урын юк. Коточкыч эссе, бөркүлек. Шул сәбәпле, гәрчә куркыныч булса да, вагон түбәсендә дә барабыз. Ниһаять, Бөгелмәдән чыгып, өч-дүрт көн үтүгә, Ташкентка килеп җиттем. Мәгълүм ки, 1966 елда биредә коточкыч җир тетрәү булды. Элеккеге бина-корылмаларның күпчелеге җимерелеп, алар урынына яңалары төзелде һәм, гомумән, яңа Ташкент корылды. Мин исә бу мәһабәт каланың искесен, аның урам-бакчаларын, мәйданнарын, кырмыска оясы кебек кайнап торган зур базарларын күрү бәхетенә ирештем. Көне буе Үзбәкстан мәркәзе белән хозурланып йөргәннән соң, поезд белән Ленинабадка юнәлдем. Мин барып бер-ике ай да үтмәде, абыйны хәрби хезмәткә җибәрделәр. Заводка эшкә урнашып, төрле эшләрдә эшли башладым. Урта Азия ягында элек, көз җиттеме, күп кенә укучы-студентларны, завод эшчеләрен мамык, җиләк-җимеш җыярга озаталар иде. Мин дә өч айдан артык бу төр эшләр белән мәшгуль булдым. Мамык шундый үсемлек: ул ап-ак. Аны җыясың, берничә көннән соң ул янә өлгерә. Бу хәл көз буе дәвам итә. Бездәге салам эскертләре кебек, мамык чүмәлә-эскертләргә дә өелә. Алар өстендә уйнап, сикереп йөргән өчен, хуҗаларның нык кына ачуланулары да хәтердә. Мин

кечкенәдән үк физик эшкә күнеккән кеше. Мамык җыюга да бик тиз өйрәндем. Сменага алтмышар килограмм җыйганым да истә. Хәтта җирле матбугатта «Рабочий Миннегулов устанавливает рекорд» дип мәкалә дә язганнар иде.

Ленинабад янындагы Табошар бистәсендәге тормышка тиз ияләндем. Әмма минем «зимагурлык» чорым озакка бармады, ярты елдан артык Урта Азиядә яшәгәннән соң, әни авырып китү сәбәпле, туган якларга әйләнеп кайттым. Кышның бер көнендә Бөгелмәдә поездда төшеп, Әлмәт аркылы Акташка кайтуым, аннан егерме чакрым араны җәяүләп үтүем әле дә хәтердә. Көн салкын, башта фуражка, өстә юкарак кына кием, аякта туфли, кулда чемодан. Суык бабай йөгертте дә, кызу-кызу атлатты да. 1958 елдан мин янә туган йортта яши башладым.


## Университетка юл алдым

1958-1959 елларда авылда яшәү чорында янә бер һөнәрем артты: мин «корреспондент»-хәбәрче булып киттем. Кечкенәдән үк китап, гәҗит-журналлар укырга ярата идем. «Зимагур»лыктан соң ул гамәлем тагын да көчәйде. Авылда кечкенә генә гәүдәле, кызык сүзле Пётр дәдәй Емельянов белән очраштыргалап торабыз. Ул «Кызыл Зәй» район гәҗитендә эшли иде. Күрше Сармашбаш авылыннан Кашфразый Камалиев белән мине хәбәрчелеккә ул тартып китерде. Узыша-узыша төрле темаларга мәкаләләр яза башладык. Алар район гәҗитендә генә түгел, республика басмаларында да дөнья күрде. Без шактый «билгеле» кеше булып киттек. Тәнкыйтькә эләккән колхоз рәисе Рамазанов агайның: «Бу Миңнеголның авызын ничек яптырырга?» – дигән сүзләре дә ишетелгәләде. Кыскасы, язу-сызу минем яшәешемдә тиз арада сизелерлек урын ала башлады. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, ике еллык эш стажы да тулып килә. «Укырга кая барырга?» дигән сорау бөтен тулылыгы белән янә алга килеп басты. Күп кенә якташларымның, туган-тумачаларымның мине киләчәктә колхоз рәисе, агроном, механик, зоотехник итеп күрәселәре килә. Авыл хуҗалыгы яисә ветеринария институтына укырга керергә өндиләр. Икеләнеп йөргән көннәрдә Пётр дәдәй очрады. Сөйләштек. Шунда ул миңа болай диде: «Башыңны катырып йөрмә, тот та Казан университетының татар бүлегенә кер; анда укыганнар югалмый, кирәк икән, тормышның төрле тармагында эшли ала». Якташымның бу сүзләрен мин, ничектер, бик тиз кабул иттем. Мөгаен, үземнең теләк-ихтыяҗлар да шул якка каергандыр. Шулай итеп, 1959 елның җәеннән гомер юлымның Казан, университет белән бәйләнешле сәхифәләре башланды.

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ**

**Редакциядән:**

*Бу айда күренекле галимебез Хатыйп Миңнегуловка 80 яшь тулды. Аны юбилее белән котлыйбыз! Алга таба да гыйлем дөньясында ат уйнатып, бетмәс-төкәнмәс фәнни ачыш-яңалыкларны халкыбыз белән уртаклашып яшәвен телибез!*



# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## БАШКОРТСТАНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КӨННӘРЕ

Башкортстанда Татарстан Республикасы көннәре булып узды. Бу уңайдан Уфага ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов килде. Әүвәл ул Башкортстандагы татар иҗтимагый оешмалары активы белән очрашты. Рөстәм Нургали улы анда әлеге чараның Башкортстанның 100 еллыгы уңаеннан уздырылуын искәртте. «Башкорт белән татардан да якынрак халыклар юк. Татарстан да, Башкортстан да Россия күләмендә алдынгы төбәкләр. Безнең бернәрсәне дә бүлешәсебез юк. Без бер-беребезгә кирәк», – диде ул.

Татарстан Республикасы һәм Башкортстан Республикасы арасында сәүдә, икътисади, фәнни-техник һәм социаль-мәдәни хезмәттәшлек турында рәсми Килешү төзелде. Аны ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм БР башлыгы вазифаларын вакытлыча башкаручы Радий Хәбиров имзаладылар. Президентыбыз «Татарстан-Башкортстан» эшлекле форумында катнашты, Уфа дәүләт нефть техник университетында булды. Рөстәм Нургали улы Миңнеханов ике республика арасындагы хезмәттәшлекне ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Салават Юлаев ордены белән бүләкләнде. Олы бүләкне Радий Хәбиров тапшырды.

Башкортстанда Татарстан Республикасы көннәре кысаларында «Татар-информ» белән «Башинформ» мәгълүмат агентлыклары арасында Меморандум төзелде.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның халык шагыйрьләре Разил Вәлиев, Рәдиф Гаташ, Роберт Миңнуллин, Зиннур Мансуров, Татарстанның халык язучысы Гәрәй Рәхим Уфадагы 84 нче татар гимназиясендә укучылар белән очраштылар. Шул ук көнне Татарстаннан килгән каләм ияләрен Башкортстан Язучылар берлегендә кабул иттеләр.

Уфада булган зур вакыйгаларның тагын берсе – бөек шагыйрь Габдулла Тукайга һәйкәл (авторлары – Уфа сынчысы Владимир Дворник һәм архитектор Леонид Дубинский) ачу. Биеклеге сигез метр булган бронза һәйкәл Уфа «Нур» Татар дәүләт театры каршында урнаштырылган. Тукайга һәйкәл ачу тантанасында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, БР башлыгы вазифаларын вакытлыча башкаручы Радий Хәбиров катнашты һәм чыгыш ясады. Рөстәм Нургали улы Башкортстан җитәкчелегенә һәм һәйкәл ачу тантанасына килгән халыкка рәхмәт әйтте. Бәйрәмдә Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин һәм Башкортстанның халык шагыйре Хәсән Назар да чыгыш ясады. «Башкортостан» дәүләт концерт залында Татарстан һәм Башкортстан сәнгать осталарының зур концерты булды. Киләсе елда Татарстанда Башкортстан Республикасы көннәре узачак.

## ПРЕЗИДЕНТ ХОЗУРЫНДА

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов «Казан Экспо» комплексында татар иҗат зыялылары белән очрашты. Әлеге чарада ТР мәдәният министры Ирада Әюпова, ТР мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары Илсур Һадиуллин, ТР Дәүләт Советының мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, ТР Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, шагыйрьләр Ренат Харис, Роберт Миңнуллин, Ркаил Зәйдулла, Рүзәл Мөхәммәтшин, Луиза Янсуар, Йолдыз Миңнуллина, язучы-прозаик Рөстәм Галиуллин, драматург Илгиз Зәйниев һ.б. катнашты.

Очрашу барышында татар телен саклап калу һәм популярлаштыру, татар әдәбиятын һәм театр сәнгатен үстерү, мәдәният өлкәсендә кадрлар әзерләү һәм башка актуаль мәсьәләләр турында фикер алыштылар.

## ТУКАЙ КӨННӘРЕ

Габдулла Тукайның туган көнендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Россия Федерациясе Президенты ярдәмчесе Анатолий Серышев шагыйрьнең Казан үзәгендәге һәйкәленә чәчәк салды. Чәчәк салу тантанасында ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Дәүләт Советы депутатлары, министрлыклар, ведомстволар җитәкчеләре, республикабызның әдәбият, сәнгать әһелләре, галимнәр, башкалабыз кунаклары, студентлар, укучылар катнашты.

***

Туган тел һәм Г.Тукайның туган көнендә «Казан Экспо» күргәзмәләр комплексында өч мең кеше сыйдырышлы Илһам Шакиров исемендәге концерт залы ачылды. Аны ачу тантанасында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты. Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең быелгы лауреатларын да ул шушы залда яңа форматта котлады. Рөстәм Нургали улы олуг бүләккә лаек булган язучы, әдәбият галиме Тәлгат Галиул-

линга, рәссам Надир Әлмиевкә, Татар дәүләт фольклор музыкасы ансамбле җитәкчесе Айдар Фәйзрахмановка, Г.Камал театры артистлары Люция Хәмитовага, Радик Бариевка, Искәндәр Хәйруллинга диплом һәм күкрәк билгесе тапшырды.

***

Г.Тукайның Татар дәүләт опера һәм балет академия театры янындагы һәйкәле каршында Шигырь бәйрәме үткәрелде. Бәйрәмгә җыелган халыкны ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов сәламләде. Татарстанның халык шагыйрьләре Ренат Харис, Разил Вәлиев, Рәдиф Гаташ, Роберт Миңнуллин, Зиннур Мансуров, шагыйрьләр Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Ләбиб Лерон, Рәмис Аймәт, Хәнәфи Бәдигый, Эльмира Шәрифуллина, Нәҗибә Сафина, Илсөяр Иксанова, Марат Закир, Луиза Янсуар, Йолдыз Миңнуллина, Гөлүсә Батталова, Алексей Остудин, Рүзәл Мөхәммәтшин, Булат Ибраһимов, Рифат Сәлах, Фәнил Гыйләҗев, кунаклардан Карачай-Черкес Республикасының халык шагыйре Әскәр Додуев, Чувашия Республикасының халык шагыйре Валерий Тургай, Башкортстан шагыйрьләре Хисмәтулла Юлдашев, Тамара Искәндәрия, Удмуртия Язучылар берлеге рәисе Пётр Захаров үзләренең шигырьләрен укыдылар. Бәйрәмдә Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендә Татарстан дәүләт фольклор музыкасы ансамбле, җырчылар Айгөл Хәйри, Ярамир, Айгөл Гардисламова чыгыш ясады. Идел Кыямов каһарман-шагыйрь Фатих Кәрим шигырьләрен яңгыратты. Бәйрәмне К.Тинчурин театры артистлары Резеда Сәлахова һәм Артём Пискунов алып барды.

***

Г.Тукайның туган көне алдыннан Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт җитәкчелегендә бер төркем язучылар Сасна Пүчинкәсе авылы зиратында шагыйрьнең әнисе Бибимәмдүдә каберен зиярәт кылды. Монда аның рухына багышлап Коръән сүрәләре укылды. Кунаклар Субаш, Янгул, Бөрбаш, Салавыч авылларында үткәрелгән шигырь бәйрәмендә, район Мәдәният йортында укучыларның ел буена барган иҗат бәйгеләрендә җиңүчеләрне, иң күп китап укучыларны бүләкләү тантанасында катнашты, чыгыш ясады.

***

Бәйрәм Арча районында, аерым алганда, Яңа Кырлай Мәдәният йортында, музейда, Сәгъди абзый нигезендә, Кушлавычта дәвам итте. Кушлавыч зиратында Г.Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф (ул шушында җирләнгән) рухына Коръән сүрәләре багышланды. Бу чараларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, аның урынбасары Рәмис Аймәт, Г.Тукай премиясенең быелгы лауреатлары Тәлгат Галиуллин (җәмәгате, шагыйрә Фәүзия Солтан белән), Айдар Фәйзрахманов (үзенең ТР фольклор музыкасы дәүләт ансамбле белән), Татарстанның халык шагыйрьләре Ренат Харис, Зиннур Мансуров, каләм ияләре Газинур Морат, Илсөяр Иксанова, Хәбир Ибраһим, Рәдиф Сәгъди, Тукай фонды рәисе, журналист Риман Гыйлемханов, кунаклардан Карачай-Черкес Республикасының халык шагыйре Әскәр Додуев, Чувашиянең халык шагыйре Валерий Тургай, Башкортстан шагыйрьләре Хисмәтулла Юлдашев белән Тамара Искәндәрия катнашты. Аларны Арча муниципаль районы башлыгы Илшат Нуриев сәламләде.

### «АДЫМНАР – БЕЛЕМГӘ ҺӘМ КИЛЕШҮГӘ ЮЛ»

Казан Кремлендә «Яңарыш» республика фондының Попечительлек һәм Административ утырышы узды. Аны Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, «Яңарыш» республика фондының Попечительлек советы рәисе Минтимер Шәймиев алып барды.

Утырышта ТР Президенты Аппараты Җитәкчесе Әсгать Сәфәров, ТР Премьер-министры урынбасары, ТР Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе Шамил Гафаров, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, «Яңарыш» республика фондының Административ советы җитәкчесе Юрий Камалтынов, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, «Яңарыш» республика фондының башкарма директоры Татьяна Ларионова, шулай ук фондның Халыкара ведомствоара эксперт советы әгъзалары, ведомство һәм министрлык, мәктәп һәм мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре катнашты.

«Сезгә билгеле булганча, без республикада полилингваль белем бирү системасын булдыруга керештек. Проектның максаты – заманча полилингваль комплекслар моделен булдыру. «Адымнар – белемгә һәм килешүгә юл» – безнең комплекслар шулай аталачак», – диде Минтимер Шәймиев.

### ХАЛЫКАРА ОЛИМПИАДА

Татар теленнән VII Халыкара олимпиаданың Гран-при ияләре билгеле булды. Менә алар: Чихиро Тагучи (Япония), Лилия Гатина (Татарстан, Чирмешән), Тимур Суфиянов (Башкортстан). Аларны Идел буе дәүләт физик тәрбия, спорт һәм туризм академиясендә узган тантанада ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин котлады. Чихиро Тагучи олимпиадада Бөекбритания исеменнән катнашты. Ул анда укый. Шушында ук «Илһам» әдәби конкурсында җиңүчеләрне дә бүләкләделәр. Тантанада ТР Дәүләт Советының мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов катнашты.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Р.МУХАМАДИЕВА «Отчего желтеет белый лист...», роман Р.ТУФИТУЛЛОВОЙ «Ветер судьбы»; научно-поэтический трактат Р.РАХМАНИ «Феномен «Хак» в бытие и философском сознании нашей нации»; стихи Р.РАХМАН, И.АШИРОВА; рубаи Д.ГАРИФУЛЛИНА.*
*«Драматургия»: комедия Р.ШАРИФА «Я всегда буду тебя любить».*
*«Новые имена»: рассказ Р.ТИМЕРБУЛАТОВОЙ «Тоска».*
*«Актуальная критика»: рубрику ведёт Д.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*Конкурс «Исцеляющие руки»: рассказ Г.АЙЗАТ «Чистый родник».*
*Конкурс «Татарстан. История. Личности»: очерки И.ТАГИРОВА и Р.ГИЛЕМХАНОВА.*
*«Тукай и татарская литература»: статья Р.РАХМАН.*
*«80 лет со дня рождения Фаиля Шафигуллина»: фотоархив.*
*«Юбилеи»: 80 лет Фариту Юсупову. Статья О.ХИСАМОВА, Б.МИННУЛЛИНА, Р.МИРХАЕВА.*
*«История одной песни»: «Мой солдат» (слова М.НУГМАН, музыка С.САДЫКОВОЙ).*
*«Наши музеи»: Л.ГУБАЙДУЛЛИН. «Дом-музей Фатиха Карима».*
*«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.*
*«Маленькие»: Х.МИННЕГУЛОВ. «Маленький Хатип».*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: дом-музей Фатиха Карима. Фото Р.Хафизовой.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by R.MUKHAMADIEV «Why the white piece of paper turns sallow...», novel by R.TUFITULLOVA «Winds of Fate»; scientific and poetic treatise by R.RAHMANI «Phenomenon «Hack» in the existence and the philosophical consciousness of our nation»; poems by R.RAHMAN, I.ASHIROV; rubaiyat by D.GARIFULLIN.*
*«Drama»: comedy by R.SHARIF «I will always love you».*
*«New names»: stories by R.TIMERBULATOVA «Tosca».*
*«Actual criticism»: section is led by D.ZAGIDULLINA.*
*Contest «Healing Hands»: story by G.AYZAT «Pure spring».*
*Competition «Tatarstan. History. Personalities»: essays by I.TAGIROV and R.GILEMKHANOV.*
*«Tukay and Tatar literature»: article by R.RAHMAN.*
*80th anniversary of the birth of Fail Shafigullin (photo archive).*
*«Anniversaries»: 80 years old to Farit Yusupov.*
*Article by O.KHISAMOV, B.MINNULLIN, R.MIRHAEV.*
*«The story of a song»: «My Soldier» (lyrics by M.NUGMAN, music by S.SADYKOVA).*
*«Our museums»: L.GUBAIDULLIN. «House-museum of Fatih Karim».*
*«Pages of humor»: section is conducted by M.GALIEV.*
*«The little»: H.MINIGULOV. «Little Khatip».*
*From the photo archive of the magazine.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: the House-museum of Fatih Karim. Photo by R.Khafizova.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Фатих Кәримнең музей-йорты.

*Рәйсә Хафизова фотосы.*